БАШКОРТ ӘКИЯТЛӘРЕ

БАШКОРТ ӘКИЯТЛӘРЕ

БАШКОРТ ӘКИЯТЛӘРЕ

УФА
«КИТАП»
1996

БАШКОРТ ӘКИЯТЛӘРЕ



ББК 82.3 Баш
Б 29

Т ө з ү ч е с е *Динә Морзакаева*
Р ә с с а м ы *Азат Мөхтәруллин*

Р е д к о л л е г и я:

Кадим Аралбаев, Нур Зарипов, Әхмәт Сөләйманов, Сабир Шәрипов

Б 29 Башкорт әкиятләре. Уфа: Башкортстан «Китап» нәшрияты, 1996. 400 бит.

ISBN 5-295-01804-0

Башкорт халкының әкият иҗаты искиткеч бай. Бу китапка җанвар-киекләр хакындагы; батырлар турындагы; тылсымлы, героик эчтәлекле; тормыш-яшәеш, көнкүрешкә кагылышлы киң билгеле башкорт халык әкиятләре сайлап алынды.

Б $\frac{4803110100-183}{М\ 121(03)-96}$ 37—96 ББК 82.3 Баш

ISBN 5-295-01804-0

© Төзү, тәрҗемә: Морзакаева Д. Г., 1996
© Мөхтәруллин Азат рәсемнәре, 1996

ӘКИЯТЛӘР

Без, «әкият» дидекме, чынбарлыктан кайсы ягы беләндер аерылып торган хыялый дөнья һәм шул дөньяда яшәүче, кара көчләргә каршы көрәшүче, җил җиткермәс куш канатлы таянычы— тулпарына атланып, яшен яшьнәтмәле алмаз кылычын болгап җилгән каһарманнарны, көмеш калакка салып йотарлык, бер бите көн, бер бите ай чибәрләрне, теләсә нинди четерекле хәлдә дә югалып калмас акыл ияләрен, адәмчә сөйләшеп, адәми гамь белән яшәүче җәнлекләрне күз алдыннан кичергәндәй булабыз. Фән һәм техника үсешкән хәзерге дәвердә, дөнья яменә караганда, яшәү гаменә ныграк бирелеп, исәп-хисап буенча яшәүгә күнегеп киткән кеше әкиятне олылар өчен әһәмиятен югалткан, бары балаларның гына эстетик зәвыгына хуш килә торган иҗади күренеш дип белә. Ә элгәре әкият авыр хезмәттән соң күңел юату, вакыт үткәрү чарасы булган. Әкият аша тыңлаучыларга халыкның әхлаки, эстетик тәҗрибәсе күндерелгән.

Бик борынгы заманнарда әкиятне зәвык өчен генә дә сөйләмәгәннәр: әкият сөйләү һәм аны тыңлау йола аткаруга кергән. Безнең ерак кардәшләребез булган Себер төркиләрендә (саха, алтай, шор, кызыл, хакас һ. б.) әкият үзенең шушы вазифасын соңгы дәверләргәчә саклап калган. Ауга чыгучылар үзләре белән әкиятче алып барып, сунарның нәтиҗәсен (уңышлы йә уңышсыз булуын) аның сүзгә маһирлык кимәле белән «үлчәгән». Аларның уенча кичен сунарчылар алачыгында йә ачык һавада ягылган учак янында әкият сөйләшү фарыз эш, йола дип исәпләнгән. Чөнки урман, киек ияләре әкият тыңларга әвәс дип белгәннәр. Әкиятче үзенең сүз сәнгатен күрсәтә башлауга, алар да килеп тыңлый була. Иртәгәсенә сунар уңса, урман, тау ияләре әкиятне ошатты, шуның әҗерен кайтарды, дип уйлаганнар.

Кыскасы, элек әкиятне бер дә юк-бар сөйләү йә балаларны мавыктыру чарасы дип кенә бәяләмәгәннәр. Хәтта бу дөньяның хыял түгелен, аның асылын аңлаган олылар да шулай әкияткә хуш күңел күрсәтмәгәч, табаннары җирдә булуга карамастан, хыял канатларын талпындырырга гына торган яшь буынга ни сан! Ул, гомумән, әкиятсез яши алмаган.

Бер үк әкиятне, милли җирлектәге барча әкиятләрне дә, олысы да, кечесе дә; бае да, фәкыйре дә уртак хәзинә дип белгән, бердәй күргән. Шуның белән бергә шул төркемнәрнең һәрберсенең мохитендә генә яратып сөйләнелгән әкиятләр дә булган.

Күптомлы «Башкорт халык иҗады» җыентыгының биш китабында 532 әкият тексты тупланган. Хайваннар турындагы әкиятләр; батырлар турындагы, тугрылык, инсафлык, гаярьлек кебек сыйфатларга ия булырга өндәүче гыйбрәтле әкиятләр; тәүдә башкалардан җәберсетелеп, азак агаларыннан акыллырак, җитезрәк булып чыккан төпчек малайны, үги анадан кыерсытылган ятим кызны төп герой иткән тылсымлы әкиятләр; үз максатларына зирәклек, гыйлем ярдәмендә ирешүчеләрне идеаллаштырып, юләрлектән, саранлыктан көлүче тормыш-көнкүреш әкиятләре яратып тыңланучан. Әкиятләр аша яшь буын изгелек һәм явызлык, хакыйкать һәм ялган, батырлык һәм бахырлык, гаделлек һәм гаделсезлек, инсафлык һәм тупаслык, матурлык һәм ямьсезлек кебек әхлакый-этик, эстетик төшенчәләр хакында мәгълүмат ала, яхшыны яманнан аерырга өйрәнә.

Хайваннар турындагы әкиятләрнең күпләрендә төлкенең хәйләкәрлегә сокландыра. «Хәйләкәр төлке» дигән бер әкият бар. Анда төлкенең үлгәнгә салышып ятуы аңа балыкчы картны алдатырга ярдәм итә. Арытабан төлке, бүрене алдап, төне буе койрыгын бәкегә тыгып утырырга акыл бирә (янәсе, ул үзе балыкны шулай тоткан). Бу хәл исә төлкенең хәйләдә нитиклем камилләшкәнен бигрәк тә ачык чагылдыра.

«Төлке белән бытбылдык» дигән әкияттә исә, тәү карамакка үз җаен гына карап, бытбылдый-бытбылдый, үзаллы көн күргән гади бытбылдык төлкенең үзенә хәйләкәрлек дәресе бирә: ир белән хатынны үзенә ымсындырып, берчә төлкенең тамагын туйдыра, берчә кәмит күрсәтеп, күңелен ача.

Менә шулай бытбылдыктан сабак алып, хәйләкәрлеген арттыра барып, аюны да, бүрене дә, балыкчыны да уңайсыз хәлгә калдыруга карамастан, төлке уңышсызлыкка да очрап куя, хәтта үз башына үзе җитә. «Тычкан, аю, бүре, төлке...» дигән әкияттә хәйлә белән әтәч аның котын ала. Үзен ашарга җыенган бүре белән аюны төлке: «Карагыз әле менә бу тау башына, күрәсезме, аннан бер сунарчы төшеп килә? Туп-туры безнең өскә килә», — дип алдый. Әтәчкә килеп: «Ишеттеңме әле син, яңа закон буенча, куян, бүре, төлке белән әтәч берберсенә тимиләр», — дип аны киртә башыннан үзенең янына төшер-

мәкче була. Әмма әтәч: «Бик яхшы закон икән. Әнә теге яктан безгә таба бер кеше килә», — дигәч, төлке таю ягын карый.

Хайваннар турындагы әкиятләрдә һәр җәнлек билгеле бер сыйфатның символы (төлке — хәйләкәрлек; бүре, арыслан — явызлык, аю — беркатлылык, үтә тиз ышанучанлык, куян — кыерсытучанлык гәүдәләнеше) кебек кабул ителә. Әмма әкиятләрдә бу кагыйдә аксиомалаштырылмый. Моның төбендә явызның да ип-сапка килүенә өмет өзмәскә өндәү ята булса кирәк. Ә инде «Куян белән арыслан» әкиятендә куянның явыз арысланны хәйлә белән кое төбенә ташланырга мәҗбүр итүе — дәрт итсә, ихтыярын туплый алса, көчсез дә көчле була ала дигән ышаныч тәрбияләүгә кулай. Бытбылдык белән әтәчнең төлкедән дә хәйләкәррәк итеп күрсәтелгән очраклар да шушы фикерне куәтли.

Батырлар турындагы әкиятләр халыкның фантазиягә нинди дәрәҗәдә ирек куя алуын күрсәтә. Монда бигрәк тә әкият каһарманының дөньяга яралу рәвеше, тиз үсүе гаҗәпкә калдыра. «Оморзак бик тиз үскән, батыр булып җитешкән», — дип әйтелә «Оморзак батыр» әкияте каһарманының балачагы хакында. Алдына куелган тәүге бурычны үтәгәнендә үк шушы әйтелгәнне раслый батыр. Өч пәһлеванга бирешмәслек батырны җиңә Оморзак. Әйткәндәй, «җиңә» дип әйтү генә аз. Әкият алышны да, җиңүнең яуланышын да асруча җентекләп сурәтләүгә әвәс: «Әй көрәшәләр болар, әй көрәшәләр. Көрәшә торгач, Оморзак теге пәһлеванны һавага ыргытып җибәргән дә төшеп килгән чагында тегенең башын аягы белән тибеп өзгән дә куйган. «Беркем каршы тора алмый» дигән даны чыккан пәһлеван белән алышны, аны җиңүне менә шулай сурәтләү әкият өчен нигә кирәк? Шуның белән монда төп каһарманның арытабангы алышларга әзерлек кимәле ачыклана. Ә инде әкият каһарманына арытабан очраячак каршылыклар, ул алышасы көчләр, тәүгесе белән чагыштырганда, арта бара. Шулай итеп, әкият каһарманының тәүге җиңүе аның алдында тагын да авыррак сынаулар торачагын искәртә һәм шул сәбәптән сюжетның елдам үсүенә стимул була.

Әкият каһарманы тышкы булмышы, кыяфәте җәһәтеннән, гадәттә, махсус тасвирланмый. Күрәсең, нинди каршылыкларны җиңүе үзе үк тыңлаучыга аны күз алдына китерү мөмкинлеген бирә дип исәпләнгәндер. Мондый тасвирламаларның төшереп калдырылуы элек булганнарын тыңлаучының белергә тиешлегенә исәп тотылу белән дә аңлатылуы ихтимал.

Батырлар турындагы әкиятләрдә рәткә янә бер үзенчәлек күзәтелә. Ул да булса — батырларның буын-буын алмашынуы. Әйтеп үтелгән «Оморзак батыр» әкиятендә батырларның өч буыны чыгыш ясый, өчесе дә актив хәрәкәттә күрсәтелә.

Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк, әкият каһарманнары буын-

буын күрсәтелсә, һәр яңа буынны гәүдәләндергәне өлкәненнән көчлерәк тә, тасыллырак та була!

Әкият каһарманнарының сын-килбәтен, көрәшен йөрәк алкымга килерлек итеп сурәтләп, батырлык, тәвәккәллек кебек сыйфатларга сокландыру белән бергә, аларның әхлакый-этик камиллегенә дә игътибар итела.

Әкият батырлары арасында шундый әхлакый-этик кагыйдә тотрыклы күзәтелә: кече олыны олы дип белә, олы, олылыгына барып, кеченең фикере беләп исәпләшә: «Ялгызак батыр» әкиятендә Ялгызакның улы: «Әти, миңа батырлар белән көрәшергә рөхсәт ит!» — дип, рөхсәт сорап кына, көч сынаша. Оморзак батырның бер батырдан җиңелүен күреп, улы йөгереп килеп җитә дә аннан үзенә көрәшергә рөхсәт сорый. Үз чиратында үз улы, аннан рөхсәт алгач кына диюләр патшасының батыры белән көрәшергә тотына.

Әти сүзе, әти рөхсәте, ул намусы турында әйтелгәннәр турыдан-туры «Урал батыр» әсәренә карый. Ата сүзен тотып, турсыктан өлкәннәр генә эчәргә хаклы булган канны эчүдән тыелып калган Урал батыр бар кешелеккә, табигатькә мәңге яшәргә шарт тудырган (бөтен кара көчләрне җиңеп, тересуны тирә-юньгә бөркеп, бар табигатьне җанландыра) дөнья батыры, алай гына да түгел, изге, илаһи затлы кеше рәвешендә (фәндә андыйларны демиург, культур герой дип нәрыклыйлар) гәүдәләндерелә. Ә юханың коткысына бирелгән туганы Шүлгән кешелекнең дошманына әверелә.

Гадәттә батырлар турындагы әкиятләр рәтендә йөрсә дә, «Урал батыр», асылда, шундый ук исемдәге башкорт эпосының бер версиясе ул. Эпос герое ил алдында бурычын үтәгәч, фани дөньядан бакый дөньяга күчүчән. «Урал батыр»ның герое да шундый язмышка дучар була. Ә әкият батыры үлми, хәтта «бүген булса да яшәп ята». Бу кагыйдә батырлар турындагы әкиятләр өчен дә уртак.

Тылсымлы героик әкиятләр дә батырлар турындагыларга тартым. Аларның да төп герое кадимге кешенең кулыннан килмәслек эшләрне аткара. «Незнай» әкиятенең герое берүзе тәүдә өч башлы, аннан унике башлы дию һәм аларның гаскәре белән алыша. Шултиклем куәтле көчкә каршы чыкканында ул турыдан-туры тылсымны файдаланмый. Әмма аның бар булмышы — тылсым нәтиҗәсе. Юк, ул батырлар турындагы әкият герое кебек, дөньяга могҗиза ярдәмендә яралмый. Егет булып җиткәч кенә, ул батырларга гына тәтер көчкә ия була: атының сул колагына кереп, уң колагыннан чыгуы нәтиҗәсендә, пәһлеванга әверелә. Незнайга, моннан тыш, ата йортыннан үзе белән качкан эте белән мәчесе дә булыша. Тугры атының киңәше буенча, ул карт диюгә алданрак барып, аның улына тәгаенләнгән көчне дә ала.

Кайдан һәм ничек көч алуы хакында әйтелмәгән сурәттә дә, тылсымлы героик әкият герое баһадирларча эш итә. «Таз батыр» әкия-

тенең герое — Акылбай. Карамакка, бүз тарпан (кыргый ат) булып очрап, өч тапкыр аны сынап (егет, ачыкса да, аны атып әрәм итәргә теләми), ак сакаллы карт кыяфәтенә керүче биргән кырык колач тимер чылбыр белән җиңел генә эш итеп, Таз батыр сунар мәлендә патшага ташланган юлбарысны да җиңә: кылычы белән бер кизәнә— башын кисеп тә төшерә. Ук атса, Акылбай мәргәннең мәргәне итеп күрсәтә үзен. Тулпарга ия булу да — баһадирлык сыйфаты. Әмма әкият мондый «даими билге» белән генә чикләнми. Тулпар иясенең кыланышына да баһадирлык сыйфаты бирә.

Тылсымлы героик әкият кануны буенча, герой алдына беләк көчен генә түгел, тылсым көчен дә таләп иткән бурычлар куела. Шуңа күрә дә Таз батыр иң кирәк чакта тылсым кодрәтен дә файдалана. Патшаның аты хәлсезләнә башлагач, тылсымлы каурый белән аның сыртын бер сыпыра — ул син дә мин шәбәя дә китә. Агалары зинданга япкач, бетмәс ризык белән ризыклана. «Алтынчәч», «Кече ул», «Тугыз олан» ише әкиятләрнең герое да Акылбайны хәтерләтә.

Пәһлеванлык, мәргәнлек, тылсымны эшкә җигү кебек сыйфатлар гына түгел, әхлакый камиллек бизи тылсымлы героик әкият батырын: ул кешелекле, гадел, эчкерсез булуы белән аерылып тора.

Әхлакый камиллек сыйфаты тормыш-көнкүреш әкиятләренең героен характерлауда аеруча мөһим роль уйный. «Ата васыяте», «Ана сүзе» кебек әкиятләр, мәсәлән, ата-ана сүзен тоткан, агай-эне белән тату кеше генә бу дөньяда кадер-хөрмәткә лаек, дип әйткәндәй була. Ата да, ана кеше дә улына, сынамак өчен, васыять урынына киңәш бирә йә шелтә ясый. Егет кеше ата-ана сүзен вакытыннан алда сынап карамакчы булып, алар әйткәннең киресен эшләп карый һәм аларның хаклы икәненә үз тәҗрибәсендә төшенә. Ике әкият тә ата-ана, олы кеше — акыл чыганагы, дигән фикерне раслый. Шушы идеяне «Курайчы», «Патша белән сабанчы», «Локман Хәким» ише әкиятләр дә куәтли. Соңгысында, мәсәлән, тормыш йөге дип, картларны санламау акылсызлык дип бәһалана. Үлемгә хөкем ителгән Локман Хәким, зирәклеге аркасында, патшаны үлемнән коткара. Патшаның улын корбан итүне имитацияләү хакимнс тамагына кадалган сөяктән арындыруга форсат бирә.

«Фәкыйрь кияү», «Кыз сере», «Балкантаз» кебек тормыш-көнкүреш әкиятләре дә зирәклеккә басым ясый. Зирәклек бу очракта мәхәббәтне яклау чарасы рәвешендә ачыла. «Фәкыйрь кияү» әкиятендә байның «ат белән дә килмә, җәяү дә килмә, юл белән дә килмә, юлсыз да килмә» дигән шарты да, кышын җылытылмаган өйдә күлмәкчән төн үткәрергә, мичтән әле генә алынган икмәкне кискәләргә дигән шарты да тылсымлы әкият геройлары алдындагы каршылык дәрәҗәсенә ия. Әмма тылсымлы әкият геройларыннан аермалы рәвештә, тормыш-көнкүреш әкияте герое аларны зирәклеге ярдәмендә

аткарып чыга. Әкият еш кына зирәклек күрсәтүне мәхәббәтне яклау, гаилә бәхетенә ирешү чарасы дип таба.

«Назлы кыз», «Халикъ кызы Хәдичә» кебек әкиятләрнең герое, шуңа өстәп, зирәклек-түземлелек, сабырлык билгесе дә (яки сабырлык та — зирәклек) дигәндәй була. Ә, халыкча, сабырлык төбе — сары алтын. Чынлап та, ике әкиятнең дә герое, бары чиксез сабыр булулары аркасында, башкалар дөнья күтәргә яраксыз, дип кул селтәгән кызны, акылга утыртып, үзенә тугры гомер юлдашы итүгә ирешә. Мондый әкиятләре аша халык, егет кешенең зирәклеге хатын күңеленә ачкыч таба белүдә дә, димәкче. Димәк, әкият, ир белән хатын төрле чараны, төрле юлны файдаланырга, әмма мотлак аңлашырга тиеш, шулчакта гына гаилә бәхетенә ирешергә мөмкин, дигән идеяне алга сөрә. Шушы ук мәсьәләгә «Явыз хатын белән дию пәрие» әкиятендә икенче яктан карый халык. Хатын иренең сүзен бөтенләй санламый. Әлеге әкиятләрдәге кебек чаралар куллану да файда бирмәячәк: хатын ире белән бөтенләй исәпләшмәс һәм килешмәс хәлгә җиткән. Нәтиҗәдә гаилә юкка чыга. Әкият шундый нәтиҗәгә китерә: бер оя коручы ике кеше «Назлы кыз», «Халикъ кызы Хәдичә» дигән әкиятләрдәге кебек, баштан аңлашырга тиеш — моның чарасы төрлечә булырга мөмкин, нәтиҗәсе генә уңай булсын.

Рус һәм көнбатыш халыклары әкиятләрендә вакыйга билгесез патшалыкта, билгесез дәүләттә барса, татарлардагы кебек үк, башкорт әкиятләрендә дә вакыйга борын-борын заманда, бүре — багавыл, карга каравыл чакта...», ягъни борыннан да борын — билгесез дәвердә бара. Әмма идеясе белән алар безгә дә якын, бүген дә үз. Алар чынбарлыктагы мөнәсәбәтләрне шартлы дөньяга күчереп, барысын да шаштыра. Әмма асылы бер: мәңгелек хакыйкатьнең, яхшылыкның, яктылыкның, матурлыкның җиңәргә тиешлеген раслый алар.

Башкорт халкының әкиятләре хакында әйтелгән әлеге фикерләрне башка халыкларныкына карата да кабатларга булыр иде. Чөнки бөтен халыкларның авыз-тел иҗаты өчен дә әкият — уртак жанр. Уртаклык бер үк сюжет тибының күп халыкларга билгеле булуында да күзәтелә. Әмма адәм баласының, бер төр кош-кортның сөяк-сыны бериш булса да, гәүдәсе, төсе, фигыле төрле булган кебек, сюжет тибы уртаклыгы һәр халыкның авыз-тел репертуарындагы әкиятләр бер-берсенә суйган да каплаган кебек була дигәнне аңлатмый. Башкорт фольклорында батырлар, хайваннар турындагы, тормыш-көнкүреш әкиятләре бик популяр булуы да, аларның күпләренең башка халыкларда күзәтелмәве дә шул турыда сөйли. Ә инде һәр әкиятнең кайсы милли мохиттә таралуына карап, шул мохиткә генә хас билгеләр алуы турында әйтеп торасы да юк. Хәер, хөрмәтле укучылар, бу китапка кергән әкиятләр белән танышкач, әле әйтелгәннәргә сез үзегез дә яхшы төшенерсез, мөгаен. Башкорт әкияте дөньясына рәхим итегез! Хәерле сәгатьтә!

Әхмәт Сөләйманов

ҮЗ КЕТӘГЕНДӘ ӘТӘЧ ТӘ БАТЫР

АЧ АЮ, ТӨЛКЕ, ЕГЕТ

Борын заманда бер егет урманга бара. Шунда бер ач аю очрый. Егетне тотып ашамак була бу аю. Ашыйм дигәндә генә, бер төлке килеп чыга. Аю, егетне ычкындырып: «Сине ашамаска булдым, төлкене ашыйм», — ди.

Төлке егеткә:

— Ни эшләп торасың? — ди.

Аю егетнең колагына: «Утын алам, дип әйт тә, мине арбага төртеп ек. Мин шунда үлгән булып ятармын. Төлке, хәлемне белер өчен, яныма ук килер. Шулчак мин аны тотып алып ашармын», — ди.

— Утын алырга килдем, — ди егет. Аюны арбага төртеп ега. Төлке егеткә:

— Утынны арбага салгач, аркан белән бәйләргә кирәк. Бәйлик, — ди. Аю:

— Дөрес әйтәсең, — дигән була.

Егет аюны уратып-уратып бәйли.

— Уратып бәйләгәч, агач белән бораулап та куялар ул утынны, — ди төлке.

Егет бораулый. Аю акыра, кыймылдый да алмый. Төлке, арбага бораулап-боргычлап бәйләп салынган аюның баш очына килеп:

— Менә, йөри идең урманны бер итеп, ерткыч аю, безгә көн күрсәтми! Хәзер яттыңмы инде, бик әйбәт кенә, утын булып! — дип көлә. Шуннан егеткә:

— Утынның юанын чөй кагып яралар ул. Шулай ит,— ди.

Егет имәннән чөй ясап, аюның койрык астына кага. Егет кага, аю акыра. Аю акыра-акыра үлгән шунда. Аю урынына арыслан киекләр патшасы булып алган, ди, моннан соң.

ТӨЛКЕ БЕЛӘН БЫТБЫЛДЫК

Өлгергән арыш арасында, арлы-бирле пырылдап, бер бытбылдык очып йөри иде, ди. Шунда, якында гына, күләгәдә әлсерәп беткән бер ач төлке ята иде, ди. Бытбылдык килде дә шул төлкенең колагы очына кунды, ди. Төлке, башын селкеп, бытбылдыкны колагыннан төшерде дә:

— Бер кабымга җитмәс башың белән бимазалап йөргән буласың! — дип ачуланды, ди.

— Хикмәт зурлыктамыни ул? Менә мин бәләкәй генәмен, ә шулай да сине туйганчы ашата алам. Эшне хәйлә белән эшли белүдә ул! — дип әйтте ди, бытбылдык.

— Кит моннан, күз көеге! Ни эшләп инде бытбылдык төлке чаклы төлкене туйдырганчы ашата алсын? — дип көлде, ди, төлке.

— Ышанмасаң, менә күр, хәзер мин сине туйдырам, — ди бытбылдык. — Хәзер мин юл өстенә чыгам, син юл читендә, арыш арасында качып кына ят та миннән күзләреңне алмый күзәтеп тор. Мин пырылдап очып кит-

кәндә генә син, юлдагы азыкны алып, менә шул урынга килерсең дә тәмләп торып ашарсың, — дип әйтте, ди.

Төлке юл читенә яшеренеп ятты, бытбылдык арлы-бирле чәбәләнеп йөри башлады, ди. Шулвакыт иңбашларына урак салган бер ир белән бер хатын килә ята икән. Хатыны кулына бер төенчек тә тотып алган. Хатын юлда йөреп яткан бытбылдыкны күреп кала да:

— Әй, атасы, кара әле монау бытбылдыкны: шундый симез, хәтта оча да алмый! Тотып алыйкчы үзен, пешереп ашарбыз. Бытбылдык ите бик тәмле була, диләр, — дип кычкыра, ди.

Шуннан болар икәүләп бытбылдыкны тотмак булалар. Хатын төенчеген юл читенә куя да бытбылдыкны куа башлый. Бытбылдык очмый да, качмый да, тоттырмый да. Шулай куып йөри торгач, инде тотам дигәндә генә, бытбылдык пырылдап очып китә. Ир белән хатын авызларын ачып торып калалар. Төлке дә, бытбылдыкның очканын күреп, юл читендәге төенчекне авызына кабып ала да баягы урынга китә. Төенчекне ачып караса, эчендә тавык ите икән. Төлке рәхәтләнеп ашый. Бытбылдык карап тора. Ә теге ирле-хатынлы уракчылар буш кул белән үз эшләренә китәләр.

Төлке ашап туйгач:

— Хикмәт чынлап та зурлыкта түгел икән шул, синең кебек хәйләкәр булуда икән, — ди. Шуннан ул: — Ярар, бытбылдык дус, син минем тамакны туйдырдың, монысы өчен рәхмәт. Хәзер син мине бер рәхәтләндереп көлдер дә инде, — дигән.

Бытбылдык моны тыңлап:

— Сине көлдереп утырырга хәзер минем вакытым юк шул. Кич белән көлдерермен, хәзергә син шушында ятып йокла. Кичкә таба мин синең яныңа килермен, — дип, үз эше белән китте, ди.

Кичкә таба төлке уянуга бытбылдык килде дә:

— Әйдә, төлке дус, авызың колагыңа кадәр ерылган-

чы рәхәтләндереп көлдереп алып кайтыйм үзеңне, ияр минем арттан! — дигән.

Бытбылдык аулак җирдән генә үтеп, әкрен генә очып барды, төлке качып-посып кына атлап, аның артыннан иярде, ди. Менә алар ындыр артыннан гына үтеп, бер авылга, баягы уракчыларның йортына килеп керделәр, ди. Йорт хуҗасы казык очлый, хатыны сыер сава иде, ди. Төлке качып кына күзәтә башлады, бытбылдык хатынның сыер сауган җирендә аяк астында уралып йөрде, ди. Хатын бытбылдыкны танып калып:

— Әй, атасы, кара әле, безне ашамлыксыз калдырган баягы бытбылдык йортыбызга килгән, сугып үтерик үзен!— дип кычкырды, ди.

Ире казыгы белән кизәнгән иде, бытбылдык сыер мөгезенә килеп кунды, ди; яңадан кизәнеп, сыерның мөгезен чак кына сындырмый калды, ди. Сыер куркып, сөтле бидрәне тибеп аударды, хатын сөт түгелгән җиргә таеп егылды, ди. Бытбылдыкны тота алмагач, теге ир ачуланып хатынын кыйнап ташлады, ди.

Төлке авызы колагына кадәр ерылганчы, буыны катып көлде, ди. Үзе көлде, үзе бытбылдыкның хәйләсен отып утырды, ди.

Менә шуннан соң бытбылдыктан өйрәнеп, төлке хәйләкәр җәнлек булып киткән дә инде, диләр.

ТЫЧКАН, АЮ, БҮРЕ, ТӨЛКЕ

Ялгыз каен төбендә бер тычкан утыра иде, ди. Җил чыгып китте дә, тычкан өстенә бер яфрак өзелеп төште, ди. Тычкан куркуыннан каен төбеннән чыгып качты, ди.

Китеп утыра, ди, бу, китеп утыра, ди, китеп утыра торгач, аюга тап булды, ди. Аю аннан:

— Кайда йөгерәсең болай? — дип сорады, ди.

Тычкан аюга:

Үрге авылдан яу килде,
Иңбашыма туп тиде.
Шуннан качып барамын,
Әйдә, сине дә аламын.
Ябыш минем койрыкка,
Буйсын минем боерыкка! —

дип әйтте, ди. Аю тычканның койрыгына ябышты да, икәүләп китеп бардылар, ди. Бара торгач, бүрегә тап булдылар, ди, болар. Бүре тычканнан:

— Кая китеп барасыз болай? — дип сорады, ди.

Тычкан бүрегә:

Үрге авылдан яу килде,
Иңбашыбызга туп тиде.
Шуннан качып барабыз,
Әйдә, сине дә алабыз:
Ябыш аю койрыгына,
Буйсын минем боерыгыма! —

дип әйтте, ди. Бүре аюның койрыгына ябышты да, өчәүләп китеп бардылар, ди. Бара торгач, төлкегә тап булдылар, ди, болар. Төлке тычканнан:

— Кая китеп баруыгыз бу? — дип сорады, ди.

Тычкан төлкегә:

Үрге авылдан яу килде,
Иңбашыбызга туп тиде.
Шуннан качып барабыз,
Әйдә, сине дә алабыз:
Ябыш аю койрыгына,
Буйсын минем боерыгыма! —

дип әйтте, ди. Төлке бүренең койрыгына ябышты да, дүртәүләп китеп бардылар, ди. Бара торгач, боларга карсак, азрак баргач — куян, бераз киткәч — көзән тап булды, ди. Болар да, бер-берсенең койрыкларына тагылышып, тычкан артыннан киттеләр, ди.

Әй киттеләр, ди, болар тезелешеп, әй киттеләр, ди. артларына борылып карасалар, бастырык буе җир киткәннәр, ди.

Бара торгач, аю туктады да:

— Бик ачыктырды да, азрак тамак ялгап алыйк, — дип әйтте, ди. — Арагызда мин иң олыгыз булам, тыңлагыз минем сүземне! — дип, такмаклап торып сөйләп алып китте, ди:

Аю — сезнең агагыз,
Бүре — сезнең бүләгез,
Төлке — сезнең түрәгез,
Карсак — сезнең картыгыз.
Куян — сезнең энегез,
Көзән — сезнең кечегез,
Тычкан сезнең кемегез? —

дип әйткән иде, тегеләр тычканны өзгәләп ташладылар, ди. Шуннан янә:

Аю — безнең агабыз,
Бүре — безнең бүләбез,
Төлке — безнең түрәбез,
Карсак — безнең картыбыз,
Куян — безнең энебез,
Көзән безнең кемебез? —

диделәр дә, көзәнне өзгәләп ашадылар, ди. Янә күмәкләшеп:

Аю — безнең агабыз,
Бүре — безнең бүләбез,
Төлке — безнең түрәбез,
Карсак — безнең картыбыз,
Куян безнең кемебез? —

дип, куянны өзеп-йолкып ташладылар, аның артыннан «карсак безнең кемебез?» дип, карсакны ботарлап куйдылар, ди. Аю, бүре, төлке генә калды, ди. Шуннан бүре сүз башлап:

Аю — безнең агабыз,
Бүре — сезнең бүләгез,
Төлке безнең кемебез?

дип, төлкене өзеп-йолкып ташламакчы булган иде, төлке аны бүлдереп:

— Аю абыем белән бүре абыем! Сез мине өзгәләргә өлгерерсез, мин сезнең кулыгызда. Рөхсәт итсәгез, үзем исән чакта сезгә бер изгелек күрсәтер идем. Карагыз әле менә бу тау башына, күрәсезме аннан бер сунарчы төшеп килә? Туп-туры безнең өскә килә. Мин хәзер шул якка барыйм, ә сунарчы минем арттан төшеп алыр. Сез шул арада качып китәрсез. Сунарчыны күз яздыргач, мин сезне эзләп табармын. Шуннан мине өзгәләп ашарсыз, — дигән.

Аю белән бүре моңа риза булдылар, ди. Төлке тотты да сызды, ди. Йөри торгач, басу киртәсе буенда, чүплектә тибенеп йөргән бер әтәч янына килеп чыкты, ди. Әтәч моны күрү белән киртә башына очып кунды, ди. Төлке тәмле телләнеп:

— Әтәч дус, мин аю белән бүредән кайтып киләм әле, аларда җиде көн буена кунакта булдым, — дигән булды, ди. — Ишеттеңме әле син, әтәч дус, яңа закон хакында? Хәзер, яңа закон буенча, куян, бүре, төлке белән әтәч

бер-берсенә тимиләр бит, бертугандай йөриләр. Төшче монда, дус булыйк! — диде, ди.

Әтәч моны тыңлап торды да:

— Бик яхшы закон икән, — диде, ди. — Анау яктан безгә карый бер кеше килә. Ул да килеп җитсен дә, бергә-бергә дусларча сөйләшеп тә серләшеп утырырбыз, — диде, ди.

— Минем алай озак сөйләшеп утырырга вакытым юк шул, күл буендагы казларга кунакка барасым бар, — дигән булып, китеп барды, ди, төлке.

Аю белән бүре урман эченә кереп алалар да төлкенең үзләренә азык булып килүен әле булса көтеп утыралар икән.

КУЯН БЕЛӘН АРЫСЛАН

Борын-борын заманда бер арыслан булган. Башка җәнлекләр арысланнан бик куркып кына яшәгәннәр. Ни өчен дисәң, арыслан аларга бер дә көн күрсәтми икән, кайда очратса, шунда тота да егып ашый, ди, үзләрен. Арыслан җәнлекләрнең берсен тотып ашаган чакта, бишесе йөрәге ярылып үлә, ди. Качып котылырга һичбер әмәл булмаган, ди, бу ерткычтан.

Арысланның шулай теңкәгә тиюеннән тәкатьләре калмагач, бердәнбер көнне урмандагы булган киек-җәнлекләр җыелышып, киңәш кордылар, ди.

— Бу арыслан бетерә бит безне, болай булса. Ул беребезне тотып ашаганда, бишәүебез йөрәге ярылып үлә. Ни эшлибез хәзер, агай-эне? — дип әйтте, ди, төлке.



— Без көн саен шобага тотыйк. Шобага кемгә чыкса, шул арысланның корбаны булыр, — дип әйтте, ди, аю.

Шулай итеп, болар көн саен шобага тотарга булдылар, ди. Алар бу хакта арысланның үзенә дә хәбәр иттеләр, ди.

Беренче көн шобага куянга чыкты, ди. Куян торып, җәнлекләргә:

— Агайлар! Безгә болай итеп һәрвакыт арысланның корбаны булып үлү бер дә килешкән эш түгел. Берәр хәйлә корып, шуннан котылу ягын карарга кирәк, — дип әйткән булды, ди.

Төлке куянның сүзен тыңлап торды да:

— Кит, хәсрәт! Синме соң хәйлә корып, арысланны алдар җан! Белер-белмәс телең белән хәбәр сөйләп торган буласың, ачуымны китереп, — дип әрләп ташлады, ди.

Куян арыслан янына китте, ди. Бер дә кабаланмады, ди, бу. Көтеп утырган арыслан бик ачуланды, ди, куянга.

— Нигә алай җай йөрисең син? Ата-бабаларың җай йөрмәделәр заманында. Син иртәнчәк үк килергә тиеш идең, хәзер төш җитеп килә, — дип әрләп ташлады, ди, куянны.

Куян куркып кына:

— Мине сиңа көндезгелеккә ашарга җибәргән иделәр, икенче бер куян сиңа иртәнчәк килергә тиеш иде. Килеп ятканда юлда башка бер арыслан очраган да теге куянны тотып ашаган. Менә мин дә әле сиңа килеп ятканда шул арысланга тап булдым: «Кайда барасың?» — диде. Мин аңа: «Үземнең хуҗама — арыслан агай янына барам», — дип җавап бирдем. Шулай дигәч, теге ачуланып үкерә башлады: «Кем монда миннән башка хуҗа булырга йөри тагы», — ди. Мин аннан көчкә-көчкә генә качып котылдым. Шуңа күрә соңга калып килдем, — дигән булды, ди, куян.

Арыслан куяннан тегенең кайда яшәгәнен сорады, ди.

— Ул моннан ерак түгел, әнә теге якта, — дип җавап бирде, ди, куян.

— Әйдә, алып бар әле син мине аның янына. Мин аңа күрсәтим әле, монда кем хуҗа икәнен! — дип әйтте, ди, арыслан, ачуланып.

Куян алдан китте, ди, аның артыннан арыслан төште, ди. Болар бик тирән бер кое янына килделәр, ди.

— Менә шушы коеның эчендә утыра теге яман арыслан, — дигән булды, ди, куян куркып кына.

Арыслан коеның эченә караса, чынлап та тап үзенә охшаган бер арысланны күрде, ди.

Арыслан, котырынып, үкерә башлады, ди.

— Дөмектерим әле моны! — дип, гайрәтләнеп, кое эченә сикерде, шунда шомбырдап батты да үлде, ди.

Шатлыгы эченә сыймаган куян, бу хәбәрне җәнлекләргә тизрәк белдерер өчен, сикерә-сикерә кайтып китте, ди.

КУЯН БЕЛӘН КЕРПЕ

Берзаман бер керпе, өеннән чыгып, көннең матурлыгына хәйран калып тора иде, ди. Керпе үзалдына үзе: «Бүген бик матур икән, басуга барып, ашарга бераз тамыр-томыр җыеп китерим әле», — дип, басуга чыгып китте, ди. Бераз җир киткән иде, бер куянга барып очрады, ди. Куян, сикерә-сикерә, кәбестә басуын карарга китеп бара икән.

— Саумы, куян тиңдәш? — дип исәнлек-саулык сораша керпе. Ләкин куян берничди дә җавап бирмәде, ди.

керпенең сәламенә. Бераз торгач, бик эреләнеп кенә, керпедән:

— Ни эшләп син болай иртүк монда йөрисең? — дип сорады.

— Саф һава иснәп йөрергә чыктым, — ди керпе.

Куян, көлеп:

— Син ул кәкре аякларың белән аркылы-торкылы басып, тиктомалга гына йөрмисеңдер әле, берәр эш куптарырга йөрисеңдер, мөгаен! — ди.

Керпегә куянның бу сүзе бер дә ошамаган. Ул бик гарьләнгән, ди, моңа. Ни өчен дисәң, керпенең аяклары тумыштан кәкре.

— Син шулай дисең инде, ярар, — ди керпе. — Синең аякларың озын булса да, миннән ары әллә ни кыйрата алмассың!

Куян, көлеп, керпегә:

— Һәрхәлдә, минем аяклар, синеке шикелле, кәкре түгел инде! — ди.

— Карап карыйк, алай булгач, — ди керпе. — Йөгерешеп карыйк, кем узар. Мин, мөгаен, узармын сине.

Куян сыны катып көләргә тотынды, ди.

— Колакка ятмаган хәбәрне сөйлисең, керпе энем. Синме соң инде мине узар җан иясе? Син дигәнчә булсын, йөгерешеп карыйк. Нәрсәдән? — ди куян.

— Бер талир тәңкә дә бер шешә сөт.

— Яхшы. Әйдә, хәзер үк йөгерешәбез.

Керпе әзрәк уйлап торды да, куянга:

— Ул тиклем кабаланырга ярамый. Мин әле тамакка да ашамаганмын. Мин тәүдә өйгә кайтып, ашап килим. Бер сәгатьтән соң шушы урында очрашырбыз, — ди дә җәһәт кенә өенә кайтып китә.

Өенә кайтып кергәч, уйлый, ди, теге керпе: «Куян үзенең озын ботларына ышана, ярый. Менә мин күрсәтим әле аңа. Исәр дә инде бу куян дигәнең! Талир тәңкә белән бер шешә сөтен бик әйбәтләп кенә түләсен әле ул керпе агасына!»

Керпе, инә керпене чакырып ала да:

— Син минем белән басуга барасың, — ди.

— Ни булды сиңа, атасы?

— Без куян белән кемузардан йөгерешергә булдык. Син шаһит булырсың.

— Атак-атак, өнемме бу, төшемме, атасы? Куянны ничек йөгерешеп узмак кирәк? — дип аптырап кала инә керпе.

— Анысы минем эш. Әйдә, тиз бул, күп сөйләнеп торма!

Болар икәүләп куян янына китәләр. Юлда барганда ата керпе инә керпегә:

— Тыңла, мин нәрсә әйтсәм, син шуны эшләрсең. Әнә, ике озын буразнаны күрәсеңме? Менә без шул ике буразна арасында йөгерешәбез. Без аргы буразнадан йөгерешә башлыйбыз. Ә син монда, бирге буразнада утырып кал. Куян син утырган буразнага йөгереп килеп җитү белән үк, син аңа: «Мин әллә кайчан монда инде!» — дип кычкырырсың, — ди.

Басуга килеп җиттеләр, ди, болар икәүләп. Инә керпе, сөйләшү буенча, үз урынында кала, ата керпе үзе аргы буразнага китә. Килсә, куян моны көтеп утыра икән.

— Башларга ярый хәзер, — ди керпе.

Болар икесе дә буразна буена барып, тиңләшеп бастылар, ди. «Бер, ике, өч!» — куян чабып китте, ди, мин сиңа әйтим, бервакыт, ә керпе куянның койрыгын гына күреп калды, ди. Керпе үзе бер-ике генә сикерде дә буразнада ятты да калды, ди.

Куян бирге буразнага килеп кенә җиткән иде, инә керпе:

— Мин әллә кайчан монда инде! — дип кычкырып та җибәрде, ди.

Куян, бу хәлне күреп, бик аптырап кала.

— Әйдә, тагы бер тапкыр кире йөгерешәбез! — ди дә, колагын сыртына салып, кире чабып китә куян. Артын-

нан тузан тузып кына кала. Куян аргы буразнага барып кына житкән иде, ата керпе:

— Мин монда инде, мин монда! — дип кычкырып җибәрде, ди.

Куянның бик ачуы килә моңа.

— Әйдә, кабатлап йөгерешәбез! — ди ул.

— Каршылык юк, — ди керпе.

Куян чабып китә. Керпе тагы буразна эчендә ятып кала.

Шулай итеп, ике буразна арасында житмеш жиде тапкыр йөгерде, ди, бу куян. Кайсы гына буразнага килсә дә: «Мин әллә кайчан монда инде!» — дигән сүзне ишетә икән куян. Җитмеш сигезенче тапкыр йөгергәндә, хәле бетеп тәгәрәде, ди, куян.

Керпе талир тәңкә белән бер шешә сөтне алды да, бик күңеле булып, инә керпе белән өенә кайтып китте, ди.

СОРЫСАЙ БЕЛӘН КАРАСАЙ

Бер бабай белән әби яшәгән, ди. Бала-чагалары булмаган, икәүдән-икәү генә гомер иткәннәр. Күзгә күренерлек мал-туарлары да булмаган, бары ике песи генә асраганнар: берсе — кара песи, икенчесе — соры песи.

Бабай да, әби дә песиләрне бик яратканнар. Кара песине Карасай дип, соры песине Сорысай дип кенә йөрткәннәр алар.

Сорысай бик уңган булган. Ул, төн йокламый, тычкан тота, көндез дә тик ятмый, бөтен тишек-тошыкны күзә-

теп тора, әбинең бөтен ашамлык нәрсәләрен тычканнардан саклый, ди.

Карасай бик ялкау булган. Бер дә тычкан-мазар тотып мәшәкатьләнмәгән. Төнен әбинең сөтен эчеп, каймагын ашап куя да, көндез, түшәккә менеп, мырылдап йоклый да ята, ди, бу.

Әби аптырауга калган. Уенмыни! Ике песи асрыйлар, шуңа карамастан, һәркөн төнлә сөт белән каймак ашап куелган була. Ни эшләргә кирәк? Тота да бу картына әйтә:

— Шулай да шулай, төн булдымы, каймак белән сөтне ашап китәләр. Бу, ахры, үзебезнең песиләр эшедер, — ди.

— Кайсысы эшләде икән бу явызлыкны! — ди карт.

— Белмим шул, — ди әби, — Карасай болай бик акыллы күренә инде: ничә карама түшәктә генә утыра. Сорысай эше булырга тиеш бу.

Болар тагы сынап карарга булалар. Карасай төнен тагы сөт белән каймакка зыян китерә. Өстәвенә, азрак майны да авыз итеп куя. Сорысай бу төнне дә тычкан артыннан йөреп үткәрә.

Иртәгәсен Карасай түшәккә менеп ята да мырылдап йоклап китә. Сорысай, гадәтенчә, тагы тишек-тошыкларны сагалап йөри.

Бабай әйтә:

— Дөрес, Сорысай эше булырга кирәк бу, — ди.

— Әйе, әйе, — ди әби, — Карасай бик инсафлы, гел шулай ул.

Шуннан бабай белән әби киңәш итәләр дә, Сорысайны урманга алып барып олактырырга булалар. Беркөн бабай аны капчыкка салып алып китә дә караңгы урманда калдырып кайта.

Сорысай ялгызы калгач, кайда барырга белми, бераз аптырап йөргән, ди. Ул арада караңгы да төшеп китә, бүреләр дә улый, ябалаклар ухылдаша башлаган, ди. Сорысай шүрләп тә куя икән. Шулчак, йөгереп килеп, агач

башына менеп, үзенчә тавыш чыгарып, мияулап утыра башлады, ди, бу.

Урмандагы җәнлекләрнең песи мияулаганын ишеткәне юк икән. Болар бөтенләй аптырашта калган. Килеп сорарга куркалар. Ни эшләмәк кирәк? Җыелышып алалар да киңәш итәләр.

Аю әйтә:

— Тәүдә без аның кем икәнен белик, шуның өчен арабыздан берәүне сайлап җибәрик.

Бүре әйтә:

— Андый эшкә Көлтәкойрык төлке бик шәп була торган. Ул барсын.

Төлке әйтә:

— Юк, мин булдыра алмыйм: авырып торам. Анда минә Шешколак барырга тиеш.

Шешколак куян, бахыр, куркуыннан шүрләп үк җибәрде, ди. Шулай да ни эшләсен инде, бармый булдыра алмый. Ни өчен дисәң, тегеләр моны тотып ашарга торалар.

Шешколак калтырана-калтырана гына Сорысай утырган агач төбенә килеп эндәште, ди:

— Әйтегезче, сез кем буласыз?

Сорысай, тегенең курыкканын сизеп, батыраеп китте, ди.

— Минме? Мин песи затымын. Исемем песи батыр булыр.

— Ни телисең, песи батыр?

— Минме? Миңа тычкан кирәк. Тычкан китерегез миңа! Тычканнарны кырып беткәч, аннан тагын күз күрер!..

Шешколак куян кайтып, тегеләргә хәбәр сала. Урмандагы барлык җәнлекләрне җыеп, песи батыр өчен тычкан тотарга чыгып китәләр. Әй йөриләр, ди, тик берсе дә тычкан таба алмый, ди.

Кичен тагы аю янына җыелалар. Ни эшләргә киңәш итәләр.

Төлке әйтә:

— Бүгенгә без менә Шешколак куянбикәне балалары белән биреп торыйк. Ә иртәгә тагы күз күрер, — ди.

Бүре төлкегә әйтә:

— Иртәгә чират сиңа була.

— Юк, минем койрык бик зур бит, иртәгә син барырсың.

Аю әйтә:

— Юк, җәмәгать, болай ярамый. Болай барса, ул безне берәм-берәм ашап бетерер, без аны чакырып сыйлап карыйк...

Шуннан болар песи батырны чакырып сыйламак булалар. Һәркайсысы үзенчә әзерләнә: аю бал китерә, бүре сарык ите китерә, көлтәкойрык төлке тавык ите китерә, Шешколак куян усак кайрысы алып килә. Сый әзерләп беткәч, Сорысайны чакырырга әлеге Шешколак куянны җибәрәләр.

Шешколак куян Сарысай янына килеп, курка-курка гына эндәшә:

— Мин сезне, песи батыр, кунакка чакырып килгән идем.

Сорысай да сер бирми: тычкан таба алмый ачыккан булуына карамастан, оеп кына утырган була. Шешколакның курыкканын күргәч, ул тагы батыраеп китә.

— Ярар, барсам барырмын, — дигән була бу. Үзе, Шешколак куян кайтып киткәч тә, тегенең артыннан бара.

Сорысайның килергә риза булганын ишеткәч, тегеләр тагы куркып китәләр. Кем каршы алырга тиеш? Киңәш итәләр.

Төлке әйтә:

— Шешколак куянбикә аны белә инде, ул каршы алсын.

Бүре әйтә:

— Дөрес, бик дөрес. Шешколак куянбикә каршы алсын.

Аю әйтә:

— Сез риза булгач, мин дә каршы түгел. Алайса, син,

Шешколак, кадерле кунагыбызны каршы ал. Ә без өйдә көтеп торырбыз.

Шуннан аю үзе агач башына менеп китә. Бүре шул агач төбендәге ялгаш астына кереп ята. Көлтәкойрык төлке чытыр астына кереп китә. Шешколак куянбикә генә торып кала. Тегеләр киткәч, бу да куркышыннан үлә язып, бер түмгәк артына яшеренә.

Менә берчак, эре генә атлап, Сорысай килә. Килә бу, бер-ике атлый да мыраулап куйган була. Үзе тирә-якка карап ала. Килеп җитә дә әйтә:

— Мырам, мырамм! Барыгызны да кырам! Кайда монда хуҗалар?

Җавап юк. Ни өчен дисәң, тегеләр барсы да шүрләп посып бетәләр. Сорысай эшне сизеп ала да тагы да ныграк итеп мыраулый башлый:

— Мырам, мырамм! Барыгызны да кырам!

Үзе шулчак килеп, тегеләр әзерләгән сыйны тәмләп карый. Караса — бал да сарык ите, тавык ите дә усак кайрысы... Бу тагы мыраулап кычкыра:

— Ни өчен миңа тычкан әзерләмәдегез? Мырам, мырам, барыгызны да кырам!

Тегеләр аның саен куркышалар. «Инде ни хәл итик», — дип ятканда гына, Сорысай түмгәк артында бернәрсә селкенгәнен күреп кала. Ул моны тычкан дип уйлый. Әлегечә мыраулап, тегеңә табан бара башлый.

— Әһә, эләктеңме?! — ди Сорысай. — Мин сине күпме вакыт эзләп йөрим!

Моны ишеткәч, түмгәк артындагы Шешколак куян бөтенләй һуштан яза. Сорысай инде килеп эләктердем дигәндә генә, көч-хәл белән атылып, чытыр өстенә менеп китә. Сорысай аптырый, караса: чытыр астында да бернәрсә селкенеп ята. Бу тагы мыраулый башлый:

— Әһә, каптыңмы? — ди бу. — Юк, миннән качып котыла алмассың!

Сорысай килеп, Көлтәкойрык төлкенең чытыр астыннан күренеп яткан койрыгын эләктереп ала. Шуннан Көл-

тәкойрык төлке, куркышыннан чытыр астыннан чыгып, җан-фәрманга чабып, урман эченә кереп югала. Бу хәлгә Сорысай, үзе дә бик куркып, тиз генә якындагы агач башына менеп китә.

Теге аю шул агачның башында утыра икән. Капыл Сорысайның менеп килүен күргәч, бу, куркып, утырган җиреннән егылып төшә. Шул агачның төбендәге ялгашка килеп төшә. Ә ялгаш астында бүре ята. Ул да куркып китә. «Бу Сорысай дигәне тегеләрне ашап беткән икән дә миңа тотынырга булган икән», — дип уйлый. Тиз генә ялгаш астыннан чыгып кача.

Шулай итеп, тегеләр барсы да куркып, качып бетәләр. Сорысай берүзе торып кала.

Калуында ни файда бар инде, әзерләгән сый ашарлык булмагач! Сорысай карап тора-тора да агач башына менеп утыра.

Кичкә таба бу җәнлекләр тагы шул җиргә җыелышалар. Шешколак:

— Колагымнан тотып чытыр өстенә ташлады, кем, җаным уч төбендә генә калды, — ди.

Көлтәкойрык төлке:

— Ә минем койрыгымнан тотып алып ыргытты, үләм икән дип торам, — ди.

Аю:

— Мин менгән агачны килеп селкетә башлады, кем, тәгәрәп төштем дә киттем, — ди.

Бүре:

— Ялгаш астында ятам, әй, теге бервакыт килеп басты, көчкә чыгып котылдым! — ди.

Ярый, болар шулай сөйләшә торсын, Сорысай агач башында кайгырып утыра торсын, без килик авылга, керик әби белән бабайга.

Бабай Сорысайны урманда калдырып кайта да:

— Инде тынычландык, зыян итүче булмас, — ди.

Әби дә бик сөенә:

— Шулай гына булсын инде, — ди.

Бер кич куналар болар, ике кич куналар. Карасалар — әбинең һаман сөтен дә эчәләр, каймагын да ашыйлар. Җитмәсә тагы, тотучы булмагач, тычканнар да күбәеп китә. Моның Карасай эше икәнен инде хәзер болар төшенәләр. Бахыр Сорысайны жәлләп алалар.

Инде ни акыл итәргә? Хәзер бабай Карасайны капчыкка салып, әлеге урманга алып китә.

Урманга килә бу, бераз карап йөри дә бер җирдә туктап, капчыгының авызын чишә башлый. Чишеп тә өлгерми, әлеге Карасай тырнаша да башлый.

— Әһә, син әле шулай усаллашырга уйлыйсыңмы, явыз? — ди бабай. — Алай булса, мин сине капчыктан чыгармыйм.

Шул көе капчыкның авызын кабат бәйли дә карагайга асып куя, үзе кайтып китә.

Кайта-кайта, бу бер елаган тавыш ишетеп кала. Абайлабрак караса — тавыш песи баласыныкына охшаган, үзе якында гына сыман. Бабай шул якка китә, китә-китә, бер карама төбенә килеп чыга. Караса — карама башында әлеге Сорысай утыра. Карт тегене күтәреп ала да, бик кадерләп куенына тыгып, өенә алып кайтып китә.

Карагай ботагына асып куйган Карасай капчык эчендә бераз ята да чыгарга тырышып чәбәләнә башлый. Чыгарга әмәл таба алмагач, бу каты итеп мырылдап ала, алай да булмагач, яман итеп кычкырырга тотына.

Урмандагы җәнлекләр тагы куркышып китәләр. Җы-лып, тагы киңәш итәләр.

Аю әйтә:

— Булмаса, бүре дус, берәрегез барып килегез әле. Тагы нәрсә сорый икән?

Бүре әйтә:

— Бик дөрес әйтәсең, аю агай, барып килергә кирәк. Бу юлы минә Көлтәкойрык төлке барса, әйбәт булыр.

Төлке әйтә:

— Әйе, әйе, мин дә кушылам. Икегез дә бик дөрес әйтәсез, барырга кирәк, барырга кирәк. Инде Шешколак

куянбикә — бер өйрәнгән җәнлек, ул барса, әйбәтрәк булыр.

Аю әйтә:

— Бик дөрес әйтәсез. Син, Шешколак, тагы барып, карап кил әле. Нәрсә эшли икән ул песи дигәннәре, тагы нәрсә сорый икән, белеп кил.

Шуннан Шешколак куян, куркышыннан елый-елый, тагы китә. Түмгәктән-түмгәккә, түмәрдән-түмәргә ышыклана-ышыклана гына, Карасай асылынып торган карагай төбенә килә. Килсә, ни күзе белән күрсен: зур карагай, карагай башында зур ботак, ботакка бер капчык эленгән, капчык эчендә әлеге песи кычкыра. Шешколак башта аптырап кала, шуннан, эшнең нидә икәнен төшенеп алгач, шатлыгыннан сикерә-сикерә, тегеләр янына кайтып китә. Кайта да әйтә:

— Курыкмагыз, иптәшләр, теге явыз песине берәү килеп, капчыкка салып, бикләп киткән!

Аю да, бүре дә, Көлтәкойрык төлке дә бу хәбәргә бик сөенәләр. Шешколак куян артыннан ияреп, әлеге карагай янына киләләр.

Болар килгәч, капчык эчендәге Карасай ныграк кычкырып җибәрә. Күпме кычкырсаң да, капчык эчендә ятып ни эш кырасың инде! Бу да шул, хәле бетеп, тына...

Тегенең капчык эчендә икәнен күреп ышангач, аю әйтә:

— Туктагыз әле, булмаса, мин карагай башына меним. Менем дә бу явызны алып төшим.

Аю шатырдап карагай башына менеп китә. Теге капчык эленгән ботакка җитә. Шул ботак буйлап капчыкка таба килә башлый бу. Килә ята, килә ята, инде килеп тоттым дигәндә генә, ботак сынып китә дә аю дөрселдәп барып төшә бер якка, капчык эчендәге песи — икенче якка.

Бүре дә, Көлтәкойрык төлке дә, Шешколак куян да куркып урман эченә ташлана. Аю ачуланып кычкыра, ди:

— Ә син шулай капчык белән башка сугасың икән әле, — дип әйтә, ди, — үзең капчык эчендә ятканыңны белмисең! Явыз!

Шуннан аю, ачуланып, капчык янына килеп, Карасайны тукмый башлый, ди. Әй тукмый, ди бу, әй тукмый, ди, Карасай аның саен акыра, ди. Тавышка тегеләр дә килеп җиттеләр, ди. Кызып алып, алар да Карасайны тукмарга керешеп киттеләр, ди. Бүре килеп капчыкны чәйнәп-чәйнәп куя, ди. Көлтәкойрык төлке килеп тырнап-тырнап ала, ди. Хәтта инде Шешколак куян да килеп капчыкны типкәләп китә, ди.

Болар шулай тукмый торгач, капчык эчендәге Карасай тына. Капчыкны чишеп җибәрсәләр, эченнән үлгән кара песи килеп чыга. Болар аптырап калалар.

Шешколак куян әйтә:

— Үлүен үлгән дә инде, ул хәтле тукмагач, үлми чыдамас. Тик менә ни эшләп соры песи карага әйләнде икән соң?

Аю әйтә:

— Мин бик каты тукмадым шул. Минем кул тигән җир кара янып китә ул.

Бүре әйтә:

— Юк, мин бик каты чәйнәдем, мин чәйнәгән җиргә кап-кара кан сава да куя торган.

Көлтәкойрык төлке әйтә:

— Юк, мин бик каты тырнадым аны. Мин тырнаган җир караймый калмый.

Шешколак куян әйтә:

— Мин соң, мин типкәләп ташладым бит аны. Менә бу табан белән типкәләүгә ни чыдамак кирәк, караю түгел, агарырсың!

Шулай итеп, урмандагы җәнлекләр песи дигән ят җәнлектән котылалар. Шуннан урман тынып калган, ди.

Ә Сорысай, өйгә кайтып, бабай белән әбигә бик озак хезмәт иткән, ди.

ТАВЫК БЕЛӘН ТИЛГӘН

Берзаман тавык белән тилгән дуслашып китте, ди. Тилгән тавыкка кунакка да йөри башлаган. Килгән саен ул, дөньясын онытып, гел генә һавада очып йөрүнең рәхәтлеген сөйли торган була. Моннан күрмәкче тавыкта да очып йөрү дәрте кузгалып китте, ди. Әмма ул, күпме генә тырышмасын, үзе куна торган читәннән дә биек оча алмый.

Моны күреп торган тилгән тавыкны очарга үзе өйрәтмәкче булды, ди. Шулай да барыбер эш чыкмый. Тилгән тавыкны очарга гына өйрәтә башлаган иде, арага әтәч килеп кысылып, җәнҗал кубып китте дә, тавык белән тилгәннең дуслыгы бетте дә куйды, ди. Ни өчен дисәң, тавык белән дуслашканга тиклем, тилгән муенына бик матур муенса киеп, башына шундый ук асыл тарак кадап йөрер булган. Әтәчнең менә шуңа күзе төшкән икән. «Ул тарак ни эшләп минем башта түгел дә, шул муенса ни эшләп тавык муенында түгел?» — дип уйлый икән әтәч. Менә шул аркада ике арада җәнҗал чыгып китеп, тавык очарга өйрәнә алмый калган да инде.

Ә ул җәнҗал менә ничек чыгып киткән. Бердәнбер көнне (бу тилгәннең соңгы тапкыр кунакка килүе булган да инде) әтәч белән тавык тилгәнне тилебәрән орлыгы белән сыйлаган. Шуннан тилгән бөтенләй исереп егылды, ди. Шулчакта әтәч аның тарагын алып, бик әйбәтләп кенә үз башына кадап куйды, ә муенсасын алып, тавык муенына кидерде, ди. Тилгән шулай иссез булып ятып калды, ә купшыланып алган әтәч, башын югары күтәрә биребрәк, «күрдегезме агаегызмы?» дигән сымак, як-ягына каранакарана, күрше-күлән арасына йөрергә чыгып китте, ди.

Тилгән исенә килеп торса, муенса да, тарак та юк, ди. Шуннан ул якында гына йөреп яткан тавыкны күреп:

— Бир минем муенсамны! — дип кычкыра.

Ә теге бирми дә бирми икән. Ни өчен дисәң, муенса тавыкка, бердән, бик килешеп тора; икенчедән, кеше әйберен сорамый алырга ярамавын бөтенләй белми дә икән

бу тавык миле кош! Менә шунда инде ике арада ызгыш-талаш китте, җәнҗал купты, ди.

Тилгән үзенең котсыз тырнаклары белән тавык муеныннан муенсаны тартып алырга иткән иде, муенсаның җебе өзелеп, мәрҗәннәре чәчелде дә китте, ди. Шуннан тилгән бөтенләй ачуланып:

— Ярар, безнең дуслыкның бетүе шулдыр инде. Мин сиңа күрсәтермен әле күрмәгәнеңне! — дип янады да очып китте, ди.

Ә бу вакытта әтәч, тилгәннең тарагын кикрик итеп, авылның теге очында масаеп йөреп калды, ди.

Менә бервакыт тавык оя басып, чебеш чыгара. Беркөнне ул үзенең чебешләре белән чүплектә тибенеп йөрсә, һавада тилгәннең талгын гына очып йөрүен күреп кала. «Минем иске дус рәхәтләнеп очып йөри икән. Муенса турында да бөтенләй оныткандыр әле ул», — дип уйлап куйды, ди, тавык.

Онытыр сиңа тилгән! Ул шунда ук җиргә килеп төшә дә бер чебешне тырнаклары белән эләктереп алып, яңадан югарыга күтәрелеп тә китә.

Тавык белән әтәчтән тилгән үзенең үчен әнә шулай ала башлый. Шуннан бирле чебешләрне берәм-берәм алып китеп кенә тора икән бу каһәр суккырың.

Тавык кайгыга сабышты, ди. Аптырагач-йөдәгәч, ул, елның-елында гел генә кабатланып торган бу бәладән котылыр өчен, тилгәнгә муенсасын кайтарып бирмәк була. Үзе артыннан чебешләрен ияртеп, әтәч белән бергә тилгән муенсасының чәчелеп-югалып беткән мәрҗәннәрен эзләп, тиреслектә, чүп-чар арасында тибенеп-тибенеп казынырга тотыналар. Әй эзләнәләр, әй эзләнәләр, ди, болар, тик бер генә мәрҗән дә таба алмыйлар.

Бердәнбер көнне әтәч тилгән муенсасының бер мәрҗәнен табуын тапкан иде дә, бер дә исе китмәде, ди, аның моңа: бу хакта тавыкка да әйтеп тормады, ди. Төкереп бирде әтәч синең муенса бөртегеңә! Башында шундый кик-

рикләнеп торган асыл тарак була торып, кукыр этәч муенса бөртеге эзләп йөриме соң!

Ә бахыр тавык әнә шул чәчелеп киткән мәрҗәннәрне әле булса тибенә-тибенә эзләп йөри икән.

САНДУГАЧ

Борын-борын заманда бер авылда бик бай бер сәүдәгәр яшәгән. Аның байлыгының иге дә, чиге дә булмаган. Өендәге келәмнәре Персиядән, савыт-сабалары Кытайдан алып кайтылган булган. Сәүдәгәрнең өстендәге җиләне Төркиядән, хезмәтчеләре Һиндстаннан алынган икән. Кайда гына барса да, ул үзенә истәлек өчен берәр нәрсә алып кайта торган булган.

Сәүдәгәр өендә бер сандугач яшәгән. Сандугачның читлеге алтыннан эшләнгән, ә түбәсе пыяладан булган. Читлекнең идәненә дә алтын ком сибелгән булган. Сандугачы өчен сәүдәгәр бернәрсәсен дә кызганмаган.

Иртән дә, төш вакытында да, кичен дә хезмәтче сандугач өчен салкын суны көмеш савытка салып, ә орлыкларны гәрәбә подноска салып китергән. Шулай итеп, сандугач бер кайгы да күрмичә, җырлап көнен уздыра торган булган.

Берданбер көнне сәүдәгәр үз эшләре белән чит илгә китәргә җыенган. Бу турыда сандугач белеп калган да хуҗасыннан болай дип сораган:

— Хуҗам, син минем белән һәрвакыт яхшы мөгамәләдә булдың, нәрсә сорасам, шуны бирдең, бер соравыма да, теләгемә дә каршы килмәдең. Бу юлы да минем телә-

гемне үтә инде. Син минем туган илемә барасың. Анда асыл җимешләр үскән бер бакча булыр, шул бакчада минем барлык туганнарым яши. Аларны эзләп табып, миннән бик күп сәлам әйт, минем сау-сәламәт икәнлегемне, бертөрле дә авырлык күрмәвемне белдер, — дигән.

Сандугачның бу теләген үтәргә хуҗа сүз биргән. Озын юлга чыккан. Бик күп көннәрдән соң ул бу илгә килеп җиткән. Сатасы нәрсәләрен сатып, аласыларын алып беткәннең соңында, сандугач әйткән бакчаны эзләп тапкан. Бакча шултиклем матур, әйтеп тә, сөйләп тә бетерерлек түгел, ди. Бакчада үскән агачлар күзнең явын алып тора, ә агачтагы җимешнең иге-чиге күренми, ди. Һава хуш ис белән тулы, ди, һәр агачта сандугачлар сайраша, аларның тавышына бөтен бакча күмелгән, ди. Бу бакчага килеп кергәч, сәүдәгәр һуштан калган да, бик озак ни өчен килгәнен онытып утырган. Шулчак аның каршына килеп, бер сандугач сайрый башлаган. Ул шултиклем матур сайраган, сәүдәгәр бу минем сандугачның энесе дип уйлап, аңа мөрәҗәгать иткән.

— Тыңла әле, сандугач! Минем өйдә алтын читлектә синең абыең яши. Ул сиңа да, башкаларыгызга да күп итеп сәлам әйтеп җибәрде. Бик яхшы яшәгәнлеген, кайгы-хәсрәт күрмәгәнлеген белдерде, — дигән.

Сәүдәгәр сөйләп беткәч тә сандугач, атып төшергән кебек, җиргә егылган. Сәүдәгәр нәрсә эшләргә белми икән. Иелеп сандугачны караса, ул инде тын да алмый, канатларын җәеп, авызын ачып, үлеп ята, ди.

«Ах, юкка мин моңа абыйсы турында сөйләдем, кайгысыннан үлде, ахры», — дип, сәүдәгәр үз эченнән уйлап алган. Ул үлгән сандугачны алган да читкә ыргыткан. Ә сандугач җиргә барып бәрелү белән кире дән терелгән дә очып киткән. Сайрый-сайрый күздән дә югалган. Сәүдәгәр кычкырып караса да, сандугач кире әйләнеп килмәгән.

Өйгә сәүдәгәр бик кайгылы әйләнеп кайткан, эшнең ничек булганын сандугачка сөйләп биргән. Хуҗасының

сөйләгәнен ишеткәч тә сандугач бик кайгырган, көн буе бернәрсә ашамаган да, эчмәгән дә, сайрамаган да. Ә иртәгәсен хезмәтче ашарга-эчәргә китергәндә, сандугач үлеп яткан. Моны ишеткәч, сәүдәгәр чак еламаган. Ул сандугачын терелтү өчен төрлечә эшләп караган, авызы белән су да эчереп караган, кояшта да җылыткан. Ләкин бернәрсә дә ярдәм итмәгән. Сандугач үлгән. Сәүдәгәр хезмәтчесен чакырып алган да сандугачны чыгарып ташларга кушкан. Хезмәтче сандугачны чүплеккә илтеп ташлаган. Сандугач җиргә барып бәрелү белән терелгән дә, күңелле итеп сайрап, үз иленә очкан.

ҚАЗЛАР НИГӘ АЛА БУЛГАН?

Моннан бик күп заман элек, дәү әтиләребезнең дәү әтиләре малай чакта, дәү әниләребезнең дәү әниләре кыз вакытта казлар гел ак булган, ә ала каз исем өчен генә булса да очрамаган, ди.

Ала казлар Котсыз Котый дигән бер кешенең явызлыгы аркасында гына килеп чыкканнар икән.

Котсыз Котый, сабый балаларны урлап, җиде урман, җиде диңгез артындагы диюләргә илтеп сата торган булган. Бердәнбер көнне менә шул Котсыз Котый Хәлимә исемле бер бите ай, бер бите көн кебек сылу кыз баланы урлап, тимер читлеккә бикләгән дә, үзе башка балаларны урларга дип китеп барган, ди. Китәр алдыннан ул читлек эргәсенә сихерле ак ташлар сала торган булган. Бу ташлар читлекне, хуҗасы килгәнче, саклап торалар икән.

Ак ташлар тын гына ятып, ә инде читлеккә ябылган бала аннан берәр ничек чыга калса, шунда ук аңа ташла-

нып, аякларына ябышыр булганнар. Мескен бала кузгала да, кычкыра да алмый, катып кала торган була.

Ә Котсыз Котый бер китсә, атналар, кайсычакта айлар буе йөри икән.

Хәлимә бахыр әнә шул читлек эчендә икән, аның монда икәнлеген беркем дә белмәгән, ди. Ул, шундый тоткын булып утыра торгач, ябыгып, йомычка сыман булып калган, алсу йөзе сарыга сабышкан. Ә читлек чыгып качарлык түгел: чит-читләре бик нык, түшәм кебек нәрсәсе бик биек булган, тик ишеге астында каз бәбкәсе сыярлык кына бер тишек бар икән.

«Нигә мин каз бәбкәсе булмадым икән — шушы тишектән чыгар да китәр идем?» — дип елый икән Хәлимә бахыр. Зарыгып утыра торгач, Хәлимә кибеп бәләкәйләнә башлаган. Шулай бәләкәйләнгәннән-бәләкәйләнә барган да йомыркадан яңа гына борынлап чыккан сап-сары каз бәбкәсе кебек булып калган, ди. Аяклары урынында — каз бәбкәсенең тәпиләре, куллары урынында — бәбкә канатлары, ди, моның. Хәлимә, шатлыгыннан, әле кауры да катып җитмәгән бәләкәч кенә канаткынасын каккалап, ишек астындагы тишектән тышка килеп тә чыккан, ди.

Теге сихерле ташлар, каз бәбкәсен күрсәләр дә, моның Хәлимә икәнен белмәгәннәр.

— Бу каз бәбкәсе кайдан килеп чыкты соң әле? — дип хәйран калганнар алар, ни эшләр икән бу дип, аны күзәтеп торганнар.

Каз бәбкәсе киткән дә киткән. Шул җирдә теге ак ташлар, каз бәбкәләренә әверелеп, Хәлимә артыннан төшеп алганнар да бастырып киткәннәр, ди.

Хәлимә бер елга буена барып чыккан. Яр башында бик күп каз үзләренең бәбкәләре белән җим эзләп йөри икән. Хәлимә шулар арасына барып сыенган. Ләкин чын каз бәбкәләре бу ят бәбкәне чукырга тотынганнар. Хәлимә алар белән талашып тормаган, читләшкән дә алардан ары китеп барган. Шуннан ул елгага төшеп алган да йөзеп киткән. Ә бәбкәгә әверелгән теге сихерле ташлар, Хәлимә-

не күздән югалтып, читлек янына кире кайтканнар да яңадан ак ташка әйләнгәннәр, ди.

Ләкин Хәлимә үзенең әүвәлге хәленә кайта алмаган, гомергә каз булып калган, ди. Аның баягы чын каз бәбкәләре чукыган җирләре ала-кола булып калган. Ә үзе олы каз булып, оя баскач, бәбкәләре дә аның ала булып яралган, ди. Менә шуннан башлап дөньяда ала казлар үрчеп киткән, имеш, ди.

КАРАМУЛЛА

Элек Карамулла дигән бер хәлфә булган. Бер карт белән карчык бердәнбер балаларын шул хәлфәгә укырга җибәрәләр. Уку башлана. Алты ай укыгач, малай атасы белән әнисе янына кайта. Кайткач та әтисенә:

— Мин бер ел укыгач, Карамулла сезне үзенең янына чакыртып алыр. Сез барганда, ул безнең барыбызны да бүре итеп утыртып куяр. Мин уң яктан өченче урында утырырмын да койрыгымны кыбырдатып алырмын. Шул вакыт Карамуллага: «Минем улым шул», — дип әйтерсең. Карамулла икенче тапкыр икенче бүлмәгә безне куян итеп утыртып куяр. Шулчак мин сул яктан өченче булып утырырмын да алгы аягым белән битемне сыйпап алырмын. Шулвакыт: «Минем улым шул», — дип әйтерсең, ди.

Уку елы беткәч, Карамулла малайның әтиләрен чакырта. Малай бүре булып өченче урында утыра. Шарт буенча, әгәр дә әтисе үз баласын таный алмаса, ул Карамуллага ике мең сум акча түләргә тиеш була. Малай койрыгын болгап утыра. Әтисе улын таный. Боларны хәлфә икенче бүлмәгә алып чыга да куян итеп утыртып куя.

Этисе улын тагы да таный. Карамулланың ачуы килә, ләкин бернәрсә дә эшли алмый. Карт улын түләүсез алып кайтып китә.

Картның улы, укып кайткач, йорт тирәсендә бернинди дә файда китерә алмый. Бердәнбер көнне улы әтисенә болай дип киңәш бирә:

— Мин бик матур бер ат булыйм, син мине базарга алып барып сат, тик йөгәнне сатма, йөгән мин үзем булырмын, — ди. Шулай эшлиләр. Иң тәүдә атны сатып алырга Карамулла килә. Аңа ат бик ошый. Бер меңгә атны сатып ала да кайтып китә. Кайткач, атны сарайга куя. Ә йөгәнне карт үзендә калдырган була.

Карамулла өйгә кереп китә дә карчыгына:

— Кунакка барырга бик яхшы ат китердем, — ди. Карчыгы чыгып караса, ат урынында юк. Карамулла атның үзе укытып чыгарган малай икәнен аңлый. Малайның әтиәнисе мең сум акча беткәнче бик яхшы яшиләр. Акча беткәч, тагы аптырауга калалар. Карт белән улы көне-төне эшләп тә карыйлар, акча җиткерә алмыйлар. Улы әтисенә тагы киңәш бирә:

— Әти, мине тагы базарга ат итеп алып барып сат. Тәүдә Карамулла килер, ул бер меңнән алып уң меңгә тиклем бирер, тик йөгәнне сатма, — ди.

Малай бик яхшы атка әверелә. Әтисе базарга алып бара. Карамулла килә. Ул ун меңгә тиклем хак бирә. Акчаның күплегенә кызыгып, карт атны йөгәне белән сата да җибәрә. Карамулла атның малай икәнен белә. Ул элекке үчен алырга уйлый. Атның алгы аякларын, җиргә тидермичә, тарттырып бәйләп куя да, үзе өйгә кереп йокларга ята. Шулчак карчыгы арлы-бирле эш эшләргә йортка чыга. Ул, атны күреп калып, тезгенне чишә дә, өйгә кереп, атның интегеп торуын әйтә. Карамулла:

— Әллә йөгәнен чиштеңме? — дигәч:

— Чиштем шул, — ди. Карамулла йөгереп чыкса, ат урынында юк. Күккә караса, малай саескан булып, очып кайтып бара икән. Карамулла бөркеткә әйләнә дә малай-

ны куып китә. Бервакыт малай арый башлый. Арый башлагач, тургайга әйләнә. Карамулла кыйгырга әйләнә. Малай тагы арый. Суга җиткәч, малай балык булып суга чума. Карамулла зур балыкка әйләнә дә судагы балыкларны тотып ашый башлый. Малайны инде тотам дигәндә генә, ул тагы тургай булып очып китә. Чишмәгә җиткәч, алтын балдак булып, суга чума. Карамулла кыйгыр булып оча, ләкин эзләсә дә малайны таба алмый.

— Мин үземне үткермен дип уйлаган идем, мин укыткан малай миннән дә үткеррәк булып чыкты, — ди дә Карамулла кайтып китә. Ә малайга:

— Яшә әйдә шунда, — ди.

Бер кыз чишмәгә суга килә. Суга иелсә, ялтырап алтын балдак ята. Кыз балдакны ала да кулына кия. Кичке ашны ашагач, кыз йокларга ята. Йоклаган чакта балдак кулында кыбырдый. Кыз караса, балдак сузылып чыга да бик матур егеткә әйләнә. Алар бер-берсен яраталар. Кыз әтисенә бу турыда белдермәскә уйлый. Көндез егет балдакка әйләнә, кыз аны киеп йөри. Бик күп шулай йөргәч кенә әтисе моны сизә.

— Ни эшләргә икән? — дип, кызның әтисе Карамуллага бара. Карамулла:

— Кызыңның кулында балдагы бармы соң? — дип сорый. Әтисе барлыгын әйтә. Карамулла:

— Кичкә барып чыгармын, — дип торып кала. Кич булгач, егет кызга:

— Карамулла килер, синнән балдакны алырга итәрләр, тик син бирмә, көчләп алырга итсәләр, син балдакны авызыңа кап. Әгәр авызыңнан да көчләп алырга уйласалар, өр дә җибәр. Балдак тары булып җиргә чәчелер. Шуннан син бер тарыны аягың белән басып калырга тырыш, — ди.

Карамулла килә. Кызның әтисе белән икәүләп кызның бүлмәсенә керәләр. Балдакны алырга тырышалар. Кыз авызына каба. Авызыннан алырга тырышкач, кыз өреп җибәрә. Балдак тары булып идәнгә чәчелә. Кыз аягы бе-

лән бер тарыны басып кала. Карамулла тавык булып, тарыны чүпли башлый. Чүпләп беткәч, чикылдап куя.

Кызның аяк астындагы тары әтәч булып килеп чыга да тавыкка ташлана. Әтәч белән тавык сугыша башлыйлар. Әтәч тавыкны үтерә дә егеткә әйләнә. Кызның әтисе:

— Син чын егет икәнсең, икегез мәңге бергә яшәгез, — дип икесен калдырып чыгып китә.

ҮГЕЗ

Борын-борын заманда бер әби белән бер бабай яшәгән. Аларның үгезләре булган. Бервакыт үгез бабайга:

— Бабай, хан кызына миннән кода булып бар, — дип әйтте, ди. Бабай аптыраган.

— Кит, юкны сөйләмә, кеше үгезгә кыз бирәмени? — дип, үгезне уеннан кире кайтарырга тырышкан. Үгез дә сүзендә каты торган, бабайны яучы итеп җибәргән, ди.

Бабай, барып кергәч, ханга:

— Минем үгез синең бер бите ай, бер бите көн кебек кызыңа мине кода итеп җибәрде, — дип әйтте, ди.

— Эзең булмасын монда, кеше үгезгә кыз бирәмени! — дип, бабайны куып кайтарды, ди, хан.

Үгез бабайны тагы җибәрде, ди, бабай бу юлы тукмалып, көчкә сөйрәлеп кайтты, ди.

Бабайны үгез сөзеп савыктырды да:

— Йә, бабай, нихәл? — дип сорый, ди.

— Юк, бирмиләр, — диде, ди, бабай.

— Өч барып бирмәсәләр, белермен мин нишләтергә, — дип, үгез күмәч салып, бабайны тагы җибәрде, ди. Кызның әнисе:

— Бирсәк, бирик инде, өч килде, ярар, бер хәл бардыр инде, — дип әйтте, ди. Күршеләре:

— Үгезгә кеше кыз бирәмени? — дип килеп әйттеләр, ди.

Кызны күндерделәр, ди. Бабайга:

— Ярый, бер хәл бардыр инде, бирәбез, — диделәр дә: — Кайчан бирнә туена киләсез? — дип сорадылар, ди. Бабай, көнен әйтеп, кайтып китте, ди.

Билгеләнгән көн килеп җитә. Үгез бара. Чәй эчәргә утыргач, бер дә коймак ашамый. Аның бер ягына печән, икенче ягына су куйдылар, ди. Ашады-эчте, ди, бу. Кызның бер бите кап-кара булды, ди.

Үгез:

— Мунча яксагыз, бер ялгаш су, бер бәйләм печән куегыз, — диде, ди. Мунчада ашап-эчкәч, кызның икенче бите дә кап-кара булды, ди.

Йокларга булгач, үгез, тиресен чишеп, түшәк астына кыстырган иде, күреп туймаслык матур егеткә әйләнде, ди. Кызның ике бите дә яктырып китте, ди.

Кыз иртәгәсен иртүк тора да үгезнең тиресен утка яга. Үгез, йокысыннан торгач та, тиресен таптыра кыздан. Кәләше:

— Утка яктым, — ди. Үгез:

— Әниеңә әйт, тимер таяк, тимер келәт эшләтсен. Тимер келәттән сөт елгасы агып торсын. Тимер таякка таянып елга буйлап бар. Юлда өч абыем очрар. Шуннан мине табарсың, — дигән дә аккош булып очып киткән дә барган.

Кыз елга буйлап юлга чыгып китте, ди. Бара торгач, егетнең олы абыйсына килеп җитте, ди. Кыз сәлам бирде, ди. Өлкән абый:

— Ул сәламең булмаса, уртага өзеп бер кабар идем, — дип каршы алды, ди.

— Капма, капма, киленсезгә килен булам, кызсызга кыз булам, улсызга ул булам, — дип әйтте, ди, кыз.

Ашатты, эчерде, кунак итте, ди, бу кызны. Бер кич

кунып, үгезнең уртанчы абыйсына китте, ди, кыз. Олы абыйсы:

— Анның сыерлары усал, сине кертмәсләр, — дип кызга азык биргән. Уртанчы абыйсына килеп җиткәч, сыерларына азык биреп, өйгә кереп китте, ди, сәлам бирде, ди.

— Шул сәламең булмаса, уртага өзеп бер кабар идем, — диде, ди, үгезнең уртанчы абыйсы.

— Капма, капма, киленсезгә килен булам, кызсызга кыз булам, улсызга ул булам, — диде, ди, кыз.

— Киленем юк, килен бул, — дип әйтте, ди, үгезнең уртанчы абыйсы. Кунак булып, бер кич куныл, ары китте, ди, кыз. Уртанчы ага:

— Кардәшемнең казлары усал, сине кертмәсләр, солы ал, — дип, солы биреп җибәрде, ди. Барып җиткәч, казларына солы сибеп, кереп китә, сәлам бирә.

— Шул сәламең булмаса, уртага өзеп кабар идем, — диде, ди, кызга үгезнең бу абыйсы.

— Капма, капма, киленсезгә — килен, кызсызга — кыз, улсызга ул булам, — диде, ди, кыз.

— Килен бул, — диде, ди, үгезнең өченче абыйсы.

Ага-энеле дүрт үгез шушында җыелган икән. Бал койдырып, аш салдырып, өчесе сунарга киткән. Дүртенчесе өйдә калган. Ул, бер уҗау бал эчертеп, бер кисәк ит ашатып, кызны сәндерәгә салып куйды, ди.

Тиздән, тегеләр, сунардан кайтып, ашарга утырдылар, ди. Олы абыйсы:

— Бер уҗау балым, бер кисәк итем юк, кем ашады? — дип сорады, ди.

— Белмим, үзең ялгышасыңдыр, кем тисен аңа! — диде, ди, өйдә калган туганнары. Үзе:

Изүемә карасам,
Хан кызының тегене.
Итәгемә карасам,
Хан кызының тегене, —

дип җырлап җибәргән, ди. Агалары:

— Кем ул хан кызы? — дип сорагач, бернәрсә дә эндәшмәде, ди. Олы абыйсы:

— Адәм исе чыга, өйгә адәм кергән, кем бар бездә? — ди.

— Кем булсын бездә, үзең адәм ашап йөрисең дә, шуңа ис чыга, — ди өйдә калганы. Кыз, бу сүзләрне ишетеп, акрын гына елап җибәрде, ди.

Иртән үгезләрнең өчесе, дүртенчесенә аш салырга, бал коярга кушып, сунарга киттеләр, ди. Өйдә калганы, кызны ашатып-эчереп, алар кайтуга тагы да сәндерәгә салып куйды, ди. Туганнары очып килеп төштеләр, ди. Ашарга утыргач, икенче ага:

— Бер кисәк итем юк, бер уҗау балым юк, кайда иттең? — дип сорады, ди.

Өйдә калган туганнары:

— Итеңне ким калдыргансыңдыр, ә балны көрәгә үзе эчә, шуңа кимегәндер, — ди. Шул җирдә үзе дә:

Итәгемә карасам,
Хан кызының тегене.
Изүемә карасам,
Хан кызының тегене, —

дип җырлады, ди. Олы агасы:

— Нинди хан кызы ул? Нәрсә дип җырлап утырасың? — дип сорады, ди. Хан кызы мич башында сулкылдап елады, ди.

Иртәгәсен өч туган, өйдә калган дүртенчесенә ике кисәк ит, ике уҗау балны артык салырга кушып, сунарга чыгып китте, ди. Болар киткәч, аш пешерергә калган үгез:

— Килен, бүген актык кичең. Менә сиңа ун аршин ефәк бирәм. Ирең булган үгез-егет үзеңне асарга, кисәргә итәр. Шулчакта ефәкне билеңә урарсың. Тирене утка яккан өчен ул синнән үч алырга тырышыр, — ди.

— Аның үгез тунын мин яктым, үзем гаепле, ни эш-

ләтсә дә эшләр. Буләгең миңа кирәкми, — дип әйтте, дию кыз. Шул җирдә әлеге үгез баягы ак егеткә әйләнде дә куйды, ди. Шуннан ирле-хатынлы бу икәү, ефәкне билләренә урап, хан өенә кайтып киттеләр, ди.

Рәхәт кенә гомер итә башладылар, ди, болар.

СӘФӘР

Борын-борын заманда Эйек елгасы буенда яшәгән, ди, бер карт белән бер әби. Аларның булган, ди, өч улы. Кече улы Сәфәр исемле булган. Карт белән әби бик картайган, уллары ир җиткән.

Бердәнбер көнне әби үлеп киткән. Менә үлем түшәгенә бабай да яткан. Картның булган, ди, ике аты, ике баш сыеры, кыексыз бер өе, янә киртә-куралары. Үләр алдыннан карт улларын чакырып ала да:

— Йә, балалар, мин бу дөньяны ташлыйм инде, минем кебек картаеп, бәхетле тормыш итүегезне телим. Шуннан, улларым, минем байлыгым күп түгел, шулай да булганын сезгә бүлеп бирмәкче булам. Сезнең арагызда талаш-бүлеш булмасын. Тәүдә сездән шуны сорыйм: зур улым, сиңа нәрсә кирәк? Байлыкмы, акылмы? — дигән. Зур улы:

— Минем үз акылым үземә җиткән, байлык кирәк,— дигән. Уртанчы улы да шул җавапны кайтара. Карт өченче улыннан сорый:

— Йә, иң кече улым, сиңа нәрсә кирәк, байлыкмы әллә акылмы?

Өченче улы:

— Мин байлык белән кайда барыйм? Миңа акыл кирәк, — дигән. Шул җирдә карт:

— Олы улларым, шушы байлыкны бүлешеп алыгыз, ә, Сәфәрем, сиңа акыл өйрәтәм. Син, мин үлеп киткәч, абыйларың белән хушлашып, чыгып китәргә тиешсең. Башың кайсы якка тели, шул якка кит. Олыларга кечелекле бул, сәламеңне бир, кечеләргә өлкән булырга тырыш. Юлыңда берәү җәфа чиксә, борылып үтеп китмә, аңа ярдәм ит. Шул акылны тотсаң, һәрвакыт бәхетле булырсың, дөньяда беркемнән дә ким-хур булмассың! — дип, картның әйтеп бетүе булган, үлеп тә киткән.

Картны кадерләп җирләп куйганнан соң, олы агалары ата малын бүлешеп, үзалдына дөнья көтә башлыйлар. Сәфәр, туып-үскән ата йортын ташлап, баш суккан якка чыгып китә. Йөри бу чит-ят җирләрдә. Тамагы ачыккан вакытта кармак белән балык тотып ашый. Шулай су буйлап йөргәндә, Сәфәргә бер балыкчы карт очрый.

— Йә, балам, ни эш бетереп йөрисең? Кайдан киләсең? — дип сорый карт.

Сәфәр:

— Мин, бабай, ерак яклардан киләм. Торыр урыным да, барыр җирем дә юк. Ул иткән кешегә ул булам, кол иткән кешегә кол булам, — ди.

Шулвакыт карт, көймәсеннән ярга чыгып:

— Улым, бик чирләп тә торам, көймәгә утырып, минем җылымнарымны карап чык әле, — ди. Сәфәр:

— Була ул, бабай! — дип көймәгә сикереп төшеп тә утыра.

Әмәлгә каршы, җылымнарга балык бик күп эләккән була. Сәфәр, ауларны карап беткәннән соң, ярга чыга. Бераз сөйләшеп утырганнан соң карт:

— Әйдә, улым, утыр көймәгә, ал ишкәкне, безгә барып тамак ялгап алыйк, — дигән.

Болар көймәгә утырып авылга кайтып китәләр. Кайтсалар, әбинең самовары гөрләп кайнап утырган була.

— Әйдүк, балам! Бабай, кунак алып кайткансың икән, — дип, ачык йөз белән каршы ала.

Карт белән Сәфәр, балыкларны урнаштырып, бит-

кулларын юып, чәй янына утыралар. Шулвакыт карт әбигә Сәфәрнең кайдан килеп чыгуын түкми-чәчми сөйләп бирә. Сәфәрнең теләген дә әйтә. Әби, бабайның уйлаган уен белгәндәй, болай дип әйтеп сала:

— Бабай, безнең улларыбыз юк бит, ул итик, — ди. Картның күңеле күтәрелеп, куанып китә. — Бердәнбер кызыбыз гына бар. Шушы айда ундүрт тулып, унбишкә китте. Исеме Зөләйха. Хәзер кайтыр, утын-фәлән алып кайтырга киткән иде, — ди.

Шулай дип әйтүе була, бер матур кыз килеп тә керә. Күрмәгән-белмәгән малайдан оялып, бераз тартынып тора.

— Менә бу егет синең абыең булыр, исеме Сәфәр, — ди әтисе.

Кыз, салмак кына атлап, килеп күрешә. Шуннан бөтен гаилә белән тәмләп утырып чәй эчәләр. Тамак туйдырганнан соң, Сәфәр:

— Йә, бабай, нәрсәләр эшлим? — дип сорый. Карт:

— Юк, балам, син бик йончыгансың, юынып, ял итеп ал, иртәгәдән эш башлап җибәрербез, — дигән.

Шулай итеп, Сәфәр, бабай кебек, балыкчы булып киткән.

Айлар, еллар үткән, Сәфәрнең унсигезе тулып, унтугызга киткән, Зөләйхага унҗиде яшь тулган. Сәфәр шулхәтле уңган егет булып чыга, авылдагы кызлар Сәфәрне телдән төшерми мактыйлар. Авыл арасында күпне күреп, күпне ишетеп йөргән әби бабайга:

— Сәфәрнең акыл-фигыле, уңганлыгы бөтен авылга билгеле. Үзен уллыктан кияү итү ягын карарга иде, — ди.

— Әнисе, кыз белән син сөйләш, ә егет белән мин үзем сөйләшермен, — ди бабай.

Балыкта йөргәндә сүз уңаенда сүз чыгарып, бабай үзенең теләген әйтә. Сәфәр:

— Мин, бабай, сезгә иң тәүдә күрешкәндә үк үземне

белдердем, сез ни теләсәгез, мин шуңа риза, тик кызыгыз риза булсын, — ди.

Балык тотып, эш бетереп кайтканнан соң, бабай әбигә:

— Йә, синең яктан эшләр ничек? Мин егет белән сөйләштем, егет риза, Зөләйха ризамы? — ди. Әби:

— Кыз һичбер тартынмыйча риза булды, — ди.

Шул көнне үк, кулларыннан килгәнчә туй ясап, кыз белән егетне өйләнештерәләр. Шуннан соң үзалдына хуҗа булып, рәхәт тормышта яши башлыйлар. Шулай яши торгач, карт белән әби дөньялыкны ташлап, үлеп китәләр. Зөләйха хуҗабикә булып, үз эшен үзе бетерә. Өй эшләреннән башка да Зөләйханың төрле-төрле һөнәрләре күп була. Ул төрле кул эшләренә бик оста була. Рәсемнәр төшерә, келәмнәр суга, төрле тастымал, ашъяулыклар эшли белә. Җәйнең иң ямьле айларында илнең бер үзәк каласында бер тапкыр ярминкә ачыла торган була. Зөләйха үзенең кул эшләрен елдан-елга җыеп килә. Беркөнне ул Сәфәрне үзенең кул эшләре белән ярминкәгә җибәрә.

— Әгәр бу әйберләрне кайдан алдың, кем эшләде дип сорасалар, чит илләрдән йөреп алып кайттым, дип җавап бир, — дип әйтеп җибәрә.

Берничә еллар буе Сәфәр шулай дип җавап бирә. Бердәнбер елны: «Нишләп мин үз хатынымның эшләрен яшерәм әле», — дип уйлый да дөресен әйтә. Шул җирдә Сәфәрне кулга алып, патша алдына китереп бастыралар. Патша:

— Бу әйберләрне синең хатының эшли икән, әйберләреңә күпме сорыйсың? — дип сорый.

Сәфәр, куркып-өркеп тормыйча, әйберләренең хакларын әйтә. Патша, карышып тормыйча, сораган хакны тулысынча түләргә боера. Бу егетнең кайдан икәнлеген белергә куша.

Сәфәр каладан баеп кайта. Сәфәрнең кулындагы байлыкны күреп, Зөләйха сораша башлый:

— Йә, ни хәлдә йөрдең? Минем сүзне тотмадыңмы, хатыным эшли белә дип мактандыңмы? — ди.

— Әйе, Зөләйха, хаталык миндә булды. Син әйткәнчә эшләмәдем, дөресен әйттем дә бирдем. Алданиләр булыр, ансын белмим, — ди Сәфәр.

— Ярар, Сәфәр, кайгырма, кулдан килгәнен эшләрбез, — ди Зөләйха.

Бердәнбер көнне Сәфәргә патша янына барырга боерык була. Сәфәр патшага барып керә. Патша:

— Менә, егет, сиңа минем әмер. Син миңа өч кыр аты тотып килергә тиешсең. Сиңа бер атна вакыт, — ди. — Шушы әмерне үтәмәсәң, хатыныңны тартып алам, үзеңә үлем җәзасы бирәм, — ди.

Сәфәр, ни эшләсен, тизрәк кайтып китә. Кайтып керүе була, Зөләйха:

— Йә, патша нинди бурыч бирде? — ди. Сәфәр:

— Патша бер атна эчендә өч кыр аты тотып алып килергә кушты. Алып килмәсәң, хатыныңны үземә алам, ә үзеңә үлем җәзасы бирәм, дип әйтте, — ди.

— Ярый, ят, йокла, кайгырма, берәр әмәлен табарбыз әле, — дип юата Зөләйха ирен.

Сәфәр иртәнчәк йокысыннан торса, өч ефәк йөгән әзер була. Иртәнге чәйне эчкәннән соң Зөләйха:

— Менә сиңа дару. Фәлән җирдәге фәлән чишмәгә бар, шул чишмәгә һәрвакыт кыр атлары килеп су эчәләр. Атларны тәүдә карап ят. Нинди вакытта төшеп су эчкәннәрен бел. Алар су эчәргә төшәр вакытлары җиткәч тә шушы даруны чишмәгә сибәрсең, үзең яшеренерсең. Атлар, суны эчәрләр дә, яр башына чыгып, һуштан язып тәгәрәрләр. Шулвакыт үзеңә өч ат сайлап алып, башларына йөгән кидереп, атлар аңына килгәнче, менә шушы камчы белән торгызып, ике атны ике аягыңа бәйләп, уртадагы атка үзең атланып, атлар кайда алып китә, шул якка атлар талчыкканчы җилдерә бир. Алар талчыккач, син кайда боерасың, алар шул якка китәрләр.

Шулай итеп, син ул атларны патшага алып барып тапшырырсың, — ди.

Сәфәр патша биргән бер атнаны бер тәүлеккә алдан үти. Патша, Сәфәрнең бу кыен әмерне үтәвенә хәйран калып, аптырап тора. Шул җирдә Сәфәр:

— Йә, патша, мин бушадыммы? — ди. Патша:

— Юк, егет, синең алдыңда үти торган тагы зур бер эш бар. Сиңа өч ел вакыт. Белмим — нәрсәне, алып кил шуны, — ди.

Сәфәр, берни төшенми, өенә кайтып китә. Зөләйхасы:

— Патша ни боерды? — дип сорый. Сәфәр патшаның боерыгын әйтә. Шуннан Зөләйха: — Ярар, кайгырма, ашап-эч, төн урталарына тиклем ял ит, — ди.

Төн урталары килеп җиткәч, хатыны Сәфәрне тәмле йокысыннан уятып, капчыкка Сәфәрнең көче җитәрлек азык-төлек тутырып, үзләре яшәгән Эйек елгасының яр башына алып чыгып китә. Әмәлгә каршы, төн бик матур, тын, ай якты була. Шулвакыт Зөләйха кулындагы алтын балдагын суырып алып, йөзек үтә әче итеп сызгырып җибәрә. Сызгыруы була, һавадагы кошлар, җир йөзендәге җанварлар, суда йөзгән терлекләр барсы да бер җиргә тупланалар. Һәркайсысы үзләренчә Зөләйхадан:

— Бездән сиңа ни кирәк? — дип сорыйлар. Зөләйха:

— «Белмим — нәрсәне, алып кил шуны» сүзенең мәгънәсен әйтегез, кем белә? — ди. Һавадагы кошлар:

— Без белмибез, — дип очып китәләр. Җир йөзендәге җанварлар да:

— Белмибез, — дип таралышалар. Судагы балыкларның берсе:

— Безнең бик күп яшәгән бер чуртан бабаебыз килеп җитә алмыйча артта калды, бәлки, ул белер, — ди.

Чуртан килеп җитә. Зөләйха белән Сәфәр чуртаннан:

— Әй, чуртан, «Белмим — нәрсәне, алып кил шуны» сүзенең мәгънәсен әйт әле безгә, — диләр. Чуртан бабай:

— Юк, балалар, белмим мин аны. Шушы Эйек буйлап

бик озак барсагыз, бер яшел өй күрерсез. Шул өйгә кереп, яшел өстәл астына кереп утырыгыз да нәрсә булганын күзәтегез. Шуннан ни эшләргә кирәген үзегез белерсез,— ди.

Сәфәр, Зөләйхасы белән хушлашып, берүзе генә юлга чыгып китә. Бик озак барганнан соң, бер яшел өй күренә. Шул яшел өйгә керә, бөтен булган нәрсәләрне карап чыга. Бер як читтә бер яшел таяк, яшел чикмән, яшел эшләпә, яшел чабата элүле торган була. Ә өйнең уртасында яшел эскәтер ябылган өстәл, яшел утыргыч. Сәфәр, уйлап-нитеп тормый, чуртан әйткән буенча, өстәл астына кереп утыра. Бик нык арыганлыктан, ачыкканлыктан ул йокыга тала. Ишек ачылуга сискәнеп, уянып китә. Ни күзе белән күрсен, бер ак сакаллы карт килеп керә. Ул яшел әйберләрне киеп, яшел таякны кулына алып, яшел утыргычка килеп утыра да:

— Үзбәк, ашамак-эчмәк кирәк, — ди. Шулвакыт өстәл өстендә төрле-төрле ашамлыклар барлыкка килә.

Сәфәр моңа бик нык аптырый. Бабай шултиклем комсызланып ашый, хәтта Сәфәрнең дә ашыйсы килеп китә, ләкин тыела. Бабай ашап бетеп, калганнарын кесәсенә тутырып, кигән киемнәрен салып чыгып китә. Сәфәр өстәл астыннан чыгып, әлеге яшел киемнәрне киеп, яшел өстәл артына килеп утыра да:

— Үзбәк, ашамак-эчмәк кирәк, — ди. Шулвакыт тәмле ашамлыклар барлыкка килә. Сәфәрнең берүзенең генә ашыйсы килми. Ул:

— Әй, Үзбәк, кил минем яныма, икәү бергәләп ашасак, яхшырак булыр. Бу тиклем ашамлыкны ничек итеп ашап бетмәк кирәк, — ди. Әйтеп бетүе була, Үзбәк күренә дә:

— Хөрмәтле егет, сезнең шултиклем яхшылыгыгыз өчен зур рәхмәт. Мин сезнең кебек кешеләрне гомеремдә күргәнем булмады. Менә яңа ашап чыккан карт шултиклем комсыз, кайсывакыт ике өстәл ашамлык сорап ашап чыгып китә, — ди.

Сәфәр белән Үзбәк сүз куешып, бергә чыгып китәләр. Әй баралар, әй баралар, бер комлык җиргә килеп чыгалар. Яңа гына ком бураны булып басылган чак була. Якындарак кына кеше тавышлары ишетелә. Шул тавыш чыккан якка китәләр. Барсалар, кешеләр үзләренең дөяләрен, иптәшләрен ком арасыннан казып алып йөриләр. Боларны ком бураны басып киткән була. Бу кешеләр, сәүдә итеп, байлык төяп кайтып килгән булалар. Алар бик ачыккан, сусаган булалар. Ашарларына да беткән була. Сәфәр боларның яннарына бара да:

— Сезгә су кирәкме? — ди.

Кешеләр ни эшләргә белмиләр, бу кеше алдыйдыр, юри бездән көләдер дип, Сәфәрне тукмамакчы булалар. Шулмәл Сәфәр:

— Менә шушы җирдән су чыгарга тиеш, сез аны киңрәк итеп казыгыз, — ди.

Тегеләр әй казыйлар, әй казыйлар, су чыкмый да чыкмый, казучылар бик нык арыйлар. Сәфәр болай ди:

— Тәүдә үзегез эчәсезме, әллә дөяләрегезне туйдырасызмы?

— Үзебез ничек булса да түзәр идек әле, тәүдә дөяләребезне эчерер идек, — диләр кәрванчылар.

— Ярый алай булгач, барыгыз, дөяләрегезне алып килегез, — ди. Үзе, тегеләр дөяләрен алып килгәнче, яшел эскәтерне түшәп: «Үзбәк, дөяләргә эчәргә су кирәк», — ди. Шулвакыт казыган җирдән су атылып килеп чыга. Кешеләр дөяләрен эчерә башлыйлар, үзләре дә ятып эчәләр. Суга туйгач, кешеләр ял итәргә яталар. Барысы да йоклап беткәч, кәрван хуҗасы Сәфәргә:

— Әйдә, дус кеше, синең шушы Үзбәгеңне бер тылсымлы сандыкка алышыйк, аңа өстәп кыйммәтле товарлар, иң көчле дөямне бирәм. Бу Үзбәк белән минем дөяләрем бервакытта да сусамаслар, — ди.

— Үзбәк риза булырмы икән? — ди Сәфәр. Үзбәк үзенең ризалыгын белдерә. Сәфәрнең үзенә ишетерлек итеп кенә:

— Мин риза, син дә риза бул. Мин барыбер сиңа әйләнеп кайтырмын, — ди.

Сәфәр, серле сандыкны алып, дөягә атланып, байлыкны төяп кайтып китә. Кайтып барышлый, кәрван хуҗасыннан алган товарларын ярлыларга өләшә. Хатыны аны ачык йөз белән каршы ала. Теге сандык эчендә коралланган солдатлар була.

Сәфәрнең чыгып китүенә өч ел тулып, дүртенче елга китә. Патша Сәфәрне алып килергә әмер бирә. Сәфәр:

— Патшага мин кирәк икән, патша үзе килсен, — ди.

Солдат патшага кайтып әйтә. Патша ачуыннан ни эшләргә белми, тагы да өч коралы солдат җибәрә. Сәфәр теге серле сандыктан өч солдат чыгара да:

— Бер солдатын качырыгыз, ә ике солдатын кулга алыгыз, — ди.

Качып котылган солдат, патшага кайтып, нәрсәләр булганын сөйләп бирә:

— Аларның солдатлары бар, атсаң да, чәнечсәң дә үлмиләр, — ди.

Патша ни эшләргә белми, бик күп гаскәр җибәрә. Сәфәрнең исе китми, үзе рәхәтләнеп ишек алдында эшләп йөри, ә сандыктан чыккан гаскәр патшаның солдатларын кыйрата. Чөнки Сәфәр, дөнья гизеп, «Белмим — нәрсәне, алып килгән шуны».

Патша яңадан гаскәр җибәрә. Сәфәрнең солдатлары тагы да патша гаскәрләрен кыйраталар. Патшаның үзен кулга алып, үлем җәзасына хөкем итәләр.

Шулай итеп, патшаны үтереп, илне дан кылып, үзе патша урынына кала.

ТИМЕРКАЗЫК

Булган, ди, заманында бер Тимерказык исемле егет. Әти-әнисе булмаган. Берүзе яшәгән. Бервакыт ул бәхет эзләргә чыгып киткән. Юлда ике егетне очраткан. Алар да бәхет эзләп йөри икән. Икәүдән өчәү яхшы булыр дип, бергә киткәннәр.

Әй киткәннәр болар, әй киткәннәр, килеп чыкканнар бер елганың буена. Шул урында очраган бер мосафир. Башына чалма, өстенә чапан кигән, кулында ак таяк булган.

— Оланнар, кая барасыз? — дип сораган мосафир.

— Бәхет эзләргә, — дигәннәр.

— Бәхетне табарга теләсәгез, бу елганы төнлә аша чыкмагыз, — дигән дә карт юк булган.

Ике егет елга аша чыгып киткән. Тимерказык, картның сүзен тыңлап, елганың бу ягында торып калган. Кунарга булган, урман читенә барып яткан. Төн уртасы җиткәч, дүрт кеше килә, ди. Дүртесе дә ак киемле, ди. Җирне казып, нәрсәдер күмделәр дә ары киттеләр, ди.

Тимерказык таң атуга килә дә чокырны ача. Ачып җибәрсә, табут, ә аның эчендә бер сылу кыз ята. Тәнендә җиде җәрәхәт була. Егет кызның авызына пыяла кисәге куя, пыяла тирли. Егет кызның тере икәнен белә. Тимерказык, балык тотып, мае белән кызны дәвалый. Кыз терелә, тора да егеткә:

— Мин киенеп беткәнче, тал арасына кереп тор, — ди. Киенеп беткәч, кыз:

— Безгә елганы аша чыгарга вакыт җитте, — ди. Чыгалар. Егеткә кыз бер пакет бирә дә:

— Нәрсә телисең, шул алдыңа килер, — ди.

Тимерказык бер каланың хуҗасы булып ала. Төрмәдәге кешеләрне барсын да үзе карап чыгара. Шулар арасында теге ике иптәше дә була. Аларны үзенә ярдәмче итеп ала.

Бервакыт бу илнең патшасы Тимерказыкның шулай

баеп, чибәр кыз белән торуы хакында ишетеп кала да аңа шарт куя:

— Үти алсаң, хатының үзеңдә калыр, үти алмасаң, хатыныңны мин алам, — ди. — Никто дигән нәрсәне тап, — ди.

Тимерказык уйга кала, юлга әзерләнә башлый. Шулчак хатыны:

— Кайгырма, — ди дә иренә бер пакет биреп, юлга озата.

Егет әй бара, әй бара, диңгезләр, таулар үтә. Бер сазлыкта аждаһа очрый. Егет пакетны бәреп җибәрә, аждаһа җиңелә.

— Егет, кайда телисең, шунда алып барам, — ди. Тимерказык:

— Никто дигән нәрсә янына алып бар, — ди.

Очып китәләр. Алда бер ком тавы тора, ди. Шунда туктыйлар. Егет тауга менә алмый. Шулчак бер бака килә дә:

— Баштүбән тор, — ди. Тимерказык баштүбән торса, тауга менеп тә җитә. Менсә, бер өй тора, өйгә керә, уртада өстәл тора, ди. Тимерказык:

— Никто, ашарга китер! — ди. Шунда ук өстәл тулы ашамлык була. Ашап туйгач, егет:

— Рәхмәт, — ди. Шул җирдә бер кыз тавышы ишетелә:

— Моңа тиклем миңа беркем дә рәхмәт дигәне юк иде, мине үзең белән алып кит, — ди.

Тимерказык кызны үзе белән ала да әй киләләр, әй киләләр. Егет:

— Ачыктым, Никто, ашарга, — дисә, шунда ук бер өстәл ашамлык килеп утыра, музыка уйный башлый.

Килә торгач, Тимерказык белән кыз бай сәүдәгәрләргә очрыйлар. Байлар аптырап калалар:

— Никтоны безгә сат, — диләр. Күп итеп акча, алтын бирәләр. Тимерказык:

— Сатмасаң, болар барыбер талап алырлар, — ди дә Никтоны бирә.

Сәүдәгәрләр баралар, бер җирдә туктыйлар да ашарга утыралар. Ашап туялар да тагы китәләр. Бара бирәләр дә тагы ашарга утыралар. Бервакыт тып-тын, өстәл дә, музыка да юк.

Рәхмәт әйтә белмәгәч, сәүдәгәрләрдән качып, Никто Тимерказыкка кире килә. Егет кайта, патшага бара. Патша:

— Кайда Никто? — ди.

Тимерказык Никтоны патшага бирә дә:

— Никто, ашарга китер, — ди. Өстәл тулы ашамлык килеп утыра, музыка уйный башлый. Патша:

— Алай булгач, үз хатының үзеңә булсын, — ди.

Тиздән патша картаеп үлеп китә, бөтен байлыгы Тимерказыкка кала. Әле дә ул муллыкта дөнья көтеп тора, ди.

СОНТАЙ ЕГЕТЕ

Элекке заманда Сонтай дигән авылда бер карт белән бер карчык булган. Алар кетмердәп, ярлы гына көн иткәннәр. Ашыйм дисә, туйганчы ашарга азыгы, киим дисә, рәтле киемнәре булмаган, ди, боларның. Аларның бар шатлыгы — Янсары исемле бердәнбер уллары булган.

— Ичмасам, шушы балабыз ир җитсә, бәлки, без дә адәм рәтле көн итәр идек, — дип, әби белән бабай күңелләрен юатыр булганнар.

Әмма аларга бу көткән шатлыкларын күрергә туры

килмәгән: Янсары ундүрт яшенә җитеп, кул арасына керә башлаган чакта гына икесе бер төптән үлгән дә киткәннәр.

Янсары, нишләмәк кирәк, үзалдына дөнья көтә башлаган. Башта ялгызына бик кыен булган егетнең: нәрсәгә тотынса, шул кулыннан төшеп бара, көн елый, төн елый. Азак: «Тукта, болай ярамый, булмаса, сунарга барып кайтыйм әле, берәр җай чыкмасмы икән?» — дигән уйга килгән бу. Әйткән сүз — аткан ук, ярты эшләнгән эш. Янсары күп итеп тозак ясый да яланга чыгып китә.

Төрле җәнлекләр күбрәк йөри торган уңайлы урынны чамалап, өч тозак сала бу. Әләгер булса, шул өч тозак та җитәр әле дип уйлап, егет авылына таба уңайлый. Кайтып килә ятса, моңа бер карт тап була да:

— Нихәл, улым, әллә тозаклар кордыңмы? — дип сорый.

— Әйе, бабай, тозаклар корган булган идем шул, — ди Янсары.

— Ә соң, улым, тозагың артып калмадымы, мин дә тозак кормакчы булган идем, — ди карт.

— Калды, бабай, эшләгән әзер тозакларым да калды, — ди дә егет калган барлык тозакларын картка бирә дә куя. Карт аңа рәхмәтләр әйтеп, яхшы теләкләр теләп, үз юлына, егет үз юлына табан китеп бара. Бара торгач, егетнең башына келт итеп бер уй төшә: «Бәй-бәй, бик ипле генә карт булды түгелме соң әле бу? Исемен дә сорамадым. Безнең авылда андый карт юк, якын-тирәдә дә күргән-белгән кешемә охшамый...»

Янсары, аны янә күрмәкче булып, артына борылып караса, карт инде күз күреме җир китеп өлгергән була.

Янсары өенә кайтып җитә. Инде күптән караңгы төшкән. Тамагына ашар иде, локма кабым азыгы юк. Шуннан ни бу, төлке сымак кына бөгәрләнеп ята да, бар кайгысын онытып, йоклап китә.

Иртәнчәк бик иртә уяна бу. Караса, тышта эре кар явып үткән, көн җылы, чалт аяз. Ул тиз генә киенә дә

тозакларын карап кайтырга йөгерә. Аягы тигән җиргә — тия, тимәгән җиргә тими йөгерә ул. Кичәге урынына барып җитеп караса, бер тозагына куян эләгеп яткан. Булды бу! Ул куянны ботыннан тотып биленә бәйли дә икенчесенә йөгерә. Килсә, анысында ап-ак тамаклы, йоны кып-кызыл уттай янып торган төлке эләккән. Менә бәхет! Шатлыктан егетнең түбәсе күккә тигәндәй була. Өченче тозак янына кайсылай барып җиткәнен дә тоймый кала ул. Азакты тозагына караса, ни күзе белән күрсен, монсына бик сылу бер кыз эләккән. Ә кыздан арттарак, борынын карга тыгып, күзен бәзрәйтеп, бер эт шыңшып ята, ди. Кыз елап егеткә инәлә башлый.

— Егет, ычкындыра күрче, тозакка каптым бит әле мин, — дип әйтә, ди. Егет башта бик куркып, каушап кала. Мондый хәл бер дә күз күргән, колак ишеткән нәрсә түгел бит. Шулай да куркуын җиңеп, кызны ычкындырган бу тозактан. Караса, кызның бәләкәй генә чанасы да бар икән.

Кыз, тозактан ычкынгач, өстен-башын каккалый да, яшьле күзләрен сөртә-сөртә:

— Рәхмәт инде, егет, коткардың бит. Шуның өчен әйдә, үзеңне бер рәхәтләндереп йөртим. Чанама утыр, — ди. Янсары кыяр-кыймас кына килеп чанага утыра. Шуннан болар кар бураны туздырып таудан төшеп китәләр. Чана күз иярмәслек шәп шуа, ди. Теге эт, телен аркылы тешләп, чак артыннан өлгерә, ди.

Менә болар тау астына төшеп җитәләр. Егет: «Төшим әле. Чананы тау үренә сөйрәп мендерергә кирәк», — дип уйлап бетерергә дә өлгерми, чана үзеннән-үзе артка борыла да тау үренә табан җилдерә башлый. Эт тә болар артыннан бер тотам калмый, ди.

Егет бу эшкә шаккаткан. Тау үренә менеп җиткәч, ул инде ни эшләргә белми тора икән, моңа кыз карап елмая да:

— Тозакка эләктердең бит. Хәзер мин — синеке, син — минеке. Әйдә, өенә кайтыйк, — ди. Болар кабаттан чана-

та утыралар да, кар бураны туздырып, авыл ягына карап чыгып китәләр. Егет кызга:

— Шушыннан, шушыннан, — дип, юлны күрсәтеп кенә бара, ди.

Авылга җитә башлагач, егет эченнән генә: «Ул алама йортка бу сылу кызны ничек алып керермен дә тамагын нәрсә белән туйдырырмын?» — дип уңайсызлана башлый. Менә болар чажылдатып ишек алдына килеп керәләр. Егет үзенчә хөрмәт итеп, кызны өенә алып кергән була. Керсәләр, өй эче шундый ярлы, үгез мөгезенә элеп чыгарырлык чүпрәк-чапрак заты юк, ди. Егет, оялышыннан кызга күтәрелеп карарга да кыймый, авыз эченнән генә мөңгерди:

— Тукта әле, мин күрше-күләннең хәлен белеп килим әле, — дигән сылтау белән, икмәк эзләргә чыгып киткән.

Егет, кичкә кайдандыр икмәк табып, өенә кайтып керсә, өй эче гөлт итеп җыештырылып куелган, ди. Ул түшәмгә тиклем өеп куелган урын-җир нәрсәләре, асыл келәмнәр күзнең явын алып тора, ди. Тәрәзә төпләрендә гөлләр хуш ис бөркеп, күпереп чәчкә атып утыралар, ди. Егетнең, моны күргәч, исе-акылы киткән. Аның аптыравын күргәч, кыз аңа:

— Егетем, мин синең хәлеңне белмәгән идем, оялып әйтмәгәнсең икән. Моннан соң без ару яшәрбез, ни теләсәң, шул булыр, — ди.

Шуннан соң болар утырып, бер туйганчы тамакларына ашыйлар, үпкәләрен йөздергәнче чәй эчәләр. Шушы көннән башлап алар бик тату дөнья көтеп китәләр. Егетне базарга җибәреп, кыз үзенә ошаган әйберләрне алдыра. Хәзер инде боларның җитешмәгән нәрсәләре юк, бер итеп дөнья көтәләр. Күрше-күләннәрен җыеп, кунак итәләр болар. Егет белән кызның җитеш дөнья көтүләренә шакката халык. Аннан бигрәк аларның тигез-тату торуларына сокланып, сөйли-сөйли авыз сулары корый кешеләрнең.

Сонтай егетенең сылу хатын алып, бик яхшы торып

ятуы хакындагы хәбәр патшага барып җитә. Патша: «Дөньяда миннән дә яхшы яшәүче кеше булмаска тиеш!» — дип, бик ачуланып, хәзер үк Сонтай егетен үз каршысына китерергә боера. Аның яраннары шунда ук Янсары янына чабып килеп җитәләр. Егет бик каты куркуга төшә бу хәбәрдән. Бармый калырга ярамый инде патша каршысына, юкса ул халык алдында башыңны чабачак яки терелә утка салачак. Патшаның тәртәсе бик кыска, кулы каты.

Китә егет патшага.

Барып җитеп сарайга кергәч, патша аңа күтәрелеп тә карамый.

— Сонтай егете Янсары синме? — дип сорый.

— Әйе, мин, — ди егет.

— Хатының да бармы?

— Бар.

— Икәүдән-икәү генә торасызмы?

— Әйе.

Шулай итеп, патша, егеттән энәсеннән-җебенә тиклем барын төпчеп сорашып беткәч:

— Мин сине шуңа чакырттым, — ди, — сиңа бер уч тары бирәм, шуны иртәгә ялан тутырып чәчеп кайт. Әгәр шушы әмеремне төгәл үтәмәсәң, башыңны кисәрмен!

Кулдан килмәслек эш кушып, егетнең башына җитмәкче була инде бу. Егет моны төшенеп, ни дип әйтергә дә белми, авыз эченнән генә мыгырдап тора бирә. Шуннан соң патша:

— Бар, күземә күренмә, кушканны эшлә! — дип аяк тибеп җикергәч, ике-өч тупсаны бер атлап, йөгереп чыгып китә егет.

Ул, өенә кайткач, бик пошынып, кайгысын кәләшенә сөйләп бирә.

— Әй, юк хәсрәткә кайгырасың икән дә, — ди кәләше. — Бер кочак себерке, көрәк, чатлы-потлы агачтан сука яса да ятып йокла. Иртән торуыңа эш беткән булыр.

Ятып йоклаганнар болар. Иртәнчәк кәләше Янсары-

ның билен буып, битенә әз-мәз туфрак сөртә дә әлеге этне ияртеп патшага җибәрә.

— Барып җиткәч, патшага әйт: кушкан эшең үтәлде, диген. Әгәр ул, чәчкән җиреңне карыйм, дисә, эт кайда илтә, шуның артыннан ияреп бар, — ди.

Егет патшага барып, кушкан эшен җиренә җиткергәнлеген хәбәр итә. Патша бу сүзгә капыл гына ышанып җитми, яраннарын карап кайтырга җибәрә. Егет тә болар белән бергә чыга. Эт капкадан чыккач, койрыгын бутый да бер якка карый чыгып китә. Егет тә, патша яраннарын ияртеп, шул якка уңайлый. Барып карасалар, ялан тутырып тары чәчелгән, тырмалган, барлык эше җиренә җиткерелгән. Яраннар шунда ук кайтып патшага моны хәбәр итәләр. Патша, моны ишеткәч, ни эшләсен инде, мыегын тешләде дә куйды, ди.

Егетнең ал да гөл булып торуы турында хәбәр авылдан-авылга, илдән-илгә таралып, патшага һаман да җан тынычлыгы бирми. Бер ун көннәр үткәч, егетне янә чакыртып ала да бу:

— Минем ун сыерым бар иде, барсы да бертөсле — гел күк сыерлар. Шулар, менә ел тула инде, курага кайтмый, азып йөри. Шуларны эзләп алып кайт. Әгәр табып кайтмасаң, башыңны кисәрмен! — ди.

Янсары өенә бик пошынып кайтып, кәләшенә:

— Бу патша, ахры, минем башыма җитмәкче буладыр, — дип, аның нәрсә кушканын елый-елый сөйләп бирә. Кәләше аңа:

— Алай булгач, бар, патшадан бер өч көн вакыт сора, берәр әмәлен табарбыз, — ди.

Егет барып, патшадан өч көн вакыт сорап кайта. Шуннан болар очына тимер куеп торып озын кыл чыбыркы үрә башлыйлар. Чыбыркы үрелеп беткәч, кәләше:

— Эткә ияреп урманга бар, сыерларны шунда табарсың, — ди. — Тик сыерларны сарай янына куып китергәч, патша үзе чыгып карасын. Ул чыккач, сыерларга тартам дип селтәнеп, патшаның үзенә дә чыбыркың белән каеш-

тырганчы берне эләктереп ал. Аның сыер дигәне — аю булыр, — ди.

Менә өченче көн җитә, егет урман ягына китә. Ә теге эт ду итеп урманны кыдырып, аюларны куып чыгара да бер җиргә тупларга тотына. Егетнең үзенә эш тә юк, аюлар ун башка тулгач, егет һай-һау килеп, чыбыркысын шартлатып, боларны патша сараена табан әйдәп китте, ди. Патшаның яраннары тавышны ишетеп, йөгерешеп тупса төбенә чыкканнар.

— Менә алып кайттым, патша үзе сыерларын барлап карасын, — ди егет.

Патша да сарайдан килеп чыга. Кинәт шулвакыт, егет, чыбыркысын шартлатып, аюларны курага куа башлый. Кура бүрәнәләренең черегенә бал кортлары ияләшкән икән. Алар, аюларның исен тоеп, аяусыз чагарга тотыналар. Кайсы җирең генә кычый! Аюлар акырып, күзләре аларып, курадан качып чыга башлагач, Янсары, аларны таркатмыйм дип, чыбыркысы белән селтәнгән арада патшага да яхшы гына итеп берне тамызып ала. Патша һецк итеп җиргә утыра да:

— Куй, егет, мин сынар өчен генә әйткән идем. Алып китә күр аюларыңны, дөньямны харап иттермә! — дип ялына башлады, ди. Янсары:

— Юк, үзең куштың бит, куып китердем, миннән бурыч төште, теләсәң кайда куй аларны, — дип, һаман үзенекендә тора бирә, ди. Азак, патша бик нык ялына башлагач кына, ул аюларны шарт та шорт сугып, куып алып киткән.

Инде болай да эш чыкмагач, патша үзенең бер яранын чакырып алып, бу егет белән нәрсә эшләү турында киңәш кора башлаган. Күрәсең, яраны патшадан акыллырак булгандыр инде. Ул әйткән:

— Әй патшам, — дигән, — син аңа бар белән юкны алып килергә куш. Ул аны барыбер таба алмаячак. Шулай итеп без аның башына җитәрбез, — дигән.

Бу киңәшкә патша бик куана да Сонтай егетен янә

үз янына чакырта. Егет килә. Тыныч кына көтә патша әмерен.

— Егет, — ди аңа патша, — миңа бар белән юкны алып кил. Әгәр табып китермәсәң, үзеңне юк итәрмен!

— Барын табармын инде, — ди егет, — ә менә югын кайдан алырга?

— Ансында минем эшем юк, — ди патша, — теләсәң ни эшлә!

Янсары, йөзе кара коелып, өенә кайтып керә. Кәләше шунда ук аңлый аның хәлен: янә авырлык килгән. Егет патша әмерен сөйләп биргәч, кәләше:

— Авыр эш кушкан, — ди. — Ярар, кайгырма, үтәрбез. Тик син, патшага кабат барып, кырык көн вакыт бирүен сорап кайт.

Егет барып, патшадан кырык көн вакытка рөхсәт алып кайта. Шуннан соң кәләше суган суы белән каен тузына бер хат язып биргән. Туз туз инде — ап-ак. Тик аны кояшка тотсаң гына укып була.

— Менә шушы хатны, — дигән ул, — этиемә бирерсең, ул сиңа кирәк нәрсәңне табар.

— Ул мине танымас бит, — ди егет.

— Таныр, — ди кәләше. — Синең белән этебез дә барыр. Аны күргәч, синең үз кияүләре икәнлегеңне белерләр.

Шуннан соң егет юлга чыгып китә. Әй бара бу, әй бара, эт тә аннан бер тотам да калмый. Бара торгач, болар адәм аяк басмаган, кошлар гына очып килә торган бер караңгы урманга килеп җитәләр. Ул арада булмый, төн җитә, коеп яңгыр ява башлый. Инде нәрсә эшләргә, күзгә төртсәң күренмәслек караңгы. Аптырый егет. Эт, бернәрсәгә карамый, урманга керә дә китә. Егет белә бит инде аның артыннан калмаска икәнен, эт артыннан иярә. Урман эченнән бара торгач, болар зур бер диңгез читенә килеп чыгалар. Диңгезнең очы-кырые күренми. Шуннан соң эт аны бер биек тирәк төбенә китерә. Бу тирәк шултиклем биек, очы күккә олгашкан, ди, күтәрелеп кара-

сац, кәпәч төшеп китә, ди. Болар тирәк төбенә килеп туктагач, көчле җил-давыл күтәрелеп китә. Ул арада булмый, тирәк, тамыры актарылып, диңгез өстенә ава, эт шушы тирәкне буйлап ары китә башлый. Билгеле, егет тә аннан калмый инде. Әй баралар, әй баралар, диңгезнең аръягына чыгып җитә язалар. Тик шунысы: тирәкнең очы чак кына диңгез ярына җитми икән. Шуннан аның бер ботагын сындырып алып басма салалар да син дә мин аръякка чыгып җитәләр болар.

Чыгып җитсәләр, диңгез аръягы җәйрәп яткан матур тигез ялан, ди. Егет бу яланның күркенә сокланып бетә алмый. Дөньяда юк чәчкәләр бар, ди, монда. Болар, шушы ялан буйлап бара торгач, бик матур кырыккатлы бер йорт эргәсенә килеп җитәләр. Шунда ук эт өйгә керә дә китә. Ул арада булмый, эткә ияреп, йорттан алты яшьлек егермеләгән бала килеп чыга. Алар барсы да бер тиң, берсеннән-берсе сылу, бертөсле үк киенгәннәр, ди. Болар егетне күргәч:

— Әй, җизнәбез килгән! Җизнәбез килгән! — дип куанышырга тотынганнар.

— Тик, җизнәй, — дигәннәр алар, — өйгә кермә, этнебезнең бик ачулы чагы.

Егет риза булган моңа: балалар аны икенче җиргә алып китәләр.

— Бер дә башка йорт күренми ләбаса, болар кайда алып баралар икән, — дип, егет бераз куркуга төшә. Эт һаман койрыгын болгый, балаларның аяк астында уралып, уйный бирә, ди. Шуннан егет тә тынычлана. Бара торгач, болар җиргә чокып ясалган бик матур капка төбенә килеп җитәләр. Балалар шул капкадан кереп юк була башлыйлар. Егет тә алар артыннан төшә. Төшсә, ни күзе белән күрсен, җир астында искитмәле матур йорт, ди. Бу йорт эчендә зык кубып, тегеләре сымак, бәләкәй генә кырык бала уйнап йөри, ди. Болары да, Янсарыны күргәч:

— Җизнәбез килгән! Җизнәбез килгән! — дип, чәбәкәй итеп, ыргып төшәләр, ди.

— Тик, — диләр алар, — җизнәй, син шушыннан чыкмый тор, без башта әтиебезгә үзебез хәбәр итик, шуннан күрештерербез.

Ярар, балалар чыгып китәләр дә аталары янына барып:

— Әти, җизнәбез килгән, апабыздан хат бар. Җизнәбез белән этебез Коткармас та килгән, — дип хәбәр итәләр.

Бу, йөз кырык яшьлек карт, дию пәриләренең әтисе икән. Хатны алып укыгач, кызын бәладән коткаручы егет — үз кияве икәнен белгәч, карт дию:

— Барыгыз, монда китерегез, күрим, — ди.

Шуннан балалар, кабат теге җир асты сараена киләләр дә Янсарыны үзләренчә киендереп, әтиләре янына алып баралар. Карт дию кияүне кадерләп каршы алып, үз эргәсеннән урын бирә дә дөнья хәлләрен сораша башлый. Янсары бөтен күргән-белгәннәрен сөйләп биргәч, аңа:

— Мин киявегез булам инде. Менә Коткармас белән кунакка килдек, — ди.

— Ярар, яхшы булган, — ди карт дию. — Тик әйт әле, кияү: нәрсә әче, нәрсә йомшак, нәрсә каты? — ди. Бу бит инде кияүне сынамакчы була. Янсары азрак кына уйланып тора да:

— Әчесе анының, каенатам — алама сүз; йомшагы — ана куены; катысы — ил ачуы, — ди.

— Кашка ир икәнсең, кияү, мең яшә! — ди карт, киявеннән бик риза була. Шуннан болар өч көн, өч төн буена туй итәләр, кунак булалар.

Туй беткәч, Янсары каенатасына, сүзнең җаен китереп:

— Якты йөзең, сый-хөрмәтең өчен рәхмәт. Минем бер йомышым бар иде бит әле: бар белән юкны ничек итеп табарга икән? — ди.

— Ярар, балам, — ди карт, — бәлки, ул шушында гынадыр, карап карыйк, — ди дә, сәке астыннан бер сумка тартып чыгара. — Тик юлда аны ача күрмә, бар белән юкны таптырган кеше янына баргач кына ач.

Егет тагы берничә көн кунак булгач, сумканы култыгына кыстырып, кайтып китә. Инде утыз тугыз көн дигәндә ул өенә кайтып җитеп, бер кич өендә йоклый да патша каршысына бара.

— Йә, — ди патша, аны күргәч, — бар белән юкны алып килдеңме?

— Алып килдем, — ди Сонтай егете, — менә ачып кара.

Патшага сумканы тоттыра да бу, үзе чыгып китми, ишек төбендә карап тора башлый. Патша этләнеп, нәрсә барлыгын күрергә ашкынып, сумканы ача. Ачса, сумка эчендә тагы бер сумка бар, ди. Патша ансын да ача. Эчтәге бәләкәй сумканы да ачкач, аннан кигәвен зурлыгы гына кош сыман бернәрсә очып чыга да зырлап әйләнеп, патшаның башын үтә тишеп чыгып, күздән югала. Шул җирдә патша, тынын да ала алмый, егылып үлә.

Әкият шушы җирдә тәмам. Бар чагында — бәйрәм, юк чагында — әйрән. Әкиятем ошаса, ярат, бүтәннәргә тарат; ошамаса — юкны таптырма, башны катырма.

КАРА КӨЧЕК

Борын-борын заманда бер бай яшәгән. Аның дүрт хатыны булган. Берчак бай ерак сәфәргә җыена башлаган. Юлга чыгар алдыннан, иң олы бичәсен чакырып:

— Йә, хатын, мин ерак сәфәргә китәм, мин кайтуга ни эшләрсең? — дигән.

— Йөз кабыргалы тургай атып, йөз хезмәтчеңне туйдырырмын, — дип җавап биргән бичәсе.

Бай икенче хатынын чакыртып алган да:

— Йә, хатын, мин ерак сәфәргә чыгам, мин кайтуга ни әзерләп куярсың? — дип сораган.

— Комнан итек сугып куярмын, — дип җавап биргән монысы.

Бай өченче хатыныннан да шуны ук сораган.

— Бет тиресеннән бияләй тегеп куярмын, — дигән бу хатыны.

Бай дүртенче, иң яшь бичәсен чакырып алган:

— Йә, хатын, мин ерак сәфәргә юл тотам. Мин әйләнеп кайтуга ни әзерләп куярсың? — дип сораган.

— Алтын башлы, энҗе тешле, көмеш чәчле ике ул табармын, — дип җавап биргән яшь хатын.

— Хуш, — диде, ди, бай.

Бай юлга чыгып киткәч, көн артыннан төн килеп, төн артыннан көн килеп, вакыт үтеп кенә тора, ди. Иң олы хатын көн дә бер тургай атып, йөз хезмәтчене туйдыра; икенче хатын комнан итек сугарга җыена; өченчесе бет тиресеннән бияләй тегә, ә дүртенче хатын алтын башлы, энҗе тешле, көмеш чәчле ике ул таба. Бермәл өч хатын бергә җыелышып, сөйләшергә тотына. Иң олысы:

— Көн дә йөз кабыргалы тургай атып, йөз хезмәтчене туйдыру, комнан итек сугу, бет тиресеннән бияләй тегү эшмени ул?! Бай кайтса, безгә ачуланыр, әйдәгез, яшь кәнтәйнең балаларын югалтыйк, — дип, тегеләрне котыртырга тотынды, ди.

Иртәгәсен болар иң яшь көндәшләрен, кырык хезмәтчегә кушып, урманга җибәрәләр. Балаларын биябәр арасына ташлап чәңгелдәккә * бер көчек салып куялар. Хатын, урманнан кайткач, оланнарының югалуына кайгырып, елай-елый, кара көчекне имезеп салды, ди.

Иртәнчәк иртә беләп торып, бия саварга чыкса, бер

* *Чәңгелдәк* — бишек.

бия юк, ди. Эзләп караса, бер бия ике малайны имезеп ята икән. Хатын малайларны кертеп, кара көчекне чәңгелдәктән төшереп җибәргән.

Моны күреп торган өч көндәш: «Малайларны бияләр таптап үтермәгән. Иртәгә без аны печәнгә җибәрик», — дип киңәш корышкан.

Иртәгәсенә, хатынны печәнгә җибәргәч, малайларны, әйдә, сөзеп үтерсеннәр, дип, сыерлар арасына ташлыйлар. Яшь хатын печәннән кайтса, малайлар юк, алар урынына чәңгелдәктә әлеге кара көчекне күрә. Хатын, елыйелый, көчекне имезеп, йокларга ята. Иртәгәсен торып сыер саварга чыкса, бер сыер ике малайны имезеп ята, ди. Хатын оланнарын алып кире урыннарына салып куя. Болай да эш чыкмагач, өч хатын:

— Әйдәгез, моны без урманга җибәрик, малайларын каздан талатып үтертик, — дип сүз куешты, ди. Хатын киткәч, малайларны казлар арасына чыгарып ташлыйлар. Хатын кайтып килсә, малайлар юк, чәңгелдәктә әлеге көчек ята. Елап-елап көчекне имезә.

Иртәнчәк казларга җим салырга чыкса, бер каз ике баланы ике канаты астына салып яткан, ди. Хатын оланнарын сөеп-сөеп кире чәңгелдәккә салып куя.

Инде болай да эш чыкмагач, өч хатын:

— Әйдәгез, инде без аларны суга ташлыйк, — дип сүз беркетә.

Иртәгәсенә хатынны печәнгә җибәреп, малайларны суга ташлыйлар. Малайлар бер чумып, бер калкып, тешләре, чәчләре ялтырап агып китәләр. Хатын кайтып, көчекне имезә дә, караңгы төшкәч, йокларга ята.

Тиздән бай үзе кайтып төшә. Олы хатынын чакыртып алып:

— Йә, мин кайтканчы ни эшләдең? — дип сорау бирә.

— Син кайтканчы, көн дә бер тургай атып, йөз хезмәтчене туйдырдым, — ди хатын.

Бай икенче хатынын чакыртып ала да шушы ук сорауны бирә.

— Менә, ханым-солтаным, сиңа сугып куйганмын, — дип, ком итекләрне такылдатып утыртып куйды, ди, моның алдына. Өченче хатынны чакыртса, ансы, бет тиресеннән тегелгән бияләйләрне шап-шоп сугып:

— Менә, ханым-солтаным, сиңа салып куйганмын, — дип китереп бирде, ди. Бай дүртенче хатынын чакыртып ала:

— Йә, хатын, мин киткәндә биргән вәгъдәңне ничек үтәдең? — ди. Хатын эндәшми-нитми басып тора бирә. Шулчак теге өч бичә:

— Менә, син кайтуга кара көчек табып куйды, — дип, чәңгелдәктән көчекне алып күрсәтә. Бай шул җирдә сикереп торып, хатынның бер кулын, бер аягын сындырып, бер күзен чокып алды да:

— Фәлән җирдә, кырык тау аша кара урман эченә ишеге, тәрәзәсе булмаган өй салып, көчеге белән шунда илтеп бикләгез! — дип әмер бирә. Хезмәтчеләр бай кушканны эшлиләр.

Көн үтә, көн артыннан төн үтә, төн артыннан ай үтә, кара көчек эт булып җитә. Беркөн кара көчек нигез буен казый башлый. Нигез астыннан кереп, тышка чыгып утырды, ди.

— Әни, әни, бер кеше килә, — ди көчек кеше тавышы белән.

— Килсен, килсен! Йодрык сыешлы тишек уеп биреп китәр, ичмасам, — ди хатын.

Кеше килеп җитә, җиткәч, сәлам бирә.

— Байга юл эзлим, белмисезме? — дип сорый.

— Беләбез, беләбез, тик йодрык сыешлы тишек уеп бир, — ди хатын. Кеше өйнең төньягыннан йодрык сыешлы тишек уеп биргәч, кара көчек аны юл күрсәтеп алып китте, ди.

Тиздән байга барып җитәләр. Кара көчек, юлчының аягына уралып, сиздермичә генә өйгә кереп, ишек астына поса.

— Йә, мосафир, ишеткән-күргәнеңне сөйләп утыр,— ди бай.

— Ишеткәнне сөйләсәм, ялган булыр, күргәнне сөйлим әле. Кырык тау артында, кара урман уртасында бер өй бар икән. Ишеге дә, тәрәзәсе дә юк икән. Шуңа йодрык сыешлы тишек уеп биреп киттем. Менә шуның кара көчеге алып килде әле,— ди юлчы.

— Алай икән,— диде дә бай тәһарәт алырга чыгып китте, ди. Шулчак байның олы хатыны килеп керде дә:

— Авызың җәеп, юкны сөйләп утырасың. Бер күл буенда алтмыш колач ала бия бар, атлаган саен колынлый; су эчсә, күлнең суын бетергәнче эчә; йокласа, чалт төш мәлендә йоклый. Байга без шуны да әйтмибез,— дип, юлчыны әрләп ташлый.

Бай керергә дип ишекне ачкан иде, кара көчек өйдән чыгып та качты, ди. Хатын тик яза-йоза сугып калды, ди. Көчек чабып килеп җитә дә:

— Әни, әни! Миңа ефәктән нукта ишеп бир,— ди.

— Аны ни эшләтәсең? — дип сорый хатын.

— Фәлән күлнең буенда алтмыш колач ала бия бар, шуны алып киләм,— ди көчек. Хатын нукта ишеп биргән. Кара көчек чыгып киткән.

Көчек күл буена барып җитсә, алтмыш колач ала бия күл буенда йоклап ята, ди. Көчек, сак кына барып, йөгәнне кидереп, биянең җилкәсенә менеп утырган да аның колагын тешләгән. Бия ыргып торып, көчекне бер күккә, бер җиргә ыргыта башлый. Ахырда көчекне чөеп төшерә алмагач, тынып кала. Көчек бияне җитәкләп алып кайтып китә. Бия атлаган саен колынлый, колыннары ияреп килә, ди. Өйләренә килеп җиткәч, колыннары белән өй тирәсен ике-өч мәртәбә уратып ташлады, ди. Өй түгәрәге елкы белән тулды, ди.

Көчек тагы да тышка чыгып утыра.

— Әни, әни, бер кеше килә,— ди, еракта бер карачкыны күреп.

— Килсен, килсен! Тәрәзә уйдырып алып калырбыз, ичмасам, — ди әнисе.

Тиздән теге карачкы килеп җитеп:

— Сәлам бирдек, — дигән.

— Алдык, — дигән тишектән хатын.

— Мине байга алып барыр кеше булмасмы икән?

— Булыр, булыр, минем кара көчегем алып барыр. Тик безгә тәрәзә уеп биреп кит, — дигән хатын. Юлчы тәрәзә уеп биргән. Аннан көчек юлчыны байга алып киткән.

Тиздән барып җитәләр. Юлчы байның бүлмәсенә керә; беркемгә дә күренми, юлчының аягына ураланып, көчек тә керә.

— Йә, мосафир, ишеткән-күргәнне сөйләп утыр, — ди бай.

— Ишеткәнне сөйләсәм, ялган булыр, күргәнне сөйлим. Фәлән җирдә, кырык тау ашасында, кара урман эчендә, бер өй бар. Ул өйдә бер хатын белән кара көчек яши. Аларның алтмыш колач ала биясе бар, атлаган саен колынлый. Өй әйләнәсе елкы өере белән тулган. Шуларга тәрәзә уеп биреп киттем әле. Шул хатынның кара көчеге сезгә юл күрсәтеп килде, — ди.

Бай:

— Алай икән, — дип, тәһарәт алырга чыгып китте, ди. Бай чыгып киткәч, байның икенче бичәсе килеп кереп:

— Авызың җәеп, юкны сөйләп утырасың. Фәлән тауның башында гәүһәр-якутлар бар. Без шуны да әйтмибез әле аңа, — ди.

Бай ишекне ачкан иде, көчек чыгып та тая. Теге бичә:

— Һи, хәшәрәт! — дип яза-йоза сугып кала.

Көчек, җан-фәрман чабып, өенә килеп җитә дә:

— Әни, әни! Миңа ашъяулык бир, — ди.

— Ни эшләтәсең аны?

— Фәлән тауда гәүһәр-якутлар бар икән, шуны китерәм.

Кара көчек чыгып китә. Тиздән тауга барып җитеп, гәүһәр-якутлар белән ашъяулыкны тутырып кайтып килә.

Китереп, өйнең эчен дә, тышын да яктыртып ташлый.

Көчек өй алдына чыгып утырган иде, тагы да бер кеше килә, ди.

— Әни, әни, бер кеше килә, — ди көчек.

— Килсен, килсен! Ишек уйдырып алып калырбыз, ичмасам, — ди хатын.

— Сәлам бирдек, — ди юлчы.

— Алдык, — ди хатын.

— Мине байга алып барыр кеше булмасмы? — ди юлчы.

— Булыр, булыр, тик безгә ишек уеп кына биреп кит инде, — ди хатын.

Юлчы, ишек уеп биргәч, кара көчек белән бергә байга юл тоттылар, ди. Тиздән байга килеп җитеп, барып керәләр. Көчек беркемгә дә күренми генә, сәке астына кереп ята.

— Йә, мосафир, ишеткән-күргәнеңне сөйләп утыр, — ди бай.

— Ишеткәнемне сөйләсәм, ялган булыр, күргәнемне сөйлим. Фәлән җирдә, кырык тау артында, кара урман эчендә бер өй бар. Анда бер хатын белән көчек яши. Аларның атлаган саен колынлый торган алтмыш колач ала биясе бар. Өй тирәсе елкы белән тулган. Өйнең эчетышы гәүһәр-якут ташларга күмелгән. Шул өйнең көчеге юл күрсәтеп килде әле, — ди.

Бай:

— Алай икән, — дип, тәһарәткә чыгып китте, ди. Бай чыгып китү белән, аның өченче хатыны килеп керде дә:

— Авызың җәеп, юкны сөйләп утырасың. Фәлән суның буенда алтын башлы, энҗе тешле, көмеш чәчле ике малай бар. Чалт төш вакытында судан чыгып, комда уйныйлар. Уйнап арыгач, комда ятып йоклыйлар. Без байга моны да әйтмибез әле, — дип шарлады, ди.

Бай керергә ишекне ачкан иде, көчек чыгып та качты, ди. Теге хатын карганып, яза-йоза гына сугып калды, ди.

Көчек җан-фәрманга чабып кайтып:

— Әни, әни! Миңа ак киез, дүрт мөгезгә сөт савып бир. Берсе — кәҗә, икенчесе — сыер, өченчесе — бия, дүртенчесе үзеңнең сөтең булсын, — ди.

Көчек ак киез, дүрт мөгез сөт алып чыгып китә. Тиздән елга буена барып, ак киезне җәеп, дүрт мөгезне дүрт почмакка утыртып, үзе читтән яшеренеп кенә карап ята башлый. Чалт төш вакыты җиткәч, судан ялтырап, алтын башлы, энҗе тешле, көмеш чәчле ике малай килеп чыкты да яр буендагы комда уйный башладылар, ди. Уйный торгач, киез өстенә килеп меңәләр. Капыл мөгезләрне күреп, бер мөгездәгесен эчеп карыйлар.

— Эм-м-м, монсы кәҗә сөте, монсы сыер сөте, монсы бия сөте, — дип, өч мөгездәгесен эчкәч, дүртенче мөгездәге сөтне эчеп карадылар да: — Монсы әниебезнең сөте, — дип елап-елап, кояш җылысында йомшак киездә йоклап киттеләр, ди.

Малайлар йоклап киткәч, кара көчек, киезнең дүрт почмагыннан тешләп алды да чабып кайтып китте, ди. Килеп, киезне җәеп җибәрсә, хатын аптыравыннан коелып төшә. Киездә аның ике улы ята.

Шулай төн үтә, көн үтә, көн артыннан ай үтә, малайлар ел үсәсен көн үсеп, зураеп китә.

Беркөн малайлар:

— Әни, безнең әтиебез бармы? — дип сорый.

Әнисе:

— Бар, ул бай, аның өч хатыны бар, — дип башыннан үткәннәрне сөйләп бирә.

— Әни, әни, без аны чакырыйк, — ди малайлар.

— Килмәс, мине бер каһәрләп ташлагач, килмәс, — ди әниләре.

Шулай да байны чакырырга булалар. Чакыручы итеп кара көчекне җибәрәләр. Көчек байны кунакка чакыргач, бай:

— Үзегездән миңа җиткәнче гәүһәр-якутлардан юл салыгыз. Сөт, бал елгалары агып, кошлар сайрап торсын, — дигән.

Көчек малайларга килеп, байның сүзләрен әйткәч, ике малай аптырашта калдылар, ди. Шулчак көчек:

— Кайгырмагыз, барсы да эшләнер, — дип, үзе ашъяулыкны алып гәүһәр-якутлар ташырга тотына. Малайлар юл салалар. Таң атуга барсы да әзер була. Кара урман эченнән кырык тау аша байның өенә тиклем гәүһәр-якутлардан кылдай туры юл салына. Аның ике ягыннан сөт, бал елгалары ага, сандугачлар сайрап тора, ди.

Бай йокысыннан торса, барсын күреп хәйран кала, хәтта чак-чак кына һушыннан язмый кала. Аннан үзенең хатыннарын алып, кунакка китә. Аны алтын башлы, энҗе тешле, көмеш чәчле ике егет белән аларның әнисе каршы алалар. Байның һушы китеп, егылып барып төшә. Аннан, исенә килгәч, сорашып, барысын да төшенгәч, олы хатынын чакыртып ала да:

— Сиңа тугыз кысыр бия кирәкме әллә тугыз арба утын кирәкме? — дип сорый.

— Тугыз арба утын нәрсәгә кирәк, тугыз кысыр бия булса, суеп, итен ашап ятармын, — ди олы хатын. Бай тугыз бияне тотып, хатынны тугызының да койрыгына бәйләп, бияләрне дулаткан да җибәргән. Хатынның аркасы тигән җирдә арка тавы, чәче тигән җирдә чәчле тумар, күзе тигән җирдә күл барлыкка килгән.

Бай икенче хатынын чакыртып алган да шул ук сорауны биргән.

— Тугыз бия нигә кирәк, тугыз чана утын булса, кыш көне ягып рәхәт итәрмен, — ди хатын.

Бай тугыз арба утын кистереп, бер җиргә өйдергән дә, өстенә хатынны бәйләп утыртып, ут төрткән. Хатынның көле күккә очып, кара болытка әйләнгән, ди.

Өченче хатынын чакыртып алып, бияләр койрыгына бәйләп җибәрде, ди. Үзе оланнар, зәгыйфь хатыны белән торып калды, ди.

Әкиятем китте таш йөкмәп, үзем калдым аш йөкләп.

ТӨЛКЕ БЕЛӘН ТОРНА

Урманда йөри торгач, төлке белән торна дуслашып киткән. Төлке торнаны кунакка чакырган. Ботка пешергән дә тактага салып, юка гына итеп сылап куйган, шуннан:

— Аша, аша, дус, — ди икән. Ә торна, бахыр, чукышлары белән тактаны тукылдатып чокып караса да, бер дә эләктерә алмаган. Шул арада төлке ботканы ялап та куйган.

Торна төлкене үзенә кунакка чакырып кайткан. Торна ботка пешереп, үзе тирән, үзе нәзек муенлы чүлмәккә салып куйган.

Торна төлкегә:

— Аша, аша, дустым, — ди икән. Төлке күпме генә тырышмасын, нәзек муенлы чүлмәктән ашый алмаган. Ач көе утырган. Ә торна үзе, башын чүлмәккә тыгып җибәрә дә, тыгына да тыгына икән. Ботканы ашап беткәч, торна:

— Төлке, кунакка чакырып, тактага сыланган ботканы үзең ашап бетердең, ә мин карап утырдым. Мин дә сине шулай сыйларга булдым. Хәйләгә каршы хәйлә, ашка аш белән, ташка таш белән булсын, — дигән.

БАТЫР ЕГЕТ — ИЛ КҮРКЕ

УРАЛ БАТЫР

Борын-борын заманда, Урал тавы да, Агыйдел дә әле юк чакта, шыр урман эчендә яшәгән, ди, бер бабай белән бер әби. Озын гомер иткәч, әби үлеп киткән, ә бабай берсе Шүлгән, икенчесе Урал исемле ике үсмер улы белән торып калган, ди.

Бабай сунарга йөргән, ә Шүлгән белән Урал өйдә калыр булган. Аю дисәң — аюны, бүре дисәң — бүрене, арыслан дисәң — арысланны тере көе тотып алып кайтуны бабай уенга да күрмәгән, ди, — ул шулай көчле булган. Ни өчен дисәң, бабай сунарга гел генә бер кашык ерткыч җәнлек каны эчеп китә икән. Шул канны эчеп алдымы — аңа әнә шул ерткычның көче өстәлер булган.

Йола буенча, ерткыч киекне үз кулы белән үтергән кешегә генә аның канын татып карарга яраган. Шуның өчен бабай үзенең улларына: «Кечесез әле, киек ауларга яшегез җитмәгән; миннән күрмәкче турсыктагы канга авызыгызны тидерәсе булмагыз тагын — һәлак булырсыз», — дип, гел генә искәртә торган булган.

Бердәнбер көнне, аталары сунарда чакта, Шүлгән белән Урал янына бик сылу бер хатын килгән дә:

— Әтиегез белән бергә сунарга йөрмичә, нигә өйдә утырасыз? — дип сораган, ди.

Шүлгән белән Урал:

— Йөрер идек тә, әтиебез алып бармый, яшегез җитмәгән әле, дип, өйдә калдыра, — дигәннәр, ди.

Шуннан соң теге хатын:

— Өйдә утырып, яшь җиткереп буладыр шул! — дип көлгән, ди.

— Ә нәрсә эшләргә соң?

— Әнә, турсыктагы канны эчәргә кирәк, — дигән, ди, теге хатын. — Шуны бер генә кашык эчеп алдыңмы — бер көн эчендә үк ир җиткән егеткә әйләнәсең, арысландай көчле буласың.

Шүлгән белән Урал:

— Әтием кан салынган турсык янына якын барырга да кушмады. Эчсәгез — һәлак булырсыз, диде. Без әтиебезнең сүзен тотабыз, — дигәннәр, ди.

Шуннан теге хатын:

— Сез кечкенәсез шул әле. Әтиегез ни әйтсә, шуңа ышанасыз, — дигән, ди. — Бу канны эчсәгез, сезгә арысландай көчле егетләргә әверелеп, рәхәтләнеп сунарга йөрергә, әтиегезгә өй саклап утырырга туры килә. Менә шуны белеп алган да, әтиегез турсыктагы канны үзе генә эчеп йөри, ә сезгә күрсәтми дә... Ихтыяр үзегездә, әйттем дә беттем, — дип, теге сылу хатын юк та булган, ди.

Бу хатынның әйткәненә ышанып, Шүлгән канны тәмләп карамакчы булды, ә Урал, әтисенең сүзен нык тотып, канга якын да бармады, ди.

Шүлгәннең турсыктан бер кашык канны алып йотуы булды — аюга әверелүе булды, ди. Шунда ук теге сылу хатын кереп, Уралга:

— Менә күрдеңме — туганың ни эшләде! — дип сыны катып көлә икән, ди. Үзе шунда ук: — Хәзер мин аны бүре ясыйм! — ди икән.

Хатын аюның маңгаена бер чирткән иде — теге бүрегә әйләнде, ди. Бүренең маңгаена бер чирткән иде — арыслан булды, ди. Шуннан теге хатын әнә шул арыс-

ланга атланып алды да үз юлына чаптырып чыкты да китте, ди.

Бу хатын дигәнебез юха елан булган икән. Сылу хатын кыяфәтенә кергән әнә шул юха еланның хәйләсе аркасында Шүлгән үзенең кешелеген гомергә югалтып, киек булып калган; бер карасаң — аю, икенче карасаң — бүре яки арыслан булып йөргән-йөргән дә, йөри торгач, бер күлгә батып үлгән, ди.

Ә Урал тиңдәше юк батыр егет булып үсеп җиткән. Ул, әтисе кебек, сунарга йөри башлаган мәлдә генә тирәякны үлем куркынычы чолгаган: күлләр, елгалар корыган, үләннәр кипкән, агач яфраклары саргаеп беткән. тын алуы авырлашкан. Кешеләр үлгән, маллар кырылган. Дөньяны кыдырып, бөтен тереклекне корытып йөргән Әҗәлгә каршы беркем берни эшли алмаган.

Урал батыр Әҗәлнең үзен тотып үтерү хакында хыяллана башлаган, ди. Әтисе аңа үзенең атасыннан калган, селтәгәндә яшен утлары чыгара торган алмаз кылычын биргән дә:

— Бу кылыч белән бөтен нәрсәне кыйратып була, тик Әҗәлне генә үтереп булмый. Шулай да син аны ал, кирәге булыр, — дигән. — Кайдадыр, бик еракта Тересу дигән бер чишмә агып ята икән. Әнә шул Тересуның бер тамчысы үлеп ятканны терелтә, авырып ятканны савыктыра, ә Әҗәлне үтерә икән. Әҗәлне шул чишмә суына салырга кирәк. Аннан котылу өчен башка әмәл юк, — дигән, ди.

Урал әтисе биргән кылычны тагып, башы суккан якка чыгып китте, ди. Әй китте, әй китте, ди, бу, бара торгач, җиде юл чатына килеп чыкты, ди. Шунда ул, бер картка тап булып:

— Бабай, Тересу чишмәсенә кайсы юл белән барырга? — дип сорады, ди. Бабай җиде юлның берсен күрсәткәч, Урал батыр:

— Ә ул моннан еракмы, ничә көнлек юл? — дип сорады, ди.

Шуннан бабай:

— Ансын инде, балам, мин әйтә алмыйм. Кырык ел буе мин шушы җирдә узгынчыларга Тересу юлын күрсәтеп торам, иллә мәгәр шушы гомер эчендә аннан әйләнеп кайткан бер кешене дә күргәнем юк әле, — дигән, ди. Моңа өстәп, бу бабай янә шулай дигән: — Улым, бераз баргач, елкы өеренә очрарсың, шул өердә бер Акбүзат булыр. Булдыра алсаң, шуны менеп ал.

Урал батыр, бабай белән хушлашып-аманлашып, Тересу юлы белән китеп барды, ди. Китә торгач, теге бабай әйткән елкы өеренә барып чыкты, ди. Караса — елкы өере арасында:

Башы йөгән күрмәгән,
Сыртына ияр тимәгән;
Колагын бездәй кадаган,
Ялын кыздай тараган;
Карчыга түш, тар бөер,
Җиңел, текә тояклы;
Сарымсактай азаулы,
Урае куш, яңагы ач,
Кыйгыр-бөркет сабаклы;
Муеннары бер колач,
Кыйгач камыш колаклы;
Кысыр елан тамаклы;
Алгыр бүре күзедәй,
Күз бәбәген чылатыр;
Җилсә, коштай җилпенеп,
Артында чаң уйнатыр
Акбүзат тора иде, ди.

Урал Акбүзатка исе китеп карап торды-торды да әкрен генә янына барды, ди. Акбүзат бер борылып карады да ятсынмый-нитми тик торды, ди. Шуннан Урал җәһәт кенә Акбүзне менеп алып, чаптырып китмәкче булган иде, Акбүз, ачуланып, Уралны шулкадәр биеккә чөеп

җибәрде, ди, кем, теге атылып төшеп, биленә кадәр җиргә батты, ди. Урал тырышып-тырмашып баткан җиреннән чыкты да яңадан Акбүзатка барып атланды, ди. Акбүз Уралны янә чөеп җибәрде, ди. Бу юлы Урал җиргә түбыктан батты, ди. Ул тагын тырышып-тырмашып тора салды да янә Акбүзгә атланып, аңа талпан сыман ябышып алды, ди. Акбүз күпме генә тырышмасын, бу юлы өстендәге Уралны очыртып төшерә алмады, ди. Шуннан Акбүз Уралны баш тарткан якка карап, җилдереп алып чыкты да китте, ди.

Әй бара, ди, Урал, әй бара, ди. Озын-озын яланнарны, тау-таш җирләрне, чокыр-чакыр урыннарны үтте, ди. Бер кара урманның уртасына җиткәч, Акбүз туктады, ә Урал, ни булды икән, дип, җиргә сикереп төште, ди. Шулвакыт Акбүз, телгә килеп: «Без хәзер Тересу юлын бүлеп ятучы тугыз башлы дию пәрие янына килеп җиттек. Сиңа аның белән алышырга туры килер. Ялымнан өч бөртек кылымны алып кал. Кирәк булсам, шуларны өтәрсең дә, мин килеп җитәрмен», — дип әйтте, ди.

Урал Акбүзнең өч бөртек кылын өзеп алды, ә Акбүз шунда ук юк та булды, ди.

Урал, ни эшләргә, кая барырга, дип аптырап торганда, аркасына авыр капчык аскан бик сылу бер кыз узып барганын күреп калды, ди. Урал, кызны туктатып:

— Әй, сылу, кая китеп барасың? Капчыгыңда нәрсә ул, бик авыр күренә? — дип сорады, ди.

Шуннан кыз елый-елый үз кайгысын сөйләп бирде, ди. Каракаш исемле бу кызны күптән түгел генә дию урлап алып килеп, үзенә кол иткән икән. Каракаш, тугыз башлы диюнең тугыз баласына уйнар өчен, иртәдән кичкә чаклы елга буеннан чуерташ ташый икән. Урал, кызны җәлләп китеп:

— Кая, сылу, капчыгыңны үзем күтәрим, — дигән иде, Каракаш аңа:

— Юк-юк, егет, минем белән бергә барасы булма, дию

сизеп калса, үзеңне шунда ук юк итәр бит! — дип әйтте, ди.

Әммә Урал, үзенекен итеп, таш тутырылган капчыкны тугыз башлы диюнең тугыз баласы җыелышып торган урынга хәтле күтәреп барды, ди. Уралның ташны җиргә куюы булды — дию балаларының бер-берсенә таш атышып уйнап китүләре булды, ди. Алар атышып уйнаган арада Урал якындагы бер карама ботагына бау белән ат башы хәтле бер таш асып куйды да үзе, качып-посып кына, дию яшәгән мәгарә алдына үтеп китте, ди.

Дию балаларының уеннары озакка бармады — ташлары төрле якка атылып, югалып бетте, ди. Шуннан алар озын бау белән карамага асып куелган зур ташны күреп калып, шуның тирәсенә җыелдылар, ди. Берсе, кызык күреп, ташны атындырып җибәргән иде, таш кире килеп, тегене сугып екты, ди. Дию малае егылган урыннан ачуланып тора салып, ташны бөтен көче белән очырта суккан иде, таш бу юлы дию малаеның башын яра сугып ук куйды, ди. Башы ярылган туганының үчен алмак булып, ташны диюнең икенче малае сугып җибәрде, ди. Ләкин ансы да шунда ук башы ярылып, җан бирде, ди. Тугыз башлы диюнең тугыз баласы шушылай берсе артыннан берсе кырыла торсын, без диюнең үзенә күчик әле.

Юлның тауны кисеп үткән җирендә генә, бер караңгы мәгарә алдында, тугыз башлы дию ята иде, ди. Тирә-юне адәм сөякләре белән тулы, ди. Урал батыр ерактан ук:

— Әй, дию, юл бир, мин Тересуга китеп барам! — дип сөрәнләде, ди.

Дию моңа бер дә исе китми генә, юлга аркылы төшкән көе ята бирде, ди. Урал батыр янә: «Юл бир!» — дип кычкырган иде, дию, ачуы килеп, Уралны тыны белән үзенә тартып ала башлады, ди. Урал батыр дию кырына килеп басканын сизми дә калды, ди. Шулай да кяушап калмады, гайрәтен җыеп, диюгә эндәште, ди:

— Алыштанмы, чабыштанмы?

Дию, мондый кыю егетләрне бик күп күреп тә, моңача һич тә җиңелмәгәнлектән, бер дә исе китми генә:

— Минем өчен барыбер. Ничек үләргә телисең, шулай булсын, — дип җавап кайтарды, ди.

Шуннан болар тауның иң калку җиренә менеп алдылар да тирләп-пешеп көрәшә башладылар, ди. Әй көрәшәләр, әй көрәшәләр, ди, болар, көрәшә торгач, төш авып, көн кичкә сарыкты, ди. Менә берзаман дию Уралны күтәреп алып ыргытты, ди. Урал биленнән җиргә батты, ди. Шуннан дию аны баткан җиреннән тартып чыгарды да янә көрәшә башладылар, ди. Дию Уралны янә атып бәрде, ди. Бу юлы инде Урал муеныннан җиргә батты, ди. Дию аны ике колагыннан тотып тартып чыгарды да яңадан көрәшә башладылар, ди.

Әй көрәшәләр, әй көрәшәләр, ди, болар, көрәшә торгач, кич булып эңгер төшә башлады, ди. Менә берзаман әллә кем булып ирәеп йөргән диюне Урал җилтерәтеп тә алды, атып та җирбәрде, ди. Дию биленнән җиргә батты, ди. Шуннан Урал аны баткан җиреннән тартып чыгарды да янә көрәшә башладылар, ди. Бу юлы дию муеннан җиргә батып, тугыз башы тугыз якка карап серәеп калды, ди. Урал диюне тартып чыгарды да яңадан көрәшә башладылар, ди. Дию алан-йолан каранырга да өлгермәде, Урал аны капыл элеп алып, җан ачуы беләк шулхәтле атып бәрде, ди, дию җиргә сеңде дә куйды, ди. Явыз диюнең башына кыямәт килүе шул булды, ди.

Каракаш, бичара егетнең сөякләрен җыеп алып, күмеп куярга дип, тау башына менсә, Уралны сау-сәламәт көе күреп, шатлыгыннан елап җибәрде, ди. Шуннан ул, бөтенләй гаҗәпкә калып:

— Дию кая китте соң? — дип сорады, ди.

Урал батыр:

— Диюне мин җиргә сеңдерә суктым, — дип әйтеп тә өлгермәде, алар басып торган урыннан өч-дүрт адым гына читтәрәк бөркелеп-бөркелеп төтен күтәрелеп чыкты, ә төтен артынан ялкын чыга башлады, ди.

Моны күреп, Каракашның:

— Бу ни хәл? — дип соравына, Урал батыр:

— Мин шушы урында диюне җир астына тыккан идем. Җир бу хәшәрәтнең үләксәсен үзенең куенына алудан җирәнде, күрәсең. Менә шуңа күрә ул янып, төтене чыгып ята, — дип җавап бирде, ди.

Бу тау шушы януыннан туктамас булды, ди. Шул көннән алып аны Янгантау * дип йөртә башладылар, ди.

Диюның башына җиткәч, Урал батыр бу тау башында озак тормады, ди, кесәсеннән теге өч бөртек кылны алып өтүе булды — Акбүзатның каршыга тып итеп килеп басуы булды, ди. Шуннан Урал батыр, Каракашны үзе белән бергә ат өстенә утыртып, Тересу юлы белән чаптырып китеп тә барды, ди.

Әй баралар, ди, болар, әй баралар, ди. Озын-озын яланнарны, таулы-ташлы җирләрне, чокыр-чакыр урыннарны үттеләр, ди. Бара торгач, Акбүзат туктады да телгә килеп: «Без хәзер Тересуга якынлаштык. Ләкин аның юлын унике башлы дию пәрие бүлеп ята. Сиңа аның белән алышырга туры килер. Ялымнан өч бөртек кылымны алып кал. Кирәк булсам, шуларны өтәрсең дә, мин килеп тә җитәрмен», — дип әйтте, ди.

Урал Акбүзнең өч бөртек кылын өзеп алды, ә Акбүз шул арада юк та булды, ди. Шуннан Урал Каракашка:

— Син шушы җирдә мине көтеп тор, диюнең башына җиткәч, килеп алырмын. Менә сиңа кураемны калдырам. Юлым уңса, курай очыннан сөт тамар, уңмаса, кан тамар, — дип, дию белән алышырга китте, ди.

Менә алда Тересу челтерәп агып ята, ди. Ул таудан агып чыга да шунда ук әллә кая, җир астына китеп юк та була икән. Тересуны өем-өем адәм сөякләре уратып алган, ди. Авыруны савыктыра, сауны үлемсез итә торган бу

---

* *Янгантау* — Башкортстанның Салават районында. Биредә хәзер авыруларны җирдән чыккан җылы пар белән дәвалый торган шифаханә урнашкан.

чишмәне, бер тамчы суын дә бирмичә, унике башлы карт дию үзе саклап ята икән. Урал батыр күз күреме җирдән үк:

— Әй дию, юл бир, мин Тересу алырга килдем! — дип сөрәнләде, ди.

Дию, бер дә ыжламыйча, Тересу алдында кузгалмый ята бирде, ди. Урал батыр янә: «Юл бир!» — дип кычкырган иде, дию, ачуы килеп, Уралны тыны белән үзенә тартып ала башлады, ди. Урал батыр дию каршына килеп басканын сизми дә калды, ди. Шунда да каушап калмады, баягыча гайрәтләнеп:

— Алыштанмы, чабыштанмы? — дип әйтте, ди.

Дию мондый кыю егетләрне байтак күреп тә, моңача һич тә җиңелмәгәнлектән, бер дә исе китми генә:

— Минем өчен барыбер. Ничек үләргә теләсәң, шулай булсын, — дип җавап кайтарды, ди. Урал батыр:

— Ярый, алай булса, — дип, билендәге алмаз кылычын суырып алып, уңлы-суллы чатрашлап селтәнгән иде, тирә-якка яшен утлары чәчелеп китте, ә диюнең күзләре шуннан чагылып торды, ди. Урал: «Ярый, алай булса», — дип, янә бер тапкыр әйтте дә кылычы белән диюне туракларый да башлады, ди; кылыч селтәнгән саен, диюнең унике башының берсе киселеп төшә торды, ди.

Бу вакытта Каракаш кулындагы курай очыннан сөт тамды, ди. Каракаш моны күреп, бик нык сөенде, ди.

Ләкин күп тә үтмәде, диюнең бөтен көче белән үкерүен ишетеп, тирә-яктагы ваграк диюләр, аждаһалар ярдәмгә килделәр, ди. Урал батыр аларга да бирешмәде, ди; аның авыр гәүдәсен күтәргән аяклары тайшанмыйча, һаман җиргә баткан көе, башы болытка тиярдәй булып югары күтәрелгән көе торды, ә кулындагы кылычы, яшен утлары чыгарып, уйнап кына торды, ди.

Менә берзаман, барча диюләрне, аждаһаларны кыйратып беттем дигәндә генә, Урал батырның өстенә сансыз күп җен-пәри көтүе килеп ябырылды, ди, — тын да

алдырмыйлар, күз дә ачтырмыйлар, бөреп алып баралар, ди, егетне.

Бу вакытта баягы курай очыннан кан тамды, ди. Каракаш, моны күреп, бик нык борчылды, ди. Шуннан ул, күп уйлап тормый, курайны алды да өздереп-өздереп әллә нинди, ишетер колакка ягымсыз бер бию көен тарта башлады, ди.

Теге җен-пәриләргә шул гына кирәк икән: алар, үзләренең бию көен ишетү белән, бөтен дөньяларын оныттылар, Уралны ялгыз калдырып, курай тавышы ишетелгән якка йөгерештеләр дә шунда барып, тыела алмыйча, биергә керешеп тә киттеләр, ди.

Урал батыр, җен-пәриләр дөньясын кыйратып, Тересу чишмәсен дию кулыннан коткардым, хәзер инде аның тереклек суы кешеләргә булыр, дип шатланып, чишмә янына килсә, анда бер тамчы да су юк иде, ди. Ни өчен дисәң, бу сугышта исән калган дию пәриләре, Тересу адәм затына калмасын дип, эчеп корытканнар икән. Урал батыр чишмә янында күпме генә утырмасын, бер тамчы да су чыкмады, ди.

Урал батыр моңа бик көенде, ди. Шулай да аның диюләрне, аждаһа-еланнарны пыран-заран китереп кырып ташлавы файдасыз булмады: бөтә тирә-якка җан керде, ямьләнеп китте, үләннәр, агачлар яшәрде, кошлар сайрашты, кешеләр йөзендә шатлык балкыды, ди.

Урал батыр, үзенең Акбүзен менеп, алдына Каракашны утыртып алды да Тересуны ташлап китеп тә барды, ди. Бу урында Урал тураклаган дию пәриләре, аждаһаеланнар гәүдәсеннән зур бер тау өелеп калды, ди. Әнә шул тауны халык телендә Ямантау дип йөртә башладылар, ди.

Урал белән Каракаш, ирле-хатынлы булып, дөнья көтә башладылар, ди. Аларның өч улы булды, ди: өлкәне — Идел, уртанчысы — Җаек, төпчек уллары — Сакар.

Хәзер инде бу тирәгә Әҗәл дә сирәк килә торган булып китте, ди. Ни өчен дисәң, ул пәһлеван Урал батыр-

дан, аның яшен уты чыгара торган кылычыннан шүрли иде, ди. Менә шул аркада халык бик ишәеп китте, ди. Шулкадәр күбәйде, хәтта эчәр су да җитми башлады, ди. Урал батыр, бу авыр хәлне күреп, бердәнбер көнне кынынннан кылычын тартып алды да баш өстендә өч тапкыр селтәп, аяк астындагы җирне уйдыра чапты, шуннан:

— Менә шушы җирдә зур суның башы булыр! — дип әйтте, ди. Үзе шунда ук өлкән улы Иделне чакырып китереп: — Бар, улым, аягың тарткан якка чыгып кит тә халык арасында йөре, иллә мәгәр берәр зур агымсуга барып җитмичә артыңа әйләнеп карыйсы булма! — дип әйтте, ди.

Әтисе сымак авыр гәүдәле Идел, аягының тирән эзен калдыра-калдыра көньякка карап чыгып китте, ди. Әтисе аның артыннан күз яшьләрен мөлдерәтеп карап калды, ди. Чөнки ул Иделнең кире әйләнеп кайтмаячагын белеп тора иде, ди.

Әй бара, ди, Идел, әй бара, ди, туктап хәл җыюны да белми, ди. Бик озак баргач, уңга каерылып китте, шуннан төньякка юнәлде, ди. Әй китте, ди, Идел, әй китте — ай үтте, ел үтте, ди, шуннан ул көнбатышка юл тотты, ди. Бара торгач, камышы кама белән тулган зур бер елгага килеп җитте, ди. Шуннан Идел артына әйләнеп караса, аның эзеннән киң елга булып ап-ак су ургылып агып килеп, шушы камалы елгага коя башлады, ди.

Менә шул көннән алып ямьле Агыйдел елгасы барлыкка килде, ди.

Идел батыр озын юлга чыгып киткән көнне аның әтисе теге ике улын да шундый ук шарт белән илгә чыгарып җибәрде, ди. Ләкин алар агаларына караганда кыюсызрак, түземсезрәк булганнар, ди: Идел батыр сымак, берүзләренең генә шундый озын, авыр юлны үтәргә йөрәкләре җитмәде, ди. Сакмар үзенең туып-үскән җиреннән ераклаша башлагач, ямансулап китеп: «Ни эшләп әле мин әллә нинди ят җирләрне япа-ялгызым кыдырып йөрим? Җаек агаема барыйм да кушылыйм, бергә йөрүе

җиңел дә, күңелле дә булыр», — дип, Җаекка барып кушылды, ди.

Ничек кенә булмасын, халык Иделгә генә түгел, Җаек белән Сакмарга да беткесез рәхмәт укыды, ә Урал батырның үзенә әнә шундый данлы уллар үстергәне өчен озын гомер теләде, ди.

Ләкин йөз дә бер яшькә җиткән Урал батырның гомере күп калмаган иде: аның картаеп, хәлсезләнә башлавын күптән көтеп йөргән Әҗәл якынлашкан иде инде, ди. Менә хәзер Урал батыр хәл өстендә ята. Аның янында, изгелекле батырыбыздан аерылабыз инде, дип кайгырышып, бөтен тирә-як халкы җыелган, ди. Шулвакыт әле генә әллә кайдан кайтып төшкән ир уртасы бер кеше, җыелган халыкны икегә аерып үтте дә, үлем түшәгендә яткан Урал батырга карап:

— Әй, батырларның батыры Урал атабыз, син түшәккә яткан көнне үк мин, халыкның соравы буенча, суын теге заман җен-пәриләр эчеп бетереп киткән Тересуга барган идем. Ул бөтенләй үк корып бетмәгән икән: мин анда җиде көн, җиде төн утырып, соңгы тамчыларыннан бер мөгез тереклек суы җыеп алып кайттым. Менә хәзер шул суны халык исеменнән сиңа бирәм. Кадерле Урал атабыз, син шул суны эчеп җибәр дә, үлемнең ни икәнен дә белмичә, халык бәхете өчен мәңге яшә! — дип, мөгезне түшәктә яткан Урал батырга сузды, ди.

— Тамчысын да калдырмый эч, Урал батыр! — дип үтенде, ди, халык.

Урал батыр әкрен генә торып, аягына басты, Тересуның соңгы тамчы суы салынган мөгезне уң кулы белән алды, шуннан халыкка баш иеп, рәхмәт белдерде дә мөгездәге суны уртлады, ди. Ләкин суның бер тамчысын да йотмады, ә бер алдына, бер артына әйләнеп, бер уңга, бер сулга карап — бөтен тирә-якка бөркеп җибәрде, ди. Шуннан үзе:

— Мин — бер кеше, сез — күп кеше; мин түгел, ә

җир-су үлемсез булсын; җирдә кешеләр шат, рәхәт яшәсен! — диде, ди.

Урал батыр шулай дип әйтеп бетерүгә барлык тирә-як үзгәреп, яңарып китте: аяк астына ямь-яшел үлән түшәлде, агачлар яңа яфрак ярды, җир өстендә төрле-төрле җиләкләр, агачта төрле-төрле җимешләр кызарып пеште, гөлләр чәчкә атып, күз явын алып торды, ниндидер асыл кошлар килеп сайрый башлады, челтерәп чишмәләр акты, куе камыш белән уратылган түп-түгәрәк күлләр барлыкка килде, шул күлләрдә, шулай ук Агыйделгә, Җаекка, Сакмарга килеп кушылган яңа елгаларда моңа кадәр күренмәгән аккошлар каңгылдашып йөзделәр, баш өстендә акчарлаклар чәрелдәшеп очып йөрделәр, ди.

Менә шул ямьле дөньяда кешенең яшисе килеп кенә торды, ди. Шунда туксан яшьлек бер чәчән халык алдына чыгып, калкурак җиргә басып алды да болай дип көйләде, ди:

Ай, туган җир, туган җир,
Ата-бабам торган җир.
Дүрт аяклы җанварга
Төяк булган туган җир.
Тугайлары түшәктәй,
Тал, шомырты курчактай,
Балтырганы беләктәй,
Саранасы кура җиләктәй;
Чәчкәләре мең төсле,
Исертерлек хуш исле,
Җәйрәп яткан җиребез!

Алпан-толпан атлаган
Аюы күп җиребез;
Алырын аңдып йөргән
Бүресе күп җиребез;
Кыска койрык, шеш колак
Куяны күп җиребез;

Ыспай басып йөргән
Төлкесе күп җиребез;
Балыгы аттай дулаган,
Камасы куйдай сулаган,
Суы ярына сыймаган
Елгасы күп җиребез!

Ай, туган җир, туган җир,
Ата-бабам торган җир;
Елкылары чыңгырдап,
Сыерлары мөңрәп,
Куй-сарыгы куңырап,
Көтү-көтү йөргән җир;
Ятып калган бер бәрәч
Йөз куй булып үрчер җир;
Торып калган ялгыз тай
Өер булып йөрер җир;
Атам кияү булган җир,
Анам килен булган җир,
Кендегемне кискән җир,
Тәмле суын эчкән җир!

Карт чәчән әнә шулай үзе яшәгән җирнең байлыгына, матурлыгына сокланып, кобаер әйтте, ди. Ә тап менә шулвакытта Урал батыр үзе дөнья куйды, ди.

Халык Урал батырны бик зурлап, хөрмәтләп, калкурак бер җиргә күмде, шуннан һәркем аның кабере өстенә бер уч туфрак салып чыкты, ди. Көн үтте, ел үтте, Урал батырның кабереннән кеше аягы өзелмәс булып китте, ди. Аның каберенә учлап-учлап сала торгач, шулкадәр күп туфрак өелде, хәтта кабер өстендә бик зур тау барлыкка килде, ди.

Әнә шул тауга халык Урал дигән исем биргән, ди. Анда Урал батырның сөякләре әле дә саклана икән: казысаң, Урал тавыннан чыга торган беткесез күп алтынкөмеш, төрле-төрле асылташлар дигәнебез әнә шул Урал

батырның кыйммәтле сөякләре икән ул. Урал батырның асыл сөякләре саклана бирү генә түгел, хатта аның каны да суынмаган икән әле, тик, күп гомер үткәнлектән, төсе-сыйфаты гына үзгәргән икән: бүген бөтен Урал буенда ургылып атып торган нефть — тап әнә шул олы Урал батырның кибү белмәс каны икән ул.

АКЪЯЛ БАТЫР

Борын-борын заманда бер авылда бер ир белән бер бичә булган. Алар бик ярлы гына көн иткәннәр. Ураза да тотмаганнар, намаз да укымаганнар, муллаларга да һичбер хәер бирмәгәннәр, ди. Үз көннәрен үзләре күргәннәр: сулардан балык тотканнар, урманга сунарга йөргәннәр, ди.

Бервакыт, кыш килеп җиткәч, боларның яга торган утыннары бетеп киткән. Болар, ирле-бичәле икәүләп, мәчет ишеге алдына кергәннәр дә, шунда үсеп утырган бер юан каенны егып алганнар да кайтканнар, шул мәчет каенын чуваллларына ягып, өйләрен җылыта башлаганнар, ди. Иртәгәсен бу эшне белеп калып, биләр, муллалар мәчет каенын кисеп яккан кешене эзләп табарга боерык биргәннәр. Бервакыт авыл халкы тегеләрне эзләп табып, шул арада икесен дә урамга алып чыкканнар да, тукмап-тукмап, аяк-кулларына богау салып, Себер җибәргәннәр: бик еракка, Урал тауларының кеше аягы басмаган бер җиренә алып барып, кулларын-аякларын чишеп, ташлап киткәннәр. Теге ир белән хатын, шунда бер бәләкәй генә өй салып, ирле-бичәле яшәп ятканнарында, боларның бер ир балалары дөньяга килгән. Бу малай

түбәсеннән алып калак сөяге арасына җиткәнче ап-ак озын чәчле, ди, үзе. Шуңа карап, аңа Акъял батыр дип исем кушканнар.

Бу малай ай үсәсен көн үскән, ел үсәсен ай үскән, җиде яшендә батыр булып җитешкән, аюга да, бүрегә дә бирешмәгән. Әтисенә булышып, кош, җәнлек сунарына йөргән. Сунарга өйрәнеп, болан, кыр кәҗәсе тотып алып кайткан; мал асрап, бу малларның сөтен эчеп, итен-маен ашап, болар яхшы гына дөнья көтеп алып киткәннәр. Әтисе белән әнисе, моңа сөенеп, кинәнеп бетә алмаганнар.

Акъял батыр уналты, унҗиде яшькә җиткәндә, моның әти-әнисе үлеп киткән. Бу вакыт инде Акъял батыр бик зур гәүдәле, киң күкрәкле батыр булган. Әти-әнисе үлеп, ялгыз калгач: «Кайда кемнәр яши икән, нинди хәлләр бар икән?» — дип уйланып утырган да, болан тиресеннән тегелгән тунын киеп, бер батман угын аркасына асып, очып төшеп барган йонны да кыркып алган үткен елтыр кылычын тагып, дөнья күрергә дип, чыгып та киткән.

Акъял батыр ай киткән, ел киткән, күп таулар, урманнар, сулар үткән. Бара торгач, бер биек тауга үрләгән җирдә хәл җыярга туктаган. Шулчакта ул чаң туздырып, тау-таш актарып йөргән бер кешене күреп калган. Артык уйлап тормый, болан тунын киеп, кылычын тагып, ук-җәясен алып, торган да шул кеше янына киткән. Килгән дә саулык сорашкан, ахыр:

— Эй, агай, син кем? Нишләп алай тузан туздырып йөрисең монда? — дип сораган.

— Менә тауларны күчереп йөрим, эшем шул, — дип әйтте, ди, теге кеше.

— Эш юкта эш тапкансың икән, — дигән Акъял батыр. — Бу тирәдә күптән яшисеңме, нинди хәлләр бар? Сөйлә әле, исемең кем? — дип, кат-кат сорау бирде, ди.

— Мин үзем Тау батыр булам, — ди теге кеше. — Бик күп заманнан бирле шушы таулар арасында яшим. Якын-

тирәдә авыллар юк, булганнары моннан берничә йөз чакрымнарда гына, — ди. Шуннан: — Ә син үзең кем буласың соң? — дип сорый.

— Мин Акъял батыр булам. Туган илемне ташлап, җир-су тикшерергә, дөнья күрергә чыктым. Менә сиңа очрадым. Йөрисе җирләрем күп әле, ярый, мин китим, — ди дә, ук-җәясен иңбашына асып, кузгала башлый. Шулвакыт Тау батыр:

— Үзеңә юлдаш итсәң, мин дә синең белән барыр идем, — ди. Акъял батыр аны-моны уйлап тормый:

— Ярый, алай булгач, әйдә, киттек, — ди. — Берәүдән икәү яхшы булыр, сөйләшеп йөрергә күңелле булыр, — дигәч, болар урыннарыннан кузгалып, тау буйлап, икәүләп китеп бардылар, ди. Китеп баралар, китеп баралар, ди. Тау батырның йөргән тауларыннан, яланнарыннан айлар буена бара торгач, бер зур калын урманга барып житкәннәр. Урманның шарт та шорт килеп торганын ишеткәннәр, ди. Шулвакыт болар: «Бер-бер куркынычлы нәрсәгә очрамадык микән?» — дип, коралларын алып, урманга кереп китсәләр, бер кеше күрәләр. Туктап, карап торалар. Бу кеше агачны тамырлары белән куптарып, икенче урынга алып барып утыртып йөри, ди. Батырлар, аның янына килеп:

— Агай, ни эшлисең болай? — дип сорадылар, ди. Теге кеше:

— Менә бу җирдән анавы җиргә агачларны күчереп утыртам. Бу җирнең урманы куерып киткән, тегендә бик сирәгәйгән, — дип җавап кайтарды да, үзе батырларга якынрак килеп: — Мин Урман батыр булам. Сез үзегез кем буласыз? — дип сорады, ди. Акъял батыр:

— Мин ил күрергә чыккан идем, менә үземә иптәшкә Тау батырны очраттым да икәүләп бергә йөреп ятабыз әле. Хәзер килеп сине очраттык, — дип әйтте, ди.

— Алай булгач, мине дә үзегез белән алыгыз, — ди Урман батыр.

— Ярый, әйдә, бердән ике булыр, икедән өч булыр, сөйләшә-сөйләшә йөрергә ару булыр, — дигәч, болар хәзер өчәүләп кыйблага карый бер сукмактан китеп бардылар, ди.

Урман батыр пычакларны үткерләп, әзерләп алып, кысыр бияләр яткан җиргә чыгып киткән. Бик озак сайлап йөргәннән соң, Акъял батыр сокланган кысыр биягә күзе төшә, янына бара, тотарга уйлый. Бу бия бик кыргый булып чыга. Урман батырны якын да җибәрми. Урман батыр бияне тота алмый. Шуннан, башкасы булса да ярар дип, башкаларын тота башлый. Озак маташканнан соң, бер кола бияне тотып пычаклый, тиз генә тиресен сыдырып ташлап, итне кырыккалап, казанга салып, ут ягып җибәрә. Ит пешә башлый, батырлар да әйләнерләр инде дип торганда, тышкы яктан кинәт ишек кагылды, ди. Урман батыр:

— Анда кем бар? — дип сорауга:

— Мин — кунак, — дигән тавыш ишетелә. Урман батыр:

— Ярый, кунак булсаң, ачыйм, — ди.

Ишекне ачып җибәрсә, алдында үзе бер карыш, сакалы мең карыш карт басып тора.

— Мине күтәреп керт! — ди карт.

Урман батыр күтәреп кертә. Өйгә кергәч:

— Мине күтәреп утырт! — ди.

Урман батыр күтәреп утырта. Түргә менеп утыргач, сакалы мең карыш карт әйтә:

— Ашарга бир! — ди.

Урман батыр бу картка казаннан бер зур кисәк ит алып бирә. Карт аннан-моннан гына кабып йота да:

— Тагы да бир! — ди. Урман батыр:

— Минем иптәшләрем бар. Иптәшләр кайткач, бергәләшеп ашарбыз, — ди. Карт кычкырып җибәрә:

— Әйткәч, салып бир! Мин синең иптәшләреңне белмим! — ди.

Урман батыр бирми карыша башлагач, карт урынын-

нан ыргып төшә дә, Урман батырны күтәреп алып, бармагын өрлек ярыгына кыстырып куя. Шуннан казандагы итне аннан-моннан кабалана-кабалана ашап бетереп, чыга да китә. Урман батыр каннарын туздырып, бармагын тартып алып; «Инде нишләргә? Батырлар кайтса, ничек итеп җавап табарга?» — дип сөйләнә-сөйләнә, тиз генә киез кыркып алды да, аны көйдереп, бармагына басты, тагы да ат суярга чыгып китте, ди.

Урман батыр, җан ачуы белән бер атны тотып алып, суеп, тулы казан ит пешерә башлый. Шулвакыт Акъял батыр белән Тау батыр кайтып керәләр.

— Аш пештеме? — ди Акъял батыр. Урман батыр:

— Пеште, — дип җавап кайтара.

Батырлар ашарга утыралар. Ашап, күңел тынычлангач, Акъял батыр Урман батырга:

— Кулыңа ни булды? Нишләттең? — дип сорау бирә Урман батырга.

— Әнә теге ат суйдырмый дулап китте, шуның белән карышып йөргәндә, сизмәгәндә пычак кадалып куйды, — дип кенә сылтау тапты да куйды, ди. Теге карт турында ләм-мим сүз әйтмәде, ди.

Ашап-эчеп тамак туйдыргач, ятып йокларга булалар. Яталар, йоклыйлар. Иртә белән торып, юынып эш беткәч, Акъял батыр Тау батырга карап торды да:

— Бүген син ашарга әзерләрсең, без Урман батыр белән чыгып йөреп кайтырбыз, — диде дә, коралларын күтәреп чыгып киттеләр, ди.

Озын-озын юл буйлап, калын-калын урман аша, киңкиң тугайлар үтеп, тирән-тирән су буйларын үтеп барып, бик ерак җир киткәч, ял итәргә утырдылар, ди. Бу вакыт өйдә калган Тау батыр пычакларын чарлап, маллар арасына чыгып, бер атны тотып алып суеп, казан асып, ит пешерә башлаган була. Менә бервакыт берәү бик каты ишек дөбердәтә башлый. Тау батыр:

— Анда кем бар? — ди. Тыштан:

— Мин — кунак, ач! — дип җавап кайтаруга, Тау ба-

тыр ишекне ачып җибәрсә, ишек төбендә үзе бер карыш, сакалы мең карыш әлеге карт басып тора, ди. Тау батыр эчтән генә: «Монда да бер җан иясе бар икән әле», — дип уйлый да:

— Әйдә, бабай, рәхим ит! — ди. Карт:

— Юк, мин керә алмыйм, күтәреп керт! — ди.

Тау батыр картны күтәреп кертеп, түр башына утыртып куя. Күп тә утырмый, теге карт:

— Миңа ашарга бир! — ди.

Тау батыр аңа бер зур кисәк ит алып бирә. Карт итне аннан-моннан гына йотып, тагы да сорый башлагач, Тау батыр:

— Иптәшләрем өчен пешергән итне сиңа гына ашатып бетерер хәлем юк, — дип җавап кайтарган икән, карт ыргып төште дә, Тау батырны кочаклап алып, өйнең тәрәзә ягында кагулы торган чөйгә колагыннан асып куеп, казандагы итне ашап бетеп, чыкты да китте, ди.

Тау батыр колагын ычкындырып алып, казанны килеп караса, бер генә кисәк тә ит калмаган, ди. Тиз генә чыгып тагы да бер атны суеп, казан тутырып яңадан ит пешерә башлауга Акъял батыр белән Урман батыр да кайтып керәләр. Өчәүләп ит ашарга тотыналар. Акъял батыр үзләренең йөргәннәрен, йөргәндә күргәннәрен сөйләп бетте дә Тау батырга:

— Колагың нишләде? — дип сорау бирде, ди. Тау батыр:

— Атлар тотып йөргәндә бер усалы тибеп җибәрде дә, шуның тоягы колакка эләгеп китте, — дип әйтте, ди. Акъял батыр:

— Йә, нишләп сез алай, берегез бармак кырка, икенчегез колак өздерә? Ярый, иртән мин үзем калыйм әле, миңа нәрсә булыр икән? — ди.

Батырлар, итне ашап бетереп, йокларга яттылар. Йоклап торгач, тамак туйдырдылар да, Акъял батыр, сүз башлап:

— Егетләр, бүген сез икегез йөреп кайтыгыз, мин

ашарга әзерләп торырмын. Мин, бәлки, теге, килгән чакта күреп калган кола бияне очратырмын, аның ите яхшы булырга тиеш. Сез ничек уйлыйсыз? — диде, ди.

Урман батыр белән Тау батыр: «Шулай ук кола бияне тота алыр микән?» — дип уйлашып, икәүләп, өйдән чыгып киттеләр, ә Акъял батыр пычакларын үткерләп, бер аркан алып, кола бияне тотарга әзерләнә башлады, ди.

Акъял батыр елкы өере арасында бик озак эзләп йөргәннән соң, бер тугайда үзе күргән кола бияне очрата. Биягә якынрак барып аякларын ныгытып баса да тозакны биягә ыргыта. Аркан муенына салына төшкәч, бия дулап карася да, ычкына алмый. Акъял батыр тиз генә арканны арт аягыннан аша бәйләп, бияне тартып екты да, чалып җибәреп, аннан-моннан тиресен сыдырып ташлап, итләрен ваклап, казанга тутырып, пешерә башлады, ди. Бервакыт ишек кага башлаган тавыш ишетелә. Тыңлап-тыңлап тора да:

— Анда кем бар? — ди. Тыштан кемдер:

— Мин — кунак! — дип җавап кайтара.

Акъял батыр тышка чыкса, теге үзе бер карыш; сакалы мең карыш карт басып тора. Болар бер-берсенә озак карап торгач, теге карт:

— Мине күтәреп керт! — ди. Акъял батыр:

— Монда җиткәнче атлап килгәнсең бит, керерсең дә утырырсың! — дип өйгә кергән дә киткән.

Теге карт үзе өйгә кереп, үзе түргә менеп утырды да:

— Ашарга китер! — дип, кычкырып җибәрде, ди. Акъял батыр аның кычкыруына игътибар итми генә:

— Бездә кунаклар сорап ашамыйлар, салып биргәнне көтәләр, — дигән икән, карт:

— Әле син минем белән әрепләшергә уйлыйсың икән! — дип ыргып төшеп, Акъял батырны тотыйм дигәндә, Акъял батыр картның сакалыннан урап тотып өрлек агачына асты да куйды, ди.

Карт куркуыннан нишләргә дә белми, әй дулый, ду-

лый торгач, сакалы өзелеп китеп, чыга да кача. Ул арада булмый, Урман батыр белән Тау батыр икәүләп бик күп җирләр йөреп, арып-талып килеп керәләр. Акъял батыр артык хәл сорашып тормый:

— Әйдәгез, тизрәк ашагыз, безнең бер эш бар. Эшкә башлаганчы, сезгә бер сүз әйтергә кирәк: сезнең бармакларыгыз да, колакларыгыз да юктан гына өзелмәгән, әнә теге, өрлектә салынып торган ак сакалның иясенең эше булса кирәк, — ди. Шуннан соң гына Урман батыр белән Тау батыр, бер-берсенә карашып, икесе берьюлы:

— Дөрес, батыр, шулай булды шул, — дип авыр гына көрсенеп куйган булдылар, ди. Шуннан Акъял батыр:

— Безгә ул картны эзләп табарга, үч алырга кирәк,— ди.

Батырлар ашап-эчеп тамак туйдырдылар да, кораллары белән теге картның сакалын алып, өчәүләшеп юлга чыгып киттеләр.

Өч батыр, тауларны, урманнарны, яланнарны үтеп, бик зур бер тауның башына менеп җитсәләр, ерак түгел бер җирдә берәүнең тузан туздырып йөгереп китеп барганын күреп калалар. Шулчак Акъял батыр:

— Егетләр, әнә теге карт бездән качып бара, — ди.

Батырлар йөгерә башлый. Карт кача, батырлар куа, карт кача, батырлар куа. Әй куалар, әй куалар, ди. Бервакыт тауның тап башына менеп җиткәч кенә, карт кинәт кенә күздән юк була да куя. Батырлар карт югалган урынны барып карасалар, бер зур куыш барлыгын күрәләр. Бу куыш тауны туп-туры өңеп төшкән, бик тирән чокыр булып чыккан. Батырлар бер-берсенә карап, аптырашып тордылар, ди. Акъял батыр:

— Бу тау астында берәр хәл булырга тиеш. Төшәргә, анда булган хәлләрне безгә белергә кирәк. Йә, батырлар, кайсыгыз төшә? — ди. Батырлар эндәшмиләр. Шуннан Акъял батыр:

— Алай берегез дә төшәргә теләмәсәгез, мин сезгә төшәргә кушам! — дигәч, Тау батыр батырчылык итә:

— Ярый, алай булгач, мин төшәм, — ди.

Теге картның сакалын алып, аркан ишәләр дә Тау батырны аркан бәйләп, төшерә дә башлыйлар. Бераз гына төшә биргәч, Тау батыр кычкырып җибәрә:

— Ай, төшә алмыйм, зинһар, чыгарыгыз! — ди.

Моны кире тартып чыгаралар. Тау батыр җир өстенә килеп чыкты да:

— Әлдә тартып алдыгыз, әтү үләр идем: үзе караңгы, үзеннән әллә нинди ис килә, бик куркыныч җир икән, — дип куйды, ди.

Шулчак Акъял батыр:

— Тау батыр, син батырлыгыңны югалттың, батырлар чокырдан, таудан, җирдән, судан курыкмыйлар, батыр каршында куркыныч бернәрсә дә юк, батыр үлемнән курыкмас булыр! — ди.

Акъял батырның сүзен тыңлап торганнан соң, Урман батыр:

— Кая, бәйләгез, үзем төшеп чыгам! — ди. Акъял батыр, ышаныр-ышанмас кына:

— Ярар, алай булгач, төшеп кара, — ди. Урман батырны биленнән бәйләп, төшерә дә башлыйлар. Аз гына төшерә биргәч:

— Батырлар, юк, мин төшә алмыйм, зинһар, тартып алыгыз! — дип кычкыра.

Акъял батыр, бу батыр да чын батыр түгел икән, дип уйлап тора да, тегене кире тартып чыгара.

— Урман батыр, синнән дә эш чыкмады, батыр сүзе бер була ул. Сездән изгелек булмас, ахры. Үземә төшәргә туры килә, — дип, арканны яхшылап, берничә тапкыр тикшереп чыга да:

— Ярар, егетләр, төшәм, иллә мәгәр сез китмәгез. Мин әйләнеп чыкканчы, көлдә күмәч пешереп, көн күреп, шушы җирдән китми мине көтеп торыгыз! — ди.

Арканга тотынып, чокырга төшә башлый. Чокыр төбенә төшеп тә җитә, тирә-якка карап ала: «Ну нинди җир икән, монда тагы да нинди дөнья бар икән?» — дип

уйлап куя. Уйлап-уйлап утыра да төрле якларга таралып киткән юлларның берсеннән чыгып китә.

Акъял батыр бик озак җирләр бара торгач, бик матур салынган бер шәһәр читенә килеп чыга. Тирә-якка карап торганнан соң, үзенең каткан болан тунын кигән, бер батманлы җәясен, ярты батманлы угын аскан, очып килгән йонны урталай кисеп төшерә торган үткер кылычын таккан көйгә, шәһәрнең читендәге бер бәләкәй генә өйгә барып керде, ди. Өйгә барып керсә, алама гына кигенгән бер карт белән бер әби утыра икән. Акъял батыр бераз хәл җыйганнан соң, карт белән әбидән мондагы хәлләрне сораша башлый. Ахырда үзенең кем булуын, илдән ничек чыгып киткәнен сөйләп аңлата. Карт белән әби егетнең Акъял батыр булуын белгәч:

— Балам, син тиз генә суга барып кил инде, — дип әйттеләр, ди. Акъял батыр:

— Нигә, бабай, әллә сездә су бик еракмы? — дип сорый.

— Балам, бездә суны үлчәү белән генә бирәләр. Безнең синең тамагыңа әзерләү өчен суыбыз юк. Ә син кунак кеше булгач, сиңа бер чиләк суны берсүзсез бирерләр, — ди. Акъял батыр озак уйлап тормый:

— Кая, әби, чиләгеңне бир, алай булгач, мин тиз генә барып су алып кайтыйм, — дип, чиләкне күтәреп суга китә.

Урамның буеннан-буена барып, шәһәрнең икенче очындагы бер буа эченә шаулап агып ята торган салкын сулы бер бәләкәй генә елга янына барып, чиләген батырып, су алырга гына торганда:

— Син нишләп суга килдең? Син кем буласың? — дигән калын тавыш ишетелә. Акъял батыр:

— Мин — кунак, — дигәч:

— Ярар, кунак булсаң, бер чиләк су ал инде, — ди теге тавыш.

Акъял батыр чиләген тутырып алып кайтып китә.

Су күтәреп урам буйлап кайтып барганын күргән халыклар тәрәзәдән башларын тыгып карап торалар, ди.

— Бу нинди кеше булыр икән, бу вакытта ничек су ала алды икән? — дип сөйләшәләр, ди.

Акъял батыр суны өйгә алып кайтып утыртыр-утыртмастан ук, карт белән әби чиләк өстенә ябырылып, кабаланып эчә башлыйлар. Су Акъял батырның үзенә җитми кала. Карт белән әби сусыннары басылгач, Акъял батырга:

— Балакай, син безгә көймә инде, без бик сусаган идек. Син алып кайткан суны эчеп бетердек тә куйдык, — дигәч, Акъял батыр тирән уйга чумып торды да, үзалдына сөйләнә башлады ди: «Адәм баласы бу дөньяда яшәргә туган. Нигә соң ул туктаусыз агып яткан суны да үзе теләгәнчә эчә алмый? Булмас, бу эшнең болай булуы мөмкин түгел. Мин чын батыр булсам, бу хәлгә чыдап тора алмам, ул явыз җан белән сугышырга, халыкка рәхәт көн тудырырга тиешмен!» — дип, тиз генә кылычын биленә тагып, чиләген беләгенә элеп, чыга башлагач, бабай белән әби, батырның итәгенә ябышып:

— Балакаем, зинһар, бара күрмә инде, үзеңне харап иттерерсең, вакытсызрак барасың, анда сине үтерерләр, — дип елаша-елаша Акъял батырны җибәрмәскә тырыша башлагач, Акъял батыр:

— Еламагыз, еламагыз, ул мине үтерә алмас. Минем бу беләкләрем аның сыман явызларны күп күргән, егет сүзе бер булыр, мин сезне бу җәфадан коткарырга тиешмен! — дип чыгып киткән. Бабай белән әби бик нык куркышып, Акъял батырны җәлләп, елашып калдылар, ди.

Акъял батырның урам буйлап икенче кат китеп барганын күреп, халыклар тагы да аптыраша төштеләр, ди. Аның һәрвакыт кылыч тагып йөрүенә гаҗәпләнәләр икән: «Бу кеше нишләп тагы суга бара икән, нигә ул корал белән йөри икән?» — дигән уйга калдылар, ди.

Акъял батыр елгага барып җитә дә, эндәшми-нитми генә батырып су ала башлый. Шулчак кайдандыр теге

кәрлә килеп чыгып, батырга ташланган иде, Акъял батыр, кылычын ала салып:

— Әһә, син икәнсең! Мин сине эзләп монда килеп чыктым. Син әле минем иптәшләремне рәнҗетү генә җитмәгән, бөтен ил халкын сусыз изалап ятасың икән. Сакалыңны да мин өзгән идем, хәзер инде башыңа да мин җитәм! — диде дә, картның башын чабып өзде дә куйды, ди.

Картны үтереп ташлап, үзе тулы чиләк су күтәреп, урам буйлап кайтышлый очраган бер кешегә:

— Су алырга барыгыз, мин сезгә су бирми яткан явыз картны үтердем, хәзер су иркен калды, теләгәнчә алыгыз! — дип сөрән салып узган.

Акъял батырның бу сүзләренә ышаныр-ышанмас торган халык, берсе артыннан икенчесе, өченчесе, башкалары йөгереп барып, яр өстендә су хуҗасының үле гәүдәсен күргәч, бөтен шәһәргә шатлыклы хәбәр таралды, ди: «Илебезгә бер батыр килгән, кәрләне үтергән, су алу иреккә калган!»

Һәрбер өйдән дүртәр, бишәр чиләк күтәреп йөгерешәләр. Берничә сәгать эчендә бөтен шәһәр халкы суга туена. Акъял батырның арымый-талмый таза егет булып яшәвен теләп таралдылар, ди.

Акъял батыр тагы да бер чиләк су күтәреп өйгә кайтып кергәч, карт белән әби аптырап калалар:

— Балакай, ничек исән-сау кайтып җиттең? — дип сорау бирәләр. Акъял батыр:

— Мин су хуҗагызны үтердем, хәзер суга аптырамассыз инде. Әнә, халык нинди зур шатлык белән шаулаша-шаулаша су ташый, — дигәч, карт белән әби дә, чиләкләрен күтәреп, чишмәгә йөгерделәр, ди.

Акъял батыр карт белән әбинең йорт-каралтыларын карап керә. Карт белән әби судан кайткач:

— Йортыгызның башы бик искергән икән, аны яңартып ябарга кирәк, — ди. Карт әйтә:

— Йортның түбәсен ябарга кирәк дисең дә бит, улым,

минем көчем беткән шул, кулымнан эш килми. Ярар, үзебез үлгәнче торыр әле, — ди. Акъял батыр:

— Кайда, алай булгач, мин үзем сезгә ярдәм итим әле, кайсы урманда юкә агачлары бар, миңа өйрәт, мин аннан кабык суеп алып кайтыйм, — ди.

Карт урманны өйрәтеп җибәрә. Батыр урманга барып, ат йөгеннән зур итеп, кабык төшереп алып кайта. Иртәгә үк йорт түбәсен ябарга булып, карт белән әбине сөендереп, ашап-эчеп алгач, йокларга яттылар, ди.

Иртән торып тамак туйдыргач та Акъял батыр өй ябарга тотына. Яртысын ябып бетеп барганда гына шәһәрнең бер як читендә тавыш ишетелә. Акъял батыр өй башыннан төшә дә карт белән әбидән сорый:

— Анавы якта бик гүләшәләр, ни булды икән? — ди.

Карт белән әби батырны анда җибәрергә теләмәгәнлектән, әйтмәскә тырышсалар да, әйтәләр дә куялар.

— Балам, анда бик зур мәйдан корылган, бүген безнең илнең патшасы мәйдан ясый. Аның кызы бар, бик сылу. Чәчләренең бер бөртеге алтын, бер бөртеге көмеш. Менә шул кыз: «Кем дә кем балдакка атып, балдак аша чыгарса, шул минем киявем булыр, шуңа кияүгә чыгам»,— дип әйтә, ди. Әтисе, патша: «Кем дә кем минем киявем була, шуңа бөтен малымны бирәм», — ди икән, — дип әйттеләр, ди. Акъял батыр шул сүзләрне ишеткәч тә, үзенең болан тунын киеп алып:

— Тукта, мин дә барып карап кайтыйм әле, — дип чыгып китте, ди.

Бервакыт Акъял батыр үзенең каткан туны белән мәйдан алдына килеп баса. Патшаның вәзирләре, күп кенә кешеләр яхшы киемнәр киенеп, мәйданда беренчелекне алырга килгәннәр, ди. Патша тарафыннан: «Атуга катнашып балдак уртасыннан атып чыгара алмаган кешене бик каты розга белән суктырып ташларга», — дигән закон куелган, ди. Акъял батыр берничә кешенең тукмалганын үз күзе белән күреп торса да, бик нык сабырлык күрсәтеп, азактан үзе патшаның алдына бара да:

— Патшам-солтаным, әгәр рөхсәт итсәгез, мин дә атып карар идем, — дип сорагач, патша:

— Күңелеңдә булгач, нигә атмыйсың, ат, — дип җавап кайтарган икән, шулчак Акъял батыр тагы да:

— Патшам-солтаным, алай булгач, мин атам, минем коралларымны алып килергә бер өч кеше бирсәңче, — дигәч, патша азрак аптырап калып:

— Ярар, әнә өч санатны бирәм, — дип җавап кайтарды, ди.

Бу хәлне күргән вәзирләр, санатлар бер-беренә карашып көлешә башладылар:

— Бу каткан тунлы бәндә үзен тукматырлык урын таба алмагандыр шул, шуңа монда килгән икән, — дип әйтәләр, ди.

Күп тә үтми, өч санат Акъял батырның бик зур җәясе белән ярты батман угын күтәреп китерделәр дә, ахылдашып, ухылдашып, мәйдан уртасына ташладылар, ди. Акъял батыр бер угы белән җәясен күтәреп алды да, җәя керешен киерелеп тартып, балдакка төзәп атып җибәргән иде, угы балдакны әләктереп, патша сараена барып кадалды, ди. Моны күреп торган мәйдан халкы аптырауда калды, ди. Шулчак патша:

— Минем киявем дә, минем тәхетемнең хуҗасы да шушы булыр, — дип, Акъял батырны сараена алып кереп китте, ди.

Акъял батыр бер бөртеге алтын, бер бөртеге көмеш чәчле кызның кияве булып, тәхеткә менеп утырды, ди.

Азмы-күпме вакыт үткәч, икенче бер патшалыктан: «Тиздән мәйдан җыела. Кем дә кем әнә күзенә ук ата ала, патша тулган ай сымак нурлы йөзле кызын шул кешегә кияүгә бирә, мөлкәтен аның карамагына тапшыра»,— дигән хәбәр килеп төшә. Акъял батыр шул мәйданга бару нияте белән хатынына әйтә:

— Мин шушы арада сунарга чыгып кайтырга уйлыйм, — ди.

Үзенең мәйданга барган мизгелендә яратып кия торган болан тунын киеп, коралларын асып чыгып китте, ди.

Көн китте, төн китте, байтак вакытлар үтте, ди. Менә беркөн Акъял батыр мәйдан ачылган җиргә дә барып җитте, ди. Исәнлек-саулык сорашып, мәйдан хәлен белгәч:

— Ярар, алай булгач, мин соңга калмаганмын икән әле, — дип әйтте, ди.

Бу мәйданда: «Кем дә кем туры ата алмый, ул кешенең кулын кисеп ташларга», — дигән шарт куелган икән. Акъял батыр аннан тартынмыйча, мәйдан башлыгына барып, үзенең атып карарга теләге барлыгын белдереп, рөхсәт сорады, ди. Рөхсәт ителгәч, үзенең бик нечкә башаклы бер угын алып атып җибәргән иде, угы энә күзенә барып тиеп, Акъял батыр бу патшалыкның да кияве булып, патшаның кызын икенче бичәлеккә алып, дөнья көтә башлады, ди.

Берничә атна үткәннән соң, бу патшалыктан ерак түгел тагы да бер патшалыкта зур мәйдан ачылачагы турында хәбәр таралды, ди. Бу патшалыкның башында бер кыз патша утыра икән. Ул кыз үзе батырларның батыры икән, ди. «Әгәр дә көрәштә миңа чыга алган батыр булса, мин шул батырга кияүгә чыгам, патшалыгымны шул кеше кулына бирәм», — дип әйткән, ди. Ә кыз патша үтә гайрәтле генә түгел, өстәвенә бик матур да — бөтен дөньяда иң гүзәл кыз икән, ди. Бу хәбәрне ишеткәч, Акъял батыр тыныч кына ята алмаган:

— Мин шул мәйданны күреп кайтыйм әле, — дип, бичәсеннән рөхсәт сораган. Бичәсе моңа ризалык белдергән, ди.

Акъял батыр, үзенең әлеге болан тунын киеп, коралларын асып, янә юлга чыгып киткән. Киткән дә киткән, алсыз-ялсыз килә торгач, баһадир кыз патша шәһәренә дә барып җиткән, сораша-сораша мәйдан корылган җиргә килгән. Килсә, ярыш башланган, берничә егетнең башы ботаклы бер юан баганага элеп тә куелган, ди, инде.

Кыз патшаның фәрманы шулай икән шул: «Көрәштә катышып та җиңә алмаган егетнең башын чабып өзәргә!»

Акъял батыр байтак вакыт карап-күзәтеп торган да, бик саллы тотынып, тырышып-тырмашып көрәшкән тагы берничә егетнең башы чабып өзелгәнен күргәч:

— Рөхсәт итсәгез, сезнең белән мин көрәшеп карыйм әле, — дип, кыз патшадан рөхсәт сораган, ди.

Моны ишетеп, мәйдан гөж килгән:

— Каткан туныңны киеп, башыңны өздерергә килгәнсең икән, исәр! — дип кычкырганнар.

— Кайда инде ул сиңа! Әнәниндирәк патша оланнары, зифа егетләр дә җиңә алмадылар, башларын чаптырдылар!

Акъял батырны мыскыллап көлгән тавышлар да ишетелде, ди.

— Алай үләсең килгәч, әйдә, чык соң уртага, — дип, менә Акъял батырга тастымал китереп бирделәр, мәйданга чакырдылар, ди.

Акъял батыр килеп чыккан иде, кыз патша тастымалын җилпи-җилпи каршы килеп:

— Йә, егет, алай бик теләгәч, көрәшсәк көрәшеп карыйк соң, — дип тастымалын җитез генә Акъял батырның биленә салды, ди.

Кыз батыр Акъялны да баягы егетләрне ыргыткан сыман гына алып ыргытырга омтылган иде дә, — булдыра алмады, ди. Акъял батыр кыз патшаны, биленнән шундый итеп каты кысып алып, һавага чөеп җибәрде, төшеп килгәнендә, кабат тотып алып, ике беләгенә салып күтәреп алып барып, мәйдан читендәге затлы урындыгына иплән кенә утыртты, ди. Шуннан батыр кыз мәйдандагы халыкка карап:

— Батырның батырлыгы киемендә түгел, көчендә. Мин — бүгеннән гайрәтле дә, әдәпле дә шушы егетнең хатынымын! — дип, урта бармагыннан алтын балдагын суырып алып, Акъял батырга бирде, ди. Ә Акъял батыр үз балдагын аның бармагына кидерде, ди. Мәйданны

ябып, кыз Акъялны җитәкләп, патша сараена кереп киттеләр, ди. Мәйдан халкы:

— Кайда туган да, кайда үскән бу егет? — дип уйланып, аптырашып, шул ук вакытта тагы да күпме егетнең башы киселмәвенә шатланып таралышты, ди.

Акъял батыр әнә шулай баһадир кыз патшаны да үзенә алып, җир астындагы өч патшалыкның һичнинди дошман җиңә алмас хакиме булып танылды, ди.

Күпмедер вакыт үткәч, Акъял батыр җир өстендә калган иптәшләрен исенә төшереп, сискәнеп китте, ди. Үзе чыкканчы көтеп торырга кушып киткәнен хәтерләп, уйланып, көрсенеп куйды, ди. Шуннан ул уй-хәсрәтен бичәсенә сөйләп:

— Мин бит җир йөзендә яшәгән батырмын, мин үз илемә кайтырга тиешмен, — дип әйтте, ди.

Акъял батырның бичәсе моңа ризалык белдерде, ди. Күп тә үтми, бик күп маллар алып, кораллар төяп, юлга чыгалар. Юлда килә торгач, Акъял батырның икенче бичәсенең иленә килеп җитәләр. Акъял батыр көрәшеп алган батыр бичәсенә бөтен хәлне аңлата:

— Мин сине ташламыйм, син минем белән гомерлеккә калырсың. Ә бу бичәләрем тау башында мине көтеп торган Тау батыр, Урман батыр дигән иптәшләремә булырлар, ди. Акъял батыр юл уңаенда тәүге бичәләренә кереп, аларның да малларын-байлыкларын төяп, үзе белән алып китә. Шулай килә торгач, Акъял батыр кәрләне үтереп, чишмә суын халыкка кайтарып биргән шәһәргә килеп җитәләр. Акъял батыр бичәләренә әйтә:

— Туктагыз әле, минем иң башта төшкән урыным менә шушы инде, — дип, түбәсен яба башлап киткән өйгә, карт белән әбинең хәлләрен белергә кереп китте, ди.

Карт белән әби Акъял батырны күргәч:

— Әй, безнең улыбыз кайтты! — дип шатланышып каршы алдылар, ди. — Кайда булдың, ниләр күрдең? — дип сораша башладылар, ди. Акъял батыр үзенең йөргән-

нәрен, күргәннәрен берәм-берәм сөйләп беткәч, карт белән әби Акъял батырга акыл бирделәр, ди:

— Акъял батыр улым, син күп илләр үтеп, күп байлыклар тапкансың. Монда үзең төшкән җир тишегенә барып җиткәч иң башта син үзең чык, аннан малларыңны, шуннан соң гына бичәләреңне чыгарырсың. Ишетсен колагың, безнең сүзне тот, — дип әйттеләр, ди.

Бу көн шәһәр халкы өчен бер бәйрәм көненә әйләнеп китте, ди. Акъял батыр бабай белән әбигә бик күп мал бүлеп биргән. Бу хәлне ишетеп, бөтен халык Акъял батыр янына җыелды, аның көчсезләр, изелүчеләр, малсызлар хәлен кайгыртып йөрүче бер батыр ир булуын мактады, ди. Атсызларга ат, сыерсызларга сыер, аеры тояк гайре мал өләшкәне өчен кат-кат рәхмәт укыдылар, ди. Акъял батыр да әби белән бабайга, бөтен шәһәр халкына бәхетле тормыш теләп, юлга чыкты, ди.

Күп малларны төяп, өч бичәсе белән бара торгач, үзе төшкән тау тишегенә килеп җитәләр. Тау тишегенә килеп җиткәч тә, Акъял батыр, Тау батыр белән Урман батыр әзерләп куйган арканга малларын бәйләп, берәм-берәм мендерә башлый. Өч бичәсен чыгарганнан соң, иң азактан үзе чыгарга була. Әмма ул уйлаганча булмый шул. Малларын, бичәләрен тартып алгач, Акъял батырның үзенең менеп килгәнен күреп калалар да, Тау батыр белән Урман батыр, бер-берсенә ымлашып: «Әгәр дә без аны чыгарсак, ул безгә бернәрсә дә бирмәс, әйдә, кире төшереп җибәрик», — дип, арканны кистеләр дә куйдылар, ди. Акъял батыр, дөбер-дөбер җир астына төшеп китеп, шунда торып калды, ди. Хыянәтчеләр малларны, бичәләрне үзләренә алып, илләренә кайтып киттеләр, ди.

Акъял батыр чокыр төбендә бик озак уйланып утырганнан соң: «Ярар, болар мине болай итеп калдырдылар инде. Әгәр мин батыр икәнмен, бу хәлдән чыгу әмәлен дә табарга тиешмен», — дип, кире теге шәһәргә китте, ди. Кабат килеп кергән иде, баягы әби белән бабай аптырап калдылар, ди.

— Ни булды, улым, берәр хәлгә тарыдыңмы әллә? — дип сораша башладылар, ди. Акъял батыр:

— Мин сезнең сүзне тотмый ялгыштым. Сезгә кабат киңәшкә килдем. Миңа тагы да акыл бирегез, — дип, ни булганын барысын да сөйләп бирде, ди.

Әби белән бабай, моның бик авыр хәлдә калуына борчылып:

— Әй, балам, бик зур хаталык ясагансың икән, нишләп карыйк инде? — дип кайгырышып алдылар да: — Менә, улым, безнең сиңа актык акыл шул. Әгәр булдыра алсаң, шулай итеп кара: моннан бик ерак түгел бер кара урман бар. Анда бер сәмруг кош яши. Аның балаларын ел саен бер аждаһа ашап бетереп тора. Әгәр син шул кошның балаларын аждаһа авызыннан тартып ала алсаң, ул кош сине, бәлки, тау тишегеннән якты дөньяга алып чыгар, — дип әйттеләр, ди.

Бабай шул сүзләрне сөйләгәч, Акъял батырның йөзе ачылып китте, ди. Тамагын туйдырып алгач, кылыч белән ук-җәясен тагып, кара урманга карап чыгып китте, ди.

Акъял батыр кара урманның уртасына барып, бер юан агач төбенә якынлашкач, кош чебешләренең тавышларын ишетә. Ныклабрак караса — бабай белән әби әйткән сәмруг оясы шушында икән. Акъял батыр агач башына үрмәли. Шулчак чебешләр елаша башлый:

— Абый, сиңа нәрсә кирәк? Әнә безне бер аждаһа ашарга килә бит! — диләр.

Акъял батыр артына әйләнеп караса, урманны ярып, давыл куптарып, бу якка бер аждаһа елан шуыша, ди. Акъял батыр, атыннан төшеп, кылычын кынынннан чыгарып, аждаһаны көткән. Теге килеп җитеп, туп-туры агачка үрмәли башлаган икән, Акъял батыр явызның башын чапкан да өзгән. Шуннан гәүдәсен тураклап, әрдәнә итеп өеп, сәмруг кошның балаларына күрсәткән. Аждаһадан котлары очкан чебешләр, бу хәлне күргәч, бик шатланганнар, ди.

Акъял батыр агач башындагы ояга менеп утырып, чебешләргә үз хәлен сөйләгән. Шул арада, канатларын җилпүдән җил-давыл чыгарып, сәмруг кош та кайтып төшкән. Бу чак чебешләр Акъял батырны үзләренең канаты астына яшереп утырганнар. Сәмруг кош ояга килеп төшкән дә, тирә-ягына каранып:

— Фу-фу, адәм исе чыга. Кайда ул? Хәзер ашыйм үзен, — дип әйтә, ди. Сәмругның бер чебеше:

— Әни, әнә агач төбенә кара әле, нәрсә ятканын күрерсең! — ди. Сәмруг аптырап кала:

— Ә... бу теге аждаһа лабаса! Ничек ашамады ул сезне? Кем үтерде аны? — ди. Кошның соравы була, чебешләре чыр-чу килә:

— Безне бер абый коткарды. Әни, син аңа тимә, яме? Тимисеңме? Әтү күрсәтмибез.

— Ярар-ярар, тимәм. Кайда ул, күрсәтегез.

Чебешләренең канаты астыннан бик дәү кеше килеп чыккач, сәмруг, чукышын шакылдатып, омтылып-омтылып куйды, ди, Акъял батырга. Балалары: «Әни!» — дип кычкыргач кына тукталып калды, ди.

Акъял батыр, башыннан үткән хәлләрне сөйләп, үзенең моннан ерак түгел бер тау тишегеннән якты дөньяга чыгарга теләвен белдергәч, сәмруг:

— Ярар, егет, мин сиңа ярдәм итәм, тик син миңа ашарга бер капчык сыерчык, бер капчык чыпчык әзерлә, аннан очып китәрбез, — ди.

Шул сүзләрне ишеткәч, Акъял батыр тиз генә урманга чыгып китеп, озак та үтми бер капчык сыерчык, бер капчык чыпчык җыеп кайтып килгән. Шуннан теге кош:

— Йә, егет, минем аркама менеп утыр. Уңга карагапда сыерчык, сулга караганда чыпчык ашатып барырсың, — дигән.

Шулай итеп, болар тау тишегеннән менеп баралар, менеп баралар, ди. Һаман менәләр, һаман менәләр, менгән саен тау тишеге тарая бара икән. Сәмругның канат очы тигән урыннан җир ишелеп, чукышы тигән җирдән

киртләч-киртләч баскыч ясалып кала бара, ди. Болар артыннан тау юлы киңәеп, җир астына кояш яктысы төшеп, бөтен шәһәрне яктыртып җибәрде, ди. Шәһәр халкы:

— Сусыз идек — су булды, малсыз идек — мал булды, йортыбыз яктырды, йөзебез ачылды, — дип сөенештеләр, ди.

Инде чыгып җиттек дигәндә, сыерчык та, чыпчык та беткән бит. Инде нишләргә? Сәмруг уңга да карый, сулга да — ә каптырырга сыерчык та юк, чыпчык та юк. Күп уйлап тормый, Акъял батыр үзенең балтыр итен кисеп ашата башлаган иде, шул арада тау өстенә менеп тә җиттеләр, ди. Тау өстенә менгәч, сәмруг кош:

— Йә, егет төш инде, — ди.

Акъял батыр төшкән иде, аягына басып тора алмый егылды да китте, ди.

— Ни булды, егет?

— Мин сиңа балтырымны кисеп алып ашаткан идем...

— Әйтәм, соңгы ике йотымым бик тәмле булды, кая, күрсәт әле.

Балагын күтәреп, балтырын күрсәткән икән, сәмруг ике тапкыр кикереп, балтыр итен коскан да, аны урынына куеп, төкереге белән сылап ябыштырган. Шуннан соң Акъял батыр син дә мин аягына баскан, кошка зур рәхмәтләр әйткән. Хушлашканнар. Сәмруг түбән төшеп киткән, Акъял батыр үзе бер карыш, сакалы мең карыш картны куып килгән юлдан Тау батыр белән Урман батырны юллап киткән.

Хыянәтче юлдашларын куып җитәргә тырышып атлаган да атлаган Акъял батыр. Ашыгып бара торгач, үзенең баһадир бичәсенең җырлаганын ишеткән:

Урал таукайлары борма-борма,
Бормалары саен аерма.
Бөтен батырлардан көчле булган
Сөйгән батырымнан аерма.

Шушы җырны ишетә-ишетә Акъял батыр килеп җиткән икән, тегеләр коелган да төшкән. Тау батыр, Акъял батырның алдына тезләнеп:

— Батырларның батыры, көчсезләр белән изелгәннәрнең иң якын таянычы Акъял батыр! Синең батырлыгың, гайрәтең минем йөрәгемдә сиңа каршы кара уй тудырды. Мин синең ирлек намусыңа каршы кул күтәрдем. Ниндидер бер яшерен көч минем кулларымны сиңа каршы күтәрергә мәҗбүр итте. Эшләгән эшемнең җәзасы үз өстемдә, бу җәзаны кичерү, батырларның батыры Акъял батыр, синең иркеңдә, — диде дә, маңгаен җиргә куеп, өч тапкыр ук-җәясен үпте, ди. Акъял батыр:

— Алтын җирдә ятып тутыкмый, — дип җавап кайтарды, ди. Тау батырны гафу итеп, тагы да алга табан киттеләр, ди.

Шулай итеп болар, күп җирләр күреп, күп ел гомер уздырып, үзләренең туган илләренә кайтып барышлый, болар Урман батырның иленә килеп җиттеләр, ди. Шулчак Акъял батыр:

— Батырлар, хәзер безгә таралырга вакыт җитте, — ди. — Сезгә әйтә торган сүзләрем бар, шушы җирдә сезгә ул сүзләремне әйтеп үтәм, — ди дә, болай дип, сөйләргә тотына:

— Моннан соң үзегез белән йөргән иптәшләрегезгә бервакытта да явызлык күрсәтмәгез. Картлар: «Йөз сум акчаң булганчы, йөз дусың булсын», — дигәннәр. Үз иптәшеңә һәрвакыт ярдәм итәргә кирәк. Мин сезнең ташлап китүегезгә үпкәләмим. Сез мал, бичәләр өчен кызыгып шулай эшләдегез. Ярар, кабат алай итмәссез. Урман батыр хәзер дөнья көтәргә тиеш, аңа мал биреп, өлеш чыгарырга кирәк, — ди дә, Урман батырга күп кенә мал бүлеп, бер бөртеге алтын, бер бөртеге көмеш чәчле бичәсен аның карамагына тапшыра. Тагы да әйтә:

— Урман батыр, әгәр дә минем белән дус булырга теләсәң, мин сиңа серемне ачам. Мин ике йөрәкле кеше. Минем йөрәгем шушы булыр, — дип, култык астыннан

алып бер ак беләү ташын күрсәтте, ди. — Минем исәнсаулыгымны шуннан белерсең: иртә белән чык та йолдыз сана; әгәр дә санаган чакта йолдызлар так булса, мин авыру булырмын; әгәр дә йолдызлар җөп булса, мин исән булырмын, — дип, Урман батыр белән кул бирешеп, кочаклашып, саубуллаштылар, ди.

Тау батырның туган иленә килеп җиткәч, Акъял батыр аңа да мал бүлеп биргән, үзенең икенче бичәсен аңа бичәлеккә калдырган. Азак бер курай тоттырган да:

— Тау батыр, син һәркөн саен иртә белән тышка чык та, шушы курайны сызгыртып кара. Әгәр дә сызгырткан чагында кан тамса, мин авыру булырмын; бернәрсә дә таммаса, мин таза булырмын, — дигән.

Тау батыр белән дә кочаклашып хушлашып, Акъял батыр үз иленә кайтып китте, ди. Озак вакытлар үткәннән соң, үз иленә җитеп, кыз батыр бичәсе белән дөнья көтә башладылар. Акъял батыр көн аралаш бер тапкыр урманга сунарга чыга, төрле кошлар, җәнлекләр аулап алып кайта башлады, ди.

Көннәрнең берендә Акъял батыр сунарга чыгып киткәч, бичәсе янына ниндидер бер әби килеп кереп, бераз утыра төшкәч, кыз батырдан:

— Сине ирең яратамы, яхшы торасызмы? — дип сорады, ди. Акъял батырның бичәсе, ирен мактап:

— Акъял батыр белән минем тормышым шундый яхшы, күңелле, һичберкем дә безне аера алырлык түгел! — дип әйтте, ди.

Кыз батыр Акъял батырның илендә яңа гына дөнья көтә башлаганлыктан, бу әбинең кем булуын белә алмаган. Ә ул шушы тирәдәге урманда дию пәриләренең илендә яшәгән бер әби булган икән, ди. Ул Акъял батырның бичәсе бик матур булганлыктан, үзенең улына бичә итеп, урлап китәргә йөри икән. Кыз батыр үз ирен мактый башлагач, боларны аерып булмас микәнни, дип кире чыгып киткән. Акъял батыр һәркөн урманга йөреп, кичен кайтып йоклый да, иртәгәсен тагы да чыгып китә икән.

Ә кыз батыр теге әби турында иренә бернәрсә дә сөйләми икән.

Беркөн теге әби тагы да Акъял батырның өенә килеп керде, ди. Бу килүендә дә Акъял батыр өйдә булмаган. Бу юлы әби икенче хәйлә корып килгән икән. Өйгә кергәч тә:

— Нихәл, балам, яхшы гына яшисеңме? Ирең белән тату торасызмы? Ирең сине яратамы? — ди.

Акъял батырның бичәсе элеккечә:

— Ярата, ярата, әби, — ди.

— Ирем ярата дисең дә диюен, соң иреңнең йөрәге ничәү икәнен беләсеңме? Ул сиңа әйткәне бармы? Әгәр дә мәгәр ирең бик нык ярата икән, үзенең икенче йөрәгенең кайда икәнлеген синнән яшермәс, әйтер. Ә белдерергә теләмәсә, сине яратмавы шул булыр. Ирең кайткач, сорашып кара, сынап бел, — диде дә, тиз генә чыгып китте, ди.

Озак та үтми, Акъял батыр кайтып керә. Үзенең урманда күргәннәрен, бик күп җәнлекләр үтергәнен сөйли. Ашап-эчеп тамак туйдырып алгач, тагы да дөнья хәлен сөйләшеп утырганда, бичәсе кинәт кенә:

— Әй, син мине яратасыңмы? — дип сорау бирде, ди.

Акъял батыр:

— Мин сине дөньядагы бөтен нәрсәләргә караганда да ныграк яратам, сине бервакытта да ташлаячак түгелмен! — ди. Шулчак бичәсе:

— Әй, батырым, яратуың чын булса, җаныңның ничәү булуын әйт, — ди.

Акъял батыр йөрәкләренең кайдалыгын белгертәсе килмәсә дә, бичәсен бик нык яратканлыктан әйтә дә куя:

— Минем йөрәгем икәү, берсе күкрәгемдә, ә икенчесе менә, култык астымда, — дип, култык астыннан ак беләү ташы сыман бернәрсә алып күрсәтте, ди.

Шуннан соң бичәсе бер сүз дә эндәшми. Кич була. Болар йокларга яталар. Иртәнчәк Акъял батыр үзенең

күреп кайткан җәнлекләрен ауларга тагы да сунарга чыгып китә.

Акъял батыр чыгып китеп, күп тә тормый, әлеге әби елт итеп килеп тә керде, ди.

— Йә, кызым, иреңнең сине ятратканын белдеңме, йөрәкләрен күрсәттеме? — ди. Кыз батыр:

— Әби, Акъял батыр мине бик нык ярата бит ул. Җанын миннән яшерми, күрсәтте. Берсе — күкрәгендә, икенчесе — култык астында икән, — ди. Әби моны тыңлап торды да:

— Балам, син сүзеңнең дөреслегенә сынау ясап кара әле. Ирең йоклаган чагында шул култык астындагы җанын берәр җиргә куеп тор, шуннан соң ул нишләр икән,— диде дә, — ярар, балам, мин кайтыйм әле, без моннан байтак ук ерак торабыз, — дип аннан-моннан басып чыгып китте, ди.

Акъял батырның бичәсе: «Ирем дә тиздән кайтып керер», — дип ашарга әзерли башлады. Күп тә үтми, Акъял батыр кайтып керә. Ирле-бичәле кара-каршы утырып, уйнап-көлеп, ашап-эчәләр дә, кич булгач, йокларга яталар. Акъял батыр көн буе сунарда йөреп, арып кайтканлыктан, таңга тартым бик каты йоклап киткән була. Шулчак бичәсе иренең беләү йөрәген урыныннан алып чыкты да, үзләренең өйләре яныннан агып яткан елганың чуерташлары арасына ташлап җибәрде, ди. Бу вакыт теге әби үзе белән берничә кешене ияртеп килеп тә җитә.

Тыштан бик нык тәрәзә кагалар. Акъял батырның бичәсе ирен уятырга итеп карый — Акъял батыр һич уянмый, үлек кеше сыман, бернәрсә дә тоймый тик ята икән. Шулчак хатын моның сәбәбен сизеп ала да, Акъял батырның йөрәген кире урынына куярга дип, тышка йөгереп чыгып китә. Ишекне ачып, ябар-япмастан, ишек төбендә көтеп торган пәриләр аны тиз генә тотып алалар да, атка утыртып, алып чыгып та китәләр. Акъял батыр бернәрсә дә белми, йоклап ятып кала.

Байтак гомер үтеп киткәч, көннәрдән беркөн, Акъял

батырның әйтеп калдырган сүзләре буенча, Урман батыр таң алдыннан чыгып йолдыз санап карады, ди. Бер санап карый — так чыга, ике санап карый — так чыга. Шуннан Урман батыр аны-моны уйлап тормый, тиз генә киенә дә Тау батырга йөгерә. Тау батырга килеп керә дә:

— Акъял батыр үлгән булырга тиеш, — ди.

Тау батыр тиз генә курайны ала да, тышка чыгып, өреп карый. Бер сызгырып җибәрде, кан тамды, ике сызгырып җибәрде, тагы да кан тамды, ди. Болар бер-берсенә карашып тордылар да:

— Болай булгач, эш яхшыдан түгел икән, тизрәк булыйк, — дип, тиз-тиз генә коралларын алып, Акъял батырның иленә чыгып киттеләр, ди.

Өйгә керсәләр — Акъял батыр йоклап ята, өйдә беркем дә юк, ди. Акъял батырны уятырга итеп карыйлар — һич уята алмыйлар. Шуннан тиз генә хәтерләп алып, култык астын ачып карасалар, — теге ак беләү ташы урынында юк, ди. Өй эчен пыр туздырып эзләделәр, эзләделәр — таба алмадылар, ди. Тыштан эзләп карадылар, — анда да таба алмадылар. Шулай итеп йөри торгач, су буена килеп карасалар, Акъял батырның йөрәге чылтырап аккан елга читендә ятканын күреп калдылар, ди. Тиз генә алып кайталар да, Акъял батырның култык астына кыстырып куялар. Акъял батыр беркадәр вакыт үткәч, киерелеп-сузылып:

— Һай, һай, озак йоклап җибәргәнмен, иптәшләр дә килгәннәр икән, — дип урыныннан торып утырды, ди.

Тау батыр белән Урман батыр, бер-берсенә карашып:

— Әйе, Акъял батыр, бик озак йоклагансың шул. Әгәр дә без килеп җитмәсәк, мәңгегә йоклаган булыр идең әле. Йөрәгеңне су төбеннән табып кертеп, үз урынына куйгач кына уяндың, — дип көлештеләр, ди.

Шулчак Акъял батыр, тирә-ягына караштырып, бичәсенең өйдә юклыгын күрә дә бик озак уйга кала. Урыныннан торып:

— Батырлар, мин бу хәлнең серенә төшендем, бу дию

пәриләренең эше булырга тиеш. Минем бичәмне дә, мөгаен, алар урлаганнардыр. Коралланыгыз, дөньяларын туздырып, минем бичәмне тартып алып кайтыйк! — дигәч, батырлар тиз генә киенеп, коралланып, пәриләр яшәгән илгә карап юлга чыгып киттеләр, ди.

Берзаман батырлар пәриләр иленә барып җитәләр. Ләкин сарайга керү бик кыен була. Сарайның тирә-ягына сакчылар куелып беткән икән, ди. Батырлар аңа-моңа карап тормый, сакчыларны кысып алалар, бик күбесен кырып ташлап, сарайның ишеген кыйратып, ишек төбенә кереп утыралар. Шулчак Акъял батыр бичәсенең тавышына охшаган бер тавыш ишетә. Ләкин аның кайсы урында икәнен һич тә төшенә алмый утыра торгач, ашханәгә табан китәләр. Анда барып керсәләр, бер әби бер бәләкәй генә алтын савытка ботка салып тора икән, ди. Акъял батыр әбине күргәч тә, бу тикмәгә булмас, минем бичәмә ашарга әзерли торгандыр, ди дә, әби башка эш белән булганда, бичәсе бүләк иткән алтын балдагын тиз генә ботка эченә батырып куя. Әби зур-зур авыр ачкычларны алды да, алтын савыт белән ботканы күтәреп, сарайның икенче очындагы зур ишекләрне ачып кереп китте, ди.

Әби чыгып китү белән берәү олы тавыш белән елый башлый. Акъял батыр:

— Ишетәсезме, бу минем бичәнең тавышы бит, таптык! Әйдәгез, боларның ояларын туздырып, көлләрен күккә очырыйк! — дип, коралларны кул очларына гына тотып сарай эченә керә башладылар, ди. Очраган бер пәрине үтерә баралар, ахырда бер бүлмәгә кереп, пәри әбинең үзен дә, аның малаен да берьюлы сугып үтереп, тагы да бер ишекне каерып керсәләр, анда зур бер сандык утыра, ди. Батырлар сандыкны ачып җибәрсәләр, — калын ефәк юрганга урап салынган бер бичә ята, ди. Акъял батырның үз бичәсе булып чыккан ул. Батырлар бичәне сандыктан чыгарып алалар да, шунда күмәкләшеп утырып, хәл җыйганнан соң, пәриләрнең бөтен бул-

ган мал-мөлкәтләрен төяп, Акъял батырның иленә кайтып китәләр.

Акъял батырның йортында зур бәйрәм үткәргәч, Тау батыр белән Урман батыр үз илләренә юнәләләр. Шушы көннән башлап бу өч батыр өчесе өч илдә иркен, тыныч дөнья көтеп яталар, ди.

ИСМАЙ

Борын-борын заманда бер патшаның бер дә балалары тормаган: туган бере үлеп торган. Патша, аптырап, күрәзәче әбигә барган.

— Ни эшләп безнең балаларыбыз тормый? — дип сораган.

— Балаларыгыз тугач, егерме яшькә тиклем җир астында асрагыз, — дигән күрәзәче әби.

Шуннан соң кыз баласы тугач, патша аны җир астына яшереп куйган, шунда асраган. Кызга җиде яшь тулгач, аны укыта башлаганнар, җир өстендә якты дөнья барлыгын сөйләгәннәр. Кызның якты дөньяны бик күрәсе килгән. Унике яше тулганда, әтисеннән рөхсәт сораган. Кыз бик үтенгәч, әтисе риза булган, ди, моңа аз-аз гына якты дөньяны күрсәтеп кертер булганнар. Шуннан бу кыз тагы да дәртләнебрәк укый башлаган, якты дөнья белән соклануы артканнан-арта барган. Унҗиде яшенә җиткәч, озаккарак чыгаруларын сораган. Бик матур бер аяз көнне аңа иптәш кызы белән алма бакчасында йөрергә рөхсәт иткәннәр. Шулчакта бер кара болыт килеп чыккан да, җил-давыл кубып, кызны очырып алган да киткән.

Патша бу хикмәткә бик аптыраган, тирә-якка сөрән салган:

— Кем дә кем кызымны табып китерә, шуңа ярты байлыгым белән кызымны бирәм, — дигән.

Патша әмерен ишетсәләр дә, һичкем, батырчылык итеп, кызны эзләргә чыкмаган. Ике-өч ай вакыт үтеп киткән. Шулвакытта эш эзләп йөргәндә, Исмай дигән бер егет патша язып элгән кәгазьне күреп калган да патшага барган.

— Кызыңны табам, ике иптәш, бер пароход, бер еллык азык әзерлә, — дигән.

Патша моңа риза булган, Исмайның әйткәнен барсын да үтәгән. Ике иптәш алып, пароходка бер еллык азык төяп, Исмай хәтәр юлга чыгып киткән. Бик күп вакыт барганнар болар. Бара торгач, диңгез бер тауга килеп терәлгән. Карасалар, диңгез суы, өерелеп-өерелеп, шул тау тишегенә агып ята икән. Пароход белән үтү мөмкин булмагач, болар шушында туктарга булганнар. Кызны эзләп, тау башына менеп киткәннәр. Көн дә икесе эзли, берсе пароходта кала икән.

Беркөнне Исмай белән икенче иптәше кызны эзләргә чыгып киткәч, күп тә үтми, яр читенә бер атлы кеше килеп туктый. Ул үзе бер карыш, сакалы мең карыш була.

— Аттан төшер! — дип кычкыра карт.

Егет аттан төшерә.

— Мине күтәреп эчкә керт! — ди тагы.

Егет картны күтәреп пароходка алып менә. Бабай ашарга сорый. Егет иптәшләренә дигән итне ашата. Карт бөтен ашны ашап бетерә, канәгать булмый, тагы сорый. Егет:

— Башка юк, — дип җавап биргәч, карт егетнең кулын ишеккә кыстырып чыга да китә. Егет кулын чак тартып ала. Бармагы канагач, егет кулын бәйләп куя. Кич белән иптәшләре кайта, ашарга сорыйлар. Егет җавап бирми.

— Кулыңа ни булды?

Егет тагы җавап бирми.

Иртәгәсен икенче иптәшләре пароходта кала. Әлеге сакалы мең карыш, үзе бер карыш карт тагы килә. Килеп, үзен күтәртеп кертеп, пешкән итләрен ашап бетереп, егетнең колагыннан чөйгә асып чыгып китә.

Өченче көнне ике иптәше кызны эзләп китә. Исмай пароходта кала. Теге карт килә.

— Аттан төшер! — ди карт.

Исмай аны аттан төшерә.

— Мине күтәреп керт!

Исмай моны күтәреп пароходка алып керә.

— Ашарга бир! — ди карт.

— Хәзер иптәшләрем кайта, бергә-бергә ашарбыз, — ди Исмай.

Карт, ыргып торып, Исмайга ташланган иде, Исмай моның сакалыннан эләктереп алып, пароходның тоткасына бәйләп куя. Тиздән иптәшләре дә кайта.

— Хәзер мин белдем инде ни өчен сезнең ашыгыз әзер булмаганын, — ди Исмай. — Әнә, чыгып карагыз, бабаегызны асып куйдым, — ди.

Чыгып карасалар — бабай юк, сакалы гына җилфердәп тора, ди.

Иртәгәсен егетләр бабайны эзләп киттеләр. Юлын куып барсалар, теге карт бер мәгарәгә кереп киткән. Болар сакалдан аркан ишәләр дә, берсе мәгарә тишегенә төшмәкче була. Төшә башлагач, караңгыдан, сасылыктан куркып, бу кире чыгаруларын сорый. Аны тартып алалар. Икенчесен төшерәләр. Ансы да кире чыга. Шуннан Исмай үзе төшә. Аркан бетте дигәндә, бу төшеп тә җитә. Караңгы дип тормый, китә бу ары. Бара торгач, бер яланга килеп чыга. Ялан уртасында бер йорт тора, йортта бер әби белән бабай яши, ди. Исмай өйгә керә, саулык сорап, ни эшләп йөргәнен, хәл-әхвәлләрен сөйли. Әби белән бабай тыңлап утыралар да, Исмайга юл өйрәтәләр.

— Моннан ары дию заты яшәгән җир булыр. Тәүдә

кош оясы очратырсың. Кош оясы астында йөз ачкыч, туксан тугызы көмеш, йөзенчесе алтын булыр. Шул ачкычларны алып, йөзенче бүлмәгә җитсәң, анда карт ятар, ә син эзләгән кыз пыяла шкафта булыр, — диләр.

Егет юлга чыга. Тиздән теге кошны да барып таба. Кош шундый усал, егетне якын да җибәрми, ди. Алыша торгач, егет аны җиңә. Ачкычларны оядан ала да бүлмәләрне ачарга тотына. Туксан сигезенче бүлмәдә бөтен диюләр җыелышып киңәш корып утыралар икән. Үзе бер карыш, сакалы мең карышның улы:

— Җир өстендә минем әтигә һөҗүм иткәннәр, иртәгә үк сугышка китик, — ди.

Картның улы сөйләп бетү белән, Исмай ишекне шарачып җибәрә. Диюләр ишектән берәм-берәм чыгып тора, егет аларның башын чабып өзеп тора. Шулай итеп, бөтен диюләрне кырып бетә. Исмай йөзенче бүлмәне алтын ачкыч белән ачып керсә — бүлмәдә чәңгелдәк, чәңгелдәктә карт йоклап ята. Егет аны үтерә дә шкаф эчендәге кызны чыгара. Кыз якты дөнья күрә алмый саргаеп, кибеп беткән, ди.

— Үләсең, егет, тизрәк чык, — ди кыз.

— Нигә чыгыйм, сине коткарырга килдем мин, — дип, Исмай теге картның үле гәүдәсен күрсәтә. Бу шатлыктан кыз:

— Вәгъдәм — антым булыр, — дип, егеткә алтын балдак бирә.

Исмай белән кыз, җир өстенә чыгарга дип, әлеге тишеккә киләләр. Егет тәүдә кызны бауга бәйләп чыгара, аннан үзе күтәрелә башлый. Өстә иптәшләренең Исмайны чыгармаска сөйләшеп торганнарын ишетеп кала да бауга түмәр тагып чыгара. Аркан өзелеп килеп төшә. Егет арканны ялгый да икенчегә үзен бәйләп чыга. Чыккач, берни дә эндәшми. Күмәкләшеп пароход янына киләләр. Ашап-эчеп ял итеп алалар да пароходка утырып кайтып китәргә булалар. Пароходка кереп утыргач, Исмай кулына караса, бармагында теге кыз биргән йөзек юк, юын-

ган җирендә онытып калдырган, ди. Шуны алырга дип, ярга чыккан арада иптәшләре китәләр дә баралар. Кызны куркытып, мине шушы ике егет тапты, дип әйтергә мәҗбүр итәләр.

Исмай утрауда ялгызы торып кала, сунарда йөри, җәнлекләр аулап туклана. Утраудагы бер агачны бер ай буе кимереп ега да, шуңа атланып, диңгезнең аръягына йөзеп чыга. Тирә-ягына караса, еракта бер авыл күренә. Барса, бу авылда дию заты яши, ди. Егет диюләрне кыра да патшаларына бара.

— Миңа эш бир, — ди Исмай. Патша аңа эш бирми:

— Безнең диюләрне кыргансың, — ди.

— Эш бирмәсәң, бөтен дөньяңны тар-мар итәм, — ди Исмай.

— Ярый, алай булгач, — ди диюләр патшасы, — минем ике улым бар: берсе атларга су эчерә, икенчесе печән сала, ә син асларын тазартырсың, — ди.

Исмай атларга су да эчерә, печән дә сала, тизәген дә тазарта. Яхшы эшләгәч, диюләр патшасы моны ярата башлый. Бер ай чамасы вакыт уза. Беркөнне ат эчергәндә, Исмай патша улына:

— Әтиең мине бер айга өйгә кайтарса иде, — ди.

— Ул кайтарыр. Сиңа атның иң яхшысын сайлап алырга кушыр, ә син сарайдагы иң алама атны сора. Кылычларның иң яхшысын сайлатыр, ә син тартмадагы алама кылычны сора, — ди дию патшасының улы.

Исмай патшадан:

— Өч көнгә генә кайтып килимче, — дип сорый. Патша рөхсәт итә:

— Яхшы эшләдең, теләгән атыңны, теләгән кылычыңны сайлап ал, — ди. Егет:

— Миңа яхшысы кирәкми, иясенә күрә биясе, сарайдагы алама ат белән тартмадагы иске кылыч та миңа ярар, — ди. Патша уйлап тора да рөхсәт итә. Егет юлга чыгар алдыннан гына патша моңа бер көзге бирә.

— Атыңа өч сук та күзеңне йомып ач — син түгәрәк

яланда булырсың, шунда ял ит. Аннан тагы өч тапкыр сук та күзеңне йомып ач — кылдан нәзек, кылычтан үткер күперне үтәрсең, шуннан авылыгызда булырсың, — ди патша.

Исмай атына өч тапкыр сугып, күзен йомып ачса, түгәрәк яланда була. Шунда ял итә. Тагы өч тапкыр сугып, күзен йомып ачса, — кылдан нәзек, кылычтан үткер күперне үткән, авылларына җиткән. Авыл читендәге ярлы гына карчыкка керә бу. Караса, патша сараеның башында кызыл әләм җилфердәгәнен күрә.

— Ни уңай белән кызыл әләм элгәннәр? — дип сорый Исмай әбидән.

— Патшабызның кызын тапканнар, алар бүген килеп җитәргә тиешләр, бүген туй була, бөтен халык барырга тиеш, — ди әби. Кичләтеп кенә Исмайның ике иптәше белән кыз килеп төшәләр. Патша халыкны туйга чакыра.

Бөтен халык туйга җыела. Авыл очындагы бу әби иң азак бара.

— Бөтен халык килеп беттеме? — дип сорый патша.

— Юк, бездә бер юлаучы калды, — ди әби. Әбине Исмай артыннан җибәрәләр. Исмай, әбине җәлләп, бара. Патша халыкка:

— Ике егет кызымны тапкан. Икесенә дә кызымны бирәм, — ди. Патша һәр кешегә берәр тустак бал тоттыра. Икенче аякны кыз үзе өләшә. Исмай иң азакта торган була. Кыз аңа бал бирә, егет сул кулы белән алырга итә.

— Уң кулың белән ал, — ди кыз.

— Юк, уң кулым пычрак, тустагыгызны буяр, — ди егет.

— Юк, тотыгыз, пычрамас, — ди кыз. Егет һаман:

— Йогышлы авыру белән авырый ул, — дип тылкый.

— Алай булгач, табибка күрсәтик, — ди кыз. Бөтен халык җыелганлыктан, халык арасында табиблар да була. Шунда ук табиб чакыртып, карарга дип кулын чишәләр. Кыз егет кулында үз балдагын күрә дә патшага:

— Менə мине тапкан егет, ə тегеләре мине куркытып әйттерделәр, — ди. Патша Исмайның ике иптәшен үлем җәзасына тарттыра, кызын Исмайга бирә.

Болар шулай берничә ел рәхәтлектә яшиләр.

Бервакыт икенче патша боларны кунакка чакырып килә. Икенче патшаның улы, кызны күреп, аңа гашыйк булган икән. Егет белән Исмайның кәләше, ничектер инде, үзара сүз куешып та өлгергән булалар.

— Мин сине яу белән барып алырмын, — ди патша улы. Исмай кәләше риза була. Кунактан соң болар кайтып китәләр.

Иртәгәсен патшаның улы бу патшага сугыш игълан итә. Патша Исмайга сугышка әзерләнергә куша. Исмай: «Мин сугышырга теләмим», — дип ята да йоклый.

Теге яу әйтелгән сәгатьтә боларның шәһәренә басып керә. Патша ни эшләргә белми, бик пошына. Исмай, уянып китеп, урамга чыкса, — урам тулы гаскәр, ди. Ул кереп, кылычын алып чыга да бер селтәү белән теге патшаның тезелеп торган гаскәрен кырып та бетерә. Теге патша улы аптырый, кызга хат яза. «Ул нинди кылыч икәнен бел дә сиздерми генә миңа җибәрт», — ди.

Кылычны алыр өчен, кыз Исмайны эчереп исертә. Кыз нәкъ шундый кылычны Исмайның кылычы урынына элә дә анысын патша улына җибәртә. Күрше патша тагы сугыш игълан итә:

— Шул сәгать, шул минутта сугыш булачак, — ди.

Патша тагы Исмайга килә. Егет тагы баш тарта. Әйтелгән сәгатьтә күрше патшаның гаскәрләре килеп җитә. Исмай чыга да кылычы белән селти, кылычы бер дә чапмый. Патша улы кылычы белән селтәп җибәрә, Исмай атының дүрт аягы берьюлы өзелеп төшә. Исмай аптырый, су буена юынырга төшә, дию патшасы биргән көзгегә карый. Каравы була, үзе хезмәт иткән патшалыкта була. Дию патшасы аңа тагы бер көзге белән бер чәчкә бирә.

— Кайда булырга телəвеңне әйтеп, көзгене ватсаң,

шул урында булырсың; икенче затка әйләнергә теләп чәчкәне капсаң, шул затка әйләнерсең, — ди.

Исмай: «Үзем сугышкан патшаның шәһәренә илт!» — дип көзгене ваткан иде, шул шәһәрдә булды, ди. Күп уйлап тормый, шәһәр базарына килә бу хәзер. Бер олы гына картны чакырып ала да:

— Бабай, сиңа акча кирәкме? — дип сорый.

— Кирәк, улым, кирәк, — ди карт.

— Кирәксә, менә син нәрсә эшлә: мин хәзер бер бик шәп атка әйләнермен, син шуны сатарсың, тик бик кыйммәт сора, патша улы гына алырлык булсын. Ә йөгәнне сатма, — ди.

Бабай риза булгач, Исмай, теләген әйтеп, чәчкәне капкан иде, менә дигән матур атка әйләнә. Бөтен халык ат тирәсенә җыела. Аласылары килә — хак бик югары, беркемнең дә алырга көче җитми. Патша улы килә. Биш йөзне бирә дә атны йөгәне белән бергә алып китә. Уйламаган җирдән шулчаклы акча кулга килеп төшкәч, бабай йөгән хакында оныта. Патша улы атны карандаска җигеп алып кайта да, кереп, хатынына әйтә:

— Менә дигән ат сатып алдым, — ди.

Ә хатыны атның Исмай икәнен белә, аны үтерергә куша. Ялчы кызыкай боларның сөйләшкәнен ишетеп кала да, атка килеп:

— Харап итәләр сине, — ди.

— Минем башыма сугарлар, мием чәчрәр, син минем миемне алма бакчасына күм, — ди.

Патша улы чыга.

— Мә, ал кирәгеңне, Исмай! — дип атның башына суга. Суккан көе атның мие чәчрәп, кызның итәгенә барып төшә. Атның сөяген үртиләр. Кыз үзенең итәгенә килеп төшкән мине алма бакчасына илтеп күмә. Шул урында бик матур алмагач үсеп чыга. Ә патша улы белән патша кызы атны үтерүләренә шатланышып яши башлыйлар.

Беркөнне болар икәүләшеп алма бакчасына чыксалар, патша улы яңа үсеп утырган алмагачны күреп кала. Мо-

һача булмаган бу алмагачның алмалары үзе күп, үзе кып-кызыл булып янып тора, ди. Патша улы, моңа бик кызып, алма өзеп алып ашарга омтылган иде, хатыны моны тотып ала.

— Куй, ашама! Ул — алма түгел, Исмай! — дип кычкырып җибәрә. Ире аптырый.

— Ни эшләп барысы да Исмай да Исмай соң әле ул?! — ди.

Шуннан хезмәтчеләренә бу алмагачны төбе-тамыры белән йолкып алып ташларга куша. Ялчы кыз эшне сизеп кала да алмагачка килә:

— Харап итәләр бит сине, — ди.

— Мине балта белән чапкан вакытта читкә барып төшкән йомычканы суга ыргыт, — ди алмагач кызга. Алмагачны чабып егалар, кискәлиләр. Бу эшне кыз читтән генә карап тора. Алмагачны тураклаган чакта, бер йомычка моның алдына килеп төшә. Кыз тиз генә ала да күлгә ыргыта. Йомычка, үрдәккә әйләнеп, йөзеп китә.

Берзаман патша улы сунарга чыга. Күлнең читендә генә матур үрдәк йөзеп йөргәнен күреп, аны атмый гына алырга уйлый. Үрдәккә якын килә. Үрдәк яр читеннән чак кына ерагая. Егет үрдәкне куркытмый гына тагы алга омтыла, үрдәк тагы кача. Шулай итеп, үрдәк ярдан ераграк киткән саен, егет тә суга эчкәрәк керә. Су тирәнәя башлагач, егет чишенеп төшә. Үрдәк кинәт күлгә чумып китә дә Исмайга әйләнеп килеп чыга. Тиз генә ярга чыга да атның ияреннәге үз кылычын ала. Патша улы ярга әйләнеп килеп чыккан иде, каршысында Исмай басып торганын күреп, коела да төшә, Исмай күп уйлап тормый: «Йә, җитәр сиңа, бәдбәхет!» — дип тегенең башын чаба да өзә. Шуннан хатыны яшәгән сарайга килә. Хатыны каршы чыга.

— Гөнаһың зур, — ди Исмай һәм аны да үтерә.

Әлеге ялчы кызны кәләш итеп алып, патша булып, Исмай әле дә яшәп ята, ди.

АЛТЫН ЧАБАК

Борын-борын заманда яшәгән, ди, бер карт белән бер карчык. Болар бик олыгайганнар, бала-чагалары булмаган. Карт белән карчык балык аулап тамак асраганнар. Беркөнне картка бер алтын балык эләгә. Балык телгә килә дә картка болай дип әйтә:

— Син мине үзең ашама, башымны бияңә ашат, гәүдәмне карчыгыңа ашат, койрыгымны этеңә бир.

Карт балыкның әйткәнен эшли. Алтын балыкны алып кайта да башын алты яшәр биясенә, гәүдәсен җитмеш яшьләрдәге карчыгына ашата, койрыгын этенә ташлый. Әби шунда ук гоманлы була, бия колынга, эт көчеккә кала. Күп тә үтми, әби ике ир бала, бия ике колын, эт ике көчек китерә. Малайларның башлары алтын, арт санлары көмеш, ди. Колыннарның яллары алтын, койрыклары көмеш, ди. Көчекләрнең дә башлары алтыннан, койрыклары көмештән, ди.

Бабай куанычыннан ни эшләргә белми, ди. Малайларны тәрбияләп үстерә. Малайлар бик пәһлеван булып үсәләр. Дүрт-биш яшьләрендә урамдагы олы кешеләрне тәгәрәтә сугалар да куялар. Бала-чагаларны сугып үтергән чаклары да булгалый. Малайлар олыларга ябыша башлагач, авыл халкы боларны ничек тә булса олактырырга, авылдан тайдырырга уйлаша. Беркөнне патшага хәбәр итәләр:

— Бер картта ике бала бар, үз яныңа алсаң иде, аларның башлары алтын, арт саннары көмеш, — диләр.

Патша малайларны үз тәрбиясенә ала. Атлары белән этләре дә малайларга ияреп баралар. Патша боларны укыта, сугыш һөнәрен өйрәтә, алтын ияр белән алтын кылыч биреп куя. Малайлар зураеп китәләр, тәүдә күренгәне олы булып исәпләнә.

Җиде яшькә җиткәндә малайларның олысы төш күрә. Төшен энесенә сөйли:

— Кайдадыр бер патшалыкта патша кызын аждаһа

ашарга тиеш икән. Кем дә кем кызны аждаһадан саклап кала, кыз шуныкы икән. Кызны сакларга килгән егетләр чират торалар икән.

Җиде яшәр малайларның олысы төшен юллап китәргә була. Киткән чакта алма агачының бер ботагына пәкесен чәнчә дә, астына табак утыртып, энесенә болай дип әйтә:

— Пәкедән һәрвакыт бал тамар, миңа берәр хәл булса — кан тамар. Шул вакытта мине эзләп чыгарсың, —ди.

Егет шәһәргә барып җитә. Бер әбидән фатир сорый. Бу ярлы гына әби икән.

— Юк, балам, мин бик ярлымын, сине фатирга җибәрә алмыйм. Тамагыңны туйдырырлык рәтем юк, — ди.

— Мин үзем ярлы баласымын, юкка борчылма, әби, — дип егет әбидә кала.

Шәһәрдә бөтен җиргә кара әләм эленгән була. Егет әбидән:

— Әби, нишләп бөтен җиргә кара әләм эленгән? — дип сорый.

— Без аждаһадан су алабыз, шул су өчен аждаһа көн дә бер кызны чиратлап алып китеп тора. Бүген аждаһага патша кызын алып баралар. Шуңа күрә кара әләм эленгән, — ди әби.

— Кызны алып киткәндә мине уятырсың, — ди дә егет йокларга ята. Бервакыт музыка уйный башлый, кызны аждаһага дип алып чыгалар. Әби егетне уята-уята, уята алмый. Әби нишләргә белми торганда, егетнең аты тибенергә тотына. Ат бер тибә — өй чыңгырдап китә; ике тибә — җир чыңгырдый; өч тибә — күк күкри. Егет уянып килеп тора да әбигә:

— Нигә уятмадың? Кызны кайчан алып киттеләр? — дип сорый.

— Уятсам да, уянмадың. Кызны күптән алып киттеләр, — ди әби.

Егет атын менә дә кыз янына чаба. Барса, — бер зур диңгез, яр читендә бишпочмаклы зур йорт; кыз йортка,

качмасын дип, бикләнеп куелган. Егет атын куя да кыз янына бара.

— Зинһар, егет, якын килмә, аждаһа икебезне дә ашар, үзем генә ашалыйм, — ди кыз.

— Юк, — ди егет, — синең урыныңда мин калам, син ат кашына барып көтеп тор, — ди дә егет кызны бәйдән ычкындыра. Кыз ат янына китә. Күп тә үтми, аждаһа килә. Егетне күрә дә аждаһа:

— Һай-һай, чират үзенең кызына җиткәч, патша нинди матур егетне китереп куйган. Моның ите дә тәмледер әле, — ди.

— Кемнеке тәмлерәктер бит, әллә минеке, әллә аждаһаныкы, чамалашырбыз, — ди егет.

— Бирешмәбез, — ди аждаһа, — минем баш өчәү.

— Теләсә кырык булсын!

Егет белән аждаһа алыша башлыйлар. Алыша торгач, егет аждаһаның өч башын да алтын кылычы белән киссеп төшерә дә агач астына тыга, ә гәүдәсен тураклап, зур өч әрдәнә итеп өеп куя. Кыз егеткә үзенең исемле балдагын бирә дә, болар кайтып китәләр. Шәһәргә җиткәч, аерылышалар. Кыз өенә кайтып кергәч тә, патша бөтен шәһәргә кызыл әләм эләргә куша.

Егет әбинең өенә кайта. Кайта да әбидән:

— Мин кызны күрә алмадым, нигә шәһәргә кызыл әләм элгәннәр? — дип сорый.

— Патша, алтын биреп, кызын аждаһадан алып калгандыр. Берәр ярлының баласы булса, аждаһа әллә кайчан ашаган булыр иде инде, сөякләрен дә таба алмаслар иде, — ди әби. — Кызының котылу шатлыгыннан патша бәйрәм итәргә боерган.

Егет йокларга ята. Иртәгәсен торса, шәһәрдә тагы да кара әләм эленгән.

— Нишләп бүген кара әләм элгәннәр? — дип сорый егет әбидән.

— Патша кызын алты башлы аждаһага алып китәргә тиеш. Аждаһа патшага: «Кызыңны ашарга китермәсәң,

бөтен патшалыгыңны туздырам», — дип кәгазь җибәргән, — ди әби.

— Кызны алып киткән чакта мине уятырсың әле, — ди дә егет йокларга ята. Күп тә үтми, музыка уйный башлый, кызны алып китәләр. Әби егетне уятып-уятып карый, уята алмый. Шуннан егетнең эте ишекне тырнап килеп керә дә аягыннан тешләп уята. Егет сикереп килеп тора да, атына атланып, кыз артыннан китә. Барып җитсә, кыз әлеге өйгә бәйләнеп куелган. Егет атыннан төшә дә кыз янына бара.

— Егет, килә күрмә, үзең харап булырсың. Бүген алты башлы аждаһа килә, аны беркем дә җиңә алмый, — ди кыз. Егет кызның бәен чишә дә аты кашына җибәрә, үзе аждаһаны көтә. Күп тә үтми, диңгездән аждаһаның алты башы күренә. Егет янына килә дә аждаһа:

— Ә-ә-ә, кечәге минем баламны үтерүче син икәнсең. Улымны җиңгәч тә, мине дә җиңмәк булдың, ахры. Капкан саен калҗа эләкми ул, итеңне тәмләп йотармын, — ди.

— Йотарсың, йотмый ни! Капкан саен калҗа эләкмәсә дә, алты башның өчесе эләгер әле, — дип егет алтын кылычын селтәп җибәрә. Аждаһаның өч башы шунда ук тәгәрәп килеп төшә. Икенче селтәүдә егет аждаһаның калган өч башын өзеп төшерә. Башларны агачларның төпләренә дыңкычлап салып чыга да гәүдәсен кибәннән дә зур алты әрдәнә итеп өеп куя. Шуннан кыз белән егет кайтып китәләр. Шәһәргә җиткәч, аерылышалар. Кыз егетнең атының ялына кулъяулык бәйли дә атасы йортына китә.

Кызы тагы да исән-сау кайткач, патша бөтен шәһәр буенча кызыл әләм эләргә куша. Егет кайта да әбидән:

— Әбекәй, нишләп шәһәргә кызыл әләм элгәннәр? — дип сорый.

— Патша кызы — патша кызы инде, ярлы кызларының берсе дә аждаһадан кайта алмады, барысы да һәлак булды, патша кызы ике үлемнән котылды, — ди әби. Егет йокларга ята.

— Әбекәй, иртәгә кызны тагы да алып китсәләр, уятырсың, уянмасам, шушы хәнҗәр белән маңгаема чәнчерсең, — дип әбигә хәнҗәрен бирә.

Таң ата, шәһәрдә тагы да кара әләм эленгән була. Бу юлы патша кызын тугыз башлы аждаһа сората икән. Бервакыт музыка уйный башлый. Патша кызын өченче тапкыр аждаһага алып китәләр. Әби уята-уята, егет уянмый. Хәнҗәр белән чәнчергә җәлли, еларга тотына. Әбинең бер бөртек күз яше егетнең битенә тамып яндырып ала. Егет сикереп килеп тора да, атына атланып, этен ияртеп, кыз артыннан диңгез буена китә. Барып җитә, кыз тагы да бәйләнеп куелган. Егет атын куя да кыз янына бара.

— Егет, зинһар, килә күрмә, бу юлы һәлак булырсың, — ди кыз. Егет кызны бәйдән ычкындыра да аты кашына җибәрә, үзе аждаһаны көтеп кала. Күп тә үтми, диңгезне кайнатып, тугыз башлы аждаһа килеп чыга. Килеп чыга да:

— Ә-ә-ә, егет, минем улым белән хатынымны үтергән кеше син икән. Итең бик тәмлегә охшаган, бер кабып йотармын, улым белән хатынымның үчен алырмын, — ди.

— Кабаланмый тор, адәм сөяге как булса да, үткер ул, тамагыңа кадалыр, — ди дә егет аждаһа белән алышырга тотына. Бик озак алышалар болар. Алыша торгач, егет алтын кылычы белән аждаһаның тәүдә өч башын, шуннан тагы да өч башын өзеп төшерә. Аждаһа койрыгы белән өзелгән башларын үз урынына куя. Егет аждаһаның койрыгын өзеп чаба да башларын өчәрләп-өчәрләп кисеп төшерә. Башларны тәгәрәтеп алып барып агач төпләренә дыңкычлап тыгып чыга. Аждаһаның гәүдәсен тураклап, тугыз җиргә тугыз әрдәнә итеп өя. Егет аждаһа белән эшне бетергәч, кызны ала да, кайтып китә. Шәһәргә килеп җиткәч, кыз алтын сәгатен этнең муенына бәйли дә атасы йортына кайтып китә. Патша, кызы өченче тапкыр исән-сау әйләнеп кайткач, шәһәр тутырып кызыл әләм эләргә боера.

Егет кайта да әбидән сорый:

— Әбекәй, нигә тагы кызыл әләм элгәннәр?

— Патшаның кызы бу юлы да исән-сау әйләнеп кайткан. Патша өч көн буена бәйрәм итәргә боерган. Кызны бер батыр егет коткарып тора икән. Патша кызын шул егеткә бирергә булган. Егетне таба алмыйлар. Өч көн буена егет табылмый торса, кызны икенче кешегә кияүгә бирәләр, — ди әби.

Бер көн үткән, ике көн үткән, егетне таба алмыйлар икән.

Шушы патшалыктагы бер картның кырык бер улы булган. Беркөнне улларның иң олысы:

— Әйдәгез, патшага барыйк, кызыңны без коткардык, дип әйтик. Аждаһаны үтергән егетне ике көн буена эзләделәр — таба алмадылар; исән кеше булса, күптән табарлар иде, җаны бар түзеп тә ятмас, тавыш бирер иде,— ди.

— Без күмәкләп бармыйк, арабыздан беребез генә барсын, — ди улларның икенчесе.

— Без үзара көрәшик, кем җиңәр, патшага шул барыр, — ди өченчесе. Башкалары да бу тәкъдимгә кушыла. Кырык ул үзара көрәшә башлыйлар. Әй көрәшәләр болар, әй көрәшәләр, көрәшә торгач, пыр тузышып сугышып китәләр. Кырык беренче ул таз икән. Ул көрәшми дә, сугышмый да читтә генә карап тик утыра икән. Агалары бер сусын көрәшеп, бер сусын сугышып алгач, таз болай дигән:

— Җирәбә салыгыз, кемгә чыкса, кыз шуңа булыр.

Җирәбә салсалар, җирәбә тазга чыга. Егетләр күмәкләшеп патшага китәләр. Барып җитәләр дә:

— Без синең кызыңны алырга килдек, — диләр.

— Кайсыгыз ала соң? — дип сорый патша.

— Менә иң кечебез таз ала, җирәбә аңа чыкты, — диләр егетләр.

— Ярый, — ди патша, кызын бирергә риза була. Шунда ук мунча ягарга куша, мунча әзер булгач, тазны мун-

ча төшертә, мунчадан чыккач, кияү егетне чардакка мендереп утырта.

Шул вакытта теге аждаһаларны үтергән егетне караган әби патшага якынрак килә дә болай ди:

— Миндә бер солдат бар, рөхсәт итсәң, аны да туйга алып килер идек, — ди.

—Хәзер үк алып килегез! — ди дә патша тройка җиктереп җибәрә. Арбаларының күчәре зиректән эшләнгән, ди. Патшаның вәзирләре барганда, егет атын тарап, этен карап тора икән. Вәзирләр килеп җиткәннәр дә:

— Солдат, сине патша чакырта, әйдә утыр, ичмасам, бер туйганчы ашап калырсың, — дип кычкыралар икән.

— Була ул, — ди икән егет. — Яхшы аш алдан калганчы, яман корсак ярылсын!

Егет вәзирләр янына килә дә арбаның үрәчәсенә басып карый.

— Бу мине күтәрмәс, — ди.

— Һо, — диләр вәзирләр, — сине түгел, патшаның үзен күтәрә ул! Синең ишеләр аңа берни тормый, — диләр.

Егет утырса, зирек күчәрләре җимерелеп төшә. Вәзирләр аптырыйлар, кайтып китәләр, патшага әйтәләр. Патша көя:

— Эшкинмәгәннәр, сезне җибәрсәң, шул булыр инде. Ярый, мин үзем барып кайтырмын, — ди.

Егеткә бару өчен патша урамга асфальт түшәтә. Килә, егетне алып китә. Егетнең аты асфальтны аера басып бара икән. Патша моны күреп кала да эчтән генә: «Эх, юлны бозып килә бит бу, каһәрең. Яткач, өендә ятсын иде», — дип, нигә чакырган көнгә төшә. Таз кияү белән патша кызы чардакта басып карап торалар икән. Шулвакытта егетнең аты койрыгы белән юлны тигезләп килә башлый. Патша белән егет чардак тапкырына килеп җиткәч тә, кыз әтисенә:

— Әти, синең киявең менә шушы егет булыр, — дип егеткә күрсәтә.

— Юк, — ди таз, — кызны мин коткардым, кыз минеке, — ди. Тазның агалары да килеп җитеп:

— Кызны без коткардык, кыз безнеке, — дип тырышыналар. Кыз үзе биргән әйберләрне әйтергә куша. Картның кырык бер улы әйтә алмый. Егет кызның әйберләрен куеныннан чыгарып күрсәтә. Картның кырык бер улы һаман да тырышына:

— Кыз безнеке, хәзер үк кызны безгә биреп җибәрегез, — диләр.

— Әйдәгез, алайса, — ди егет, — барыйк аждаһа яткан җиргә. Кемнең хәленнән килә, шул аждаһаларның гәүдәсен икенче җиргә өйсен, — ди. Бу тәкъдимгә риза булалар. Баралар.

— Болай бик батыр булгач, аждаһаның итләрен алып икенче җиргә өегез, — ди егет. Картның кече улы барып тотынып карый — күтәрә алмый. Өчәүләп күтәреп карыйлар — булдыра алмыйлар. Көллесе бергә ябышып күтәреп карыйлар — барыбер булдыра алмыйлар.

— Берегезнең түгел, күмәгегезнең хәленнән килмәде, — ди егет. — Хәзер аждаһаның башын табып китерегез, — ди. Тегеләр эзләп-эзләп карыйлар — башны таба алмыйлар. Таба алмагач, егеткә:

— Без башны шунда гына салган идек, мөгаен, син урлагансыңдыр әле, — диләр. Болар шулай дигәч, егет бара да бер карагайны күрсәтә:

— Аждаһа башы шушы карагай астында ята, карагайны аударыгыз да башны алыгыз, — ди. Тегеләр карагайны этеп карыйлар — ега алмыйлар. Шуннан егет карагайны сыңар кулы белән генә этеп аудара да башны алып бирә.

— Йә, хәзер башны күтәреп карагыз, — ди. Тегеләр башны да күтәрә алмыйча, кулларыннан төшереп җибәрәләр. Хәзер бөтен халык аждаһаны егет үтерүенә ышана. Мәйданга баралар, картның кырык бер улына хөкем чыгаралар:

— Кырык беренә кырык бер багана утыртып, һәр-

берсен бер баганага бәйләп куярга. Һәр баганага берәр без кадарга, үткән бер кеше без белән кырык берен дә чәнчергә тиеш. Кем дә кем чәнчеп үтми, шул кешенең үзен чәнечкәләп үтерергә.

Егет, патша кияве булып, тыныч кына яшәп ята. Беркөнне йоклап яткан вакытта егетнең янына бер алтын кош очып килә. Кош чөйгә утыра да йокларга ирек бирми, бик мазасызлый егетне. Егет, яткан җиреннән торып, тотарга итә, кош тышка очып чыга. Егет атын, этен ияртеп, кош артыннан төшә. Очканда коштан яктылык җиргә төшеп, юлны яктыртып бара икән. Таң алдыннан гына яктылык юк була да куя. Егет кире әйләнеп кайта. Кич булгач, егетнең йокларга ятуы була, әлеге кош тагы да килә, тагы да мазасызлый башлый, егет тагы да кошны куа төшә. Бу юлы таң атарга өлгерми, егет кошның торган җиренә барып җитә. Өйгә барып керсә, шәм ягып бер хатын утыра. Егет хатынга:

— Төнәп чыгарга рөхсәт итмәссезме? — дип эндәшә. Бу юлбасарлар өе икән.

— Рөхсәт, — ди хатын. Егет, тышка чыгып, атын тәрбияли, этенә ашарга бирә. Яңадан өйгә керсә, хатын өстәл артында утыра, өстәлдә кәрт ята.

— Әйдә, кәрт уйныйк, — ди хатын.

— Әйдә, — ди егет.

— Дуракмы әллә отышмы? — дип сорый хатын.

— Отышы ни дә, дурагы ни? — дип сорый егет.

— Бер отылганда — бер адым, ике отылганда — ике адым, өч отылганда өч адым артка басарга, — ди хатын.

— Алайса, әйдә, отыштан булсын, — ди дә егет хатын белән кәрт уйнарга тотына. Егет бер тапкыр отыла, бер адым артка баса, ике тапкыр отыла, ике адым артка баса. Өченче тапкыр отылганда, өченче адымны артка басыйм дисә, баз астына төшә дә китә. Егетнең атын да, этен дә китереп баз астына тыгып куялар.

Таң кыела. Егетнең өйдә калган энесе таң алдыннан тышка чыгып караса, пәкедән кан тама. Моны күреп, ул

агасын эзләп чыгып китә. Патшага бара. Барса, моны патша үзенең кияве дип уйлый. Абыйсы белән энесе арасында бернинди дә аерма юк икән. Моның да башы алтын, арт саны көмеш, аты да, эте дә бер иш. Патшага барып җиткәч, ат караучылар егетнең атын алырга итәләр, бу бирми, атын бер сарайга бикли дә ачкычын үзе салып ала, этен дә үзе карый. Патшаның бөтен кешесе аптырый. Егет хатын белән дә сөйләшми. Хатын, егетне үзенең ире дип уйлап:

— Бу бик йончып кайткан икән, — ди. Кич була. Хатын урын әзерли, хәзер бергә йокларга кирәк бит инде. Егет җиңгәсе белән үзенең арасына кылычын салып ята. Хатынга:

— Шушы кылычны аша чыгып, кул саласы булма, — ди. Хатын: «Бу шаяртадыр», — дип егеткә кулын салыйм гына дигәндә, бүлмәгә әлеге кош очып килеп керә. Хатын егеткә:

— Син киткәч, бу кошның килеп йөрүе басылган иде. Син кайткач, тагы да килгән, — ди. Егет, әһә, дип уйлап ала да кош артыннан китмәкче була. Хатын җибәрми:

— Ул кошта эшең булмасын! — ди. Егет китә, хатын елап торып кала.

Кош оча, аның яктысын күреп, аты, эте белән егет чаба. Әлеге өйгә килеп җитәләр. Егет өйгә керсә, өстәл артында бер хатын утыра, үзе бик матур, бите нурлар бөркеп тора. Егет:

— Төнәп чыгарга рөхсәт итмәссезме? — дип рөхсәт сорый.

— Рөхсәт, — ди хатын. Егет атын, этен бер сарайга бикләп керә, сарайның ачкычын хатынга бирми, үзенең кесәсенә сала. Абыйсына караганда энесе зирәгрәк булган шул.

— Әйдә, кәрт уйныйк, — ди хатын.

— Әйдә, — ди егет.

— Дуракмы әллә отышмы?

— Отыш.

Шартлар әүвәлгечә була. Кем отыла, шул бер адым артка чигә. Егет хатыннан бер отыла, ике отыла. Өченчесендә дә отылган иде, хатынны чәченнән урап торып ала да камчысы белән яра башлый.

— Минем абыйны кая иттең, хәзер үк тап! — ди.

— Белгәнем дә, күргәнем дә юк, — ди хатын.

Егет хатынны бик каты тетәргә тотына. Хатын түзә алмый.

— Абыең базда, — ди.

— Үлеме әллә тереме?

— Үле, — ди хатын.

— Үтерә белгәч, терелтә дә белерсең. Әйт, аны ничек терелтергә?

— Әнә, почмакта ике мичкә утыра. Берсендә үле су, икенчесендә тере су, — ди хатын. Егет ышанмый. Камчысының көмеш сабын тәүдә үле суга тыга. Көмеш сап капкарага әйләнә. Егет камчы сабын тере суга тыга, көмеш алтынга әверелә.

— Бу суларны ничек файдаланырга? — дип сорый егет хатыннан.

— Баз астына төш тә һәрбер чүпкә тәүдә үле суны, шуннан тере суны сибеп чык, — ди хатын. Егет бер почмакка казык кага да хатынны шунда чылбырлап куя. Баз капкачын ача да баздагы чаңга тәүдә үле суны сөртеп чыга, шуннан тере суны сибә башлый. Егет сибеп тора, баздан кешеләр чыга тора. Өй эче тулып китә, сәндерә башларына да кешеләр менеп утыралар. Бу хатынның кәсебе шул булган: алтын кошка әверелгән дә, батырларны ияртеп алып килеп, гел шулай кеше ите ашап ятар булган. Иң азактан егетнең абыйсы үзенең аты, эте белән баздан килеп чыккан.

Егет хатынны чылбырдан ычкындырган.

— Хәзер үк бөтен батырларның да тамагын туйдыр, — дигән. Хатын батырларны икенче бер бүлмәгә чакыра. Керсәләр, анда озын өстәл, өстәл төрле ашамлык-эчемлек белән шыгрым тулы, өстәл тирәләп кызлар тезелгән,

ди. Болар патша кызлары икән, хатын аларны хезмәтче итеп тоткан.

Батырлар ашап-эчеп, һәрберсе берәр кызны алып, егеткә күп рәхмәтләр әйтеп, кайтып китәләр. Егет хатынны базга төшерә дә үле су сөртә, хатын көл-күмергә әверелә. Үле су белән тере суны алып чыга да егет хатынның дөньясын урти.

Агалы-энеле ике җайдак, этләрен ияртеп, кайтып китәләр. Килә торгач, энесе абыйсына:

— Абый, миңа җиңги белән йокларга туры килде бит әле, — ди. Абыйсы: «Ул икебезгә дә хатын булырмы?» — дип уйлый да энесенең муенын чабып өзеп китә. Энесенең атын да җитәкләп ала, эте бармый. Эт тәүдә үле, азактан тере су алып килеп, хуҗасының муенына сөртә. Шуннан соң киселгән башны китереп муенга ябыштыра, тик егетнең йөзен артка каратып ябыштыра да куя.

Егетнең абыйсы, кайта торгач: «Этне дә алып кайтырга кирәк, нишләп соң әле мин аны калдырып киттем», — дип кире әйләнеп килсә, энесе ялгыш карап тора. Абыйсы энесен җәлли.

— Ил өстендә хатын табылыр әле, — ди дә энесенең башын, яңадан чабып өзеп, төзәтеп ялгый. Кайтып килә торгач, энесе абыйсына үпкәли:

— Эх, абый, шулай эшләргә ярыймыни?! Әгәр җиңгәм кочакласа, мин аның кулын чабып өзәр идем. Җиңгәм белән йоклаганда, мин уртага кылыч салып яттым бит, — ди.

Агай-энеле ике егет шәһәргә килеп җитәләр. Патша:

— Киявем берәү иде, хәзер икәү булган, — дип аптырый. Бөтен халыкның исе-акылы китә. Кыз да кайсысын ирем дип әйтергә белми.

— Менә, кода, киявегезне алып килдем, — ди дә энесе патшага барып күрешә. Патша кодасын бик нык сыйлый, бик озак кунак итә. Ашап-эчеп, уйнап-көлеп туйгач, энесе кайтып китә, абыйсы патша булып торып кала.

Алар әле дә дөнья көтеп, йон тетеп яталар, ди.

АЛПАМЫША БАТЫР

Борын заманда бер әби белән бер бабай булган. Аларның һич балалары булмаган. Үзләре бик фәкыйрь торганнар. Җимерелеп беткән өйдә яшәгәннәр. Бабай байда эшләгән. «Картайганда, ичмасам, берәр балабыз да юк бит», — дип кайгырышканнар болар.

Әмәлгә калгандай, бервакыт боларның эштән кайтуына өйләрендә бер бала елап утыра икән.

— Нинди бала бу?

— Үзебезнең бала. — Әби белән бабай би-и-ик шатлана.

— Нинди исем бирәбез?

— Әйдә, Алпамыша дип әйтик.

Күрше-күләнне чакырып, үзләренә күрә исем туе үткәрәләр. Бала бик таза була: көн үсәсен сәгать үсә, ел үсәсен ай үсә. Бер-ике ел үтүгә, эшләп йөри, әтисенә ярдәм итә.

— Син, әти, картайгансың, ял ит. Синең урыныңа үзем барып эшлим, — ди.

Әтисе:

— Балам, яшьсең әле, эшләргә өлгерерсең, — ди.

Алпамыша әтисенең ай-ваена карамый, эшкә үзе йөри. Әтисе бик нык шатлана. Нинди генә эш булса да, малай бик тиз, бик әйбәт эшли.

Берчак, эшләп йөргән мәлендә, Алпамыша ниндидер патшалыкта ниндидер мәйдан булганын ишетеп кайта. «Әти, миңа бер ат алып бир, — ди. — Бер патшалыкта мәйдан була икән, шунда көрәшкә барам», — ди. Әтисе кайгыга төшә.

— Ат алырлык хәл юк бит әле, балам, — ди.

Алпамыша ике уйлап тормый, ат эзләргә үзе чыгып китә. Бер күрше авылдагы байга бара.

— Берәр атыңны бир миңа, бай, — ди. — Хакын берәр вакыт түләрмен, — ди.

Бай карышып тормый.

— Әнә аранга кер дә үзең теләгән атны сайлап ал, — ди. Алпамыша иң элек сбруй келәтенә кереп, иң яхшы йөгән белән камчы сайлап ала. Аннан аранга керә. Атлар юшап тора икән. Йөгән шылтыратканга кайсы ат караса, шул ат аныкы була икән. Йөгәнне шылтырта бу, нача-а-ар гына корчаңгы ат карый.

— Миңа туры карагач, бәхетем шуннандыр, — дип шушы бәләкәй генә тулакны тотып алып чыга. Бик әйбәт итеп торып иярли. Хәзер корал да сорый:

— Бай, ук-җәя, кылыч бир миңа, — ди. Теге бай барын да бирә.

Алпамыша атны җитәкләп бик күп җирләр үтә, кайту ягына бара. Ат үзеннән-үзе зурая килә, ябагасын коя килә. Бара торгач, ат бик яхшы бер тулпарга әйләнә. Кайтышлый, бер елгага төшереп, атын эчереп ала да менеп утыра тегенең өстенә. Шулчак ат телгә килә:

— Алпамыша батыр, бер сук — тиремә үтәр, ике сук — итемә үтәр, өч сук — җилегемә үтәр, — ди.

Алпамыша суга. Шуннан ат тагы телгә килә:

— Күзеңне йом, батыр, — ди.

Алпамыша күзен йома. Шул арада күз ачып йомганчы ат егетне үзенең ишек алдына китереп тә куйган була. Әнисе-әтисе каршы чыга.

— Әй балакаем, кайсы илләрдә йөрдең, ни михнәтләр күрдең? — дип елый әнисе.

— Еламагыз, кайттым бит инде, — ди Алпамыша батыр.

Шул кичен куна да иртәгесен Алпамыша мәйдан тотылган патшалыкка китә. Моның баруына бик күп халык җыелган була. Көрәш бара икән. Алпамыша, атын җибәреп, үзе генә барырга итә. Шулчак аты әйтә:

— Өч бөртек кылымны алып кал. Ни вакыт кыл үтә сызгырсаң, шулвакыт килеп җитәрмен яныңа, — ди.

Алпамыша атын җибәрә дә, мәйданга якын ук килеп, көрәш арасына килеп керә. Тәүдә бераз карап тора. Бер

батырга каршы беркем дә чыкмый, куркалар. Алпамыша батыр:

— Тастымалны бирегез, үзем чыгамын, — ди.

Бөтен халык хәйран кала. Байлар, мыскыллап:

— Әй, бу йолкыштан буламыни? Нинди таза-таза егетләр чыгып җиңә алмыйлар, — дип көләләр.

Бер кешенең сүзенә карамый, үзенә-үзе куәт биреп, үзенә-үзе дәрт биреп, Карабатырга каршы чыга Алпамыша. Карабатыр, җир тырнап, моңа килә инде, янә дә моны куркытырга. Болар алышырга тотыналар. Алыша торгач, икесе дә тез тиңелте җиргә баталар. Бердәнбер-вакыт теге Карабатырны Алпамыша батыр җирдән суырып алып, күккә чөеп җибәрә. Карабатыр җиргә килеп төшә алмый, Алпамыша батыр тегене кулы белән тотып ала. Кайсы халык кычкыра:

— Булмады да булмады! — Байлар инде. Кайсылары:

— Булды, булды! — ди.

Шуннан Алпамыша батыр, гарьләнеп китеп, Карабатырны икенчегә чөеп җибәрә.

— Юк, болай булмый! — дип өченчегә көрәштерәләр. Өченчесендә Алпамыша казах батырын шултиклем нык күтәреп җибәрә, әллә кайда күккә олгаштырып, халык күзенә күренмәслек итеп, өскә ыргыта. Шулай ук җиргә төшерми, күтәреп алып, Карабатырны үзе утырган паласка, байлар янына, илтеп утырта. Алпамыша батырны бөтен халык мактый.

— Кайдан килгән бу батыр? Кайдан килгән бу батыр? — дип барчасы уратып ала. Кымыз эчерәләр, бүләкләр бирәләр.

Патшаның шарты болай булган була:

— Карабатырны кем җиңә, чабып килгән килеш боҗрадан кем ук үткәрә, кызымны ашарга килгән алты башлы аждаһаны кем үтерә, шуңа ярты патшалыгымны бирәм, — дигән, ди.

Шушы өч шартның тәүгесен Алпамыша үтәде бит ин-

де. Хәзер икенчесен үтәргә кирәк. Атлар җибәрәләр чабыштырырга бер иллешәр чакрымга. Теге божраны бие-ек тау башына мендереп куялар. Шуңа күз күреме җирдән атарга кирәк була.

Алпамыша иптәшләрен алдан җибәрә, үзе арткарак кала. Берсе дә үткәрә алмый угын божра эченнән. Алпамыша батыр үзе ерактан аткан була. Атып җибәрә — Алпамышаның угы, божраны үтеп чыгып, мәйдан уртасына килеп кадала.

Алпамыша батырны мәйданда шау-гөр килеп күтәреп алалар.

Икенче бер патшалыктан, үч итеп, патшаның кызын алырга алты башлы аждаһа җибәрәләр. Патша кызын таш келәткә бикләп куя. Сакчылар куела. Алпамыша батырны кыз янына китерәләр. Алпамыша батыр кызга:

— Мин бераз йоклап алам. Менә сиңа хәнҗәр. Аждаһа килсә, шуның белән берәр җиремә кадарсың, — ди.

Алпамыша батыр утырган килеш кенә йоклап китә. Теге аждаһа, җир тетрәтеп, гауга куптарып, кара буран туздырып килгән була. Кыз бик нык, чын күз яшьләре белән елый, хәнҗәре белән Алпамышага кадарга җәлли. Шулвакыт әче күз яше Алпамышаның битенә төшә. Шушы яшь тамчысыннан Алпамыша уянып китә.

— Һи-и-и-и, сылу, бик озак йоклаганмын бит! Нигә иртәрәк уятмадың? — ди. Тирә-ягына караса, Алпамышының янында өстәл тулы азык, ди. Ашап торырга вакыты булмый, бер-ике җамаяк кымыз эчеп ала. Эчеп бетүгә, аждаһа бик яман үкереп, капкаларны, тимер ишекләрне ачып, кереп килгән була. Алпамыша батыр моңа каршы чыга. Кызы, елап, ишек алдында карап тора.

Аждаһа:

— Патша миннән берне түгел, икене җәлләмәгән икән: кызын да, бу егетне дә китереп куйган. Бик тешләрем дә, кулларым да кычытып тора иде, — ди. Алпамыша батыр әйтә:

— Кычытса кычытадыр. Әйдә, алай булгач, алышабызмы, көрәшәбезме? — ди.

Шуннан аждаһа, мактанып:

— Син миңа бер кабымлык кына бит инде, нишләп мин синең белән көрәшеп торыйм? — ди.

Алпамыша аждаһаның ай-ваена куймый:

— Алышмы, көрәшме? — ди.

Шулай итеп, болар алышырга тотыналар. Ике төн, ике көн алышалар. Өченче көнен Алпамыша аждаһаның азаккы башын өзеп алып, тураклап, зур бер таш астына кыстырып куя.

Шуннан кыз, кайтып:

— Алпамыша батыр аждаһаны җиңде, — ди.

Патша, вәзирләрен җибәреп, сарайга чакырта Алпамышаны. Бара Алпамыша патша кырына. Патша бик шатлана.

— Ярар, егет, мин сиңа рәхмәт белдерәм, — ди. — Әйткән сүземдә торамын. Менә, — ди, — өчәү иде кызларым,— ди. — Иң кечесе генә торып калды, икесен элгрәк килеп, аждаһа ашап китте,—ди.—Син кече кызымны коткардын, шатлыгымнан ярты патшалыгымны бирәм, — ди. — Күңеленә ошаса, кызымны да ал, — ди. Кызыкай Айсылу исемле була.

Шулай итеп, монда туй ясыйлар. Патша бөтен илдән үзенең дус-ишләрен чакырган була. Алпамышаның этиәнисен дә алдырта. Туй айдан ашу бара — озак бәйрәм итәләр.

Азак Алпамыша эти-әнисен тотыш күчереп алып килеп, бер сарайда тота. Ялан тулы көтү, үзенең хезмәтчеләре була, яртылашын ярлыларга таратып бирә.

Алпамыша батыр тулпарына атланып, ерак-ерак җирләрдә сунарда йөри. Өч көн, өч төн йөрсә, өч көн, өч төн йоклаган була. Сунардан кайтып килешли һәрчак бер бие-е-к тау башына менеп утыра да атын акланга ашарга җибәрә икән. Үзе бик каты йокыга тала, ди.

Карабатыр моның кайларда йөргәннәрен күзәтеп йөргән икән. Карабатыр берчак якыннарына әмер бирә:

— Алпамыша батыр кайда йоклаган, шунда бик тирән итеп чокыр казыгыз, — ди.

Унике җайдак килеп, Алпамышаның йоклаган урынын табалар. Монда бик тирән итеп җир казыйлар. Алпамыша батырны йоклаган килеш шул чокырга очыралар. Моның өстенә яшел агачлар аударалар. Атын алып кайтып китеп, таш келәткә бикләп куялар. Шулай итеп, бу Карабатыр хәзер мактана: янә инде дөнья йөзендә ул гына батыр!

Айсылуга яучы җибәрә:

— Синең Алпамыша батырың үлде, мин сине аламын. Бер атнадан туй ясыйбыз! — ди.

Яучы килгәннән соң Айсылу бик кайгыра, көн елый, төн елый. Айсылуның ай-ваена куймый, туй ясарга булалар.

Бу вакытта инде Алпамыша батыр теге чокырда унике көн яткан була. Айсылуның иптәшләре, унике-унбишләп кыз җыелып, яланга җиләккә чыккан икән, ди. Җиләк җыеп йөргәндә, алар кайдандыр җир астыннан бер бәет ишетәләр:

Озын чәчле, кара кашлы Айсылуым бар микән?
Ялы-койрыгы җиргә тигән туры тулпарым бар микән?

— Карабатырның эше генәдер, исән-саулар шушыннан чыксам, күккә чөяр идем үзен, — дип үзалдына үзе сөйләнә Алпамыша батыр.

Теге кызлар тавышны юллап килеп, Алпамыша утырган чокырны килеп табалар.

— Кем анда? — дип сорыйлар кызлар.

— Мин, мин. Мин Алпамыша батыр. Айсылуым исән микән? Минем тулпарым кайда йөри икән?

— Тулпарың монда акланда юк. Айсылуың йортта, исән. Карабатыр туйга әзерләнә, — дип җаваплыйлар кызлар.

— Айсылу килсен иде монда, кайтып әйтегез әле, — дип куша Алпамыша кызларга.

Тегеләр йөгерешеп кайтып китәләр дә, Айсылу янына килеп:

— Сөенче, Айсылу! Алпамыша батыр исән. Сине чакыра үзе янына, — диләр.

Бу кызларның әйтеп бетүе була, Айсылу чыгып та йөгерә. Кумәкләшеп, һә дигәнче килеп тә җитәләр чокыр янына. Айсылуның чәче бик озын булган була. Башын иеп, Алпамыша чокырына чәчен төшерә. Никадәре озын булса да, Алпамышаның буе җитми.

— Минем тулпарны табыгыз, юкса эш начар, — ди Алпамыша.

Кызлар тулпарның таш келәттә бикле торганын белгән була.

— Ничек тә булса, келәтнең ачкычын урлагыз, — дип өйрәтә Айсылу кызларга.

Кызлар, сакчыларны алдап-йолдап, ачкычны урлыйлар. Туй барган вакытта уйнап йөргән булып, сарайны ачып җибәрәләр. Тулпарның чыгып чабуы була, кызлар, куркышып, чәрелдәшеп качып бетәләр. Тулпар, җир тетрәтеп, Алпамыша яткан җиргә чабып бара. Чабып барып та җитә, чүгәли биреп, чокырга койрыгын төшереп тә җибәрә. Алпамышаны сөйрәп чыгара. Чыккач, тиз генә тулпарына атлана да сарайга карый чаба батыр. Сарайга җитәрдән алдарак атын җибәрә дә үзе җәяүләп кайтып керә. Бу вакытта инде Айсылуны чыбылдыкка япкан булалар.

Алпамыша батырның сарае зу-у-р була. Аш бүлмәләре генә унике урында икән, ди. Кайтса, шуларның һәркайсысында аш өлгереп килә икән, ди. Хезмәтчеләре Алпамышаны танымыйлар: сакал-мыек баскан тегене.

— Ашыгыз өлгерәме әле? Ачыктым, юлчыны ашатып җибәрегез, — ди икән Алпамыша.

— Өлгерә, өлгерә, — диләр хезмәтчеләре.

Карабатыр унике урындагы ашны тәмләп йөри, аның

артыннан төшеп, Алпамыша һәр казанның ашын ашап бетереп йөри, ди. Соңгы казанны тәмләгәч, Карабатыр, сарайга кереп, аш көтеп утыра, ди. Алпамыша батырның азаккы казанны да ашап бетереп килгәнен күреп, хезмәтчеләр бик курыккан, ди. Алпамыша тегеләргә, тавышланмагыз, дип бармак кына янап куя, ди.

Ашап беткәч, Алпамыша Карабатыр янына керә. Тегесе танымый моны.

— Карабатыр, син ни эшләп ятасың? Алпамыша терелеп чыккан бит, әле кайтып килә, — ди Алпамыша батыр.

Карабатыр, үзен-үзе йолыккалардай булып, патша янына бара.

— Солдатлар бир, Алпамышага каршы чыгам, — ди.

Патшалыкта күпме соладт бар, шуны алып, Алпамышага каршы китә янә дә. Ә Алпамыша батыр монда ашапэчеп йөри.

Алпамыша җәһәт кенә кырынып, юынып-чайканып ала да, тимер киемнәрен киеп, коралланып тышка чыга. Атын тиз генә кыл үтә сызгыртып алып, Карабатырга каршы китә. Карабатыр солдатларын сафка тезеп кенә тора икән. Алпамыша батыр моның янына чаптырып килеп җитә:

— Йә, Карабатыр, әзерсеңме мәйданга чыгарга? — ди. — Мин сине, бик яхшы итеп әзерләнгәч, көтеп торасыңдыр дип уйласам, син гаскәр белән каршы торасың икән дә, — ди.

Карабатыр, юхаланып:

— Кайларда булдың? Ни арада кайтып җиттең? — ди.

Солдатлар да аптырап кала: чынында Алпамыша солдатлары бит инде.

Алпамыша әйтә:

— Йә, җитәр, син минем баштан көләргә уйлаган идең, килеп чыкмады бу эшең. Юхаланма юкка, Айсылуны табып китер! — ди. Айсылуны яшергән булалар бу чак.

Айсылуны һә дигәнче таптыра. Вәзирләренә әмер бирә:

— Карабатырны зинданга ябып куегыз, кирәк вакытта үзем чыгарырмын, — ди.

Алпамышаны сарайда бик яхшы итеп каршы алалар. Айсылу елый.

Бердәнбер көнне Алпамыша вәзирләренә:

— Сумала кайнатыгыз! — дип әмер бирә. Сумала кайнагач, Карабатырны зинданнан чыгарта.

— Шул кайнап торган казаннан чумып чыга алсаң, яшәрсең; чыга алмасаң, шунда калырсың инде, — ди Карабатырга.

Карабатыр бик нык итеп җир тырнап елый гарьлегеннән. Алпамышага башын иеп, аягына егыла:

— Мине харап итмә! — ди.

Алпамыша Карабатырга:

— Син куркак! — ди.

Мәйдан җыела. Шушы мәйданда Алпамыша Карабатырның башын кылыч белән чабып өзә.

Алпамыша әле булса Айсылуы белән тора, һаман батыр булып йөри бирә, ди.

ОМОРЗАК БАТЫР

Борын-борын заманда бер әби белән бабай булган. Аларның бер уллары туган. Аңа Оморзак * дип исем биргәннәр. Әби белән бабай бик ярлы булганнар. Оморзакны бер байга малайлыкка биргәннәр. Оморзак бик тиз үскән, батыр булып җитешкән. Бермәлне бер патша бәйрәм оештырган. Бу бәйрәмгә Оморзак та барган. Патшаның

* *Оморзак* — гомере озак (булсын) сүзләреннән ясалган исем.

бер кызы бар икән. Бу кыз Оморзакка гашыйк булган да үзенең этисенә әйткән:

— Әти, бирсәң дә, бирмәсәң дә — барыбер шушы егеткә кияүгә чыгам, — дигән.

— Ярар, кызым, чык, — дигән патша. Шуннан Оморзакны чакырып алган:

— Кызым сиңа кияүгә чыгам, ди. Әгәр мин сораган калымга риза булсаң, кызымны сиңа бирәм, — дигән.

— Ярый, мин риза, — дигән Оморзак.

— Минем бер пәһлеваным бар, аңа хәтта өч кеше бергәләп тә каршы тора алмый. Шул пәһлеванны егып үтерсәң, сиңа кызымны бирәм, — дигән патша.

Патша белән пәһлеван бер-берсен күралмыйлар икән.

— Ярый, — дигән Оморзак.

Шуннан патша теге пәһлеванны китерткән дә, болар көрәшә башлаганнар.

— Нәрсәгә ышанып, минем белән көрәшкә чыктың? — дип сораган теге пәһлеван.

— Әй, батыр, алай сөйләнмә! Кяфер сүзләр әйтәсең, — дигән Оморзак.

Әй көрәшәләр болар, әй көрәшәләр. Көрәшә торгач, Оморзак теге пәһлеванны һавага ыргытып җибәргән дә төшеп килгән чагында тегенең башын аягы белән тибеп өзгән дә чыгарган.

Патша бөтен җиргә әләмнәр эләргә, музыка уйнатырга, ура кычкырырга кушкан. Шуннан кызын Оморзакка биргән.

Бераз торгач, Оморзак патша булып киткән. Патша булгач, хатынын алган да туган өенә кайтырга чыккан. Кайтып барганда, Оморзакның улы туган. Бер төркем патша солдатлары боларны озата киләләр икән. Бер зур елга буена килеп җиткәч, сал саллап, елга аша чыга башлаганнар. Елга уртасына килеп җиткәч, салны бернәрсә тоткан да алган. Бу аждаһа икән.

— Улыңны бирсәң, елга аша чыгарга рөхсәт итәм;

бирмәсәң, салыгызны да, үзегезне дә суга батырам, — дигән аждаһа.

— Тәүдә яр буена барып җитик, шуннан соң мин сиңа улымны бирермен, — дигән Оморзак. Аждаһа салны күтәреп алган да күз ачып йомганчы яр буена китереп тә куйган. Шул җирдә Оморзакның улы әтисенә болай ди икән:

— Әти, син мине аждаһага бирмә, мин аның белән көрәшәм.

— Ярый, улым, көрәш, — дигән Оморзак.

Әтисеннән рөхсәт булгач, әлеге малай аждаһа белән көрәшергә тотынган. Аждаһаны әләктереп алган да җиргә сеңдерә суккан да куйган. Аждаһаны үтереп, болар кайтып киткәннәр.

Кайтып килсәләр, Оморзакның әтисе белән әнисе бик картайганнар, ди. Оланнарының исән-сау кайтуын күреп, шатлыктан елашып та алганнар. Оморзак, бик зур мәҗлес җыеп, үзен патша итеп игълан иткән. Авылга патша булып киткән.

Күрше авылда да бер патша булган. Бу патша кызын кияүгә бирү уңае белән зур туй үткәреп ята икән. Оморзакны да кунакка чакырган, башка халыклар да күп җыелган. Оморзакның бер батыры булган. Теге патшаның батыры Оморзакның батырын җиңгән. Шул җирдә Оморзак сикереп торган да теге батыр белән үзе көрәшмәк булган. Көрәшә башлаганнар икән, теге батыр Оморзакны да җиңгән. Шулвакыт Оморзакның улы йөгереп чыккан да:

— Әти, бу батыр белән мин көрәшим әле, — дигән.

— Куй, улым, син яшьсең бит әле, — дигән Оморзак.

— Көрәшим инде, әти!

— Ярый, алай булгач, көрәш, — дигән әтисе.

Оморзакның улы теге батыр әргәсенә барган да, болар, бер-берсенең биленнән алып, көрәшә башлаганнар.

— Нәрсәгә ышанып минем белән көрәшергә чыктың? — дип сораган теге батыр.

— Батыр, артык сүз сөйләмә. Үлсәм, батыр кулыннан үлим дип уйладым, — дигән Оморзакның улы.

— Ярый, — дигән теге батыр, — алай булгач, мин синең билеңне сындырыйм әле!

Шулай итеп әйтешкәннәр дә көрәшә башлаганнар. Әй көрәшкәннәр болар, әй көрәшкәннәр, көрәшә торгач, Оморзакның улы теге батырның колагыннан гына тотып алган да һавага чөеп җибәргән. Һавадан җиргә төштем дигәндә генә, йодрыгы белән теге батырның арт санына биргән икән, батыр көлгә әйләнгән дә куйган. Патша бик курыккан, ди. Куркуыннан астына хәтта комташ җибәргән, ди.

— Болай булгач, минем кызымны улыңа кодала, — дигән патша Оморзакка.

— Ярар, бирсәң, кодалармын, — дигән Оморзак.

Оморзак, патша кызын кодалап, улына кәләш алып биргән. Алты көн буе туй барган. Туйда тагы да көрәш башланган. Оморзакның улына каршы беркем тора алмаган. Теге патшаның да (хәзер кодасы булды бит инде) бер улы бар икән. Шул малай торган да:

— Әти, җизнәм белән мин көрәшеп карыйм әле? — дигән.

— Ярый, көрәшеп кара, — дигән әтисе. Шуннан теге малай җизнәсе эргәсенә килгән:

— Әйдә, җизни, бер-беребезне күтәрешеп, көрәшеп карыйк, — дигән.

— Куй, каениш, көрәшмик, оят булыр, — дигән җизнәсе.

— Булмаса, бер-беребезне күтәрешеп кенә карыйк та шуннан туктарбыз, — дигән каенише.

— Ярый, алай булгач, әйдә, көрәшик, — дигән җизнәсе. Шуннан җизнә белән каениш көрәшә башлаганнар. Җизнәсе каенишен күтәреп алган да, һавада өерелтеп-өерелтеп торып, җиргә атып бәргән.

— Ай-һай, җизни, бик батыр икәнсең, — дигән каенише.

Оморзакның улының улы туган. Ул әтисенә бер дә охшамаган, үзе бик матур булган. Теге патша кызының улына патша исеме биргән. Бервакыт Оморзакның улы патшадан туган якларына кайтырга рөхсәт сораган.

— Әй, патшам-солтаным, безгә туган илгә кайтырга рөхсәт ит, — дигән.

— Рөхсәт итәм, кайтыгыз, — дигән патша.

Оморзакның улы хатынын, улын алып, кайтып киткән. Килә торгач, биек тау башында гаскәр күреп калганнар. Якынрак килеп карасалар, бу дию пәриләре икән. Шул җирдә дию пәриләре патшасы Оморзакның улының улына:

— Әйдә, безнең белән көрәш, — дигәннәр.

— Минем улым яшьрәк әле, мин үзем көрәшәм, — дигән дә Оморзакның улы көрәшергә тотынган. Оморзакның улы берничә батырны еккан. Иң азак диюләр патшасының батыры чыккан. Әй кычкырып та үкереп, җирне тырнап килә, ди, бу. Шулвакыт диюләр патшасы әйткән:

— Кем шушы батырны җиңә, шуңа кызымны бирәм, — дигән.

Оморзакның улы көрәшкә чыгарга торса, улы килгән дә:

— Әти, тукта, мин көрәшим, — дигән.

— Ярый, улым, көрәш, — дигән әтисе.

Болар көрәшә башлыйлар. Өч көн, өч төн көрәшкәннәр. Оморзакның улының улы дию патшасының батырын һавага атып җибәргән икән, теге батыр килеп төшкән уңайга җиргә сеңгән дә беткән. Шуннан дию патшасы кызын Оморзакның улының улына биргән.

Оморзакның улы кайту ягына юлын дәвам иткән, ә улы, патша кияве булып, кунаклап ятып калган.

Күп тә үтмәгән, диюләр патшасына үләргә вакыт җиткән. Аның бер генә улы да булмаган. Бердәнбер шушы кызы гына булган. Дию үзенең патшалыгын кызына биреп үлгән, кызы киявенә биргән. Шулай итеп, Оморзак-

ның улының улы бөтен диюләргә патша булып киткән. Бервакыт Оморзак улының улы ябыга, саргая башлаган.

— Нигә болай ябыгасың? — дип сорый икән хатыны.

— Минем әтием белән әнием бар бит, шуларны сагынам, өйгә кайтып килергә иде, — ди икән Оморзак улының улы. Шуннан ул хатынын алган да бөтен диюләре белән кайтып киткән. Оморзак та патша булган, аның улы да патша булган, улының улы да патша булып киткән. Алар өчесе дә ил белән яхшы идарә итеп яталар икән.

Бүген шунда киттем, кичә кайтып җиттем.

КАМЫР БАТЫР

Борын-борын заманда яшәгән, ди, бер бабай белән бер әби. Бабай балык аулаган, шуның белән көн күргәннәр, ди. Барын барга исәпләп, югын юкка исәпләп яшәп биргәннәр, һичнәрсәгә зарланмаганнар, ди, болар. Тик балалары булмау гына аларның эчләрен пошырып торган да торган, ди. Йончу бер көнне бабай үзенең гадәтенчә диңгезгә балыкка барган. Диңгезгә авын салып, тартып алган икән — сәер бер балык эләгеп килеп чыккан. Бу балыкның тәңкәләре алтыннан да көмештән, гәүһәрдән дә якуттан гына икән. Күзнең явын алып торалар, ди.

Бабай, балыкны учына салып, озак карап торган да: «Моны ашап тамак туймас, яши бирсен әйдә», — дип диңгезгә ташлыйм гына дигәндә, балык телгә килгән:

— Бабай! Мине алып кайт. Итемне улларыңа ашат, канымны атларыңа эчер, сөякләремне этләргә бир, — дигән.

Бабайның уллары булмагач, аптырап калган. Ни эшләргә белми торган-торган да, ни булса да булыр дип, балыкны алып кайтып киткән.

Кайткач, тупсасын аша атлап, сүз катарга да өлгермәгән, карчыгы, ике малай күтәреп, каршысына килеп баскан.

— Күрәсеңме, бу малайлар безнең улларыбыз! — дигәч, бабай тагы да ныграк гаҗәпкә калган. Шуннан моның карчыгы бабай балыкка киткәч тә ни булганын сөйләп биргән.

— Син балыкка чыгып китүең белән камыр бастым да, ике малай ясап, сандыкка салдым, — дигән әби. — Шул арада үзем ишек алдына чыгып әйләндем. Килеп керсәм, колагыма бала елаган тавыш чалынгандай булды. Ипләбрәк тыңласам, тавыш сандык эченнән килә. Сандыкны ачып җибәргән идем, шаккаттым: минем бая салып куйган малайларыма җан кергән!

Ни әйтергә белмичә катып калган бабай, һушына килгәч, баягы балыкның әйткән сүзләрен исенә төшергән. Шуннан балыкның итен малайларга ашаткан, канын ике атына эчергән, сөякләрен ике этенә ташлаган.

Могҗизалы балыкның итен ашагач, малайларның башлары, алтын балык тәңкәләре кебек, асылташлар белән капланган. Бу малайлар көн үсәсен бер сәгатьтә үскәннәр. Моңа бабай белән әби бик куанганнар, үзләрен дөньяда иң бәхетле кеше итеп санаганнар, зурысына Камыр батыр дип исем кушканнар.

Бервакыт Камыр батырның дөнья гизеп йөреп кайтасы килгән. Аның бу уен белеп, бабай белән әби кайгыга калганнар. Камыр батыр үтенеп сорагач, җибәрергә риза булганнар.

Беркөнне Камыр батыр әтисенә:

— Әти! Миңа унбиш пот чуеннан чукмар койдыр, аннан да авыррак итеп кылыч суктыр, — дигән.

Әтисе чукмар белән кылыч эшләтеп биргәч, Камыр батыр коралларын сынамак булып, бер яланга чыккан.

Шуннан бу теге унбиш потлы чукмарны шундый итеп күккә селтәп җибәргән, чукмар хәтта күздән югалган. Байтак вакыттан соң төшеп килгәне күренгәч, Камыр батыр аның астына үзенең ялангач башын куйган. Чукмар, моның башына бәрелеп, челпәрәмә ватылган да тирә-якка чәчрәгән. Камыр батыр бу чукмарның ярчыкларын җыеп кайткан да, тагы да авыррак итеп, икенче чукмар койдыртып алган. Баягыча сынап карагач, монысын яраклык тапкан.

Чыгып китәргә әзерләнеп беткәч, Камыр батыр бер укны җепкә бәйләп келәт өрлегенә элгән дә энесенә:

— Син шушы укны көн саен чыгып кара. Әгәр аннан май тамса, мин исән-сау булырмын; кан тамса, үлгән булырмын. Ул чакта инде син мине эзли чык, — дигән.

Камыр батыр әти-әнисе, туганы белән хушлашкан да, теге чукмарын, кылычын тагып, атка атланып чыгып киткән. Авылны чыккач, артына әйләнеп соңгы тапкыр хуш дигән дә өермә куптарып алга чапкан. Киткән бу, киткән, чабып китеп бара торгач, япа-ялгыз бер өйгә барып җиткән, шунда йоклап китмәк булган. Аргамагын читкәрәк бәйләгән дә үзе өйгә кергән. Анда мәскәй * тора икән. Ул Камыр батырны, ишек ачып, каршы алган:

— Кем буласың, улым? Кайдан киләсең? Кайсы илгә китеп барасың? — дип сораша башлаган. Камыр батыр мәскәйнең сорауларына җавап биргәч:

— Бик ачыктым, капкалап алырга берәр нәрсәң булмасмы? — дип сораган.

Мәскәй Камыр батыр алдына төрле ашамлык өеп ташлаган. Әллә нинди бер эчемлек тә китереп утырткан. Камыр батыр, шикләнми-нитми, барсыннан авыз итеп, теге суны эчкән икән, шунда ук һуштан язган да куйган. Эчемлек дигәне агу булган инде. Шуны гына көтеп торган мәскәй Камыр батырның гәүдәсен тоташлый йоткан да асылташлы башын, өй бизәргә дип, алып калган.

* *Мәскәй* — убырлы карчык.

Камыр батыр чыгып киткәч, байтак вакыт үткән, аны хәтта бөтенләй онытканнар. Бердәнбер көнне энисе өйдә калган улына теге укны карап керергә кушкан. Камыр батырның энесе келәткә кереп караса, уктан кан тамып тора, ди. Өйгә кереп, әти-энисенә әйткән дә, абыйсын юллап, чыгып китәргә булган. Әтисе белән энисе ризалык биргәч, бу теге балыкның сөяген ашаган этләрне ияртеп чыгып киткән. Этләр моны туп-туры мәскәй әбинең өенә алып килгәннәр. Өйгә килеп керсә, аны бик сылу бер кыз каршы алган.

— Егет, җаның кадерле булса, кит моннан тизрәк! — дигән.

— Абыемны күрмичә китмим, — дигән егет.

— Алай булгач, менә нәрсә: әби сине сыйларга итәр, күп итеп төрлесеннән ашамлык куяр, эчемлек бирер. Син аның бернәрсәсен дә ашама да, эчмә дә, — дип, кыз күздән югалган.

Шуннан бу аптырап тора иде, теге мәскәй килеп керде, ди. Килеп керде дә, баягыча ялагайланып:

— Кем буласың, улым? Кайдан киләсең? Кайсы илгә китеп барасың? — дип сораша башлады, ди. Шуннан: — Ачыккансыңдыр, улым, ашап-эчеп кит, — дип, моның алдына төрле ашамлык өеп ташлады, эчемлек китереп утыртты, ди. Егет бер дә ашамагач, кыстый да кыстый, кыстый да кыстый, ди. Мәскәй күпме генә кыстамасын, егет моның сыен авыз итеп тә карамаган. Шуннан карчык моны тотып алып үтермәкче булган икән, көче җитмәгән. Бу егет үзе мәскәйнең чәчләреннән урап тотып алган да, бир минем абыемны, бир, дип, камчысы белән чажлатып ярырга тотынган. Шуннан мәскәй ни эшләсен, моңа абыйсын бирергә вәгъдә иткән. Камыр батырның сөякләрен китереп чыгарган да, башын ялгап, ниндидер су бөреккән. Шуннан соң Камыр батыр күзен ачып, сикереп торган да утырган.

— Ай-һай, озак йоклаганмын икән, — дигән Камыр батыр.

— Йоклагансың, йокламый ни! Мин булмасам, мәңге йоклаган булыр идең... — дип, энесе бөтен хәлне сөйләп биргәч, Камыр батыр явыз карчыкны шунда ук суккан да үтергән. Шуннан мәскәйнең бөтен байлыгы белән теге кызны энесенә биргән. Энесе әти-әнисе янына кайтып, шул кыз белән яши башлаган, ә Камыр батыр үзе ары киткән.

Китеп бара, китеп бара, ди, Камыр батыр, ә үзе, дөньяда миннән дә көчлерәк кеше бармы икән, дип уйлый, ди. Китеп бара торгач, үзенең көчен сынап карамак булып, юл буенда яткан бик зур бер ташка чукмары белән суккан икән, таш он-талкан булган да куйган. Китеп бара тагы да Камыр батыр, китеп бара, китеп бара торгач, хәзер бер патша яшәгән шәһәргә килеп җитә. Килеп җиткәч, бер картка фатирга төшә. Кунакны бу бабай үзендә бары белән сый-хөрмәт итә. Ашап утырганда Камыр батыр шәһәр хакында, мондагы хәл-әхвәл турында сораша. Карт, авыр көрсенеп:

— Бик бәхетсез булды әле ул, безнең шәһәребез, — ди. — Әйбәт кенә яшәп яткан бер көнне шәһәребезгә дию очып килеп төште. Шушында яшәмәк булып, барыбызны кырып бетерү белән яный башлады. Моны ишеткәч, шәһәрнең бөтен халкы мәйданга җыелды, патша да килде. Шул җирдә диюгә илчеләр җибәрергә булдык. Илчеләребез диюгә барып: «Бездән күпме түләү сорыйсың, шулхәтле бирәбез, тик үзебезне тыныч калдыр», — диделәр. Ә дию әйткән: «Миңа көн саен бер кыз биреп торсагыз, үзегезгә бернинди дә зыян китермәм», — дигән. Ни эшләмәк кирәк, шәһәр халкы шуңа риза булды. Диюгә көн дә бер кыз биреп тора башладык. Бүген менә нәүбәт патшаның кызына килеп җитте. Кызын коткарып ала алган кешегә патша зур бүләк вәгъдә итә. Хәзер аның кызы чуен сарайда, сарай тирәсен патшаның бер вәзире саклап тора.

Бабай сөйләп бетерү белән Камыр батыр үзенең чуен чукмарын алган да урамга чыккан, ди. Бу чак җиде төн

уртасы булган, караңгы. Камыр батыр чуен сарайга барып, ишеген тартып караган икән, ишек шунда ук ачылып киткән. Шулвакытта патша кызы, Камыр батырны күреп:

— Егет, нигә килдең монда? — дип сорады, ди. Камыр батыр:

— Сине коткарырга килдем, — дип әйтүгә, тышта бик яман җил-давыл кубып, күк күкрәде, яшен яшьнәде, ди. Шул арада монда әллә кайдан, җир астыннан чыккан кебек, коточкыч бер дию килеп тә басты, ди. Аның янында Камыр батыр малай сымак күренә, ди. Дию Камыр батырга:

— Син монда нәрсә дип килгән булдың? — ди.

— Сине үтереп, патша кызын коткарырга килдем! — ди Камыр батыр.

Шулай дигән дә Камыр батыр, чукмарын күтәреп, диюгә суккан икән, тегенең башы өзелеп, читкә тәгәрәгән, гәүдәсе шунда җиргә ауган. Камыр батыр диюнең башын, чуен сарайны калкытып, аның астына тыгып куйган, ә гәүдәсен шундагы диңгезгә ташлаган. Шуннан Камыр батыр, патша кызы белән хушлашып:

— Мин сезгә соңыннан барырмын, хәзер миңа ял итәргә кирәк, — дигән дә кайтып киткән.

Камыр батыр күздән югалу белән кыз янына патшаның чуен сарайны сакларга куелган санаты килеп җиткән. Ул:

— Әгәр әтиеңә диюне мин үтерде дип әйтмәсәң, хәзер үк башыңа җитәм! — дигән. Коты алынган кыз риза булган. Алар икәүләп патша сараена юнәлгәннәр.

Патша, исән-сау кайтып кергән кызын күреп, үз күзләренә үзе ышанмый торган. Шатлыгыннан хәтта кызының ничек коткарылуын, диюне кем үтерүен сорашырга да оныткан. Шунда ук кызын шушы санатына кияүгә бирүен халыкка игълан иткән.

Инде өченче көн туй бара. Патша да, кияү дә, кунаклар да — барысы да шат, патша кызы гына күңелсез, ди.

Ул Камыр батырны көтә, ә Камыр батыр һаман килми дә килми, ди. Патша кызы килгән бер кешене күздән үткәреп утыра.

Менә бервакыт сарайга бер хәерче килеп кергән дә ишек төбенә генә утырган. Патша, хәерчене күреп калып, бик ачуланган, аны куып чыгарырга боерган. Патша кызы ул хәерченең Камыр батыр икәнен таныган да, әтисенә килеп, аны монда калдыруын сораган.

— Әти, рөхсәт ит, ул да монда булсын, — дигән. Кызы сорагач, патша карышмаган. Шулчакта патша кызы хәерчегә бер аяк бал китереп биргән. Хәерче балны эчеп җибәргән дә патшадан бер җыр җырларга рөхсәт сораган. Патша рөхсәт иткән. Камыр батырның чиксез моңлы җырыннан тәэсирләнеп, бөтен кунаклар оеп киткәннәр. Патша кызы гына аек калган. Шулчакта Камыр батыр хәерче киемен чишеп ташлаган, патша кызы аңа чуен сарайдан чыккач нинди хәлләр булганын сөйләп биргән. Камыр батыр:

— Кунаклар һушын җыйгач, син шуларның барысын да аларга сөйләрсең, — дигән дә икенче җыр башлаган, ди. Бу җырга кунаклар, һушын җыеп, уянып киткәннәр. Патша кызы үзен дию дән кем коткарганын кычкырып сөйләп биргән. Кунаклар теге санатка кырын күз белән карый башлаганнар, ә ул һаман:

— Юк, юк! Диюне мин үтердем, патша кызын диюдән мин коткардым! — дип кычкырынган.

Шулвакыт патша аңа:

— Әгәр диюне син үтергәнсең икән, расла! Ничек расларсың? — дип сорау биргән.

— Диюнең башын өзә чаптым да чуен сарай астына кыстырып куйдым, — дигән теге санат.

Бу шулай дигәч, барысы да, күмәкләшеп, чуен сарай янына киткән. Барып җиткәч, патша үзенең бу санатына:

— Диюнең башын чуен сарай астына кыстырып куйгансың икән, хәзер аны кире алып безгә күрсәт, — дигән.

Санат тегеләй иткән, болай иткән, чуен сарайны күтәрү түгел, урыныннан кузгата да алмаган.

Шулчакта халык арасыннан Камыр батыр килеп чыккан да, чуен сарайны күтәреп:

— Диюне мин үтердем. Менә аның башы! — дип диюнең килбәтсез башын алып күрсәткән. Шуннан ул диңгезгә чумган да шул арада диюнең гәүдәсен дә күтәреп алып чыккан. Халык, Камыр батырның бу батырлыгын күреп, хәйран калган.

Шуннан инде патша Камыр батырга:

— Вәгъдәм буенча, ярты байлыгым белән кызымны сиңа бирәм, минем варисым булырсың, — дигән, ә теге алдакчы санатын асарга боерган, ди.

КАРАГАНДА ПАТША БЕЛӘН КЫЗ БАТЫР

Караганда дигән патшаның ялгыз кызы була. Патша бик явыз, кирәмәттән * каты кеше була. Халыкны бик рәнҗетә. Кызы кеше җанлы булып үсә.

Бервакыт кыз авырып китә. Патша, кызы янына килеп, хәлен сораша.

— Хәлең ничек, балам?

— Авыр, әти.

— Балам, ничек авырыйсың соң?

— Тыным кысыла, әти, йортка иркенчелек бирер идең.

Патша, нык ачуланып:

— Әле син әтиеңә өйрәтмәкче буласыңмы? — ди. Авыру кызының яңагына берне чаба да чыгып китә.

---

* *Кирәмәт* — коточкыч бер җан иясе, ерткыч кеше.

Кызның исе китеп ятып кала. Исенә килгәч, кыз ирләрчә киенеп ала да ата йортын ташлап чыгып китә. Шәһәрдә бер генә өйдә ут бар, ди. Шул өйгә барып керсә, ялгыз гына әби утыра, ди. Кыз йоклап чыгарга сорый. Әби кертә. Чөйдә калкан, сугыш кораллары элүле тора, ди. Кыз:

— Әби, коралларның иясе кайда? — дип сорый.

— Бабай үлеп калды, берүзем торам. Моңа да зарымны сөйлим, тегеңә дә зарымны сөйлим, — ди әби.

Йокларга яталар. Кыз әле тегеләй, әле болай әйләнә, йоклый алмый. Шулвакыт күрше бүлмәдән ике көчек килеп чыга. Әби, яткан җиреннән торып, аларны ашата, эчерә; уйнатып, иркәләп-сөеп, тагы бүлмәгә бикли. Иртәгәсен йокыдан уянгач та кыз:

— Әбекәй, нинди көчекләр ул, төн буе сөеп чыктың? — дип сорый. Кыз төпченә торгач, әби сөйли башлый:

— Алар көчек түгел. Бабаем балыкчы иде, елга буйлап агып килгән бер сандык тапты. Шул сандык эчендә агалы-сеңелле ике бала яткан. Үстердек, сигез-тугыз яшькә житкәч, ялварып сорап урамга чыккан иделәр, адашып, патша бакчасына барып кергәннәр дә шунда йоклап киткәннәр. Патша аларны ябып куйган. Дүрт ел үткәч, патшаның кыз балага күзе төшкән. Кызны патша аерым урында тоткан, асыл киемнәр кидергән, тәмле ашамлыклар белән генә сыйлаган. Патша сараенда бер әби булган. Шул әби кыздан;

— Туганыңны күрәсең киләме, балам? — дип сораган.

— Бик күрер идем дә бит, юк шул.

— Туганыңны күрәсең килсә, җир астыннан юл салдырам, тик акчаңны жәлләмә, — дигән теге әби.

Әби әйткәнен эшләгән. Кыз һәркөнне абыйсы белән сөйләшкән, аңа азык-төлек китереп торган. Патша моны сизеп калган да кызны да, абыйсын да эткә әйләндереп, төрмәгә япкан.

Беркөнне шулай ике күгәрчен өй артындагы агачка кундылар да сөйләшә башладылар:

— Апа, апа, бу әбинең хәлен беләсеңме? Аның улы белән кызы төрмәдә бит, — диләр.

Таң сызылып килер чакта, күгәрченнәр очып китте. Ә иртәгәсен тагы да килеп, хәбәрләшергә тотындылар:

— Ул балаларны коткарып буламы?

— Күзәтчеләренә әфиүн эчерсәң, коткарып була.

— Ә ничек аларны кире кешегә әйләндерергә икән соң?

— Аларны каравыллап торган явыз карчыкның канын эчерсәң, кешегә әйләнәләр, — диделәр.

Әби әнә шулай сөйләп бетә. Әлеге ирләрчә киенеп килгән патша кызы бик нык колак салып тыңлый да әбигә ярдәм итәргә була. Әтисенең өенә кайтып, крестьян хатыннарынча киенеп ала да базарга чыга. Базарда әтисенең вәзирләрен очрата. Тегеләр, халыкны ыжгыртып, салым җыеп йөриләр икән.

— Син нинди кыз?

— Торыр җирем юк.

Патшаның бер вәзире, кызның матурлыгын күреп:

— Әйдә, бик булмаса бездә торырсың, — дип, кызны алып кайтып китә. Кайткач, вәзир хатынына:

— Тамакка китер! — дип акыра. Хатыны ашарга утырта. Вәзир ашап-эчеп ала да кызга якынлаша башлый. Кыз сикереп тора да, вәзирне кылычы белән чабып, чыга да китә. Бу хәлне ишетеп, патша вәзирне үтерүчене эзләтә башлый. Икенче вәзирен чакырта да:

— Әгәр шул вакыт эчендә җинаятьчене таба алмасаң, башыңны кисәм, — ди.

Вәзир йөри-йөри, үтерүченең эзенә төшә алмый. Кайгырып-көеп, баштан язам инде дип утырганда, вәзирнең кызы:

— Әти, ни булды, нигә шулкадәре уфтанасың? — дип сорый.

— Әй, балам, бүген үлә торган көнем минем, — дип, вәзир бөтен хәлен сөйләп бирә.

— Әти, бәгърем, кайгырма. Күрәзәчене тап та пат-

шага алып бар. Ул җинаятьченең кем икәнен әйтер, — ди. Вәзир, күрәзәчене эзләп табып, патшага алып бара. Күрәзәче, патша янына баргач:

— Вәзиреңне үзеңнең кызың үтергән. Ышанмасаң, үзеннән сора, — ди.

Патша шунда ук кызын чакырта. Сораса, кыз танмый:

— Мин үтердем, — ди.

Шул җирдә патша:

— Кайда телисең, шунда чыгып кит! Бүгеннән алып син минем кызым түгелсең! — ди.

Кыз, яхшы ат, чукмар, кылыч алып, чыгып китә. Ай китә, ел китә, азмы-күпме җир үтә. Алдына караса — таудай кеше тора, ди.

— Бу язуны күрмәдеңме? — дип сорый теге кеше. Анда: «Алыштанмы, көрәштәнме?» — дип язылган икән.

— Алышыңа — алыш, көрәшеңә — көрәш! — ди кыз.

Болар алыша башлыйлар. Көн буена алыша торгач, кыз батыр чукмар белән тегенең башын сугып изә дә, китеп бара. Бара-бара икенче бер патшалыкка килеп чыга. Йөри торгач, патшаның бер вәзире моны аш пешерүчеләрнең ярдәмчесе итеп ала. Кыз егетләрчә киенеп алган була, аш пешерүче, моны егет дип белеп:

— Балам, миңа ул бул да куй, — ди.

Кыз риза була. Берчак патша вәзирне чакырта.

— Караганда патшасы белән Кытай патшасы җиде ел түләү түләмәгән өчен безгә сугыш белән килергә җыенып яталар икән, нишлибез? — дип сорый.

— Түләп котылырга кирәк, — дип киңәш итә вәзир. Патша, вәзир киңәшен тотып, түләүне түләргә була. Бу хәлне кыз ишетеп кала да бабайны патшага җибәрә:

— Түләмәсеннәр. Гаскәргә баш булып үзем чыгам. Кытайныкы исәпкә бар, санга юк, — ди.

Бабай патшага барып сөйләп бирә. Патша аптырый.

— Вәзиремнән дә батыр кеше бар икән әле, — ди. Патшадан рөхсәт алгач, кыз батыр гаскәр башында яуга чы-

гып китә. Тәүдә ул Кытай патшасының батырлары янына бара. Гаскәр башында Кытай патшасының улы чыккан икән. Бу икәү сөйләшеп китәләр. Шул җирдә кыз батыр:

— Икәүләп Караганда патшаны куыйк, син гаскәреңне кайтарып җибәр, — ди.

Кытай патшасының гаскәре кайтып китә, гаскәр башлыгы белән кыз батыр икәүләп Караганда патшага каршы чыгалар.

Караганда патша вәзиренә:

— Күрәзәчеңне китер, — ди. Вәзир алып килгәч, патша күрәзәчедән:

— Кемнәр миңа каршы килә? — дип сорый.

— Үзеңнең кызың сиңа каршы чыккан, — ди күрәзәче.

Караганда патша, ачуыннан ярылырдай булып:

— Үзем алам башын! — дип, гаскәре белән кызына каршы чыга.

Кытай патшасының улы белән кыз иң тәүдә Караганда патшаны үтерәләр. Гаскәренең дә күбесе кырыла.

Җиңгәч, кыз сугыш киемнәрен салса, Кытай патшасы улының исе китә. Кызның матурлыгын күреп, аңа гашыйк була.

— Миңа кәләш бул, өйләнешик, — ди. Халык этисе урынына кызны патша итеп куя.

Кыз батыр патша булып алгач та этисенең явыз карчыгын таптырып алып, канын ике көчеккә эчерә. Ике көчекнең берсе менә дигән пәһлеван егеткә әйләнә, икенчесе шултиклем сылу кызга әверелә. Кыз батыр егеткә гашыйк була. Кытай патшасының улына:

— Мин илемне ташлап китә алмыйм, күңелем шушы егетне үз итте. Дус яшик, ошаса, шушы кызны кәләш итеп ал, — ди. Теге кыз Кытай патшасының улына гашыйк булып карап тора икән. Кытай патшасының улы бу кызны алган, зур итеп туй ясаганнар, туй кырык көн буена дәвам иткән.

Кыз батыр патша булып утыргач, халыкның хәле яхшырып, халык үзе көрәеп китте, ди.

АҠ БҮРЕ

Борын-борын заманда әби белән бабай яшәгән. Аларның өч улы булган. Боларның өчесе дә бер шәһәрдә укырга булалар. Иң тәүге улы:

— Әни, мин укырга барыр идем, — ди.

— Ярар, балам, бар, — ди дә энисе, имчәк сөтен савып, шуңа камыр басып, икмәк пешереп бирә. Олы улы китә. Улы китеп өч көн торгач, уртанчы улына китәргә вакыт җитә. Ул да:

— Әни, укырга барам, — ди. Әби бу улына да, имчәк сөтенә камыр басып, икмәк пешерә. Бу да китә.

Әби, бабай, кече улы — өчәү генә торып калалар. Өченче улы урманга чыгып йөри. «Мин дә абыемнар кебек укырга барыр идем», — дип уйлый ул. Ҡайта да әнисеннән:

— Әни, мин дә укырга барыйм, — ди. Әнисе белән этисе риза булмыйлар.

— Куй, балам, ике абыең китте. Син дә китсәң, без ничек торыйк? — диләр. Бу малай көнен-төнен елап инәлә. Этисе белән энисе, аптырагач, малайны җибәрергә булалар. Әнисе тагы да, имчәк сөтенә камыр басып, икмәк пешереп бирә.

Бик матур айлы төн була. Әби белән бабай йокламакчы булалар. Төн уртасы җиткәч, бабайның әбиен дию пәрие урлап алып китә. Таң ата, бабай уянып китә. Тирәягына караса, әби юк. Әй эзли бабай әбине, әй эзли — тапмый. Өч көннән соң бабайның олы улы кайтып керә. Бабай елап утырган була.

— Эти, әнием кайда? — ди.

— Балам, моннан өч көн элек әниңне дию пәрие урлады.

— Эти, алай булгач, мин эзләргә чыгыйм.

Бабай риза була, өч юлдаш биреп, өлкән улын әнисен эзләргә чыгарып җибәрә. Улы чыгып китә. Ҡитеп баралар, китеп баралар, ай баралар, ел баралар, чабата

буе җир баралар. Бара торгач, бер кара урманга барып керәләр. Атларын буш җибәреп, үзләре яшел үләнгә ял итәргә яталар. Бервакыт боларның янына бер кеше килә дә:

— Монда килеп, минем үләнемне таптарга кем кушты сезгә? — ди.

— Кит моннан, син берүзең, без күмәк. Югыйсә, үзеңне атып үтерербез, — ди егет. Шул җирдә бу урман кешесе әпсен-төпсен укый да тегеләргә карап өрә. Тегеләр шул урында таш булып каталар.

Бабайның уртанчы улы кайтып керә.

— Әти, әнием белән абыем кайда?

— Әниеңне дию пәрие алып китте, абыең әниеңне эзләп китте.

— Әти, эзләргә мин дә барам.

— Ярар, ярар, — ди дә бабай алты юлдаш бирә. Ай китәләр, ел китәләр, чабата буе җир китәләр. Баягы урманга барып чыгалар. Атларын җибәрәләр дә үзләре яшел үләнгә түшәлеп яталар. Алар янына бер кеше килә дә:

— Кем кушты сезгә, рөхсәтсез, минем урманымны таптап йөрергә? Җитмәсә, үзегез түшәлеп яткансыз! — ди.

— Кит моннан, син берүзең, без күмәк. Югыйсә, һәлак итәрбез үзеңне, — ди егет. Теге кеше әпсен-төпсен укып, боларга карап өшкерә. Болар таш булып каталар.

Өйгә бабайның иң кече улы кайтып керә.

— Әти, әнием белән абыемнар кайда?

— Әй, балам, балам, әниеңне дию пәрие урлап алып качты. Аны абыеңнар эзләп киткән иделәр, кайтмадылар.

— Әти, мин дә барыйм.

— Юк, балам, сине дә җибәреп, мин берүзем нишлим? — ди карт. Өченче улы инәлеп ялвара. Шуннан этисе риза була.

— Ярар, бар! — дип, тугыз юлдаш бирергә була. Кече улы:

— Миңа юлдаш кирәкми, — ди. Бер алама гына ат

менеп, мылтык алып юлга чыга. Баягы урманга барып җитә. Атының башын өскә каерып бәйләп куя да үзе кош атарга китә. Егетнең янына теге кеше килә.

— Кем кушты сиңа минем урманыма рөхсәтсез керергә? Җитмәсә, кошымны атарга йөрисең?

— Юк, абый, атмадым әле. Әнә, атымның башын өскә каерып бәйләп куйдым, — ди.

— Бар, атыңны җибәр, — ди теге кеше. — Тик бу кошны атма; икенче бер тирәктәгене ат, кошны пешереп, мине чакыр, — ди.

Егет атны тышаулый. Икенче тирәктәге кошны ата. Аны урман читенә алып барып пешерә. Шулвакыт моның янына бер ак бүре килә. Егет ашны бүлә, ашарга утыралар. Егет уйланып утыра. Ашны ашап беткәч, ак бүре:

— Егет, нигә уйланасың? — дип сорый.

— Миңа бер кунак килергә тиеш иде, — ди егет. — Ул килсә, минем итем юк, ашап бетердек, — ди.

— Әй, егет, курыкма. Ул кунак менә мин, — ди дә бүре егетнең хәлен сораша:

— Егет, син нишләп бу якка килеп чыктың?

— Минем әнием бар иде. Аны дию пәрие урлап алып киткән. Абыемнар аны эзләп киткәннәр.

— Син абыйларыңны таныйсыңмы?

— Таныйм, алар кайда соң?

Ак бүре таш булып каткан бер кешегә күрсәтә:

— Бу синең абыеңмы?

— Әйе, минем абыем.

Бүре әпсен-төпсенне кире өрә. Абыйсы шунда ук торып утыра.

— Бу синең абыеңмы? — ди бүре, икенчесенә күрсәтеп.

— Әйе, минем абыем.

Тагы әпсен-төпсен укып өрә бүре. Бу абыйсы да терелә. Егет, рәхмәтләр укып, абыйларын күл читенә алып китә. Куыш корып, аларны шунда урнаштыра да үзе китә. Ай китә, ел китә, чабата буе җир китә. Бара торгач, бер

биек тау күренә. Шул тау янына туктый. Тауның башына менә алмый. Егет елый. Берзаман күк күкрәп, куе кара болыт калка. Егетнең янына бер кош килә дә:

— Егет, син нишләп елап утырасың? — ди.

— Менә мин шушы тауның башына менә алмый утырам.

— Әйдә, утыр миңа, мин мендереп ташлармын, — ди кош. Егет утыра. Күз ачып йомганчы егет тау башында була. Кош үз юлына, егет үз юлына китә. Бара торгач, ул бер өйдә ут күрә. Шул өйгә барып тәрәзәсеннән карый. Ни күзе белән күрсен, анда кырык кол адәм ите юа. Егеткә каршы ишектән кояш йөзле кыз чыга да:

— Син кайдан килдең, егет? — дип сорый.

— Әниемне дию пәрие урлады, шуны эзләп килеп чыктым.

Кыз егетне өйгә алып керә. Ашаталар, эчерәләр, туйдырганчы йоклаталар. Егет иртәнчәк тора да юлга чыга. Тагы бер өйгә барып эләгә. Тәрәзәдән караса, кырык кол адәм ите юа. Егет ишеккә килә. Ишектән аңа каршы бер ай йөзле кыз чыга да:

— Егет, нишләп йөрисең? — дип сорый.

— Әниемне дию пәрие урлаган иде, шуны эзләп килдем, — ди егет. Егетне ашаталар, эчерәләр, йокысы туйганчы йоклаталар. Иртәгәсен йокыдан тора да, бу тагы юлга китә.

Ай китә, ел китә, чабата буе җир китә. Бара торгач, бер өйгә җитә. Тәрәзәдән караса, анда кырык кол адәм ите юа. Ишектән бер хатын килеп чыга да:

— Әй, егет, син нишләп йөрисең монда, ничек килеп чыктың? — ди.

— Әниемне дию пәрие урлап китте. Мин шуны эзләп йөрим.

Бу хатын егетнең әнисе икән, тик егет аны танымый, әнисе танып кала. Таныса да, үзен ачмый.

Егетне ашаталар, эчерәләр, йокысы туйганчы йоклаталар. Теге хатын егеткә биек тау башына алтмыш пот-

лы герне мендерергә куша. Әби герне таудан тәгәрәтә. Егет герне урыныннан да кузгата алмый. Әби икенче катка тәгәрәтә. Егет, герне күтәреп алып, тауның яртысына җиткерә. Әби өченче мәртәбә тәгәрәтә. Егет герне күтәреп ала да тауның өстенә тәгәрәтеп җибәрсә, гер әбине узып барып туктый. Егетне өйгә алып керәләр, туйганчы ашаталар, эчерәләр, йоклаталар. Егет торгач, бер без бирәләр.

— Менә шушы безне теге бүлмәдә йоклап яткан дию пәриенең үкчәсенә батыр, — диләр. Егет керә дә безне батыра.

— Адәм заты булса, ашатыгыз! — ди дию.

— Миңа синең ашатуың кирәкми, — ди егет.

Дию пәрие акыра:

— Алышмы, бирешме?

Егет:

— Алыш, — ди.

Дию белән егет тышка чыгалар. Тәүдә дию егетне алып җиргә бәрә. Егет табаннан җиргә бата. Дию икенче тапкыр бәрә, егет билдән җиргә бата. Өченчесендә егет диюне алып бәреп җибәрсә, дию муеннан җиргә бата. Дию:

— Дәва китерегез! — дип кычкыра.

Ике төрле дәва була: беренчесе — хәл бетерә торган, икенчесе — көч кертә торган. Хәл бетерә торган дәваны ялчылары диюгә эчерәләр, көч кертә торганны егеткә бирәләр. Тегеләр тагы көрәшә башлыйлар. Дию пәриенең хәле бетә. Егет аны күтәреп бәрсә, дию муеныннан җиргә бата. Егет кылычын алып диюнең муенын чабып өзә дә куя. Шулчакта энисе килеп үзен таныта. Болар бик шатланышалар, егетне ашаталар, йокысы туйганчы йоклаталар.

Иртәгәсен егет һавага асылган машинаны күрә. Җепне киссә, машина җиргә утыра. Энисен шул машинага утырта да егет кайтырга чыга. Кояш-кыз янына килә, аны да ала. Шуннан Ай-кыз янына килә, аны да утыртып

ала. Ай китә, ел китә, чабата буе җир китә. Баягы кара урманга килеп туктый. Аның янына ак бүре килә. Егет Ай-кызны, Кояш-кызны, әнисен тезеп куя да:

— Йә, дус, кайсысын алырга телисең? — дип сорый.

— Ай кызы да ярый, — ди бүре.

Егет абыйларын чакырып кунак итә.

Шуннан болар кайтып китәләр, егет әнисен әтисенә тапшырып, үзе Кояш кызы белән яши, ди.

ӨЧ БАТЫР

Борын-борын заманда бер бик гайрәтле кеше булган. Аның өч улы бар иде, ди. Үзе бик картаеп, яше сиксәнгә җитте, ди. Көннәрдән беркөн бу картка авыру тиеп, өч улын янына чакыртып, васыятен әйтте, ди:

— Әй, оланнарым, мин бу дөньяны куярмын, ахры. Миннән сезгә бер кылыч кала. Ул кылыч сезне ризыксыз итмәс. Ризыгыгыз патша кулында булмасын. Сәфәргә чыксагыз, өчегез бергә чыгыгыз. Икегез йоклаганда, берегез сакта торыгыз. Башыгызга килгән хәвеф-хафалардан имин булырсыз, — дип васыятен әйтте дә, башын ястыкка терәп, вафат булып калды, ди.

Өч улына, әтиләре әйткәнчә, сәфәр чыгарга туры килде, ди. Алар башка патшалыкка китмәкче булганнар. Бик күп җир киткәч, көн батып, караңгылана башлады, ди. Шунда бераз ял итеп, ашап-эчеп алдылар да, әтиләре кушканча, икесе ятып йоклады, олысы каравыл калды, ди. Төн уртасы җиткәч, бер аждаһа һавадан койрыгын болгап төшеп килә икән, егет аждаһаның койрыгын ки-

сеп алган да кесәсенә салып куйган. Энеләре уянган, күргән хәвефне бу энеләренә белдермәгән.

Ашадылар, эчтеләр дә ары киттеләр, ди, болар. Тагы бернитиклем җир үткәч, караңгы төшкән. Ашап-эчеп, икесе йокларга ятты, уртанчылары каравылга калды, ди. Каравылчы егет ерακта бер ут яктысы күрде, ди.

— Тукта әле, кем икән анда, якыннан барып күрим, — дип килеп караса, өйнең эчендә җиде башлы бер дию пәрие утыра, кулында алтын балдагы бар, ди. Үзе утырган җирендә йокыга киткән, ди. Егет:

— Тукта әле, бу диюне һәлак итим, — дип акрын гына ишекне ачып керде дә, диюнең башын кылыч белән чабып өзеп, кулындагы алтын балдагын салдырып алды, ди. Шуннан туганнары янына кайтып, абыйсы белән энесен уятты, әмма ләм-мим сүз әйтмәде, ди. Торып, ашап-эчеп, юлга чыгып киттеләр, ди, болар яңадан.

Бер шәһәргә җитеп барган чакта, кояш баеп, караңгы төшә, шәһәрнең капкалары ябыла, һич тә керергә мөмкин түгел, ди. Шул җирдә боларның икесе ятып йоклый, кечесе каравылда торып кала. Шулчакта утыз тугыз кеше килә. Егет, бу кешеләрне күргәч, юл уртасына чыгып, сәлам бирде, тегеләр моның сәламен алдылар, ди.

— Кайда барасыз? — дип сорады, ди, егет.

— Без фәлән шәһәргә, фәлән патшаны басарга барабыз, — диделәр тегеләр.

— Әйдәгез, мин дә сезнең белән барыйм, — дип әйтте дә егет, кырыгынчы кеше булып, болар белән китте дә барды, ди. Бара торгач, бу кешеләр егеткә:

— Синең нинди эшкә осталыгың бар? — дип сорадылар, ди.

— Кайда югары җир бар, шунда менә алам, — ди егет.

Бара торгач, шәһәргә җитеп, патшаның сарае янына килделәр, ди. Әлеге егет, бер бик озын бауның башына тимер ыргак бәйләп, сарайның түбәсенә ташлады да,

ыргак бер җиргә барып эләккәч, үрмәләп, сарай түбәсенә менде, ди. Шуннан тегеләргә:

— Шул бауга үрмәләп, минем янга менегез, — диде, ди. Шулай дип әйтү белән тегеләрнең берсе ябышып менде, ди. Егет аны кулы белән тартып алды да, бер колагын кисеп алып, үзен чардакка ыргытты. Шуннан икенчесен, өченчесен чакырып мендереп, колакларын кисеп ала торды, үзләрен ыргыта торды, ди. Утыз тугызынчысының да сыңар колагын кисеп, кесәсенә салды да, киселгән башлары белән гәүдәләрен патша сарае чардагына өеп куйды, ди.

Шуннан бу, әйбәт кенә бер җаен табып, патшаның өенә керде дә, өч кызының да балдакларын, яулыкларын алды, ди. Икенче бүлмәгә кергән иде, бәләкәй генә эт өрә башлады, ди. Этнең муенын кылыч белән чабып үзә дә һаман йөри бу. Сарай эчен карап беткәч, «Мин булмасам, бу патшаның үлгән көне булыр иде», дип язу калдыра да чыгып китә, абыйлары янына кайта.

Иртән торып тышка чыкканда, патша эт тора торган бүлмәгә кереп караса, эт үлеп ята. Өйгә керсә, кызларының өчесе дә: «Балдагым да юк, яулыгым да юк», — дип елашып утыралар, ди. Патша сарай бүлмәсенә керсә, бер язу ята. Язуны алып укый. Чардакка менсә, утыз тугыз баш белән утыз тугыз гәүдә ята. Башларның һәрберсенең берәр колагы юк. Патша хәйран кала. Вәзирләрен чакыртып, әмер бирә:

— Хәзер үк утыз тугыз колакны табып китерегез! — ди.

Бөтен халыкны тикшереп чыгалар, берәүдә дә артык колак юк. Патша сорый:

— Тагы да кеше калмадымы?

— Тагы өч кеше бар, мосафирлар. Алардан бу эш булмас. Әле генә шәһәргә килеп керделәр, үзләре бик фәкыйрь, ач-ялангачлар. Ашарга ризык таба алмый аптырап йөриләр, — диләр вәзирләр.

— Хәзер үк яныма алып килегез, ашатырбыз, эчерер-

без, — ди патша. Вәзирләр шул сәгатьтә өч егетне патшага алып киләләр. Алларына аш китерәләр, эчерәләр. Егетләр, ашап-эчеп, тәмам хәл алдылар, ди. Патша үзе ишек артына яшеренеп тора, болар үзара сөйләшә башлыйлар. Абыйлары:

— Мин булмасам, сез әллә кайда үлеп яткан булыр идегез әле, — ди.

— Һе, нишләп үлик ди без? — диләр энеләре.

— Нишләп, имеш. Сез йоклаганда, су эченнән бер аждаһа чыгып килә иде, менә кылыч белән койрыгын кисеп алып калдым, — дип кесәсеннән койрыкны чыгарып күрсәтә олы абый.

Шуннан икенчесе дә, үзе белән булган хәлне сөйләп, егетләрнең алдына теге җиде башлы дию пәриенең балдагын чылтыратып чыгарып салды, ди.

— Абыйлар, батырлыкларыгыз сезнең ярыйсы. Шулай да, әгәр мин булмасам, сез монда чынлап та утырмас идегез. Мин утыз тугыз каракның утыз тугыз колагын кисеп алдым, үзләрен әрдәнә итеп өйдем. Шулай итеп мин сезне дә, патшаны да үлемнән коткардым. Менә ул юлбасарларның колагы! — дип, утыз тугыз колакны кесәсеннән чыгарып өстәлгә салды, ди. Колакларның барсын бер җепкә тезгән, ди, бу.

Егетләрнең сүзләрен ишетеп, патша хәйран калган, «Һай, афәрин», дип кычкырып ук җибәргән. Качып торган җиреннән килеп чыккан да, егетләрнең олысына — олы кызын, уртанчысына — уртанчы кызын, кечесенә кече кызын бирмәкче булган. Патша, өч егетнең өчесен дә яратып, хөрмәт итеп, башта олы кызын туйларга киңәшләште, ди.

Патшаның олы кызы Гәүһәрташ исемле булган. Айның ундүртенче кичәсе кебек нурлы йөзле, кызыл якут иреннәрен тибрәндереп, энҗе кебек тешләрен күрсәтеп көлгәндә, сарай эчләре яктырыр иде, ди. Дөньяда бу беренче гүзәл кызны күргәндә, кешеләрнең күзе камашып, һушсыз булып егылырлар иде, ди.

Патша, вәгъдәсендә торып, берничә көннән туй ясамакчы булып, мәҗлес өчен төрле-төрле ашамлыклар әзерләтеп, шәһәрдәге барлык кешеләрне чакырган, бөтен халыкка — фәкыйрьләргә дә, байларга да алтын өләшкән. Һәрберсе:

— Әй, патшам, гомергә яхшы яшә, гомерең озын булсын, — дип патшага рәхмәт укыды, ди.

Төн үтеп, кояш калыккач, бөтен вәзирләр эшкә тотынгач, Гәүһәрташ бакчага кергән, су буена барып, су кереп, кара ефәк чәчен үреп, матур күлмәген киеп, чибәрләнеп, йөзенә пәрдә кигәч, караучы кызлары олы абыйның өенә китереп утырттылар, ди.

Гәүһәрташның кияве бу көнне ничек тизрәк җиткерергә белми, ди. Кияү килер көнне халык төрле уеннар башлады, ди. Патшаның хезмәткәрләре төрле шигырьләр әйтеп, кияү килүен зар-интизар булып көтеп тордылар, ди. Кияү килеп, сарайның ишек төбенә баскач, ике хатын ике кулыннан җитәкләп, кызның бүлмәсенә алып кереп, алтын креслога утырттылар, ди. Һәртөрле ашамлыклар китереп, ашатып-эчереп, Гәүһәрташ белән кияүне бизәп-әзерләп куелган бүлмәдә калдырдылар, ди. Егет, җиңгәләр чыгып киткәч, ишекне бикләп, кыз белән уенкөлкеләр сөйләшеп, бер-берсенә гашыйк булдылар, ди. Бер-берсеннән күзләрен алмыйча, мәхәббәтләре артып, мәхәббәт тамырлары тибеп, минут саен бер-берсенең авызларыннан үбеп, йокларга яттылар, ди.

Туйны әнә шулай, бик яхшы итеп үткәргәннәр. Иртәгәсен Гәүһәрташның әти-әнисе бер кыз артыннан:

— Әгәр вакытлары булса, хәл белешергә керербез, — дип әйттерделәр, ди. Гәүһәрташ кияүгә бу хәбәрне әйткәч, кияү:

— Бик хуп булыр, хәзер керсеннәр,— дип әйтте, ди. Карт белән карчык килүгә бик матур киенеп куйдылар, ди. Әти-әнисе кергәч, кияү:

— Әй, каенатам, кадерлем, гомерегез озын булсын,— дип фатиха кылдылар, ди. Патша сүз башлап:

— Хәзер шатлыгымнан шаштым, гыйбадәткә күчәм, син шаһ булырсың, — дигән иде, егет:

— Әй, каенатам, кызыгызны кабул күреп, никахлап алдым, ә шаһлыкта үзегез торыгыз, — дип җавап кайтарды, ди. Патша, акыллы җавапны ишеткәч, киявенең ике күзеннән үбеп алды, ди.

Патша уртанчы кызы Җәүһәрташны, егетләрнең уртанчысына биреп, шулай ук олы туй үткәргән, икенче бер шәһәргә шаһ кылып, мәрхәмәтле булырга боерган.

Патшаның кече кызы Якутташ бигрәк матур, бигрәк белемле иде, ди. Монысын инде егетләрнең кечесенә биргән. Патша, кече кызы белән кияве янына кереп:

— Әй, минем улым тиңе күргән киявем! Мин картайдым, сине патша кылып, үзем гыйбадәткә китәм, — дигән.

Карт тәхетне киявенә тапшырган, өч елдан соң вафат булган. Кияве илле ел патша булып торды, ди. Гаделлек белән хакимлек итте, ди. Аның ике улы булып, аталарыннан соң алар патша булып тордылар, ди.

ХӘТӘР ШӘП БАТЫР

Борын заманда бер бай яшәгән. Аның егерме тугыз хезмәтчесе булган. Бай озак еллар буе бер үгез симерткән, үгез шултиклем усалланып киткән, хәтта егерме тугыз хезмәтченең көче җитми икән. Якын барсалар, сөзгәли дә ташлый, ди.

— Утыз булсак иде, — дигәннәр, ди, хезмәтчеләр. Беркөнне байны күреп:

— Тагы берәр кеше булса, көчебез җитсә җитәр, — дигәннәр.

Бай хезмәтче эзләп чыгып киткән, ди. Бер авылда аңа:

— Әнә, мич башыннан төшмәгән бер малай бар, кирәксә, шуны ал, — дигәннәр.

Бай башта: «Мич башыннан төшмәгән кешенең ни рәте булсын?» — дигән. Соңыннан сөйләшеп карарга булган.

Өйгә барып керсә, чынлап та малай мич башында ята, ди.

— Улым, улым, — дигән бай, — бер генә айга миңа хезмәтчелеккә бар әле.

— Ярар.

— Күпме сорарсың?

— Кирәкми. Маңгаеңа бер чирттерерсең, — дигән малай.

Бай, йөгерә-атлый өенә кайтып, хатынына:

— Карчык, бушка бер хезмәтче таптым, хак алмыйм, ди. Маңгаеңа бер чирттерсәң, җитәр дигәч, мин шуңа риза булдым, — дип сөенче алды, ди.

— Ай-һай, юньле кеше булмастыр ул, — дип, әбие шикләнә төшә. Бай:

— Мич башында яткан малай хак сорый беләмени ул? — дип көлде генә, ди.

Малай килә. Хезмәтчеләр белән ашап-эчә дә, үгезнең маңгаена чиртсә, үгез егылып китә. Барсы да хәйран калалар. Егерме тугыз хезмәтче күтәрә алмаган үгезне ул берүзе күтәрә икән. Тегеләр күмәкләшеп бер көн эшләгән эшне бу ялгызы ярты көндә бетерә, ди.

Бай бөтенләй гаҗәпкә кала. Көн-төн уйлана, хәсрәтләнә. Шуннан бер мәскәй әбигә үз кайгысын сөйләп бирә.

— Дөнья батырына очрагансың, — ди теге карчык. — Бер чиртүдә үзеңне дә үтерер ул, — ди.

— Нишләтергә соң аны? Үтерергә кирәк иде, — ди бай.

— Минем бер тәҗрибәм бар. Олы үгезнең ботын, егерме пот бодай китерсәң, өйрәтермен, — дигән карчык.

Бай риза булган.

— Улым, — дигән мәскәй әби байга, — дөньяда алтын тау бар. Шул тау башында алтын киле белән алтын килесап ята. Аларны дию саклый. Шуны алып кайтырга кушып чыгарып җибәрсәң, ул кире кайтмас.

Бай, әбигә рәхмәтләр укып, өенә кайта да, малайга:

— Улым, алтын тау бар икән. Шул тауда алтын киле белән алтын килесап ята икән, алып кайтып бир әле, — ди.

Малай икенче көнне үк юлга чыккан. Ай китәсен — бер сәгатьтә, ел китәсен бер көндә үтеп, малай алтын тауны эзләп тапкан. Барса, бер дию йоклап ята икән. Малай — килене тәгәрәтеп, сабын күтәреп алып кайта да китә. Кайтып җитә дә киле белән килесапны байның ишек алдына куя.

Бай, йокысы качып, тагы мәскәй әбигә йөгерә.

— Нишләтергә инде? Алып кайтты бит! — ди.

— Уразгилде суында ике тегермән ташы ята. Шуларны төшеп алып чыксын, — ди әби.

Бай малайны шул ташларны алып кайтырга җибәрә.

Малай озын итеп аркан ишә дә, байны тыңлап, икеөч көндә күл янына барып җитә. Җитсә, бер дию аш пешереп утыра. Исләмәстән генә диюне кысып үтерә. Икенчесе су китерә икән, ансын чиртеп үтерә дә, аркан буйлап төшеп, тегермән ташларын алып чыга.

Байның, малайны күреп, коты оча, ул тагы мәскәй әбигә йөгерә.

— Нишләтергә? Алып кайтты бит, — ди. Карчык:

— Ата-бабадан калган маллар киекләнеп киткән, шуларны алып кайтсын, — ди.

Бай, өенә кайтып, малайга сөйләп бирә.

— Ярар, барырмын, — ди малай. — Базарга барып, күп кенә киндер алып кайтырга кирәк, — ди.

— Нишләтәсең аны?

— Ансын үзем беләм, — ди малай.

Бай белән малай, базарга барып, киндер алып кайталар.

Малай киндердән озын итеп чыбыркы ишкән дә икенче көн иртә белән урманга чыгып киткән. Көн йөргән, төн йөргән, урман эче шаулап торган. Чыбыркы шартлавын ишетеп, барлык җәнлекләр юлга чыккан, ди.

Малай, аларны өере белән куып авылга алып кайткан да:

— Менә алып кайттым, эшем бетте, — дип кычкыра икән.

Бай, урам тулы җәнлекләрне күреп, гаҗәпкә калган. Нишләргә? Муллаларны җыеп киңәшләшә. Муллалар теге малайны үгетләргә тотыналар.

— Ни теләсәң, шуны ал, — диләр.

— Әйткән сүз — аткан ук, — дигән дә байның маңгаена чиртеп тә җибәргән теге батыр. Бай шунда ук үлеп калган. Ә дөнья батыры, аның дөньясына хуҗа булып, уртанчы кызын алып, әле дә көн күреп яши икән.



ХӘЙЛӘСЕЗ БАТЫР – БАХЫР



НЕЗНАЙ

Борын-борын заманда бер ир белән хатын яшәгән. Аларның бер генә бөртек уллары булган. Бу малай туган көнне боларның биясе колынлаган, этләре көчекләгән, хәтта песиләре дә балалаган. Малай гел генә шул колын белән, эте, песие белән уйнаган. Әтисе күп вакытта читтә сәүдә итеп йөргән.

Менә бервакыт әтисе үзенең сәүдә эше белән читкә чыгып киткәч, әнисе бер хәлфә белән очраша башлый. Моны малай белеп кала. Хатын да, хәлфә дә куркуга төшә. Нишләргә? Әтисе кайтса, аларның чуалганнарын сөйләп бирәчәк бит.

Хәлфә уйлый-уйлый да хатынга улын юк итәргә киңәш бирә. Хатын куркып китә, шулай да: «Ничек юк итәргә?» — дип сорый. Хәлфә агу салып ашатырга куша. Боларның сөйләнгәннәрен малайның аты ишетеп тора да бик нык кешнәп җибәрә. Атының кешнәвен ишетеп, малай мәдрәсәдән йөгереп аты янына кайта. Ат хәлфә белән хатынның явыз уйларын әйтеп бирә, ашны ашамаска куша.

Төшкелеккә хатын аш пешерә. Малай ашаган кеше булып утыра да ашны түгә дә куя.

Икенче көнне хәлфә хатыннан:

— Улың үлдеме? — дип сорый.

— Юк, — ди хатын. Хәлфә әйтә:

— Алай булгач, төче күмәчкә агу салып пешереп ашат, — ди.

Хатын белән ирнең бу хәйләсен дә малайның аты ишетеп кала. Шуннан малайга тагы барсын да сөйләп бирә. Малай күмәчне ашамый. Бу юлы да малайны үтерә алмагач, хатын белән хәлфә яңа хәйлә кора башлыйлар.

— Ирең кайтканда, — ди хәлфә хатынга, — син авырган кеше булып ят. Ирең, нәрсә кирәк, дип сораса, хәлфәне чакырт, диярсең. Калганын мин үзем белермен, — ди.

Бер-ике көн үткәч, хатынның ире кайта. Кайтса, капка бикле. Капканы дөбердәтә, — берәү дә чыкмый. Ничек кирәк, шулай өйгә керә. Өйдә хатыны ах та ух килеп авырып ята, ди. Ире кергәч тә, хатын:

— Тизрәк хәлфәгә бар, ул гына терелтә алыр, үләм, — ди.

Ир йөгереп барып хәлфәне китерә. Хәлфә:

— Әгәр хатыныңның исән калуын теләсәң, малаең белән атыңның уң ботын ашат, — ди. Ир аптырап кала.

— Ничек инде, хәлфә, ул бит минем бердәнбер улым, — дигәч, хатыны:

— Син мине яратмыйсың. Яратсаң, улың белән атны җәлләмәс идең. Мин исән калсам, бер түгел, биш улыбыз булыр әле, — ди икән. Ир елап-елап ризалыгын бирә дә улы белән атын суярга әзерләнә башлый.

Ат боларның барсын да ишетеп кала да малайга барсын да сөйләп бирә. Малай куркып, нишләргә белми аптырап кала. Шулчакта ат малайга киңәш бирә:

— Мине суярга дип алып чыккач, син: «Әти, атымны бер генә тапкыр менеп йөреп килим әле?» — дип сорарсың. Әтиең рөхсәт итәр. Менгәч, ишек алдын икенче тапкыр урагаида, миңа нык итеп камчы белән сугарсың, аннан калган ягын мин үзем белермен, — ди.

Менә атны суярга алып чыгалар. Малай килә дә әтисеннән: «Менеп, бер генә йөртеп килим әле!» — дип сорый. Хатын белән хәлфә: «Куйчәле», — дип, эшне ашыктыралар. Малай бик үтенеп сорагач, ишек алдында гына йөртергә риза булалар. Малай, атына атланып, ишек алдын бер урап чыга; икенче тапкыр урый башлагач, аты кушуы буенча, камчысы белән атына нык итеп сугуы була, аты атылып, малайны киртә аша алып чыгып та китә. Аларның артыннан эт белән песи дә ияpә.

Шул китүдән ай китәләр, ел китәләр, Каф тавыннан да биегрәк тауга барып җитәләр. Шул тауда туктап хәл җыялар.

Малай инде егет булып өлгереп җитә. Берчак ат егеткә болай ди:

— Монда бик зур бер таш булыр, мондый таш Каф тавы артында да юк, шул ташны күтәреп алсаң, аның астында утта янмый, суда батмый, үзе кылыч үткәрми торган сугыш киеме ятар. Кием янында кылыч булыр. Аларны безгә ничек булса да алырга кирәк.

Хәзер шул ташны эзләп китәләр. Эзләп йөри торгач, барып табалар. Килсәләр, таш һич күтәрерлек түгел, ди. Шулчакта ат егеткә әйтә:

— Син аны болай гына күтәрә алмассың, — ди. — Син башта минем сул колагымнан кереп, уң колагымнан чык, — ди. Егет атның сул колагыннан кереп, уң колагыннан килеп чыккан иде, бу бик пәһлеван бер егеткә әйләнде, ди. Килеп ташны күтәрсә, аның астында чынлап та сугыш киеме белән бер кылыч ята, ди. Киемнәрнең барлыгын күргәч, ат егеткә әйтә:

— Әлегә бу киемнәр сиңа кирәк булмас, хәзергә шушында ятып торсыннар. Кирәк булганда килеп алырбыз. Безгә аерылырга вакыт җитте. Кирәк булганда, мин сиңа үзем барырмын яки сызгырып мине чакырып алырсың. Хәзер син юлыңны дәвам ит. Юлда бер кеше белән дә сөйләшмә. Шар белән чәкән эшләп ал да шар сугып бар. Бара торгач, бер бик матур шәһәргә барып җитәрсең,

анда бик матур патша сарае булыр, сарайда өч кыз утырыр. Алар патша кызлары булыр. Сине күрү белән миңа да миңа дип, синең өчен үзара талаша башларлар. Талаша торгач, синең артыннан куарга тотынырлар. Ә син бәләкәенә генә тотыл. Иң матуры, иң акыллысы шул булыр. Тотылгач та кыз белән сөйләшмә. «Незнай» дип, гел бер сүзне кабатлап тик тор, — ди.

Егет, тыңлап беткәч, аты, песие, эте белән саубуллаша да, чәкән белән шар эшләп алып, шар суга-суга юлга чыгып китә. Юлда ул беркем белән дә сөйләшми дә, туктамый да, шар тәгәрәтеп тик бара. Бара торгач, алда бик матур бер шәһәр күрә. Шәһәр уртасында ялтырап патша сарае күренә. Егет туп-туры патша сараена юнәлә. Килеп җитә дә патша сарае алдында шар суга башлый. Патша кызлары, егетне күреп калып:

— Бу егет миңа, юк, сиңа түгел, миңа, — дип үзара талаша да башлыйлар. Шунда боларның берсе:

— Юк, безгә талашырга кирәкми, кем дә кем егетне шар суккан җиреннән куып җитеп тотып ала, егет шуңа булыр, — ди. Калганнары моңа риза булалар. Тәүдә егет артыннан олы кыз йөгерә, нитиклем генә тырышып йөгермәсен, егетне тота алмый. Шуннан уртанчысы йөгерә, ул да тота алмый. Егет шарт та шорт шарын суга да йөгерә, шарын суга да йөгерә икән. Егет шәп йөгерә, аннан да шәбрәк шар тәгәри икән.

Иң азактан бәләкәй кыз чыга. Куыша башлаулары була, егет үзен тоттыра да куя. Болар янына халык җыела, хәтта патша үзе дә килеп җитә.

— Син кем, кайдан килдең? — дип сораша башлыйлар. Егет «незнай» сүзеннән башка бер сүз дә әйтми.

«Моның исеме шулайдыр», — дип, егетне Незнай дип йөртә башлыйлар. Халык егетне жәлли.

— Нинди матур егет, ә телсез, бахыр, — диләр. Ә Незнайның бернәрсәгә дә исе китми, иртәдән алып кара кичкә хәтле шар суга да шар суга. Незнайның шарт та

шарт шар сугуыннан ялкып, патша аны берәр якка олактырмакчы була. Моны кече кызы сизеп калып:

— Әти, мин Незнайны яратам, аны җибәрмим, — ди. Патша көлә-көлә дә:

— Ул телсез белән нишләмәкче буласың? — ди.

Шулай итеп, Незнай патша сараенда кала. Аңа шар сугу өчен зур гына сарай салдырып бирәләр. Ул шунда көне-төне шар суга. Башка бернәрсә белән дә кызыксынмый. Ә бәләкәй кыз көн дә килеп аның шар сукканын карап утыра. Шул көе күп вакытлар үтә.

Менә бервакыт патша үзенең олы кызын олы вәзиренә кияүгә бирергә була. Туй була дигән көнне һаваны кара болыт каплап ала. Һавада нәрсәдер шатыр-шотыр килгәнгә йөгереп чыксалар, күктән бер кәгазь килеп төшә. Кәгазьне алып укып карасалар, анда: «Патша, син минем ала торган кызны олы вәзиреңә бирәсең икән, шуның өчен мин сиңа сугыш ачам. Өч башлы дию», — дип язылган, ди.

Хатны укыгач, барсы да куркуга төшәләр. Патша да кайгыра. Ул:

— Туй белән хәзергә бернәрсә дә чыкмас, гаскәр җыеп сугышка китәргә кирәк, — ди дә, олы вәзирен гаскәр башлыгы итеп, җиде көнлек юлга чыгара. Гаскәр артыннан үзенең кызлары белән патша юнәлә. Китәр алдыннан бәләкәй кыз, Незнай белән саубуллашып, үзенең хезмәтчесенә Незнайны яхшы карарга куша.

Гаскәр китеп, алты көн, алты төн үтә, ә Незнай уйлап та бирми, шар сугуын дәвам итә. Җиденче таңда Незнай бик нык итеп ат кешнәгәнгә тышка чыкса, аты килгән икән. Ат:

— Гаскәр киткәнгә алты көн, алты төн үтте бит инде, ә син һаман да уйлап бирмисең. Кояш калыкканчы, без сугыш яланында булырга тиешбез, — ди.

Незнай беркемгә дә бернәрсә дә әйтми, атына атлана да чыгып китә. Арттан песи белән эт тә ияраләр. Биек тауга барып, теге таш астындагы сугыш киемнәрен, кы-

7 Заказ 249

лычны алалар. Сугыш киемен киеп, кылычын тагып, атына меңгән иде, Незнайны танырлык та түгел хәзер.

Сугыш була торган җиргә килсәләр, дию гаскәре әзер, ә патша гаскәре һаман юк икән. Незнай меңләгән гаскәр белән берүзе сугышырга керешә. Песи белән эте дә ярдәм итә. Незнай кылычы белән бер селтәгәндә, әллә күпме дошманның башы өзелә, ди. Дию гаскәрен кырып беткәч, Незнай диюнең үзе белән сугышырга кала.

— Ә-ә-ә-ә, Незнай син буласыңмыни? Гаскәремне бетерсәң дә мине бетерә алмассың! Йә, алыштанмы, салыштанмы? — ди дию. Незнай:

— Алыштан да, салыштан да, — дигәч, кем башлап сугарга дип, шобага тотышалар. Беренче сугу диюгә тия. Дию Незнайны күтәреп бәрә. Незнай бәкәлдән җиргә бата. Бәкәлдән батса да, Незнайга бернинди зыян булмый, чөнки ул җирдән көч ала икән. Шуннан торып, үз чираты белән диюне атып бәргән иде, дию биленә тиклем җиргә батты. Незнай, кылычын алып, шул җирдә диюнең өч башын да берьюлы чаба да өзә. Шулвакыт, ничектер, үзе дә яраланып кала. Егет, тиз генә патша гаскәрләре янына барып, ярасын бәйләтә. Патша шундый шатлана: «Бу нинди батыр икән? Үземә чакырырга кирәк моны», — ди. Шуннан егетне чакыртып ала да:

— Әй, егет, әйдә безгә, бәләкәй кызымны сиңа бирәм, — ди. Шул урында кызы әйтә:

— Юк, мин Незнайдан башка беркемгә дә бармыйм, — ди, хәтта еларга тотына. Незнай әйтә:

— Елама, матур кыз, елама, мин сезгә бармыйм. Минем үз эшләрем бар, — ди дә, ярасын бәйләгән өчен рәхмәт әйтеп, атына менеп, елт итеп күздән югала. Патша сараена җитәр чакта атын җибәрә дә, кайтып, тагы шар сугарга тотына. Патшаның гаскәре кайта. Кайту белән бәләкәй кыз Незнай янына йөгереп килә. Хезмәтчедән:

— Незнай ничек торды? — дип сорый. Хезмәтче:

— Ничек торсын, шар сукты да шар сукты. Бер көн генә югалып торды, — ди.

Шулай тагы да байтак гомер узып китә. Патша олы кызын олы вәзиренә биреп туй ясады, Незнай бертуктаусыз шар сукты, ди. Бердәнбер көнне патша уртанчы кызын уртанчы вәзиренә кияүгә бирергә була. Иртәгә туй була дигән көнне тагы һаваны беренчедән дә зуррак кара болыт каплый. Моны күреп, халык: «Тагы берәр нәрсә булмаса ярар иде», — дип куркуга төшә. Шулай куркышып торганда һавадан кәгазь килеп төшә. Анда: «Патша, син минем ала торган кызны уртанчы вәзиреңә бирәсең икән, шуның өчен мин сиңа сугыш ачам. Алты башлы дию», — дип язылган, ди.

Патша тагы да гаскәр җыя, уртанчы вәзирне гаскәр башлыгы итеп, барсы да, хәтта кызлар да, сугышка китәләр. Бу тугыз көнлек юл икән. Ә Незнай бернәрсәгә дә исе китми, һаман шар сугуында була. Бәләкәй кызның кушып китүе буенча, аны хезмәтчеләр бик яхшы карыйлар. Шулай итеп җиде көн үтә. Сигезенче көн нык итеп ат кешнәгәнгә Незнай тышка чыкса, аты килгән, ди. Ат:

— Нишләп әле һаман шар белән буласың? Бүген гаскәр киткәнгә җиде көн, ә безгә иртәгә анда, сугыш яланында, булырга кирәк. Ату патшаның гаскәрен дә, кызыңны да һәлак итәчәкләр, — ди.

Незнай тагы беркемгә дә бернәрсә дә эндәшми, атына атланып, юлга чыгып китә. Теге тауга барып, киенеп, кылычны ала да сугыш яланына китә. Килсә, гаскәр шундый күп, күз күреме җирдә кара чәүкә булып сырып алганнар, ди. Незнай, моны күргәч, әзрәк шүрләгәндәй итсә дә, аты дәртләндереп, тагы берүзе сугыша башлый. Аңа аты да, песие белән эте дә ярдәм итә. Көн буе сугышканның соңында гына дошман гаскәрен чак кырып бетәләр. Хәзер алты башлы дию үзе сугышка чыга.

— Ә-ә, Незнай дигәннәре синмени әле? Йә хәзер минем белән алышып кара! — дип, дию Незнайны җиргә атып бәрә. Незнай тубыгыннан җиргә бата. Батса, тагы да көчлерәк булып чыга. Ул атына җитез генә сикереп менә дә кылычы белән селтәп җибәрә. Шул селтәүдән

диюнең дүрт башын өзеп төшерә. Дию, моны күреп, шундый ярсый, ничек булса да ике башын саклап калырга тырыша. Болар озак кына җаен табыша алмыйча, берберсен уратып йөриләр. Дию уңаен китереп, селтим дигәндә генә, Незнай аның калган ике башын да берьюлы өзеп төшерә. Шулчак дию Незнайны яралап өлгерә. Егет баягыча тиз генә патша кызларына барып, ярасын бәйләтә. Ярасын бәйләгәндә, патша, Незнайны күреп:

— Ә-ә-ә, теге егет! Инде сине җибәрмим. Кал инде минем патшалыкта, — дип ялына башлый. Егет риза булмый. Ә бәләкәй кыз:

— Минем Незнайга ничек охшаган, әллә аның абыйсы микән? — дип карап тора, ди. Патша:

— Теләсәң, минем уртанчы кызымны, теләсәң, бәләкәй кызымны ал, бирәм үзеңә, — дигәч, бәләкәй кыз:

— Юк, мин Незнайдан башка беркемгә дә бармыйм,— ди. Моны ишетеп, Незнай бәләкәй кызга:

— Юк, матур кыз, мин сездә калмыйм, минем эш — кагылган-сугылганнарга ярдәм итү, — дигән дә китеп барган. Патша сараена җитәр чакта Незнай, атын җибәреп, үзе бернәрсә дә булмаган сыман шар уйнап, киртәгә барып кергән, ди. Тугыз көннән соң гаскәр дә кайтып житкән. Кайту белән бәләкәй кыз Незнай янына йөгереп кергән. Хезмәтчеләрдән:

— Ничек торды, ничек ашады? —дип сорагач, хезмәтчеләр:

— Яхшы ашады, яхшы торды, көне-төне шар сукты, тик нишләптер, ике көн югалып торды, — дип җавап бирделәр, ди.

Патша кайткач, уртанчы кызы белән уртанчы вәзиренә бик бай туй ясады, ди. Ә Незнай һаман да шар сугуында булды, ди.

Шулай итеп, тыныч тормыш белән тагы да күп кенә вакытлар үткән. Бервакыт патшаның иң яраткан бәләкәй кызын да кияүгә бирергә вакыт җиткән. Патша сараен-

нан яучылар өзелмәгән, кыз гына ризалык бирмәгән, ди. Патша бәләкәй кызын чакыртып алган да:

— Кызым, син тугач та минем әйткән сүзем бар иде: кемгә теләсә, кызымны шуңа бирермен дигән идем, — дип сүз башлаган, ди. Кыз шатланып:

— Мин Незнайдан башка беркемгә дә бармыйм, — дип тик тора икән. Патша моңа риза булып җитмәгән:

— Кызым, син шуны да уйла: киявең мин үлгәннән соң патшалыкны алып барырга тиеш, ә ул телсез көе нәрсә эшли ала? — дигән. Кызы бик елый башлагач, риза булган да Незнай белән бәләкәй кызның туена әзерләнә башларга әмер биргән. Моны ишетеп, олы кияү белән уртанчы кияү:

— Әһә, патша үлгәч, патшалык безгә калачак, телсез нәрсә генә эшли ала инде ул, — дип бик сөенешкәннәр, ди.

Иртәгә туй дигән көнне тагы һаваны болыт каплаган. Бу юлы унике башлы диюдән кәгазь килеп төшкән. Ул да патшаны кече кызы өчен сугышка чакырган. Гаскәр җыелгач, кемне гаскәр башлыгы итеп куярга белмиләр, ди. Патша:

— Йә, кызым, кемне куябыз, телсезеңнеме? — дигәч, кыз:

— Юк, үзем барам, — дигән, ди. Гаскәр башлыгы булып кыз үзе киткән. Ә Незнай үзенең шарын сугып калды, ди. Бу инде унике көнлек юл булган. Тугыз көн үткәч, егет сызгырып, атын чакыртып алды да, этен, песиен ияртеп, теге урыннан коралларын барып алып, сугыш яланына китте, ди. Дию гаскәре шундый күп, кырмыска иләве кебек мыжгып тора, ди. Незнай гаскәр белән сугыша башлаган. Егет тора, ә дошман гаскәре очсыз-кырыйсыз кара болыт булып, аның өстенә ябырыла, ди. Незнай кылычын уңга селтәгән, сулга селтәгән, шулай итеп, дию гаскәрен кырып та беткән. Үзе, хәлсез булып, җиргә ауган. Әзрәк хәл алгач, ат, Незнайны уятып:

— Йә, егет, тизрәк диюгә каршы барыйк. Үзе килсә, тагы да яманрак булыр. Син аны тиз генә үтерә алмассың. Аның дүрт башы калгач, синнән ялварып атасына саубуллашырга җибәрүен сорар, аны җибәр. Тик безгә аның атасына алдан барырга кирәк. Ул атасыннан көч ала, ә аңа бирә торган көчне без алып өлгерсәк, яхшы булыр, — диде, ди.

Дию боларны күрү белән:

— Ә-ә-ә, Незнай дигәне синмени әле? Йә, алышып карыйк, — дип, алыша башлаганнар. Бер көн сугыштылар, икенче көн сугыштылар, ди, болар. Сугыша торгач, Незнай диюнең сигез башын өзеп төшерде, ди. Дүрт башы калгач, дию атасына җибәрүне сорап, ялвара башлаган. Егет риза булган. Үзе тиз генә атына атланган да диюнең атасына киткән. Барып керсә, диюнең атасы караңгы бер бүлмәдә утыра, үзе сукыр, ди. Дию, Незнайны үз улы дип, беләгеннән бер стакан кан алып эчергән. Канны эчү белән Незнайның көче аяусыз артып китте, ди.

Незнай, карт диюгә рәхмәт әйтеп, ишектән чыгып китеп кенә барганда, әлеге дүрт башы калган диюгә тап булды, ди. Дию ни дип тә уйлап өлгерми кала, егет аның өч башын өзеп төшерә. Инде соңгы башын чабып өзәм дигәндә, Незнай нык кына яралана. Ат иссез яткан Незнайны гаскәр янына алып бара. Монда аның ярасын бәйләп исенә китерәләр. Хәзер патша егетне бер дә җибәрәсе килми, үзе янында калуын үтенә:

— Калсаң, менә шушы бәләкәй кызымны үзеңә бирәм, — ди. Ә бәләкәй кыз бу юлы да:

— Мин Незнайдан башка кешегә бармыйм, — дип елый, ди. Незнай риза булмый, атына атланып, китә дә бара. Юлда ат әйтә:

— Хәзер инде мин дә синең белән барам, — ди.

Кайтып җиткәч, Незнай атын бәйли дә үзе йокыга тала. Ул бик арыган, бик йончыган була. Эте ишек төбендә, песие башы очында аны йокысын саклап торалар. Гаскәр кайтканчы, Незнай бер уянмый йоклый. Кайту

белән бәләкәй кыз Незнайның шар суга торган сараена йөгереп бара. Незнай анда булмагач, бүлмәсенә бара. Барса, ишек төбендә эт ята, ә ишеккә: «Кем дә кем керә, башын сугып изәм», — дип язылган була. Хәзер бу язуны барсы да укыйлар. Кызны кертергә куркалар. Кыз аларга карамый, керә. Керсә, бүлмәдә Незнай ята. Незнай кылычын ала да, чабам дигән булып, кызны кочаклап ала. Хәзер бүлмәгә кешеләр килеп тула. Аты белән киеменнән теге батырның Незнай икәнен беләләр. Шатланышып туй ясыйлар. Хәзер Незнай патшаның кече кызы белән ирле-бичәле булып яши башлыйлар.

Патшаның ике олы кияве ничек булса да Незнайны юк итү турында уйлыйлар. Шунда берсе әйтә:

— Кайдадыр җиде диңгез аръягында, җиде җир астында аждаһа кулында бер ашъяулык бар икән, шул ашъяулыкны җәйсәң, җаның теләгән бөтен әйбер барлыкка килә икән. Тик аны алырга барган кешенең кире әйләнеп кайтканы юк әле, диләр. Каенатадан менә шул ашъяулыкны алдырырга Незнайны җибәрүен сорыйк. Ул китәр дә әйләнеп кайта алмас, шуннан инде патшаның варислары булып, без калырбыз, — диләр.

Шулай киңәшләшеп, болар патшага ашъяулык хакында сөйләп бирәләр. Патша риза була, әмма бер Незнайга гына түгел, ә өч киявенә дә юлга җыенырга куша. Иртәгәсен иртүк торып, ике олы кияү юлга чыга. Незнайга «әйдә» дигәч: «Юк әле, сез бара торыгыз», — дип, өйдә торып кала. Өч көн тора, дүрт көн тора, бишенче көн дигәндә, патша бер вәзирен җибәрә:

— Бар әле, кече кияү киткәнме, шуны карап кил, — ди. Вәзир барып килә:

— Юк, китмәгән, — ди.

— Ярый, яшь кәләше янында торып китәсе киләдер, — ди патша.

Тагы бер-ике көн үтә. Патша тагы вәзирен җибәрә. Вәзир тагы «юк» дип килеп әйтә. Патша:

— Ярый, яшь кәләше янында торып китәсе киләдер, —

ди дә куя. Шулай итеп, ун көннән ашу вакыт үтә. Бу юлы патша үзе барып белергә була. Моны ат белеп кала да, Незнайны чакырып:

— Каенатаң килә, әйдә инде киттек, — ди. Шуннан тиз генә әзерләнеп чыгып китәләр, үзләре белән песине, этне дә алалар.

Болар алты диңгезне яхшы гына үтәләр. Хәзер җиденче диңгез генә торып кала. Шул җирдә ат:

— Җиденче диңгезне чыгуы авыррак булыр. Аны чыгу өчен, су патшасы кызы Алтынчәчне көтеп алып, аның үзенә сиздерми генә чәченә ябышып чыгарга кирәк. Әгәр ул безнең ябышканны белеп калса, диңгезгә дә төшереп җибәрүе мөмкин, — ди.

Диңгез янына килеп җитәләр. Бер бабай балык тотып утыра, ди. Незнай, бабай белән саулык сорашып, тормыш хәлләрен сөйләшеп утырганнан соң, бабайга киемнәрен алмашып киеп торырга сорый. Бабай риза була. Теге олы кияүләр килеп җиткәндә, Незнай бабай урынында балык тотып утыра. Болар Незнайны танымыйлар. Хәзер болар икәүләп Незнайдан теге ашъяулыкны китереп бирүен сорыйлар:

— Әгәр китереп бирсәң, ат башы кадәре алтын бирәбез, — диләр. Незнай:

— Китереп бирермен, тик миңа алтын кирәкми. Берегез бер бармагыгызны, икенчегез сырт каешыгызны телеп бирерсез, — ди. Болар уйлап-уйлап торалар да:

— Күлмәк кисәң, күренмәс, мин риза, — ди берсе. Шуннан икенчесе дә:

— Кулга бияләй кисәң, бармак юклык та беленми, мин дә риза, — ди.

Незнай боларга үзен шунда көтеп торырга кушып, аты янына китә. Юлда песие очрап:

— Тиз бул, хәзер Алтынчәч су коенырга килә, — ди.

Алтынчәчнең су керә торган җиренә киләләр дә көтеп яталар. Менә берзаман су өсте яп-якты булып киткән дә, судан Алтынчәч килеп чыккан. Ат:

— Сез нык итеп миңа тотыныгыз, ә мин кыз йөзә башлагач та, аның чәченә ябышырмын, — дигән дә кыз суга барып төшү белән, сиздерми генә йөзеп килеп, тегенең чәчен тешләгән, ди. Алтынчәч йөзеп киткән, аның чәченә тагылып — ат, атның койрыгына тотынып болар йөзгән. Инде килеп чыктык дигәндә генә, Алтынчәч, кемдер чәченә ябышканын сизеп калып, чәчен тарта башлаган икән, ат ялварырга тотынган:

— Алтынчәч, алып чыккач, алып чык инде ярга, чыккач сөйләшербез, — дигән. Шуннан кыз боларны ярга алып чыгып җиткән. Чыккач, ат Алтынчәчкә:

— Бер яхшылык эшли башлагач, яхшылык белән эшеңне бетер инде, — дигән дә үзләренең ни өчен килгәнен сөйләп биргән. Алтынчәч:

— Мин белмим, алда минем ике йөз яшьлек әбием бар, шул белсә белер, — дигән. Бара торгач, бу әбигә дә килеп җиткәннәр. Әби боларны:

— Ә-ә-ә, ерактан килгән кунаклар, әйдәгез, рәхим итегез, — дип, бик җылы каршы алган да туйганчы ашаткан. Ашап-туеп, ял итеп алгач, Незнай әбигә үзләренең ни өчен килгәнлекләрен сөйләп биргән. Тыңлап беткәч, әби:

— Мин ул ашъяулыкны белмим, белсә, минем апам белер. Ул моннан бик еракта яши, — дигән, ди.

— Ерак булса булыр, безгә аны тапмый кайтырга ярамый, — дип, егет, эте белән песиен ияртеп, тагы юлга чыккан. Бара торгач, әбине дә эзләп тапканнар. Бу әби дә юлчыларны бик яхшы итеп каршылаган, ашаткан, эчергән. Ләкин ул да ашъяулыкның кайда икәнен белми икән.

— Белсә, аны минем каргам гына белер, — дип, каргасын китергән, ди. Карга ашъяулыкның кайда икәнен белгән.

— Ашъяулыкны табарга мөмкин, тик алуы кыен, — ди икән карга. Юлаучылар үтенеп сорагач, ашъяулыкны кайдан табу юлын сөйләп биргән:

— Ул ашъяулык җиде кат җир астында, җиде катлы өйнең җиденче катында, җиде сандык эчендә ята, ә аны аждаһа саклый. Ашъяулыкны алганда бер тавыш та чыгарырга ярамый, шуның өчен песидәй сак булырга кирәк. Аз гына тавыш чыгып, аждаһа сизеп калса, сезне юк итәчәк. Менә сезгә тарак, кайрак, көзге. Аждаһа, белеп калып, артыгыздан куа төшсә, берәм-берәм ташларсыз, — дип, карга юлны өйрәтеп беткәч, әби боларны озатып калган.

Болар көн киткәннәр, ай киткәннәр, бара торгач, бер җир тишеген күреп калганнар. Бу әлеге җиде кат җир астына алып төшә торган тишек икән. Төшеп киткәннәр. Төшеп җитсәләр, җиде катлы бер өй утыра, ди. Песине өйгә кертеп җибәргәннәр. Песи, бер тавышсыз кереп, ашъяулыкны алып чыгып киттем дигәндә генә, койрыгы, бер кылга тиеп калып, тавыш чыгарган, ди. Аждаһа, тавышны ишетеп, ни булганын аңлап алганчы, болар юлга чыкканнар. Аждаһаның шундый ачуы килгән:

— Ниндидер бер сасык адәм баласы аждаһаның кулыннан хәзинә алып китсен, имеш, — дип гайрәтләнә икән.

Аждаһа боларның артыннан куа төшкән. Куып җитеп, тотам дигәндә генә, егет артларына көзгене ыргыткан. Ыргытуы булган, шул җирдә бик зур диңгез барлыкка килгән. Аждаһа диңгез суын эчеп корыта башлаган. Аны корытып, тагы да куа башлаганчы, болар байтак кына җир китеп өлгергәннәр. Аждаһа тагы җитеп килә икән, Незнай артына тарак ташлаган. Тарак барып төшкән җирдә үтә алмаслык урман үсеп чыккан. Аждаһа агачларны тешләре белән йолкып алып юл салып чыкканчы, болар тагы байтак кына юл киткәннәр. Аждаһа өченче тапкыр куып җитеп килгәндә, Незнай кайрак ташлый. Кайрак төшкән урында ташлары күкне тишеп торган, түбәсе дә күренмәслек тау барлыкка килә. Аждаһа тау-ташны актарып шунда торып кала. Ә Незнай, әбиләргә рәхмәт әйтеп, диңгезгә барып җитә. Алтынчәч аларны диңгез аръягына чыгарып куя. Незнай атын, этен, песиен

яшереп куя да үзе кияүләр янына килә, әлеге балыкчы карт төсен ала. Кияүләр, берсе бармагын кисеп биреп, икенчесе аркасыннан бер илле тиресен суеп биреп, ашъяулыкны алып кайтып китәләр. Алар юлга чыккач, артларыннан ук Незнай да, атына атланып, песие белән этен ияртеп, кайтырга чыга. Незнай кайтып, ун көн үткәч, кияүләр кайтып төшәләр. Незнайның өйдә икәнен белгәч, аннан көлә башлыйлар. Незнайның кайтуына, житмәсә, бернәрсә дә алып кайтмавына патшаның да ачуы килә, аңа җәза бирүне олы кияүләре белән бергәләп уйлый башлый.

Беркөн болар барсы да җыелышалар да Незнайны тикшерә башлыйлар. Шулвакыт Незнай патшага:

— Нигә синең уртанчы киявең шундый эссе өйдә бияләй киеп утыра, ә олы киявең калын күлмәк кигән? — ди. Тегеләрнең чишенүләрен сорый. Патша тегеләргә чишенергә куша. Чишенсәләр, ни күрсеннәр, берсенең бармагы юк, ә икенчесенең аркасыннан буйдан-буйга тиресе суеп алынган. Шул җирдә Незнай:

— Боларның берсенең бармагы, икенчесенең сырт каешы кайда дип беләсез? — дигән дә: — Менә кемдә ул! Мә, алыгыз, бармак белән тирегезне кире ябыштырып куегыз, ә миңа минем ашъяулыкны бирегез! — дип, бөтен булган хәлне патшага сөйләп биргән..

Моны ишеткәч, патшаның бик ачуы килгән. Олы кияүләрен алдаганнары өчен үтерергә кушкан. Незнай белән хатыннары сорагач кына, үлемнән алып калганнар, ди. Олы кияүләр Незнайга һәрвакыт тугры хезмәт итәргә сүз биргәннәр. Чыннан да патша үлеп китеп, аның урынына Незнай патша булгач, аңа бик тугры хезмәт иткәннәр. Калган гомерләрен, революциягә тиклем, бик дус яшәгәннәр, ди. Ә революция бөтен патшаларны бетергән.

ТАЗ БАТЫР

Борын-борын заманда яшәгән, ди, бер карт белән карчык. Бик тату гомер иткәннәр, ди, алар. Тырышып эшләп йорт, киртә-кура корганнар, аз-маз мал-туар булдырганнар. Карт та, карчык та кешегә яхшылык итәргә генә тырышкан, үзләре дә беркемнән дә зарар күрми, тыныч кына яшәргә теләгәннәр. Алар үлү белми, гел генә сау-сәламәт яшәү турында хыялланганнар. Авырып киткән чакларында бер-берсен карап, үз белдекләренчә дәвалап, тизрәк аякка бастырырга тырышканнар.

Бу әби белән бабайның өч улы булган. Олы улы — Алтынбай, уртанчысы — Көмешбай, кечесе — Акылбай. Әмма Акылбайга әтисе белән әнисеннән башка үз исеме белән эндәшүче булмаган, аны таз дип кенә йөрткәннәр.

Бердәнбер көнне әби бик каты авырып киткән. Бабай аны ничаклы гына дәвалап карамасын, савыктыра алмаган. Әби үлеп тә куйган. Карт та, ятим калган уллары да бик кайгырышкан. Әмма күз яше кою белән үлгән кешене терелтеп буламы соң. Бабай, карчыгын терелтер өчен берәр әмәлен тапмакчы булып, улларын чакырып алган. Өлкән улы Алтынбай белән уртанчы улы Көмешбайга карап:

— Оланнарым! Сез икегез дә акыллы, кайда барсагыз да хур булмассыз. Хәзер үк үлгән кешене терелтә торган тересу эзләргә чыгып китегез, дөньяның бөтен дүрт ягын да байкагыз, кирәк икән, җир читенә барып җитегез, әмма эзләгән нәрсәгезне тапмый кайтмагыз! — дигән.

Атасының бу боерыгын тыңлап торган таз: «Мин дә барам», — ди башлагач, абыйлары аңа:

— Син имгәкне ияртеп йөреп булмас инде. Мич башына мен дә борчак чүплә, тазыңны тырна да безне сагынып җырла. Тик шуны кара, нык кипкән борчак ашап, тешеңне кырма! — дип көлешкәннәр.

Әтисе дә тазга бармаска кушкан. Андый авыр эшне булдыра алмассың, дигән.

Алтынбай белән Көмешбай икесе дә, менә диган ат атланып, кулларына ук-җәя, кылыч алып, юлга чыгып та киткәннәр.

Таз әнисенең үлүенә барсыннан да ныграк кайгырган, ни өчен дисәң, бахырны абыйлары кимсеткән, мыскыллаган чакларда, аны әнисе генә яклый, иркәли торган булган. Шуңа таз бик ялынып сорагач, әтисе:

— Күңелең булсын, бар әйдә, иллә мәгәр бик ерак китмә, әйләнеп кайта алмый йөрүең бар, чит җирләрдә әт-кош тырнагына эләгүең дә бар, — дигән.

Тазга әтисе ябагасын да коя алмаган бер күк яшь айгыр биргән, калдык-постык кием кидергән, иске-москы корал тоттырган. Абыйлары артыннан таз шулай юлга чыккан. Әмма абыйларының нинди юлдан, кайсы якка киткәнен белми аптырап калган. Көтмәгәндә таз менгән күк айгыр телгә килеп:

— Егет, тезгенне бушат, кайда барырга мин үзем беләм, — дигән.

Таз тезгенне бушаткан. Күк айгыр иге-чиге күренмәс далага карап җилгән.

Таз Алтынбай белән Көмешбайдан өч тәүлек соңлап чыккан булса да, күк айгыр аны тиз арада абыйлары янына илтеп җиткергән. Алтынбай белән Көмешбай, артларыннан бастырып килгән энеләрен күргәч: «Кара, кара, безнең таз килә, егылып үләрсең, биллаһи», — дип буыннары катып көлешкәннәр.

Тазга абыйлары кире кайтырга кушканнар, әмма таз моңа риза булмаган. Шуннан соң Алтынбай белән Көмешбай, икесе ике яктан төшеп алып, тазны камчы белән ярырга тотынмасыннармы! Таз барыбер ат башын кире бормаган, һаман абыйлары артыннан бара биргән.

Бара торгач, алда өчесе өч якка аерылып киткән өч юл күренгән. Юл чатына җиткәч, Алтынбай:

— Алдыбызда өч юл ята. Без хәзер менә шушы юллар белән өчебез өч якка китик, — дигән.

Көмешбай моны хуп күргән булган, таз исә каршы төшеп:

— Юк, аерылмыйк, абыйлар, берлектә генә тереклек. Аерылганны аю ашар, бүленгәнне бүре ашар, дигәннәр. Кайсы якка карасаң да, үләне көйгән чиксез ялан. Күпме вакыттан бирле атларыбызны эчерергә су тапмыйбыз, үзебезнең дә өйдән алып чыккан азык-төлек бетте. Җәнлеге дә, кошы да очрамый, ичмасам. Аерылсак, ачка үләрбез, атларыбыз да хәлдән таяр. Ә бергә булсак, берәр әмәлен табарбыз, — дигән.

Абыйлары моны тыңлап торган да:

— Хәйләкәр! Таз! Гомергә синең сунарда йөргәнең, кош аулаганың юк. Син шулай безнең җилкәдә яшәмәкче буласыңмыни? Үз көнеңне үзең күр, әнә бара юлың! — дигәннәр.

Тазга сул якка киткән юлга төшеп алырга кушканнар, Көмешбай урта юлдан, ә Алтынбай уң юлдан киткән. Таз күздән югалгач та, Алтынбай белән Көмешбай кабат бергә кушылган. «Тазның башы олакты, ябага айгырны әллә кая алып китә алмас, әтием янына кайтып китәр», — дип көлешә-көлешә алга киткәннәр.

Абыйларыннан аерылгач, таз үзенең бердәнбер тугры юлдашы булган күк айгыр белән алга бара биргән. Ашамаганга-эчмәгәнгә байтак көн үткән. Атып алырдай җәнлек тә, кош та тап булмаган, су да табылмаган. Шулай изаланып барганда, кайдандыр таз алдына тоягы җәенке бер бүз тарпан килеп чыккан. Бу кыр атын күреп, таз тәүдә бик куанган. Ашарга ит булды, дип угын җәясенә сала, ә пычагын капшый башлаган. Шулчак тазның башына кинәт шундый уй килгән: «Ярый, мин бу тарпанны атармын атуын, бер-ике тапкыр туйганчы ашармын да. Ә калган итне кайда итәргә? Торып калыр, әрәм булыр. Кем белә, ул тарпанның буаз булуы да бар. Ул вакытта берьюлы ике җан иясе харап булыр. Мин абыйларымнан аерылган кебек, бу тарпан да, бәлки, үз өереннән аерылгандыр, шунлыктан минем яныма килгәндер.

Бу хайванны харап итмим. Шунда миңа дигән берәр кош-фәләп очрар әле»,—дип угын кире урынына салып куйган.

Акрынлап булса да, таз һаман алга табан барган. Күк айгыры да карышмый атлый биргән, тик аның колаклары инде шәмдәй текә басып тормаган, башы да түбән иелгән. Бахыр атның борыныннан эссе тын бөркеп торган, аскы ирене салынып төшкән, тешләре тузанланып беткән.

Менә шулай газапланып барганда, баягы тоягы җәенке бүз тарпан янә таз алдына килеп чыккан. Таз: «Мөгаен, бу ат мине ачка үлүдән коткару өчен йөридер, югыйсә бер үк хайван ике тапкыр күренмәс иде»,—дип уйлаган. Бу юлы тоягы җәенке бүз тарпанны атып алмакчы була. Әмма аның башына тагы да баягы уй килгән: «Бер-ике тапкыр туенам дип, шушындый хайванны харап итү егетлек түгел, миннән калган итне кем ашар?»

Таз тарпанны тагы жәлләгән, үзе юлын дәвам итәргә булган. Бара торгач, ул шулчаклы йончыган, хәтта аттан төшсә, кабат менеп утырырлык та хәле калмаган. Башын аска игән күк айгыр да аякларын күтәреп атлый алмый башлаган. Менә шушы мәлдә теге тоягы җәенке бүз тарпан өченче тапкыр килеп чыккан. Таз бу юлы да угын тарпанга төбәгән, шулай ук бу юлы да ату уеннан кире кайткан. Угын җәясенә кире салып, арытабан китмәкче булган. Әмма актык чиккә җитеп хәлдән тайган күк айгыр урыныннан кузгалып китә алмаган.

Менә шулчак каршыда басып торган тоягы җәенке бүз тарпан кинәт ак сакаллы картка әверелгән дә, тазга карап:

— Егет, мин синең озак юлдан килеп арыганыңны, ачлыктан йончуыңны да яхшы беләм,—дигән.—Сине өч тапкыр сынап карадым: өч тапкыр тоягы җәенке бүз тарпан булып юлыңа каршы чыктым; яныңа килгән хайванны атып төшерү авыр эш түгел иде, иллә мәгәр син атмадың, чыдамлык, сабырлык күрсәттең,—дигән.—Син

яхшылыкка каршы яхшылык күрергә хаклысың. Әйт, нинди мохтаҗың бар? — дигән.

— Әй бабай, үзең күреп торасың, үземә дә, атыма да туйганчы ашап-эчәргә кирәк, беренче мохтаҗым шул, — дигән таз.

Ак сакаллы, алтын акыллы карт, таз янына килеп, атының сыртыннан сыйпаган икән, күк айгыр янә тезгенен тотып тыя алмаслык тулпарга әйләнгән. Шул җирдә карт тазга: «Арттан ияр», — дигән, үзе кабат бүз тарпанга әверелеп, аткан уктай далага очкан. Тазның күк айгыры да аннан калышмаган. Бара торгач, биек койма белән уратып алынган бер йорт күренгән. Бүз тарпан шул йортка барып кергән, ә капкадан үткәч тә, тагы ак сакаллы картка әверелеп, тазга:

— Рәхим ит, егет, кадерле кунагым булырсың, ял итәрсең, — дигән. Тазны өйгә алып кергән, күк айгырны ат сараена кертеп куйган. Егетне дә, атын да бик әйбәтләп сыйлаган. Шуннан соң карт:

— Йә, егет, хәзер барсын да сөйләп бир. Юлыңның башы кайдан иде, нинди йомыш белән бу якка килеп чыктың? Бу тирәгә ят кешеләр килеп җитә алмый, җиткәннәре кире әйләнеп китә алмый. Шунсын да белеп тор, — дигән.

Таз үзе хакында төкми-чәчми, энәсеннән җебенәчә сөйләп биргән. Әнисенең үлүен, шуны яңадан терелтү өчен тересу эзләп йөрүен әйткән.

Карт бераз уйланып торганнан соң:

— Егет, синең күк айгырың гади ат түгел, тулпар затыннан ул, тик канатлары гына җитлекмәгән. Иллә мәгәр моның өчен кайгырма, минем өйдән чыгуга аның канатлары да үсеп өлгерер. Бу тулпар үз теләгеңә ирешергә ярдәм итәр. Бөтен эшне ул әйткәнчә эшлә, — дигән.

Шушы сүзләреннән соң карт тазны ат сараена алып барган. Шунда ул куеныннан алган кавырсын белән айгырның сыртыннан сыйпаган икән, хайван кинәт очарга омтылып торган тулпарга әйләнгән. Тулпар яңгыратып

кешнәп җибәргән, ярсый, торган урынында уйнаклый башлаган. Шуннан соң карт, тулпарның башыннан сыйпап, аңа әллә нәрсә шыбырдагач, тулпар тынычланган. Иң соңында карт тазга кырык колачлы тимер чылбыр, бер уч печән белән бер кисәк ит тоттырган да:

— Егет, боларның берсен дә югалтма. Ни өчен кирәклеген, вакыты җиткәч, тулпарың әйтер, — дигән.

Таз ак сакаллы, алтын акыллы картка мең рәхмәт әйтеп, ул биргән әйберләрне алып, юлын дәвам иткән. Аты, телгә килеп, тазга күзен йомарга кушкан. Таз күзен йомуга колак төбендә выжлап җил искәнне генә сизгән. Бераздан, тирә-якка күз салса, алтын белән саф пыяладан салынган, бакчасында төрле асыл кошлар сайрап торган бер сарай алдына килеп төшүен күргән. Әмма бу сарайга һич керерлек түгел икән: ул бик биек таш койма белән уратып алынган, ә капкасы бөтенләй юк, ди. Шул вакыт тулпар, телгә килеп, аптырап торган таздан:

— Кулыңдагы камчың белән минем уң як кабыргама сук, сул кабыргамнан кан чыгарлык булсын, — дигән.

Таз ул кушканча эшләгән. Тулпар, унике колач биеклектәге таш койманы күз ачып йомганчы сикереп үтеп, сарай ишеге алдына барып та төшкән. Әмма ишек алдында сарайны саклый торган галәмәт зур мөгезле бер үгез белән усал этләр тора икән. Бу ишектән беркем үтмәле түгел. Керергә теләгән кешене үгез сөзеп үтерә, үгездән котылганнарны усал этләр өзгәләп ташлыйлар икән. Боларны күреп таз нишләргә белми торганда, тулпар янә телгә килеп:

— Мине сарай янындагы бакчага илт, анда йөз еллаган бер алма агачы булыр. Шуңа мине кырык колачлы чылбыр белән бәйләп куй. Кулыңа баягы ак сакаллы бабай биргән ит кисәге белән бер уч печәнне ал. Печәнен үгезгә бирерсең, итен этләргә ташларсың, шуннан үзең сарайга керерсең. Кергәч, нишләргә кирәклеген үзең күрерсең. Тересу шушы сарайда саклана, — дигән.

Егет, тулпар кушканча, сарай ишегенә карап юнәл-

гән. Сактагы үгез, мөгезләрен чайкап, үкерә башлаган. Ул үкергәндә, җир тетрәп торган, бакчадагы кошлар сайраудан туктаган. Озын ботлы, зур томшыклы яман этләр тешләрен ыржайтып тазга ташланган. Егет бер дә каушамый гына үгезгә бер уч печәнне ташлаган, этләргә ит кисәген ыргыткан. Үгез — печән, этләр ит белән алданган арада, таз сарайга кереп тә киткән.

Сарай исәпсез күп бүлмәле икән. Һәр бүлмә үзенә бертөрле итеп эшләнгән. Тәүге бүлмәнең идәненә яшел келәм түшәлгән, стеналарына яшел хәтфә эленгән. Икенче бүлмә башка төстәге келәмнәр белән җиһазландырылган. Өченчесе идәненнән алып түшәменә тиклем көзгедән генә торган. Егет, тәүге ике бүлмәне үтеп, көзгедән генә торган бүлмәгә кергәч, кайда барырга белми аптырап калган. Кайсы якка гына карамасын, анда тик үзен генә күргән. Аптырап торганда әмәле табылган. Каршыда аз гына ачылып торган ишек ярыгыннан күрше бүлмәнең яктылыгы төшеп тора икән. Таз иплəп кенә шул бүлмәгә барып кергән.

Керсә, ни күзе белән күрсен: шундый иркен бүлмә, идәне дә, стеналары да, түшәме дә күзнең явын алып торган асыл пыяладан эшләнгән. Бүлмәнең нәп уртасында топ-тонык күл бар, ди, ә күлдә алтын балыклар уйнап йөри, ди. Күл тирәсендә әллә нинди агачлар, матур-матур гөлләр үсеп утыра; кызарып пешеп, өзелеп төшәргә торган җимешләр арасында былбыллар, башка төрле асыл кошлар сайрый, ди. Әнә шул сайрар кошларның кайсыберләре тазның иңбашына килеп куналар икән.

Таз аяк очына басып күл янына барган, суын татып караган. Су бик татлы булган. Ул суны татып караганда, бөтен кошлар сайраудан, алтын балыклар уйнаудан туктаган. Күл тирәсендәге агачлар җимешле ботаклары белән егетнең алдына иелгән. Шуннан таз күлнең аръягына юнәлгән. Анда киң яфраклы биек агачлар үсеп утыра икән. Әнә шул галәмәт биек агач күләгәсе астында алтын аяклы бер чын карават тора, ди. Караватта, ак атлас

тышлы мамык мендәрләргә күмелеп, яшь кенә бер кыз йоклап ята икән, ди. Тел белән сөйләп тә, кавырсын белән язып та килештерерлек түгел бу кызның сылулыгын. Көндез кояш көнләшер, төнен ай оялыр булган, ди, үзеннән. Менә нинди чибәр кыз булган ул. Әллә нинди матур кошлар, кызның баш өстенә килеп, канатларын җилпеп, җиләсләндереп торганнар. Ә кыз сарайга чит кеше кергәнен дә сизми, гамьсез йоклаган да йоклаган. (Аның әле йоклый торган чагы булган.) Баягы ак сакаллы карт тазны кызның йоклаган чагына чамалап җибәргән инде. Югыйсә кыз уяу вакытта сарайга керү бөтенләй мөмкин түгел, ди.

Үлгәнне терелтә, картны яшәртә торган тересуның хуҗасы шушы кыз икән. Ул үзе картаюның нәрсә икәнен дә белмәгән, гел генә яшь көе торган. Һәр атнаның дүрт көнен җил арбасына утырып, дөнья гизеп йөргән. Шул арбасы белән ул күз ачып йомганчы бер җирдән икенче җиргә, бер илдән икенче илгә очкан. Шулай ул үзенә тиң егет эзләгән, — һич таба алмаган. Дүрт көн ил гизгәч, өч көн ял итә торган булган. Безнең таз бу сылу янына барып кергәндә, аңа уянырга җиде тапкыр гына тын алырлык вакыт калган икән.

Менә шундый үтә сылу кызны күреп, таз нишләргә дә белми катып калган. Шул арада кошлар ныграк сайраша, чырылдаша башлаган, җил исмәсә дә, агач яфраклары шыбырдашкан. Нәкъ шул вакытта кыз акрын гына күз керфекләрен ачкан, ашыкмый гына башын калкыта башлаган, ди. Ул кузгалгач, бүлмә тагы да яктырак булып киткән, сарай эчендәге күл өстендә нурлар уйнаган.

Караватка якын гына басып торган егетне күреп, кыз кинәт сискәнеп киткән, өстеннән шуып төшкән ефәкне ике кулы белән тотып, күкрәген каплаган. Бернитиклем вакыт кыз да, егет тә бер-берсенә эндәшми, аптырашып карап торганнар. Көтмәгәндә үз бүлмәсендә ят кешене кү-

рүгә хәйран калган кыз бераздан соң гына егеткә сорау биргән:

— Егет, син кем, кайдан килдең, минем сараема ничек кердең? — дигән.

— Мин Акылбай, этием белән әнием бүтән кеше таз дип йөртә. Бик ерак илдән килдем.

— Сиңа монда нәрсә кирәк?

Мондый сылу кызны күргәч, таз тәүдә үзенең нәрсә артыннан килгәнен дә оныткан. Ахырда:

— Әй, сылу кыз! Синең кебек искиткеч сылуны өнемдә түгел, төшемдә дә күргәнем юк иде. Кем кызы буласың соң? — дип сораган.

Төрле илләрдә йөреп тә, исәпсез күп кеше күреп тә сылу кызга моңа тиклем бер егет белән дә икәүдән-икәү генә калып сөйләшергә туры килмәгән икән. Ул янында торган егеткә янә текләбрәк карап: «Бу көнгә тиклем мине бик күп егетләр эзләп-эзләп тә таба алмаган иде. Сараема керергә теләүчеләр күп булса да, берсенең дә керә алганы юк иде. Бу егет мине килеп тапкан, сараема үтә алган. Мөгаен, ул бик акыллыдыр, бик батырдыр, мин эзләгән егет шушыдыр», — дип уйлаган. Тазның күзләренә карап елмайган. Кыз елмайганда чәчелгән күз нурлары егетнең күзләрен чагылдырган, йөрәген җилкендергән. Кыз эндәшмичә генә кулларын егеткә сузган. Бу вакыт бөтен кошлар сайрашудан туктаган, пырылдашып очып, күлнең аръягына күчкән, шунда алар агачлар, гөлләр, чәчкәләр арасында яшеренгәннәр. Бөтен сарай тынтын булып калган.

Егетнең сарай эчендә күпме вакыт булуын беркем дә белмәгән. Бу хакта егет белән кыз үзләре дә әйтә алмас иде. Әмма алма агачына чылбыр белән бәйләп калдырган тулпар күптән инде егетне ашкынып көткән.

Таз батыр сарайда үткәргән вакытын төшемме бу, өнемме дип уйланып торганда, кинәт ат кешнәгән тавыш ишеткән. Шулвакыт бу сарайга ни йомыш белән килүе исенә төшеп, пошына башлаган. «Инде нишләргә? Сарай-

дан чыгып китсәм, сылу кыздан аерылам, шушындый бәхеттән, оҗмахтагы кебек рәхәт тормыштан мәхрүм булам; сарайда калып, тересуны алып кайтмасам, үлгән әнием яңадан терелмәячәк», — дип уйланган.

Тазның боекканын күреп, кызы:

— Егет, йөзеңә ниндидер борчылу галәмәте чыкты. Ни хәсрәтең бар? — дип сораган.

Таз әнисенең үлүен, аны яңадан терелтәсе килүен, шунын өчен тересу эзләргә чыгып китүен бәйнә-бәйнә сөйләп биргән. Сылу кыз, тазның сөйләгәнен тыңлагач, егетне тагы да ныграк ярата башлаган, ни өчен дисәң, моңа тиклем бушка күл булып яткан бу тересуны килеп табучы да, әҗәлгә дару итеп алып китүче дә булмаган. Шунда кыз:

— Әй, батырым, бәгырем! Мин синнән башка тора алмыйм, сарайдан китә калсаң, шиңгән гөл кебек саргаермын. Элек үземә тиң егет эзләп байтак гомерем узды, инде теләгемә ирештем дигәндә генә, мине ташлап китәсең, кайгы-хәсрәт утына саласың. Китмә минем янымнан, китмә, бәгырем, минем сараемнан, бергә-бергә гомер итәрбез; сараема, әнә шул күлгә син хуҗа булырсың, — дип ялынган.

Моны тыңлап, таз:

— Юк, җаным, сылуым, кала алмыйм, — әтиемә биргән сүземнән дүнә алмыйм. Үлгән әниемне терелтми торып, синең белән бергә була алмыйм. Мин, үз илемә кайтып, әниемне терелтермен дә кабат синең яныңа килермен. Менә шуннан соң гомер буе бергә булырбыз, — дигән дә сарайдан чыга башлаган.

Асыл сарайның асыл кызы:

— Мин сине көтәрмен. Тик үзеңне саклый күр. Юлга чыкканчы тамагыңны туйдыр, — дип, таз алдына бизәкле чүлмәккә салып каймак, күпереп пешкән чүрәк китереп куйган, бер тустак ширбәтле су да биргән. Таз чүрәкне каймаклап ашап, суын эчә башласа, хәйран калган: күп-

ме ашамасын, күпме эчмәсен, чүрәк тә, су да һич кимемәгән. Каймагы гына беткән.

Ашап-эчеп туйгач, таз юлга чыгарга булган. Кыз аңа, монсы үзеңә, дип бер чүрәк белән бер бәләкәй шешә ширбәтле су биргән, монсы әниеңне терелтер өчен дип, бер шешә тересу тоттырган.

Таз тулпарын чылбырыннан ычкындырып атланган да, аты әйткәнчә, өч тапкыр аның сул кабыргасына сугып, уң як кабыргасыннан кан чәчрәткән. Шуннан егет күзен йомган. Таз батырның битенә әче җил бәрелеп, колак төбендә выжылдаган. Күзен ачканда инде ул үзен баягы ак сакаллы, алтын акыллы картның йортында күргән. Карт аннан барсын да җентекләп сорашкан. Таз бәйнә-бәйнә сөйләп биргән.

Шуннан карт:

— Егет, син бик күп кыю батырлар ирешә алмаган бәхеткә ирешкәнсең, болай булгач. Син, чынлап та, мин эзләгән кыю егет икәнсең. Бу батырлыгың өчен мин сиңа йортымдагы кырык таш келәтнең утыз тугызын ачып күрсәтәм. Шул келәтләрдән җаның теләгән нәрсәне үзең сайлап алырсың, — дигән.

Карт бер-бер артлы утыз тугыз келәтне ачып күрсәткән. Ул келәтләр алтын, көмеш, гәүһәр, якут, тагы әллә нинди асылташлар, төрле-төрле кыйммәтле җиһазлар белән тулган икән. Әмма таз батыр бернәрсәне дә алмаган. Аның кырыгынчы келәттә нәрсә барлыгын беләсе килгән. Ә карт кырыгынчы келәтне ачарга риза булмаган. Егет бик ялынгач, карт кырыгынчысын да ачарга риза булган, тик бер шарт куйган:

— Мин кырыгынчы келәтне ачам, ә син миңа берничә тамчы тересуыңны бир, аның миндә дә булуы хәерле, — дигән.

Таз батыр:

— Бабай, син кемне терелтергә итәсең соң? — дип сораган.

— Ансын белмәсәң дә ярар сиңа, — дигән карт.

Таз батыр карышып тормаган, шешәдәге тересуның берничә тамчысын ак сакаллы картка биргән. Шуннан соң кырыгынчы келәтне дә ачканнар. Монысын күреп, таз батыр ни әйтергә дә белми аптырап калган: анда аяк-куллары богауланган хәлдә Алтынбай белән Көмешбай бикләнеп утырмасынмы!

Ә бу хәл шулай килеп чыккан. Алтынбай белән Көмешбайга, таз сыман юлда бик җәфа чигәргә, ачыгырга туры килгән. Аларга да шул ук тоягы җәенке бүз тарпан очраган. Алтынбай белән Көмешбай бу хайванны күрү белән атып екканнар. Тик янына бара башлагач, егылган тарпан кинәт юк булган. Ике туган, аптырашып калып, арытабан юл тоткан. Бераз баргач, тагы да ялгыз тарпан тап булган. Алтынбай белән Көмешбай бу юлы да аны атып екканнар, әмма янына бара башлагач, теге янә югалган. Аптыраган ике юлчы алга карый киткән. Шул ук тарпан өченче тапкыр килеп чыккан. Бу юлы хайванны икесе бергә атып екканнар. Тик пычаклыйм дигәндә генә, бүз тарпан сикереп торган да ак сакаллы картка әверелгән. Пәһлеван карт Алтынбай белән Көмешбайны, аяк-кулларын богаулап, үзенең менә шушы кырыгынчы келәтенә китереп япкан.

Таз батыр агайларын күреп бик кызганган, карттан аларны иреккә чыгаруын сораган. Әмма карт тәүдә моңа риза булмаган. Ә таз батыр һаман ялынган, һаман инәлгән:

— Миңа бүтән бернәрсә дә кирәкми, тик абыйларымны гына коткар, без өчәү бергә бер үк тересу эзләп чыккан идек, аны мин таптым инде. Хәзер өчебез дә бергә кайтыйк, әниебезне терелтик, әтиебезне куандырыйк,— дигән.

Бу сүзләрне ишетүгә, Алтынбай белән Көмешбай тазның аяк астына егылганнар.

— Коткар инде энекәш, безне, зинһар, коткар моннан! Күрсәткән яхшылыгыңны гомергә онытмабыз, бу хәлне бөтен халыкка сөйләрбез. Әтиебез үзеңә рәхмәт укыр.

Коткара алсаң, синең колың булып яшәргә дә риза булыр идек,— дип ялынганнар.

Таз бик үтенеп сорагач, ак сакаллы карт, теге икәүнең аяк-кулларын богаудан алып, иреккә чыгарган. Шуннан тазның үзенә генә:

— Шулай да бу абыйларыңнан сак бул! — дигән.

Өч туган әнә шулай үз илләренә, әтиләре янына, кайтып киткән. Туган туфракка тизрәк аяк басарга ашыкканнар. Бигрәк тә таз батыр ашыккан. Үзенең шәп тулпары белән ул җәһәтрәк тә кайтып җитәр иде дә бит, абыйларын ташлап китәсе килмәгән. Алтынбай белән Көмешбайның аты арый башласа, ул да туктаган. Ябагасын да коя алмаган күк айгырның шулкадәр елдам атка әйләнүен күреп, Алтынбай белән Көмешбай бик көнләшкән. «Тазның аты ару белми, безнең атлар аңа нярә дә алмыйлар. Таз тезгенен бушатса, айгыры очарга гына тора. Бара-бара, таз безне ташлап китәр дә, йортка алданрак кайтып, тересу белән әниебезне терелтер, ә без күзле бүкән кебек торып калырбыз», — дип уйлашканнар, ничек итеп булса да тазның айгырына берәр этлек кылырга булганнар.

Кайтыр юлның яртысын үткәч, берзаман, кояш баеп, караңгы төшә башлагач, егетләр кунарга туктаган. Атларын үлән утларга җибәреп, йокларга ятканнар. Алтынбай белән Көмешбай, яткач та, хырылдап йоклап киткән. Таз батыр, айга, йолдызларга карап, сарайда калган сылу кызын уйлап яткан, тик таңга табан гына татлы йокыга чумган. Алтынбай белән Көмешбай, таң атканда торып, таз айгырының дүрт тоягына дүрт кадак какканнар, үзләре янә ятып йоклаганнар.

Таз йокысыннан торган. Кузгалырга вакыт дип, Алтынбай белән Көмешбайны уяткан. Ике агай атларын иярләп китеп тә барган. Ә тазның күк айгыры аяктан язган. Таз батыр, атым чирләгән, инде нишлим, дип аптырап калган. Шуннан аяклары аксаган айгырын җитәкләп

абыйлары артыннан җәяүләп барган. Көн үзәге җиткәч, абыйлары туктап:

— Таз, айгырыңның рәте китте, безнең атларга иярә алмый. Җәяүлегә җайдак юлдаш түгел. Тересуны безгә бир дә, без, эш узмас борын, тизрәк кайтып әниебезне терелтик; син, айгырың аякка баскач, кайтырсың әле, — диганнәр. Таз моңа риза булмаган:

— Ничек булса да бергә кайтыйк, әниебезне бергәләп терелтербез, җәяүләп булса да сездән калышмаска тырышырмын, — дигән.

Таз бахыр әнә шулай, айгырын җитәкләп, абыйларын күрә-күрә генә арттан барган. Янә кич булган, өч туган, атларын үлән утлатырга җибәреп, йокларга ятканнар. Көн буе җәяү килгән таз батыр, яткач та, каты йокыга киткән. Алтынбай белән Көмешбай, ул йоклаган арада, киңәш корганнар. Киңәшләре шул: тазны үтермәкче булганнар. Тересуны таз үз кулында алып кайтса, без буш кул белән торып калырбыз. Ул, суны үзем генә таптым, дип, ак сакаллы картның зинданында ятканыбызны да кешеләргә сөйләр. Хурлыгыннан җир тишегенә керердәй булырсың ул чак, дип уйлаганнар.

Абыйларыннан явызлык көтмәгән таз гамьсез йоклап ята биргән. Шул арада Алтынбай белән Көмешбай энеләрен тезген белән буып үтергәннәр дә кесәсендәге сулы шешәне алып кайтып киткәннәр.

Бахыр күк айгыр, үтереп ташланган хуҗасы тирәсендә әйләнгәләп йөргән-йөргән дә, имгәнгән аякларын көч-хәлгә сөйрәп, ак сакаллы, алтын акыллы карт йортына борылып киткән. Карт, атны күргәч тә, тазга ни булганын төшенеп алган, шуннан ул үзенең батырларын чакырып:

— Минем еректан килгән дустым таз батырны юлда ике абыйсы харап иткән. Шул ике явызны бастырып китегез, үзләрен монда терелә̆й тотып китерегез. Тазның мәетен саклык белән генә алып кайтыгыз, — дип боерган.

Атлы батырлар чабышып тегеләрне бастыра киткәннәр. Байтак көн үткәч, барсы да арып-талып кире кайт-

каннар. Абыйларын да куып җитә алмаганнар, таз батырны да таба алмаганнар.

Ак сакаллы, алтын акыллы карт: «Егетне үтергәч, күмеп киткәннәрдер, җир өстендә ятса, табылыр иде», — дигән уйга килгән.

Шуннан соң бик сизгер бер бүрене чакырып китереп, таз батырны үле булса, үле көе, тере булса, тере көе табып китерергә кушкан. Менә шушы ерактан ис тояр бүре өстән-мөстән генә күмелгән таз батырны табып алып, сыртына салып, картка китереп биргән.

Ак сакаллы, алтын акыллы бабай теге вакыт таздан алып калган тересуны мәетнең авызына койган. Күп тә үтмәгән, таз батыр яткан җиреннән торып:

— Ай-һай, озак йоклаганмын ахры, — дигән.

Шунда карт:

— Йокламый ни, йоклагансың, атаң башы! Үзеңне абыйларың үтереп җиргә күмеп киткәннәр. Ярый әле, бахыр тулпарың минем йортка килде. Шуннан соң сине, бүредән таптырып, үзең биреп калдырган суны эчереп терелттем, — дигән.

— Ә тулпарым кайда, ул чирләгән иде бит, хәзер ни хәлдә?

— Юк, егет, тулпарың чирләмәгән, аның дүрт тоягына дүрт кадак какканнар, аларны суырып алдым, дәваладым, атың хәзер аякка басты инде.

Шуннан соң ак сакаллы, алтын акыллы бабай таз батырга бер кош кавырсыны биргән.

— Бу сиңа кирәк булыр, — дигән ул. — Аптыраган-йөдәгән чагыңда, теләгеңне әйтеп шушы каурый белән җиргә бер сыйпасаң, үзеңә ни кирәк булса, шул алдыңа килер. Бик яхшы сакла син аны, — дигән.

Ерак җирдән үз иленә кайтканда, таз батыр ашауэчүгә аптырамаган. Ашыйсы килсә, баягы бер дә кимеми торган чүрәкне ашаган, сусаса — бетми торган ширбәтле суны эчкән. (Ярый әле, абыйлары кесәсендәге тересуны гына алганнар, ә куенында сакланган бу нәрсәләрнең бар-

лыгын белмәгәннәр.) Йокларга кирәк икән, тулпарын далага утларга җибәргән дә, кауры белән җирне сыйпаган — йомшак түшәк җәеп, мамык мендәрләр салып ял итәргә урын әзерләгән.

Алтынбай белән Көмешбай, таз батырны үтергәч, бик ашыгып үз йортларына кайтканнар да аталарына шапырына-шапырына:

— Без, бик күп җәфалар күреп, үлгән кешене терелтә торган суны таптык, хәзер әниебезне терелтәбез, — дигәннәр.

— Һай, улларым, сез егет арысланнары икәнсез! Ә Акылбай кайда, әллә аңа берәр хәл булдымы? — дип сораган әтиләре. Уллары:

— Ул өйдән чыгып бераз баргач та, бездән торып калды, аның ябага айгыры безнең атлар артыннан иярә аламы соң? Без аны әлло кайчан кире өйгә кайткандыр дип уйлаган идек, — дигән булганнар.

Әтисе, хәсрәтләнеп:

— Һай, бахыр, бахыр, йөрмә дидем мин аңа, барыбер эш чыгара алмассың, абыйларыңа имгәк кенә булырсың, дидем. Сүземне тыңламады, үз башына үзе җитте, балакаем, — дип көрсенгән.

Уллары алып кайткан тересуны аталары карчыгының авызына койган. Бу суның берничә тамчысы да карчыкны терелтергә җитәр иде. Әмма карт аны-моны уйлап тормаган, беткәнче койган. Тересуны эчеп азмы-күпме торгач, әби күзен ачкан, ә бераздан соң торып та утырган.

— Ай-һай, бик озак йоклаганмын икән, нигә уятмадыгыз, — дигән.

Карчыкка эшнең нидә икәнен сөйләп биргәннәр. Ул, хәйран калып, улларына рәхмәт укыган.

— Эшегез уң булсын, улларым, гомер буе сезгә хәерфатиха укырмын, — дигән. Кече улының гаеп булуына әнисе бик кайгырган. Мине терелтәм дип, үзе харап булган, балакаем, дип елаган.

Алтынбай белән Көмешбайның, әҗәл даруы табып

кайтып, үлгән әниләрен терелтү хәбәре шунда ук бөтен илгә таралып өлгергән. Бу хәбәр патшага да барып житкән. Патша күрше илләргә каршы сугыш ачарга, җирләрен басып алырга әзерләнгән икән. Үткән яуларда күп гаскәре кырылгач, күрше патшаларын җиңә алмаса да, яңадан сугыш башлау уеннан кире кайтмаган икән. Үлгән кешене терелтә торган су табылуын ишеткәч тә, патша: «Әһә, хәзер көч миндә, минем гаскәрем кырыла торыр, кырылган берсен тересу белән терелтә торырмын»,— дип уйлаган. Патша шунда ук Алтынбай белән Көмешбайны үзенә чакырып алган.

— Илемдә сезнең кебек батыр егетләр булуына бик шатмын,— дигән ул.— Терелткеч суны табуы җиңел булмагандыр, әмма сез аны кулыгызга төшермичә туктап калмагансыз. Егетләрнең асылы икәнсез. Шуның өчен мин сезнең икегезгә дә янарал дәрәҗәсе бирәм, сезнең карамагыгызда солдатлар да булыр. Тик сезнең алга шундый бер шарт куям: үлекне терелтә торган суның чишмәсе кайда икәнен беркемгә дә әйтмәскә, әйтсәгез-нитсәгез, башыгызны кисәрмен! Хәзергә өегезгә кайтыгыз, казнамнан акча алыгыз, кәеф-сафа кылыгыз, вакыты җиткәч, үзем чакыртырмын.

Алтынбай белән Көмешбай казнадан күпме кирәк шултиклем акча алып, янарал киемнәрен киенеп, масаешып өйгә кайтып киткәннәр. Кайту белән кәләш алырга булганнар. Иң матур ике кызны сайлап алып, туй көнен билгеләгәннәр. Ат җиткән җиргә ат чаптырып, хат җиткән җиргә хат җибәреп, тирә-яктан кунаклар чакырганнар, курайчылар, җырчылар, биючеләр, чәчәннәр китерткәннәр.

Билгеләнгән көн килеп җиткән. Туй кызын барган чагында гына таз батыр кайтып төшкән. Шулчаклы күп халыкны күреп, монда нинди бәйрәм икән, дип аптырап калган. Аптырап торган арада, йөреп яткан әнисен күреп:

— Әнекәем, терелгәнсең икән,— дип аңа шатланган. Шатлыгыннан нишләргә белмәгән. Әнисе дә:

— Балакаем, бәпечкәем! Сине күрер көнем дә бар икән, — дип елап җибәргән.

Улы:

— Әни, монда нинди бәйрәм? Нигә бу тиклем күп кунаклар җыелды? — дип сораган.

Әнисе:

— Абыйларың, үлене терелтә торган су алып кайтып, миңа җан бирделәр. Абыйларыңның даны бөтен илгә таралды. Патша аларны янарал итте. Алтынбай белән Көмешбай икесе дә кәләш алды, менә шуларның туена кунаклар җыелды. Бик вакытлы кайттың, улым, абыйларыңның шулхәтле дәрәҗәгә ирешүләре, бөтен илгә даннары таралуы безнең барыбыз өчен дә бик зур шатлык бит. Абыйларың шундый абруйлы кешеләр булгач, инде сине дә таз дип мыскылламаслар, — дигән.

Таз батыр, никадәр сабыр кеше булса да, агайларының шулхәтле явыз, ялганчы булуларына түзә алмаган. Бер халыкка, бер җырчыларга карап:

— Туктагыз! Нинди явыз кешеләрне мактаганыгызны беләсезме? — дип кычкырган.

Җыелган халык тәүдә ни булды икән дип аптырашып, катып калган. Таз ары сөйләп алып киткән:

— Үлгән кешене терелтә торган суны мин таптым аны. Яман эш кылганнары өчен, аяк-куллары богауланып, зинданга ташланган абыйларымны мин коткардым. Миңа рәхмәт әйтү урынына атымның тоякларына кадак кагып, мине чиксез далада җәяү калдырмакчы булдылар. Ул гына да түгел, йоклап яткан чагымда мине буып үтереп, кесәмнән тересуны алып, кайтып киткәннәр...

Шунда Алтынбай каушап калуын сиздермәскә тырышып, үзен эре генә тотып, сүз башлаган:

— Хөрмәтле кунаклар! Безнең энебез, үзегез күреп торасыз, акылга чамалырак. Ул элек-электән үк авызына ни туры килсә, шуны сөйләп йөри торган бер бәндә, аның әйткән сүзенә бер дә исегез китмәсен, җырлый, бии бирегез, — дигән.

Шуннан соң абыйсының сүзен Көмешбай ялгап алып киткән:

— Хәйләкәр таз безнең туйның ямен җибәрергә маташа, ул бик көнчел, менә әле дә шул көнләшүеннән безнең йөзгә кара якмакчы була. Әйткән сүзенә кем ышансын соң! Мине ике абыем буып үтерде, ди, ә үзе менә безнең арада утыра, — дигән.

Алтынбай белән Көмешбай шунда ук, бер ялагай чәчәнне яллап, таздан көлеп такмак әйттергәннәр. Үзләре дә такмаклап биергә төшеп киткәннәр:

Безнең идән тап-такыр,
Тазның башы яп-ялтыр.
Тазның бүреге камасыз,
Исәрлеге чамасыз.

Алтынбай белән Көмешбай биюдән туктагач, таз батыр аларга:

— Черкиләр, һәртөрле хәшәрәтләр кешеләрнең канын эчәләр дә качалар. Сез шундый хәшәрәтләрдән дә яманрак. Сез кеше үтереп, халыкны алдап, туй ясыйсыз! — дигән.

Әмма таз кем дә, янараллар кем! Туй ни кыза гына биргән, ә тазны зинданга тотып япканнар.

Теге чәчән исә, Алтынбай белән Көмешбай алдында янә ялагайланып, таздан көлеп такмаклый биргән:

Елга суы татырлы,
Тазның башы кутырлы.
Абыйларын хурлады да
Таз зинданга утырды.

Җиде көн, җиде төн дигәндә Алтынбай белән Көмешбай, таз ачтан үлгәндер инде, дип зинданны барып карасалар, таз батырга берни дә булмаган, сау-сәламәт көе утыра, ди. Бу хәлне күргәч, янә зинданны бикләп куй-

ганнар. Тагы да җиде тәүлек үткән. Таз ачтан үлгәндер инде, дип зинданны кабат ачып карасалар, аңа янә берни дә булмаган, ди. Ай ярым буена ашамый-эчми зинданда утырып та үлмәгәч, таз батырга икенче төрле җәза уйлап чыгарганнар. Зур мәйдан уртасына таш төрбә салдырганнар. Төрбә уртасында кеше сыярлык кына урын калдырып, тазны шунда томалаганнар.

Еллар үткән, таз батырны онытканнар. Тик мәйданнан үткән кешеләр генә кайсычакта аны искә алыр булган.

Бердәнбер вакыт Алтынбай белән Көмешбай гаскәрләрен җыеп, мәйданда зур парад үткәрергә булган. Әмма парад ясау өчен мәйдандагы таш төрбә уңайсызлаган. Шунлыктан, таш каберне сүтеп, мәйданны тигезләргә әмер биргәннәр. Әмер бик тиз җиренә җиткерелгән. Төрбәнең ташларын актарып сүткән чакта гаскәр кешеләре ни күзләре белән күрсеннәр: таз йомшак мендәр өстендә исәнсау көлеп тик утыра, ди. Бу ни хәл, дисәң, таз батыр җиде ел буена куенындагы һич кимемәс чүрәген ашап, беркайчан да бетмәс ширбәтле суын эчеп яшәгән икән. Астына каты булмасын өчен, әлеге серле каурый белән сыйпап, йомшак урын ясаган, ди.

Тазның һаман исән-сау булуын ишеткәч, абыйлары, нишләргә белми аптырап, бөтенләй каушап калганнар. Озак киңәш иткәннән соң, иң ышанычлы ике солдатны чакыртып алып, тазны бик еракка, тау-таш арасына алып барып, дүрт санын дүрт җиргә кумәргә боерык биргәннәр. Әмма солдатлар тазны үтермәгәннәр, бетмәс чүрәге белән бетмәс суын алганнар да, үзен кайда тели, шунда җибәргәннәр.

Берписез калган таз батыр, үлемнән котылгач, байтак вакыт тау-таш арасын кыдырып йөргән, тересу хуҗасы булган сылу янына китәргә дә уйлаган, — аты да, ашарына да булмагач, бу уеннан кире кайткан. Ахырда күрше илгә чыгып киткән. Анда бер патшага елкы көтүчесе булып яллапган. Көтүдәге картаюдан хәлсезләнгән бөтен

атларны яшәрткән: теге тылсымлы каурые белән атның сыртларыннан сыйпадымы, хайванның шунда ук тазарып, көрәеп киткән. Аптырашта калган сарай хезмәтчеләре бу хәлне патшага җиткергәннәр. Патша тазны үзенә мал караучы итеп алган, аның белән сунарга да йөрер булган. Бердәнбер вакыт, сунарда йөргәндә, патша белән таз бик матур бер күл буена барып чыкканнар. Күлдән ике аккош, һавага күтәрелеп, биеккә очып киткән. Патша, тазның мәргәнлеген сынап карамакчы булып:

— Шушы аккошларның берәрсен атып төшерә аласыңмы? — дигән.

Таз патшага:

— Атып төшерә алам, әмма мин аккошка атмас идем, ни өчен дисәң, берсен атсаң, икенчесе ятим калыр, гомер буе ялгызы зарыгып яшәр, — дигән. — Минем мәргәнлегемне бик сыныйсың килә икән, боер: кайсы аккошның кайсы канатыннан нинди каурыен атып төшерим? — дигән.

Бу вакытта инде аккошлар, бик ерагаеп, бәләкәй генә булып күренгән, шунда патша:

— Алдан барганының уң канатындагы урта каурыена ат, — дигән.

Таз батыр, атын да туктатып тормастан, җиз башаклы угын төзәп атып та җибәргән. Бераз вакыт узгач, патша алдына бер каурый килеп төшкән. Патша, тазның мәргәнлегенә исе китеп, нәрсә дип әйтергә дә белми торган. Каурыйны алып кесәсенә салган.

Сунар йөреп кайтып килгәндә, болар өстенә яман бер юлбарыс килеп чыккан. Атлар үрле-кырлы сикерешә башлаганнар. Куркуыннан патша атыннан егылып төшкән. Ул арада булмый, юлбарыс патшага ташланган. Юлбарыс патшаның бугазына ябышты дигәндә генә, таз батыр, җәһәт кенә кынында кылычын суырып алып, бер чабуда ерткычның башын өзеп төшергән. Патша исә иссез булып ята биргән. Шул арада таз батыр, юлбарысның тиресен тунап алып, патшаның җәрәхәтенә япкан.

Патша исенә килгән:

— Егет, син мине үлемнән коткардың, мин моны бервакытта да онытмам, ни теләсәң, шуны эшләрмен, — дигән.

Бу бәладән котылгач, сунарчылар тизрәк өйгә кайтырга ашыкканнар. Әмма боларның башына тагы бер бәла төшкән: патшаның аты бөтенләй хәлсезләнгән, аякларын да сөйрәп атлый алмый башлаган. Шунда таз батыр:

— Патшам, без атларны алмашыйк, арыган атыңны миңа бир, — дигән.

Атлар алмашылган. Таз батыр тылсымлы каурые белән патша атының сыртыннан сыйпаган икән, арыган хайван шунда ук авызлыгын тешләп кайтыр якка чапкан. Патша моңа бик гаҗәпләнгән. «Бу чынлап та бик хикмәтле егет икән ләбаса», — дип таң калган.

Сунардан кайтканның икенче көнендә патша, үзенең бөтен вәзирләрен җыеп, сунарда күргәннәрен, таз батырның искиткеч батырлыгын бәйнә-бәйнә сөйләп биргән. Аккош канатыннан атып төшерелгән каурыйны да, юлбарыс тиресен дә күрсәткән. Азактан:

— Янымда шушы егет булмаса, мине юлбарыс өзгәләп ташлар да, мин бүген бу тәхеттә утырмаган булыр идем. Бүгеннән алып бу егетне баш вәзирем итеп тәгаенлим, үзенә кече кызымны да бирәм, — дигән.

Таз батырны вәзир булу да, патша кызын алу да кызыксындырмаган. Ул тересу сакланган сарайдагы сылуны сагынган, тик аны гына уйлап йөргән.

Сигез ел элек таз батыр тересуны алып сарайдан чыгып киткәннән соң, аннан гөманлы булып калган сылу кыз моны көне-төне зарыгып көтәр булган. Егет киткәннән соң, тугыз ай үткәч, ул бер бик матур кыз бала тапкан. Әнисе аңа Гәүһәр дип исем кушкан. Бала, үсә төшкәч:

— Әни, минем әтием кайда, нигә бер дә өйгә кайтмый? — дип сораша башлаган. Әнисе аңа:

— Ул ерак юлга китте, озакламый кайтыр, — дип

юаткан. Кызына карап, әнисе дә бик пошынган, ул үзе дә тазны бик сагынган, аны көтә-көтә көтек булган. Шуннан соң ул менә шундый хат язарга булган:

«Моннан сигез ел элек минем сараема бер егет килеп, үлгән кешене терелтә торган тересу алып киткән иде. Шушы хатны алгач та, шул егет һичкичекми минем сараема килеп җитсен. Килгән егеткә яхшылыктан башка бернәрсә дә булмаячак. Ул егет минем сараема килүдән баш тарта икән, аның ил-йортына дөнья үрти торган ут яудырачакмын».

Хатны сарайдагы кошларының берсе авызына каптырып җибәргән. Кош еракка очып киткән. Менә ул Алтынбай белән Көмешбай яшәгән сарайның тәрәзәсеннән үтеп кереп, хатны өстәл тирәли утырган кешеләр алдына ташлаган, ә үзе тәрәзә төбендәге гөлгә барып кунган. Хатны тәүдә Алтынбай, аның артыннан Көмешбай укыган. Шуннан хатны кесәгә салып куйганнар. Мәҗлестәге янараллар:

— Хатта ни язылган, нигә бик каушап киттегез, әллә берәр патша безгә каршы сугыш башлыймы? — дип төпченгән.

Алтынбай белән Көмешбай хатны укып күрсәтми булдыра алмаган. Бик озак баш ватканнан соң: «Йә Алтынбайга, йә Көмешбайга хәзер үк юлга чыгарга», — дигән карарга килгәннәр. Шулвакыт Алтынбай:

— Көмешбай туган, син яшьрәк кеше, син бар! — дигән.

— Син олырак та, тәҗрибәлерәк тә, син бар! — дигән Көмешбай. Бүтән янараллар да, Алтынбай барса, яхшырак булыр, дигәннәр.

Нишләсен, Алтынбай, бер дә теләмәсә дә, юлга чыккан, әмма үзе кайда барырга белмәгән. Шулвакыт хат китергән кош, килеп чыгып, Алтынбайның алдыннан гына очып бара башлаган. Алтынбай, тәүдә моңа игътибар итмәсә дә, соңрак аның юл күрсәтеп баручы кош булуын төшенгән. Аның артыннан калмый барган да барган.

Бик озак бара торгач, чакырылган җиренә барып җиткән.

Сарайга килеп кергән. Алтынбайны тәүдә бәләкәч Гәүһәр күргән дә, шатланып:

— Әни, әнекәчем! Әтием кайтты, әтием! — дип кычкырган.

Ишек төбендә, шәм сыман, сынын катыра биреп, басып торган янаралга күз йөгертеп:

— Юк, кызым, бу синең әтиең түгел, — дигән әнисе. Шуннан соң янаралдан:

— Син кем буласың, нинди йомыш белән монда килдең? — дип сораган.

— Мин җибәргән хатың буенча килдем, — дип җавап биргән Алтынбай.

— Туганнарың бармы?

— Бар.

— Ничәү?

— Икәү.

— Ә нигә миннән тересу алып киткән туганың килмәде?

— Ул бик каты авырый, шуның өчен мине җибәрде.

Сарай хуҗасы эчке бүлмәгә кереп бер бәләкәй генә шешәгә салган тересу алып чыккан да:

— Авыру туганыгызга шушы даруны эчерегез, ул шунда ук терелер. Үзе һичкичекмәстән минем яныма килеп җитсен! Ә мин кушканны эшләмәсәгез, бу якты дөнья йөзендә йөрермен дип уйламагыз! — дигән.

Каушап төшкән Алтынбай:

— Барсы да син дигәнчә булыр, — дигән булган. Ә үзе нишләргә белми кайтып киткән. Кайткач: «Нигә миңа баш ватарга әле? Бу бәлане Көмешбай өстенә аударырга кирәк. Тересу сараена аны да җибәреп була бит, ул теләсә кайсылай җавап бирсен әйдә», — дигән уйга килгән. Туганына:

— Көмешбай эне, тересу сараеның хуҗасы сине чакырды, бүген үк юлга чык! — дигән.

Көмешбай, бер дә барасы килмәсә дә, карышсам, кур-

как дип күземне ачырмаслар дип, шул көнне үк юлга чыккан. Серле сарайга барып җиткәч, моны да тәүдә Гәүһәр күргән. Бу юлы да ул, этием кайтты дип, әнисен чакырып чыгарган.

Әнисе:

— Юк, кызым, бу да этиең түгел, — дигән. Шуннан ул Көмешбайга карап:

— Тересуны алып киткән егет нигә үзе килмәде, мин аны чакырган идем бит? — дигән.

— Ул әллә кайчан үлде инде, — дигән Көмешбай искәрмәстән.

Шунда тересу хуҗасы бик каты ачуланып:

— Якты дөньяда яшим дисәгез, монда үлгән туганыгызның сөякләрен җыеп алып китерегез, — дигән.

Көмешбай, башын иеп, тирән уйга чумып, кайтып киткән.

Кайткач та, сарай хуҗасының фәрманы хакында Алтынбайга әйткән. Ике туган тазны, дүрткә тураклап, дүрт кабергә күмәргә боерган солдатларны чакырып:

— Хәзер үк тазның сөякләрен казып алып монда китерегез, — дип әмер биргәннәр. Солдатлар:

— Нинди генә җәза бирсәгез дә, ирегегездә, әмма без тазны үтермәдек, ул исән-сау булырга тиеш, — дигәннәр.

Бу хәбәрне ишеткәч, Алтынбай белән Көмешбай бөтенләй коелып төшкән. Нишләргә белми йөргәннәр. Азак килеп: «Тазны тотып китергән кешегә үзе чаклы алтын бирәбез», — дип бөтен тирә-якка хәбәр салганнар. Эзләүчеләр чыгарып җибәргәннәр. Бу хәбәр таз баш вәзир булып йөргән патшалыкка да барып җиткән. Патша, тазны абыйларына тотып биреп, аның үзе чаклы алтын алырга бик кызыккан. Әмма бушка чыга, ни өчен дисәң, хәбәр килеп җиткән көнне генә таз, патша сараен ташлап, үзенең сөйгән ярын эзләп чыгып киткән икән.

Таз тересу сараена килеп керүгә, бәләкәй Гәүһәр аңа:

— Син дә минем этием түгелме? — дип сораган.

Таз ни әйтергә дә белми торганда, баланың әнисе килеп чыга:

— Монсы тап синең әтиең була, кызым, — дип тазның кочагына ташланган. Бала да: «Әтием!» — дип кычкырып, таз батырның муенына сарылган. Алар шатлыкларыннан берникадәр вакыт эндәшми торганнар. Таз батыр, кәләшен дә, баласын да кысып кочаклап, өнемме бу, төшемме, дип уйлаган. Тынычлангач, хатыны тазны моннан сигез ел элек кавышкан бакчалы зур бүлмәгә алып кергән. Иреннән барсын да сорашкан. Таз батыр үз башыннан кичергәннәрне түкми-чәчми бәйнә-бәйнә сөйләп биргән.

Боларның кавышуына өч көн дигәндә, сарайга Алтынбай белән Көмешбай килеп кергән. Алар, тересу хуҗасы булган сылу хатын алдында баш иеп:

— Тазны үле көе дә, тере көе дә таба алмадык. Бөтен гаеп безнең икебездә. Нинди җәза бирсәң дә, без ризабыз. Без монда гадел җәза алырга килдек, — дигәннәр.

Сарай хуҗасы бу сүзләрне тыңлаган да:

— Ә мин сезне җәзага хөкем итмим, сезгә җәзаны минем ирем бирер, — дип каршы бүлмәдән болар янына тазны чыгарган. Абыйлары гомер буе үзләре җәфалаган энеләрен күреп, куркудан һушсыз булып егылганнар, ди. Аларны искә китерү өчен күлдән тересу ала торган буш шешәне иснәтергә кирәк булган, ди.

Шуннан таз:

— Мин сезне монда хөкем итмим, хөкем үзебезнең илдә булыр, — дигән.

Шулчак сарай ишеге алдына, теге галәмәт зур мөгезле үгез янына, җил арба килеп туктаган. Җил арбаның бер көймәсенә хатыны, баласы белән бергә таз үзе утырып, икенче көймәсенә Алтынбай белән Көмешбайны утыртып, җир өстендә тузан туздыра-туздыра җилеп тә киткәннәр. Таз батыр кайтуга, әтисе инде күптән үлгән булган, әҗәл кагылмас әнисе генә йөреп яткан.

Бөтен халыкны мәйданга җыйганнар. Таз батыр, халык алдына чыгып:

— Мин Акылбай, сезнеңчә әйткәндә, таз булам. Монавы сылу — минем хатыным, тересу патшасының кызы, менә бу бала — безнең кызыбыз Гәүһәр. Ә менә бу ике шакшы — минем абыйларым Алтынбай белән Көмешбай. Хәзер сезгә сүзне яхшылар түгел, әнә шул шакшылар әйтер. Йә, әйтегез, халыкка нинди сүзегез бар, — дигән.

Менә шуннан соң Алтынбай белән Көмешбай таз батырга кылган явызлыкларын, ерткычлыкларын бәйнә-бәйнә сөйләп биргән. Без моны тазның акыллылыгыннан, батырлыгыннан көнләшеп, әтиебез, әниебез алдында, халык каршында яхшы атлы булып күренергә тырышып эшләдек, дигәннәр. Үз гаебебезне үзебез таныйбыз, теләсә нинди җәзага да әзербез, дигәннәр.

Шуннан таз:

— Боларга нинди җәза бирергә? — дигән.

Халык:

— Тезген белән буып үтерергә!

— Терелэй таш төрбә эченә утыртырга!

— Дүрт санын дүрткә өзеп кумәргә!

— Акылбай үзе нинди хөкем чыгарса, шуңа риза булырга! — дип кычкырганнар.

Акылбай шундый хөкем чыгарган:

— Җәмәгать, — дигән ул, — Алтынбай белән Көмешбай, мине берничек тә үтерә алмыйча, үзләренең көчсезлекләрен күрсәттеләр. Ә инде хәзер мин аларны үтерә торган булсам, ул вакытта мин үземнең көчсезлегемне күрсәтер идем. Бу ике явыз бәндә минем өчен куркыныч түгел. Хәзер инде сезнең өчен дә аларның куркынычы юк. Шулай булгач, без аларны үтермик. Әмма бүгеннән башлап икесен дә үзебезнең арадан куыйк, — дигән.

Халык бу хөкемгә риза булган.

Алтынбай белән Көмешбай тәүдә: «Үлемнән котылдык бит», — дип бик куансалар да, бөтен халыктан аерылып икесе генә торып калгач, нәрсә эшләргә белми аптыра-

ганнар. Гаскәрсез торып калган янараллар далага китеп югалганнар.

Шулвакыт мәйдан уртасына җил арба килеп туктаган. Таз батыр үлү белмәс энисе белән хушлашып, халык белән исәнләшеп, бер ягына сылу хатынын, икенче ягына сылу кызын утыртып киткән. Кайда киткәне билгеле түгел. Шунсы гына мәгълүм: таз акылы кайда бик кирәк булса, ул нәкъ шул җиргә җилгән булырга тиеш.

БӘХЕТ КҮЛЕ

Борын заманда булган, ди, бер бабай белән бер әби. Өч уллары булган. Өлкәне — Өлгербай, уртанчысы — Кыңгырбай, кечесе — Елгырбай. Ярлы булсалар да, хәлдә барынча, матур гына, тыныч кына дөнья көткән болар. Беркөнне этиләре:

— Хәзер инде сез егет булып үстегез. Үз көнегезне үзегез күрергә, үз бәхетегезне үзегезгә чамалап карарга вакыт, — дигән.

Шуннан бабайның өч улы, өч атка атланып, бәхет эзләп чыгып китте, ди.

Өлгербай сул якка киткән. Бара торгач, бер ач бүрегә тап була бу. Хәлсезләнгән ач бүре:

— Мин бик озак авырып яттым, үзем дә, балаларым да ач. Ярдәм күрсәтер идең, егет, — дигән.

Өлгербай:

— Синдә минем эшем юк. Үз балаңны үзең туйдыра алмагач, бүре булуың корысын! — дигән дә үз юлына киткән дә барган.

Кыңгырбай уң якка киткән икән, аңа аю тап була.

Аю, ярдәм сорап, авызын гына ачкан икән, Кыңгырбай сәлам дә бирми чабып киткән.

Елгырбай турыга китте, ди. Аңа ач төлке очрый. Елгырбай төлкенең хәлен күреп торганга, ни әйтерен дә көтмәстән, ук-җәяләрен ала да баш өстендә очып йөргән бер бөркеткә төзәп атып җибәрә. Бөркет лап итеп җиргә килеп тә төшә. Елгырбай бөркет янына барса, теге телгә килеп:

— Батыр егет, озын гомер үлә алмый аптырап йөри идем, атып төшереп яхшы иттең. Хәзер инде мин тыныч үләм. Минем бер бөртек каурыемны йолкып ал да күзең карасыдай сакла. Кирәк чакта шуны һавага күтәреп, үзеңә кирәк нәрсәне сора, — дигән.

Елгырбай бөркетне төлкегә биргән дә, бер бөртек каурыен алып, арытабан киткән. Бара да бара икән Елгырбай.

Өлгербай да үз юлын дәвам итә икән. Бара торгач, аңа бер сукыр карт очраган. Өлгербайдан:

— Улым, алда, якында өч юл булыр. Мине урта юлга төшереп җибәрсәңче. Шуннан мин үзем арытабан китәр идем, — дип үтенгән. Өлгербай:

— Бабай, минем юлым бик озын, вакытым юк. Үз җаеңны үзең кара инде, — дигән. Үзе шунда ук, алга җиләргә уйлап, атына сугып алган. Ә аты бер адым алга китә дә, ун адым артка чигенә икән. Өлгербай аптыраган. Ахырда:

— Бабай, бу ни хәл? — дип сорый икән.

Бабай аңа:

— Син, улым, ярдәмгә мохтаҗ түгелсең дә. Әйдә, үз җаеңа юлыңны дәвам итә бир, — дип киткән дә барган, ди.

Бу вакыт Кыңгырбай да, михнәт чигеп йөри торгач, бер кара урманга барып керә. Шунда ул бер әбигә тап була. Әби:

— Улым белән киленем шушы урманга ташлап китте, харап булам бит инде, — дип елый. Кыңгырбай:

— Әби, минем юлым бик озын, вакытым юк, үз җаеңны үзең кара инде, — дигән дә, туктап та тормый, юлын дәвам иттерергә булган. Атына бер суккан икән, ат шунда ун адым җир астына төшә дә чыга, чыга да төшә икән. Аптырап беткән Кыңгырбай:

— Әби, син мине тылсымлы көчең белән рәнҗетмә, мине алга җибәр, — дигән. Егет бик ялынгач, әби үзенең тылсымлы көчен кире алган. Егет, бәхет эзләп, ары киткән.

Елгырбай да шулай үз юлын дәвам итә икән. Юлда матур уйлар уйлап кына барганда, кара урманда бер тавыш ишетә. Шул тавышка карый бара. Барса, бер тирәк төбендә бер ир бала утыра, бала тирәли унике башлы дию әйләнә, ди. Елгырбай, барлык көчен җыеп, булат кылычын селти-селти дию белән алыша башлый. Дию ут чәчеп җибәрә — Елгырбайга авыр булып китә. Көче кимегәннән-кими бара моның. Шушы вакытта теге бөркетнең кауырые исенә төшә. Куеныннан кауырыйны ала, югары карап: «Миңа көч бирсәңче!» — дип кычкыра. Шул мәлдә үк көче артканын тоя. Озакламый галәмәт көчле булып китә. Шуннан ул, диюнең унике башын тураклап өя дә, баланы коткарып, үзе белән алып китә.

Шулай итеп, өч туган арып-талып, михнәт күреп бәхет эзлиләр. Юлда алар, төрле хәлләргә очрап, авырлыклар кичереп, һаман алга баралар, ди.

Менә Өлгербай бер өйгә тап була. Өйдә бер әби утыра. Үзе хәлсез, какча, ашарына да юк, ди. Өлгербай:

— Әби, мин бәхет эзләп йөрим, ачыкканмын, ашатыр-эчерер идең, — дигән. Үзе йокыга да киткән. Йоклаганда ул бер төш күргән. Имеш, энесе Елгырбай бик бәхетле, кешегә ярдәмчел, шәфкатьле. Шуңа аны яраталар. Уянса, өстәлгә барынча азык-төлек куелган, хәтта юлга да төенчек әзерләнгән. Өлгербай ашый-эчә дә, әбигә рәхмәт әйтеп тә тормый, үз юлына китә.

Кыңгырбай да шулай кара урманда бер өй очрата. Анда да ачлы-туклы бер әби яши икән. Кыңгырбай да

шунда, абыйсы шикелле хәл җыеп, төш күреп, тамагын туйдырып юлын дәвам итә.

Елгырбай, теге бала белән бара торгач, шулай ук бер йортка тап була. Керсә, тешләре төшеп беткән, үзе бәлтерәп төшкән бер какча әби утыра. Кергәч, Елгырбай саулык сораша да:

— Әби, менә шушы балага тамак ялгар бирәр нәрсәң булмасмы? — ди.

Әби:

— Юк шул, балам, үзем дә ач утырам. Ике-өч көн элек Өлгербай белән Кыңгырбай атлы ике юлаучы булган азыгымны ашап бетереп киттеләр, — ди.

Шуннан Елгырбай, исенә төшеп, тышка чыккан да, күккә карап: «Азык-төлек булса иде!» — дип кычкырган. Шулай дип әйтүе булган, әбинең өе эчендә ни теләсәң, шул алга килгән.

Әби, рәхмәтләр әйтеп, ашатып-эчереп, егеткә төрле-төрле юллык азык биреп, озатып калды, ди. Шуннан Елгырбай теге баланы әти-әнисенә илтеп бирде, ди. Бердәнбер балалары икән. Шатлыкларының иге-чиге булмады, Елгырбайга нинди генә бүләк бирсәләр дә аз булыр төсле булды, ди. Шуннан баланың этисе:

— Менә безнең янда гына көмеш сулы бер күл җәйрәп ятар. Зәмзәм сулы бәхет күле ул. Аны уникe башлы дию, кешегә бер тамчы суын да бирми, өч йөз дә туксан тугыз ел буе саклаган. Урманга җиләккә барган балалар арасыннан минем улымны әнә шул дию урлаган. Ә син, батыр егет, шул диюнең башына җиткәнсең. Менә сиңа бер шешә. Бәхетле булыйм дисәң, менә шуңа тутырып шул күлдән бәхет суы ал. Безне шатландырган өчен мин сиңа шуннан да зур бүләк бирә алмыйм, — дигән.

Елгырбай шешәне алган да шул күлгә киткән.

Әй китте, әй китте, энә буе җир китте, ди. Бара торгач, җәйрәп яткан бәхет күленә барып җитте, ди, бу. Атыннан төшүгә Елгырбайның ике абыйсы да килеп тук-

тады, ди. Өч туган очраша. Баштан үткәннәр турында сөйләшәләр.

Өлкән абыйсы Өлгербай:

— Мин ул бәхет дигән нәрсәне очрата алмадым, гел генә бәхетсезлек: ач бүреме, ачлы-туклы адәм баласымы — очрап кына торды, — ди.

Уртанчы абыйсы Кыңгырбай:

— Дөнья фәкыйрьләр, теләнчеләр белән тулы икән. Күпме йөрдем, бәхет дигәнне күрмәдем, — ди.

Иң азактан Елгырбай:

— Кешеләргә шәфкать кулы сузмагансыз, йончып йөргән җанварларга ярдәм итмәгәнсез. Бәхет очрап торган, сез аннан качкансыз. Мин, абыйлар, үз бәхетемә ирештем. Менә бу күл — бәхет күле ул. Кем дә кем аның суын эчә, шул бәхетле була икән. Мин шул күлдән бер шешә бәхет суы алам да әтием белән әнием янына кайтам, — ди.

Өлгербай белән Кыңгырбай бәхет күлен күреп, исе-акыллары китә. Шуннан алар:

— Бәхет суының үзенә килеп, бер шешә тутырып кына каламмы соң! Тәүдә, уртасына кереп, туйганчы эчәм, шуннан чума-чума йөзәм. Азактан инде бәхет суын бер турсык тутырып алып кайтам, — дип, күлгә сикереп төшәләр. Күбенгәнче суын эчәләр, хәлдән тайганчы йөзәләр, тирәнрәк җирен сайлап, чумып-чумып алалар. Тагын бер чумып алыйк, дип чумалар да, хәлләре бетеп, һушсызланганлыктан, кабат калкып чыкмыйлар. Шунда батып үләләр.

Көтеп, көтеп тә абыйлары чыкмагач, Елгырбай нишләсен, бер шешә тутырып бәхет суын ала да, үзен генә түгел, әти-әнисен бәхетле итәргә ашыгып, туган җиренә кайтып китә.

АЛТЫНЧӘЧ

Борын заманда, моннан бик күп еллар элек, кара урман уртасында яшәгән, ди, бер сунарчы. Аның Үтәгол исемле улы була. Малай ике яшькә җиткәч, әнисе үлеп китә. Үтәгол әтисе тәрбиясендә торып кала. Алар бергәләп, кәкре-бөкре төтен чыгарып, тагы да унбиш ел яшәгәннәр. Үтәгол егет булып җитә. Ул кече яшьтән алып, әтисе белән сунарга йөреп, оста сунарчы булып үсә.

Бервакыт Үтәгол белән әтисе сунарга китәләр. Кинәт агач арасыннан бик зур аю килеп чыга да карт сунарчының өстенә ташлана. Егет абайларга өлгерми, аның өстенә икенче аю менеп килә. Үтәгол үзенә ташланган аюны үтергәнче, теге аю әтисен бик нык җәрәхәтләп өлгерә. Әтисе, шул җәрәхәттән терелә алмый, үлеп китә. Үтәгол тере ятим булып торып кала. Бу хәсрәтле урынны ташлап, ул күрше авылга эш эзләп китә. Үтәгол бик яман бер байга ялчылыкка керә. Ул аның йомышларын үти-үти арып бетә.

Бервакыт бай бер сихерчедән, имеш, алтын балык итен ашасаң, барлык җан ияләренең дә тавышын аңларга мөмкин дигән хәбәр ишетә. Бай Үтәголга елгага барып, алтын балык тотып кайтырга куша:

— Алып кайтмасаң, башыңны чабып өзәрмен, — ди. Бик озак эзләгәннән соң, Үтәголның авына алтын балык эләгә. Алып кайтып баена күрсәтә, бай бик шатлана, шунда ук пешерергә куша:

— Тик кара аны, бер кабым да ашап карама, югыйсә үтерермен, — ди бай.

Үтәгол балыкны пешерә дә, йә тозы чыкмас, йә артык булыр дип, балыкның койрыгын гына кисеп алып, тәмләп карый. Ашап караса, балык бик тәмле була. Шултиклем тәмле була, ул үзен-үзе тота алмый, ашый башлый. Шулвакыт аның янына безелдәп бер чебен очып килә дә:

— Миңа да ашат инде, мин бик еракта килдәм, сине ерактан күрәм, — ди. Егет чебенне дә туйдырып җибәрә.

Чебен рәхмәтләр укып, кирәк вакытта ярдәм итәргә вәгъдә биреп, безелдәп очып китә.

Балыкны ашап бетә дә Үтәгол, гади балык пешереп, байга ашата. Ашаганнан соң бай, төрле кош-кортның тавышын тыңлап ләззәтләнергә уйлап, ат җиктереп, урманга чыга. Ләкин кошларның берсенең дә тавышын аңламый. Үтәголдан үч алырга була. Тиздән байның катыны үлеп китә. Бай кайдандыр моннан ерак торган бер патшаның Алтынчәч исемле бик матур, зифа буйлы кызы барлыгын ишетә.

— Теләсә ничек, теләсә нинди юллар белән булса да Алтынчәчне китер, — ди бай Үтәголга. Егет янып-көеп юлга чыгып китә. Юлда барганда ул бер агач төбендә кырмыска оясының януын күрә. Бичара кырмыскалар, кайда барырга белми, як-якка чабалар. Үтәгол, аларны кызганып, янгынны сүндерә. Кырмыскалар рәхмәт әйтеп, кирәк вакытта ярдәм итәргә вәгъдә биреп, торып калалар.

Егет китә. Бара торгач, бер агач төбендә ояларыннан очып төшкән ике саескан баласын күрә. Алар чыелдашып ярдәм сорыйлар. Үтәгол аларны ояларына кире сала. Алар да рәхмәт әйтеп, кирәк вакытта ярдәм итәргә вәгъдә биреп, торып калалар.

Үтәгол тагы китә. Бара торгач, ул бер елга буенда ике балыкчының канга батып сугышып ятуларын күрә. Алар янына килеп, сугышуларының сәбәбен белә: баксаң, алар алтын балык өчен сугышалар икән. Үтәгол алтын балык өчен бик күп акча биреп сатып ала да балыкны суга җибәрә. Балык рәхмәт әйтеп, кирәк вакытта ярдәм итәргә вәгъдә биреп, йөзеп китә.

Бик күп михнәтләр күреп, Үтәгол теге патшага килеп җитә. Патша моның сүзен тыңлаганнан соң, егет алдына өч бурыч куя:

— Шуларны үти алсаң, кызны алып кайтасың. Беренче шарт шул: Алтынчәч иптәшләре белән күңел ачып йөргәндә, бавы өзелеп, муеныннан бик кыйммәтле мәрҗән-

нәрдән торган муенсасы төшеп югалды. Алар шултиклем вак, эзләп-эзләп таба алмадык. Син шуларны тап, — ди.

Үтәгол, бик кайгырып, юлга әзерләнә. Бернинди дә чара таба алмыйча йөргәндә, аңа теге кырмыскалар ярдәмгә килә. Алар үлән төбеннән бөтен мәрҗәннәрне табып бирәләр. Егет, мәрҗәннәрне алып кайтып, патшага тапшыра. Патша бик гаҗәпләнә дә икенче шарт куя:

— Икенче шарт шул: иптәшләре белән елгада көймәдә йөргәндә Алтынчәч балдагын суга төшереп җибәрде. Без эзләп-эзләп таба алмадык. Син шуны тап, — ди.

Үтәгол елга янына барып, бик кайгырып утырганда, әлеге алтын балык ярдәм итә. Ул алтын балдакны табып алып китереп бирә. Патша моңа да бик гаҗәпләнә. Өченче шартын куя:

— Өченче шарт, — ди, — җан үтерә, җан терелтә торган шифалы су табып китер.

Үтәгол бик нык кайгыра. Аптырап, ничек үтим инде, дип чыгып китә. Шулай уйланып, кара урман эченә барып керә. Агач төбендә уйланып утырганда, әлеге саескан балалары ярдәм итәләр. Алар җиде су, җиде тау-урман аша үтеп, Үтәголга теге шифалы суларны китереп бирәләр. Ләкин патша бу суларга ышанмый, сынап карарга була. Шунда ук бер карт хезмәтчесен китертә дә үтерә торган суны сибә. Суны сибү белән, хезмәтче үлә, терелтә торганын сибү белән, хезмәтче терелә.

Хәзер инде патша Үтәгол алдына иң соңгы сынау куя:

— Менә синең алдыңда унике бертөсле, бертөрле киемле кызлар. Алар арасыннан Алтынчәчне тап, — ди. Үтәгол тагы да аптырап кала. Шулчак аның колагына теге чебен килеп куна да:

— Мин ярдәм итәрмен, — дип безелди. Чебен тиз генә очып китеп, бөтеп кызларның яулык астына кереп, Алтынчәчне таба да Үтәголның колагына килеп куна.

— Әйдә, киттек, мин сиңа барып җитү белән «өстәлгә сук» дип әйтермен, — ди.

Үтәгол чебен ярдәмендә Алтынчәчне таба да, патша белән хушлашып, кызны алып кайтып китә. Бик күп җәфалар күреп, бик күп газаплар чигеп, кызны байга алып кайта. Бай, аның юлда озак йөргәнлегенә ачуланып, башын кистереп сарайга ташлый.

Алтынчәч юлда Үтәголны яратып өлгергән була. Ул байдан Үтәгол белән саубуллашырга рөхсәт сорый. Бай теләр-теләмәс кенә риза була.

Алтынчәч сарайга керә дә теге терелтә торган суны сибеп җибәрә. Үтәгол элеккедән дә матур, таза егет булып килеп тора. Алар култыклашып сарайдан килеп чыккач, байның исе китә. Аның да шулай үлеп, яңадан терелеп, тагы да яшәрәсе килә. Ул үзенең башын чабып өзәргә боера. Байның башын чабып өзәләр. Өзүен өзәләр дә, соңыннан терелтмиләр. Байны алып барып күмәләр. Үтәгол аның урынына бай булып ала. Алтынчәч белән икәүләп дөнья көтә башлыйлар.

Шуның белән әкиятемне бетереп, убырлы карчыкка бер калак тоз белән икмәк алып барып бирдем. (Шулай дип бетереп куялар безнең якта әкиятне.)

КИНҖӘБУЛАТ

Борын-борын заманда, урман-тау арасында, бер бәләкәй генә яланда яшәгән, ди, бер бабай белән әби. Алар күп еллар тигез, матур гына гомер иткән, ди. Картая төшкәч, дөнья көтәргә авырлашкач, бабай да, әби дә авырый башлаган. Озак та тормый, бер-бер артлы үлеп тә киткәннәр.

Аларның булган, ди, өч улы. Олы улы белән уртанчысын бабай белән әби исән чакта ук башлы-күзле итеп калдырганнар, ә өченче уллары Кинҗәбулатны өйләндерергә өлгерә алмый калганнар. Ата-бабадан калган гореф-гадәт буенча, алар олы улына өйләрен калдырганнар, уртанчысына үлмәс борын ук үзләренең мунчаларын юнәтеп биргәннәр, ә калган мал-туар, каралтыларын өч улы арасында бүлеп калдырганнар, ди.

Торыр җире булмагач, Кинҗәбулат ике арада йөрергә мәҗбүр булган. Кинҗәбулатны җиңгәләре бер дә яратмаган, көн күрсәтмәгән, абыйларына яман күрсәтергә тырышканнар. Алар өйдә юк вакытларда өйдән куып чыгара торган булганнар. Көн дә яланда ач-ялангач йөргәнлектән, Кинҗәбулат ябыккан, кайдандыр таз да йоктырган, ди. Абыйлары этисеннән калган җиргә ел да тары белән борчак чәчә торган булганнар. Бу урынның ике ягында өсте чикләвекле вак имән агачлары белән капланган тау, бер очында шомырт, тал агачлары белән капланган зур гына бер чокыр булган. Бу матур табигать күренеше сандугачлар, кәккүкләр сайравы белән тагы да матурлана төшә икән. Җиңгәләре куып чыгарган вакытта Кинҗәбулат чокырга килеп, сандугачларның моңлыларының моңын баса, моңсызларның күзен ача торган сайрашуларын тыңлап, күңелен юата, соңыннан җырлыйҗырлый, чәчүлекләрдәге чүпләрне чүпли торган булган, ди.

Көннәрнең берсендә Кинҗәбулатның абыйлары, чәчүлекне тазартырга вакыт дип, сүз кузгаталар. Мич башында борчак ашап утырган Кинҗәбулат, бу сүзне ишетеп:

— Анда барып йөрмәгез. Мин аны тазарттым инде,— ди икән. Абыйлары аңа ышансалар да, иртәгәсен барып карап кайтырга булалар. Иртән торып, ат җигә башлыйлар. Кинҗәбулатны яман күрсәтү өчен, җиңгәләре ирләрен чәчүлеккә җибәрмәскә хәйлә коралар:

— Чәчүлеккә без барып кайтырбыз, ә сез утынга барып кайтыр идегез,— диләр.

Тегене-моны уйлап тормыйча, ирләре риза булалар, утынга китәләр, ә бичәләр, шатланышып, чәчүлеккә китәләр. Килгәч, ни күзләре белән күрсеннәр, чәчүлектә бер генә чүп тә юк, ә иген дулкынланып үсеп утыра, ди. Кич барсы да өйгә кайткач, җиңгәләре:

— Кинҗәбулат дип әйтәсез, аңа бушка күмәч ашатасыз, ул бит безне алдаган. Менә сез дә безнең белән барсагыз икән, чәчүлекне шултиклем чүп баскан, урынын да таба алмас идегез. Ышанмасагыз, безнең өйгән чүпләрне барып карагыз, — диләр икән. Ачулары килгән абыйлары, Кинҗәбулатны мич башыннан сөйрәп төшереп, тукмап чыгарганнар. Шулай да олы абыйсының башына:

— Бичәләр сүзенә карап, аны юкка рәнҗетмәдекме икән? — дигән уй килә.

Алар чәчүлекне карап кайтырга булалар. Моны сизеп калган Кинҗәбулат җиңгәләреннән үч алырга була. Абыйлары килгәнче, чәчүлектә таралып яткан бөтен чүпләрне җыеп, читкә чыгарып сала. Абыйлары чәчүлеккә килсә, ни күзләре белән күрсеннәр, өеп куелган чүп әсәре юк, иген таза, күкрәп үсеп утыра икән. Ачуланган агайлар, өйгә кайтып, бичәләрен чыбыркы белән генә сыдыралар икән. Ирләре бераз басылгач, бичәләр:

— Күзегез чыккан икән, өем-өем чүпне дә күрмичә. Күрмәсәгез, үзебез күрсәтербез, иртәгә чәчүлеккә барабыз, — дип әйттеләр, ди. Кинҗәбулат бу сүзләрне тыштан тәрәзә аша ишетеп кала да абзыйларыннан үч алыр өчен, читкә чыгарып салган чүпләрне чәчүлеккә тарата, ди. Иртәгәсен абыйлары белән җиңгәләре чәчүлеккә китәргә җыенганда, Кинҗәбулат:

— Мине дә алып барыгыз әле. Талашканыгызны карап торырмын, — дип әйтә, ди. Абыйлары аңа ачуланалар да үзләре генә чәчүлеккә китәләр. Килсәләр, чынлап та, анда да, монда да чүпләр өелеп ята. Агайлар аптырап калалар. Бичәләр ирләрен тетеп кенә салдылар, ди. Өйгә кайткач, ачуы килгән агалары Кинҗәбулаттан:

— Син безнең талашасыбызны кайдан белдең? — дип сорыйлар икән. Ул:

— Мин кичә төшемдә күргән идем, — дигәч, абыйлары:

— Син таз гына түгел, исәр дә икәнсең, — дигәннәр.

Шул көннән башлап, бөтен тирә-як Кинҗәбулатны «Исәр таз» дип атый башлаган. Кинҗәбулат берсе белән сөйләшергә дә базнат итми башлый.

Кинҗәбулат егет булып үсеп җитә, үзенә бичәлеккә бер кыз да күзләп куя. Ләкин кызы, мин исәр тазга бармыйм дип, баш тарта. Кинҗәбулат нишләргә белмичә, күңелсезләнеп, кайгырып йөри, ахырда әтисенең кабере өстенә барып ята да үксеп-үксеп елый. Моны күргән кешеләр Кинҗәбулатны, чынлап та, исәргә исәпли башлыйлар.

— Исәр булмаса, кабердә төннәр буе утырыр идемени? — диләр.

Кинҗәбулат кабер өстендә көн дә болай дип елый икән: «Әти, нигә мин өйләнмәс борын үлеп киттең? Хәзер мин гомер буе өйләнә алмам инде. Мин бит синең иң яраткан, иң акыллы, эшчән, матур улың идем. Минем хәзер барыр җирем дә юк. Мин таз да булдым, җиңгәләр аркасында абыйлар да, бөтен кеше дә миннән бизеп беттеләр», — дип, акырып-акырып елый икән.

Көннәрнең бер көнендә Кинҗәбулат кабер өстендә йоклап киткән дә төш күргән, ди. Төшендә әтисе белән сөйләшеп, әтисе икенче көн төнен үзенең янына олы улын чакырырга кушкан, ди. Уянып, Кинҗәбулат шатлыгыннан бу турыда олы абыйсына әйтергә йөгергән, ди. Кайтып керү белән олы абыйсына:

— Сине бүген төнгә әтием үзенең каберенә чакырды, — дигән. Абыйсы:

— Әй исәр, исәр таз. Исәр булмасаң, шул сүзне әйтмәс идең. Үле кеше синең белән ничек сөйләшсен, ярый, алай булса, исәр икәнсең, минем өчен үзең бар инде. Шуның өчен мин сиңа шушы иске күлмәгемне бирермен, —

дигән. Кинҗәбулат абыйсының сүзен тотып, икенче көн әтисенең каберенә барып утырган, ди. Бервакыт кабердән:

— Кем бар анда? Олы улым, синме? — дигән тавыш ишетелде, ди.

— Түгел, кече улың, — дигән Кинҗәбулат. Шуннан соң әтисе Кинҗәбулат янына чыгып утырган да бераз сөйләшкәннән соң:

— Менә, улым, минем әйткәнне дә тыңладың, абыең әйткәнне дә кире какмадың, шуның өчен сиңа шушы кара кылны бирәм. Бу кылны кирәк чакта, яланга чыгып бармагыңа ура, бер сызгыр да очыннан тарт. Шунда синең өстеңә менәрдәй булып кара ат килер. Курыкма. Үзең киенгән, коралланган көе ат өстендә булырсың. Синнән дә матур, синнән дә көчле кеше булмас. Әгәр аттан төшим дисәң, уң колагына сук, атны җибәреп, өйгә кайтыйм дисәң, сул колагына сук. Бу кылны беркемгә дә күрсәтмә, минем белән сөйләшү турында беркемгә дә әйтмә. Иртәгә төнен икенче абыең килсен, — дигән дә юк булган, ди.

Кинҗәбулат, кайткач, әтисенең кече абыйсын чакыруын әйткән. Бу абыйсы да:

— Син бит исәр, исәр булгач, бул инде. Минем чиратка да барып кайт. Тазыңны каплар өчен такыя бирермен, — дигән.

Кинҗәбулат риза булмый нишләсен, әтисенең каберенә тагы барып утырган. Тиздән:

— Кем бар анда? Уртанчы улым, синме? — дигән тавыш ишетелгән. Кинҗәбулат:

— Юк, кече улың, — дип җавап биргән, ди.

— Шулай инде, чынлап та саф күңелле, таза фикерле, тыңлаучан улым син икәнсең, — дип, Кинҗәбулат белән бераз сөйләшкәч, әтисе аңа җирән кыл биргән дә: — Бу кыл белән дә шулай ук эшләрсең. Иртәгә үзең кил, — дип, Кинҗәбулатны кайтарып җибәргән, ди.

Кайтуга, абыйлары Кинҗәбулаттан көләләр икән. Өчен-

че көн Кинҗәбулат төнне түземсезлек белән көтеп ала. Төн булгач, этисенең кабере янына бара.

— Кем бар анда? Кече улым, синме? — дигән тавышка:

— Әйе, мин, эти, кече улың, — дип җавап биргән. Этисе Кинҗәбулатка шуны сөйләгән:

— Озак та үтмәс, фәлән-фәлән патшалыкта туй булыр. Бу туй өч ярыштан, өч сыйдан соң гына үтәлер. Шушы туйга бөтен патшалыклар, бөтен халык әзерләнер. Туй патшаның кече кызына була. Ул кызның сөйгән егете юк. Кем дә кем патша сараеның икенче катыннан тыгып утырган кулның бармагыннан кызның балдагын ала, шул кеше аның кияве була. Баймы, ярлымы, сукырмы, тазмы — ул кеше батыр кеше булыр, патша кызына тиң булыр. Шушы туйда җиңгән кеше, һичшиксез, патша булырга тиеш, ярлыларга ярдәм итәргә тиеш, бөтен халык, ир-хатын бер хокукта булырга тиеш. Менә сиңа ак кыл. Аның белән дә тегеләре кебек эшләрсең. Бу ат тегеләрдән дә җитезрәк, көчлерәк, күркәмрәк, — дигән дә юк булган, ди.

Кинҗәбулат өйгә кайткан да мич башында борчак ашый башлаган.

Бердәнбер көн абыйларының сөйләшеп утыруыннан Кинҗәбулат патшаның кече кызына туй буласын ишетеп кала. Туйга абыйлары да барырга уйлыйлар икән. Әземе-күпме вакыт үткәннән соң туйга җыю турында патшаның игъланы була. Агайлар туйга барырга җыеналар, ди. Кинҗәбулат та абыйларына:

— Мине дә бергә алыгыз. Патша кызы, бәлки, мине яратыр. Патша кияве булып алсам, үзегезне вәзир итеп алырмын, — дигән була, ди. Абыйлары аннан бот чабып көлгәннәр.

Бердәнбер көн агайлар юлга чыга, җиңгәләр өйдә кала. Кинҗәбулат җиңгәләреннән бер-ике көнгә чыгып йөрергә сорый, ди. Аулак калганга шатланып, җиңгәләр риза булалар. Кинҗәбулат өйдән чыгып китә. Яланга

чыккач, түштәге капламаның кесәсеннән кара кылны ала да бармагына урый. Бер сызгырып, кылның очыннан тартып җибәрүе була, өстенә ыргыйм дип, ат килә. Ул матур итеп киенгән, кылыч таккан, бөдрә чәчле егет булып, ат өстендә утыра. Өч көн буе барган абыйларын шунда ук, сазлыкта бата-бата барганда, куып җитә дә уңлысуллы икесен дә өчәр тапкыр камчы белән тарттырганнан соң күздән югала.

Кинҗәбулат патша сараена килгәндә, сарай тирәсендә ярышуны көтеп йөргән халыкның иге-чиге юк икән, ди. Кинҗәбулат сарайга якын килми, бер як читтәрәк ат уйнатып йөри. Берданбер вакыт патшаның игъланы буенча ярыш башланган икән, беркем дә кызның балдагына якын да килә алмый, ди. Озакламый ярышлар бетә. Кыз үзенә кияү чыкмаганга күңелсез генә тирә-якка каранып утырганда, яланда кара ат уйнатып йөргән егетне күреп, яулык болгап чакырырга куша. Шуны гына көтеп йөргән Кинҗәбулат, чабып килеп атын сикертсә, чак-чак кына балдакка җитми калган. Шул көйгә чабып чыгып та киткән, ди. Бер кешегә ике сикертергә ярамаса да, патша кызы тагы да сикертергә итим дисә, егет күздән дә югала.

Абыйлары кайткач, Кинҗәбулат белмәмешкә салышып:

— Йә, патша кызын күрдегезме? Әллә үзегезне юлда камчы белән сүттеләрме? — дип сораган була. Абыйлары бер-берсенә карашалар да Кинҗәбулатка бик нык ачуланалар.

Икенче көнне абыйлары тагы шунда китә. Кинҗәбулат бу юлы да, җиңгәләреннән рөхсәт сорап, чыгып китә дә, ялангa чыккач, җирән кылны алып бармагына урый. Бер сызгырып, очыннан тартып, өстенә ыргыйм дигән атка орып җибәрүе була, искиткеч егет булып, ат өстендә утыра. Өч көн алдан киткән абыйларын куып җитеп, кылыч белән урманлыкны абыйларының юлына аударып, алга чаба. Абыйлары, юл таба алмыйча, интегеп, арыпталып ярыш бетәр алдыннан гына килеп җитәләр, ди.

Бөтен ир-егет, ат сикертеп, балдакны ала алмагач, кыз, яланда җирән ат уйнатып йөргән егетне күреп, аны яулык болгап чакырырга куша. Шуны гына көткән Кинҗәбулат җирән аты белән чабып килеп сикерсә, кулы балдакка тиеп кала, әмма суырып алырга өлгерми. Шул уңайдан чабып чыгып та китә. Кыз егетне яңадан чакыртам дисә, ул күздән дә югала.

Өйгә кайтып, Кинҗәбулат тагы да мич башында борчак ашарга керешә. Абыйлары кайткач, Кинҗәбулат берни дә юк кебек:

— Патша кызын бирәме соң, әллә барып җитә алмыйча, урманда адаштыгызмы? — дигән була. Ансыз да ачулы агалар Кинҗәбулатны чак-чак тукмамый калалар, ди.

Озак та үтми, патша халыкны туйга өченче тапкыр чакыра. Кинҗәбулатның абыйлары, өметләрен өзеп, бу юлы бармаска булалар, ә Кинҗәбулат хәйлә белән өйдән чыгып китә. Яланга чыккач, ак кылны алып бармагына урый да бер сызгырып, очыннан тартып җибәрә. Җил-давыл чыгарып, чабып килгән ак ат өстенә ыргыйм дигәндә, Кинҗәбулат югалып калмый, төштә дә күрмәслек егет булып ат өстендә утыра.

Ярыш барганын Кинҗәбулат читтән генә карап, ат уйнатып йөри. Беркем дә балдакны ала алмагач, патша кызы торып китим генә дигәндә, бер як читтәрәк ат уйнатып йөргән Кинҗәбулатны күреп кала, яулык болгап чакырырга куша. Шуны гына көткән Кинҗәбулат, ак атын иркенә куеп, җил-давыл чыгарып чабып китә. Атның җиленнән мәйдандагы бөтен халык аяктан егыла, күзләрен йомалар. Кыз турына җиткәч, атын сикертә, ат икенче катка җитеп, кыз алдында туктап тора, ә Кинҗәбулат шушы вакытта җайлап балдакны салдыра да, кызны суырып үбеп, чабып чыгып та китә. Кыз исенә дә килергә өлгерми, Кинҗәбулат күздән югала.

Кинҗәбулат, атын җибәреп, өйгә кайта да мич башында борчак ашарга керешә. Хәзер патша балдакны та-

бар өчен бөтен дөньядагы ир-егетне сыйга чакырырга, сый вакытында балдакны табарга уйлый, фәләнчә вакытка ир затыннан булган барча кешегә җыелырга куша. Патша боерыгы буенча, күрсәтелгән вакытка бөтен ир заты сыйга бара. Кинҗәбулатның абыйлары да китә, ә Кинҗәбулат балдаклы бармагын калын чүпрәккә урап мич башында борчак ашап ятып кала. Сыйда балдак табылмагач, патша икенче тапкыр, беркемне дә калдырмыйча, сыйга алып килергә куша. Икенче тапкыр сыйга иксез-чиксез ир заты җыела, сукыры да, чатаны да, чулагы да, тазы да калмаган, ди. Бу юлы да Кинҗәбулатны абыйлары үзләре белән алмый. Сыйда балдак табылмагач, патша өченче тапкыр җәзалау куркынычы белән ир затын чакырырга боера. Аптырагач, абыйлары бу юлы Кинҗәбулатны да алып барырга булганнар. Аны яхшылап юындырып, киендереп алып барабыз дисәләр, Кинҗәбулат:

— Мин бармыйм, мин тазны, исәрне, алар ни эшләтсеннәр, — дигән була икән. Патшаның җәзасыннан куркып, абыйлары Кинҗәбулатны, ай-ваена карамый, сыйга алып киткәннәр. Сыйга бөтен ир заты җыелган, сый башланган, ди. Җамаякны һәркем ике куллап алырга тиеш булган. Бервакыт чират Кинҗәбулат белән агаларына җиткән. Агалары җамаякны ике куллап алалар, ә Кинҗәбулат бер кулын гына суза икән. Патша кызы аңа ике куллап алырга боера, Кинҗәбулат ике кул белән алырга мәҗбүр була. Чүпрәк белән бәйләнгән кулны күреп, патша кызы чүпрәген чишәргә боера. Кинҗәбулат тарткалашкан була. Кыз, үзе килеп, Кинҗәбулатның кулыннан чүпрәкне чишә. Чишсәләр, ни күзләре белән күрсеннәр, бармагында кызның балдагы кире салдырмаслык булып кереп утырган, ди.

Кыз, өлешемә тигән көмешем дип, Кинҗәбулатны патша сараенача җитәкләп алып киткән. Кинҗәбулатны күреп, патша кызына ачуланса да, кызының вәгъдәсен бозарга кыюлык итми, өстән-өстән генә булса да туен ут-

кәрә. Туйдан соң, кызы белән Кинҗәбулатны сараеннан куып чыгарып, үзенең кара мунчасына урынлаштыра.

Бердәнбер вакыт патшага каршы яу килә икән. Патша үзенең олы кияүләрен сугышка әзерли, гаскәр җыя да сугышка озата. Кинҗәбулатның үзен чакырырга гарьләнеп, кызы аркылы аңа да сугышка барырга куша. Иртәгәсен Кинҗәбулат, хатыны белән хушлашып, корчаңгы атка атлана да китә. Яланга чыккач, корчаңгы атын үтерә дә, түшендәге капламадан кара кылны алып, кара атын чакыра, аны менеп, сугыш мәйданына китә. Сугышта патша кияүләренең җиңелүен күреп, Кинҗәбулат:

— Әгәр һәрберегез чәнтеки бармагыгыздан берәр буын кисеп бирсәгез, дошман явын хәзер үк тураклап бетәм, — ди.

Кияүләрдән бармак алып, Кинҗәбулат дошманны кырырга тотына. Ул бер селтәгәндә, унарлаганы егыла, ди. Бик азлары гына качып котыла, ди. Кинҗәбулат үтереп ташлап киткән аты янына килә дә карга-саесканнарны атып ята. Патша кияүләре, кайтып килешли моңа тап булып:

— Йә, кияү кеше, кем белән сугышасың, җиңеп буламы? — дип көләләр, ди. Кинҗәбулат аларга:

— Мин дошманның үзенә атмыйм, чәнтеки бармакларын гына өздереп торам, — дигәч, кияүләр бер-берсенә карашып алганнар, ди. Кайтып, патшага сөйләп, җиңүләре белән мактандылар, ди. Кинҗәбулатның карга-саескан белән атышып ятуын да көлеп сөйләделәр, ди.

Патшаның кече кызы моңа бик гарьләнеп:

— Бу әллә чынлап та исәр микән? — дип, Кинҗәбулатны сынамакчы булды, ди.

Патшага икенче тапкыр яу белән киләләр. Ул кияүләрен яңадан сугышка җибәрә. Кинҗәбулат та сугышка дип чыгып китә. Яланга чыккач, җирән ат кылын алып, атын чакыра да, менеп, сугыш мәйданына китә. Хатыны, Кинҗәбулат киткәч, аның артыннан күзәтергә чыга, саескан-каргалар янына бара, ире анда булмый.

Кинҗәбулат сугыш мәйданына килсә, мәйдан үлекләр белән, һава кан исе белән тулган, ә патша кияүләре җиңелеп баралар, ди. Патша кияүләренә килеп, Кинҗәбулат:

— Әгәр аркагыздан бармак иңе тирегезне сыдырып бирсәгез, дошманнарыгызның барсын да кырам, — дигән. Кияүләр, риза булып, сыдырып биргәч, киткән, ди. Кинҗәбулатның кылычы бер селтәгәндә йөзәрләгән дошманны юк итә, ди. Дошманнарны җиңгән дә юк булган. Карга-саесканнар янына килеп, аларны атып яткан кеше була, ди. Бер як читтә утырган хатыны, Кинҗәбулатны күреп, яшеренгән, ди. Патша кияүләре Кинҗәбулатка:

— Йә, сугышып буламы? — дип әйтүгә, Кинҗәбулат:

— Була, мин дошманнарны укытам, аларны бер дә үтермим, арка тиреләрен генә сыдырам, — ди. Кинҗәбулатның болай дип җавап бирүеннән хатыны нидер сизенгән, әмма бу турыда беркемгә дә әйтмәскә булган. Кияүләр жавапка гаҗәпләнмәгәннәр, ачуланырга да, ачуланмаска да белмәгәннәр. Кайткач, гадәттәгечә, мактанганнан соң, Кинҗәбулатны сөйләп көлгәннәр, ди. Патша да хәзер олы кияүләрен мактап бетә алмый, ди.

Көннәрнең бер көнендә патшага тагы да яу белән киләләр. Олы кияүләр белән бергә Кинҗәбулат та сугышка китә. Бу юлы, патшаның кушуы буенча, һәрбер кияү үзенең хатынын алып барырга тиеш була. Кинҗәбулат та хатынын алган. Карга-саесканнар янына килеп җиткәч, бичәсен олы кияүләр белән җибәргән дә, үзе шунда калган, ди. Бичәсендә тагы да шик туган, шулай да сиздермәгән, жизнәләре белән киткән, ди.

Бервакыт каты сугыш башланган. Үлекләрнең иге-чиге юк, кан елга булып ага, ди. Кинҗәбулат патша кияүләре җиңелеп бетеп барганда гына ак атына атланып килеп чыга да аларга:

— Менә сез җиңелеп барасыз, болай сугышсагыз, җиңеләсез дә. Әгәр дә сез билегездәге каешларыгызны салып бирсәгез, мин дошманны үзем генә җиңәр идем, — дигән.

Бу каешлар дөньяда бер генә булып, патша кызларының ирләренә биргән бүләге булган икән. Куркудан котлары очкан патша кызлары каешларны бирергә кушканнар. Кинҗәбулатның хатыны ак атны күргәч, сискәнеп үк куйган, ди. Шикләнсә дә, бернәрсә дә әйтмәгән, ди. Кияүләр каешларын салып биргәч, Кинҗәбулат дошманны кыра башлаган. Кылычы белән бер селтәсә, меңәрләгән дошман юк була икән. Ләкин сизмәгәндә ул кулын яралый. Моны күргән хатыны, үзенең иң яратып ябынган яулыгын салып, ярасын бәйли. Дошманны кырып беткәч, Кинҗәбулат яңадан юк булган. Патшаның теге кияүләре хатыннары белән сугыштан кайтып килгәндә, ул тагы да карга-саесканнар атып ята икән.

— Йә, сугышып буламы? — дип сорыйлар икән тегеләр.

— Сугышып була, тик мин каргаларның билләреннән каешларын гына салдырам, саесканның мактанып ябынып йөргән яулыгын гына алам, — дип җавап биргән, ди, Кинҗәбулат.

Кинҗәбулатның хатыны нигә мондый җавап биргәнен аңлап алды, ди. Үзе бик ышанып та бетми, беркемгә дә бернәрсә дә әйтми.

Моңа кияүләрнең генә бер дә исе китми, ди. Алар, көлеп:

— Сугышчы остазыбыз күп каргаларны җиңгән, өйгә кайтыйк инде, — дип, Кинҗәбулатның кулыннан килеп тотсалар, кулы яралы икәнен күреп калалар. Бу вакыт ул ярасын икенче чүпрәк белән бәйләгән була. Алдан җавабы да әзерләп куелган, ди. Кинҗәбулатның хатыны хәзер бөтенләй диярлек сергә төшенеп ала. Кияүләр, кызлар өйгә кайткач, патша барсын да чакырып алган да, болай дигән, ди:

— Менә минем олы кияүләрем кияү булып чыктылар. Дошманнарны җиңеп, үзләренә дан, миңа тынычлык яулап алдылар. Ә кече кияү минем битемә кара гына яга, аны үтерүдән уңае юк.

Кияүләр аның сүзен хуплаганнар. Кинҗәбулат та, хатыны да берьюлы аякка басып, сөйләргә иткәндә, патша кызына утырырга боерган, Кинҗәбулатка сөйләргә кушкан, ди.

— Мин сиңа, патша, берничә сорау бирәм, — дигән Кинҗәбулат. — Шул сорауларга кыенсынмый гына җавап бир әле. Беренче соравым шул булыр: синең кияүләреңнең барсының да сул кулының чәнтеки бармаклары юкмы әллә? Икенче сорау: синең бөтен кияүләреңнең дә арка буйларында бармак иңе тиреләре юкмы әллә? Өченче сорау: кызларың биргән бүләк бил каешларын кияүләрең кая иткән икән? Барсын да кияүләрең табып бирсен. Кем сугышта җиңгән булса, аларны шул кеше табар. Азаккы соравым: кече кызыңның иң яратып бөркәнгән яулыгы кайда икән? — дигән дә урынына утырган, ди.

Олы кияүләр һәр сораудан соң, дерелдәп, чыдаша алмый торганнар, ди. Патшаның соравына алар йә өзелде, йә ук алып китте, йә кылыч өздедән башка җавап бирә алмаганнар, ди. Патша, кече кызы янына килеп:

— Йә, иң сөекле кызым, яулыгың кайда синең? — дип сораган, ди.

— Мин аның белән азаккы сугышта җиңгән батырның кулын бәйләдем. Ул безне үлемнән коткарды, — диде, ди, кызы. Моны ишеткән Кинҗәбулат болай дигән:

— Менә шулай, патша, синең олы кияүләрнең җиңүче түгел, ә алдакчы буш куыклар алар. Әгәр җиңүченең кем икәнен белергә теләсәгез, менә ул — мин. Җиңүче исеме өчен алар үзләренең бармакларын да, арка тиреләрен дә, бүләк каешларын да җәлләмәделәр. Менә алар. Бармаклар, арка тиреләре аларга кире үсмәсләр, бу бүләкләр киредән бирелмәс. Мәңгегә алар юк булсын, — ди дә дөрләп янган ут эченә ыргыта. — Ә менә бу яулыкны минем хатыным ярага чын күңелдән бәйләде, яра шунда ук диярлек төзәлде. Кече кызың, киявең иң тугры булырлар, алар бервакытта да кешене алдамас, үз иле өчен җанын аямый хезмәт итәрләр, — ди. Менә шуннан соң

патшалык Кинҗәбулатка күчә. Өлкән кияүләрне нишләтү мәсьәләсе дә аңа тапшырыла. Патша булып алгач, Кинҗәбулат:

— Кем дә кем тугры эшләп ашар, ул кеше генә минем илдә яшәр; кем кешене рәнҗетә, кеше көченнән файдалана, ул минем илдә яши алмас, — дип халыкка эндәште, ди.

Әле һаман да шушы патшалыкта шултиклем гаделлек, тигезлек, ди. Бөтен халык ирекле, бер кеше кебек, рәхәт, тату яшиләр, ди.

КЕЧЕ УЛ

Элгәре бер заманда яшәгән, ди, бер патша. Ул патшаның өч хатыны бар икән. Берсе бик яшь, ди. Әмма бер хатыныннан да балалары юк, ди.

Бердәнбер көнне патшага бер алма сатучы карт килә дә:

— Менә хатыннарыңның өчесенә өч алма биреп калдырам. Шуны ашасыннар, өчесе дә ул табар. Тик шундый шарт бар: кече улыңны, тугач та, мин алып китәчәкмен, шуңа риза бул, — ди.

Ни эшләмәк кирәк, патша риза була. Алмаларны хатыннарына ашата.

Вакыт үтә тора. Менә берчак өч хатыны да берәр ул таба. Яшь хатынның улы бигрәк шәп үсә. Көн эчендә ел үскән тиклем үсә. Ун көн үтүгә, теге алма сатучы бабай килеп тә җитә.

— Вәгъдәңне үтә! — ди.

Патша киреләнә алмаган. Яшь хатынның улын жәлләп, һуштан язып елап ятканын барсы да күреп торган. Карт шулай итеп кече улны үзенә алып кайтып киткән.

Әй баралар, әй баралар, ди, болар. Бер урман арасына барып җиткәч, теге бабай:

— Улым, әнә акланда бер казан бар, син аның астына ут яндыр, мин хәзер утын җыеп алып барырмын, — дигән.

Егет акланга барса, тегендә бер зур казан, казан эче тулы май икән. Казан тирәләп бик күп кешеләрнең сөяге ята, ди. Егет барган да бер баш сөяген тотып караган. Шулчак баш телгә килгән:

— Әй егет, харап буласың бит. Монда нигә килдең инде? — дигән. Егет сөйләп биргән. Баш:

— Ул хәзер, астына ут ягып, шушы казанны кайнатыр. Сине шул казан тирәли әйләнеп чыгарга кушар. Син: «Бабай, мин белмим бит әле, үзең әйләнеп күрсәт», — дип әйт. Шуннан аны казанга этеп төшерерсең дә куярсың, — дигән. — Шулчак бер песи килер, муены тулы ачкыч булыр, ачкычларны алырсың да анавы тау мәгарәсендәге келәтләрне ачарсың. Өченче келәттә бер яшел сандык булыр, шуны ач та, эчендәге кошны канын чыгармый гына сыгып үтер. Бу картның җаны шул булыр. Шуннан соңгы келәт эчендәге киемнәрне киенеп, атка менеп, теләгән якка китәрсең, — дигән.

Карт утын күтәреп килеп җиткән. Казан астына салып, егет ут төртеп җибәргән. Казанның суы кайный башлагач, бабай егеткә казанны әйләнеп чыгарга кушкан. Егет:

— Мин әйләнә белмим, тәүдә үзең өйрәтеп бир, — дигән.

— Әй-й, шуны да белмәскә, — дип адәм ашаучы карт казан тирәли лап-лап әйләнә генә башлаган икән, егет, картның артыннан карап барган кеше булып, аны казанга күтәреп бәргән дә куйган!

Бераздан, муены тулы ачкыч сөйрәп, бер песи килеп

чыккан. Егет аның ачкычын алып, үзен казанга ташлаган. Шуннан теге мәгарәгә барып, ике келәтне ачса, берсеннән-берсе чибәр яшь кенә кызлар, сөлек кебек егетләр килеп чыккан, ди. Үзләре, егеткә куркышып карап, берберсенә төртешәләр икән.

— Бу симез, мин ябык, монсы көр, мин арык, мине алма, моны ал, — диешәләр икән. Егет аларны коткаруын әйткәч, барсы да аңа рәхмәтләр укып, теләгән якка таралышкан, ди. Шуннан егет өченче келәттәге сандык эченнән теге баш әйткән кошны алган да канын чыгармыйча гына буып үтергән. Шулмәл казандагы теге карт белән песи җан биргән.

Егет, соңгы келәттәге атка менеп, киемнәрне киенеп алса, тагы да сылурак булган. Биленә кылычын, ук-җәясен таккан да чабып чыгып киткән.

Әй китте, ди, егет, әй китте, ди, тышау буе җир китте, ди. Бара торгач, бер патшаның елкы көтүчесенә тап булды, ди. Көтүче белән сөйләшеп киткәннәр. Егет, көтүчегә киемен биреп, үзе аның алама киемен киеп китте, ди, патшаның шәһәренә җәяүләп. Барып, бер ашханәгә эшкә кергән. Бераз эшләгәч, бер аш пешерүче килгән дә:

— Абау моны, ничек сасып йөрисең, бар юынып кил, — дигән. Егет бер буага су керергә барса, буа уртасында бер кыз йөзеп йөри икән. Егет, чишенеп, аның янына йөзеп киткән. Барып күрсә, кыз шултиклем чибәр, ди, егет бер караудан гашыйк булган да куйган. Бу патша кызы икән. Алар ярга чыгып утырып сөйләшкәннәр дә берберсенә яр булып яшәргә сүз бирешкәннәр.

Әмәлгә каршы, иртәгәсенә патша үзенең кызларына кияү сайлый башлаган. Өч кызын да патша уртага утырткан да кулларына алма тоттырган. Тирә-яктан карап торган бөтен патшалыкның халкына карап, алманы һәр кыз үзе ыргыта икән. Тәүге ике кызның алмасы ике бай кешенең кулына барып төште, ди. Ә бәләкәй кыз бәрми дә бәрми икән. Шулчак патша:

— Патшалыгымда тагы берәр кеше калдымы әллә? —

дип кычкырган. Аңа ашханәдә бер алама гына хезмәтченең калуын әйткәннәр. Патша аны да калдырмый алып килергә боерган.

Егетне алып килүләре булган, кече кыз алмасын аның кулына төшерерлек итеп бәрүе булган. Моңа патшаның бик ачуы килгән. Ике бай кияүгә ике зур, матур өй салып биргән, ә кече кияве белән кече кызын ат сарае янындагы камыт келәтенә керткән.

Тормыш шулай үтә торган, кияүләрнең һәркайсысы сунарга чыгып йөрер булган. Тик бай кияүләр бер дә ерата алмыйлар икән. Яшь кияүнең көн дә төрле кош-корт алып кайтуына болар бик нык көнләшә икән, ди. Беркөнне бай кияүләр икәүләп сунарга килгәннәр. Барсалар, иңбашына көч җиткесез итеп кош асып алган бер картны күрәләр дә:

— Бабай, сат син безгә бу сунарыңны, йөз тәңкә бирәбез, — диләр.

Карт:

— Миңа илле тәңкәсе җиткән. Калган илле тәңкәсе өчен янбашыгызга пичәт сугам, ризасызмы? — дигән.

— Ризабыз, — диешкәннәр кияүләр. Карт, тегеләрнең икесенең дә янбашына пичәт басып, илле тәңкә акчаларын алып кала. Бакдисәң, кече кияү карт булып киенеп кенә йөргән икән. Хәзер бу бай кияүләрне кызык итмәкче була.

Теге ике кияү кайталар да ит пешерәләр. Шуннан патшаның олы кызлары әйтә:

— Нигә болай гына утырабыз, әйдә, әтием янына барып, бергәләп ашыйк, сый күп бит, — диләр. Патшага сыйларын тотып барып, күмәкләп ашарга утыралар. Шулвакытта кече кияү, көтүчегә калдырып йөргән атын менеп, икенче бер патша булып боларның ишек алдына килеп туктый. Патша кунакны каршы ала, өйгә чакыра.

— Юк, кереп тормыйм, йомыш белән генә килдем, — дип җавап бирә кече кияү. — Минем патшалыгымнан ике солдатым качып киткән, аларны синдә икән дип ишеттем.

Билгеләре бар, икесенең дә янбашына пичәт сугылган, — ди.

Шуннан патшалыктагы бөтен кешенең янбашын карап бетәләр, солдатлар табылмый.

— Тагы кайда кемең бар? — ди патшага кече кияү.

— Өйдә ике киявем генә калды.

— Алып чык әле, алар түгел микән?

Кече кияү берсенең, ыштанын төшереп, янбашын карау белән кычкырып җибәрә:

— Берсе табылды! — ди.

Икенчесен карасалар, ансына да пичәт сугылган.

Хәзер кече кияү солдатларын алып кайтмакчы була. Патшаның гаепләнеп каласы килми. Кунакны патша өенә керергә кыстый. Кергәч, кунак өске киемен сала. Карасалар — кече кияү. Патша аптырап, шаккаткан, ди. Кече кияү патшага барсын да сөйләп биргән. Шуннан патша кече кызына бик әйбәтләп туй үткәргән, ә теге ике бай кияүне таш зинданга ташлаткан, кече кияүне үзенең баш вәзире иткән, ди.

Шулай итеп, бик әйбәтләп дөнья көтеп, нәсел үрчетеп яталар, ди, әле дә.

ТУГЫЗ ОЛАН

Элекке заманда бер патша яшәгән. Аның унсигез яшьләрдәге берданбер улы булган.

Ул заманда кич булдисә, кыз күзләргә чыга торган бер гадәт булган икән. Патша улы кыз күзләргә чыгып киткән. Йөри торгач, бер тәрәзә төбенә килгән дә тыңлап тора башлаган. Анда өч кыз утыра, ди. Берсе:

— Их, патша малаеның сылулыгы! Мине кәләшлеккә алса, мин аңа көмеш балдак аша үткәрерлек, дөньяда бер җирдә дә юк күлмәк тегеп бирер идем, — дигән.

Икенчесе:

— Мин алтыннан чигеп бик матур келәм ясап бирер идем, — дигән. Өченчесе бик ярлы бер крестьян кызы икән, эндәшмичә бер як читтә җеп эрләп утыра, ди.

— Син, мескен, ярлыкай, нәрсә эшләп бирер идең? — дип сораган теге ике кыз.

— Мин аңа бик матур тугыз ир бала табып бирер идем, — дигән.

Аның бу сүзеннән тегеләр рәхәтләнеп көлгән. Ә патша малаена кызның сүзләре ошаган. Кайткан да әтисенә барсын да сөйләп биргән. Теге ярлы кызының бик матур, акыллы икәнен, шуны алачагын әйткән. Әнисе ярлы кызына каршы килсә дә, улы яраткач, риза булган.

Ярлы кызын патша улына биреп, бик зур туй үткәрәләр. Җиде көн, җиде төн буена бәйрәм итәләр. Кызның бала табу вакыты җиткәч, кендек әбисе килә. Ә аны теге ике бай кызы җибәргән. Алар ничек тә булса, патша хатынын аерып, үзләре барырга тырыша икән. Корткага алар өч эт баласы биргәннәр дә хатынның улларын алмаштырырга кушканнар. Патша хатыны өч ир бала таба. Аларның өчесе дә бер-берсенә бик охшаган, айның ундүртенче көне кебек матурлар, ди. Теге кортка, балаларны алып, алар урынына өч эт баласы салып куйган. Шуннан патшага барып:

— Киленегез өч эт баласы тапты! — дигән. Патша да, улы да бик кайгыралар.

— Ярар инде, улым, көтик әле, — дигән патша.

Болар шулай яшәп яталар. Теге хатынның тагы бала табу вакыты җитә. Әлеге кортка килә. Хатын бу юлы да өч ул китерә. Кортка аларны да яшерә. Патшага:

— Киленегез тагы да өч эт баласы тапты, — дип әйтә. Бик гарьләнсәләр дә, патша белән ул тагы көтәргә булалар.

Хатын өченчегә йөкле була. Теге кортка тагы килә. Хатын тагы өч ир бала китерә. Үзе, нидер сизеп калып, бер баласын күкрәк астына яшерә. Кортка патшага:

— Киленегез бу юлы да эт баласы тапты, икәү, — ди.

Патша закон кора: хатынны сигез эт баласы белән суга агызырга булалар. Патша:

— Әгәр дә минем киленем гөнаһсыз булса, мичкә су уңаена агар, — ди. Мичкә су уңаена ага. Патша мичкәне судан чыгарырга куша. Шул вакытта җил-давыл чыгып, мичкәне бер утрауга ыргыта. Коры җиргә килеп чыкканлыкларын белеп, теге хатын үзе саклап алып калган улы белән мичкәдән ничек итте шулай килеп чыга. Тирә-якка карасалар, — бакча кебек матур урман. Болар елашып утырганда, кулына аркан белән балта тоткан бер карт килеп чыга.

— Нигә елашып утырасыз? — дип сорый. Хатын башыннан үткәннәрен сөйләп бирә. Карт, боларны җәлләп, серле аркан белән серле балта бирә. «Кирәге тияр, алыгыз», — ди.

Көннәр үтә, хатын белән малай яхшы гына яши башлыйлар. Малай үсә, егет булып җитә.

Бервакыт патшаның кәрваны утрауга килеп туктый. Болар, чит патшалыкка барып, әйберләрне әвеш-түеш китереп, зиннәтле товарлар төяп кайтканда, гел шушы утрауга туктап ял итәр булганнар. Бу юлы утраудагы алтын сарайны, бакчадагы зиннәтләрне күреп, алар таң калган. Җитмәсә, каршыларына матурлыклары белән адәмнең исен китәрерлек хатын белән егет килеп баскан. Хатын белән егет юлчыларны өйләренә алып керәләр. Җаныңа ни кирәк, өстәлдә барсы да бар, ди.

Ашап-туеп, рәхмәтләр әйтеп, кайтып китәләр болар. Егет тә күренми генә болар белән китә. Кәрванчыларның исән йөреп кайтулары хөрмәтенә патша зур мәҗлес җыя.

— Йә, ниләр күрдегез? — дип сорый.

— Без үзебезнең әлеге туктый торган урында гаҗәп хәл күрдек. Элек анда коры ком да урман була торган

нде. Ә бу юлы тукталсак, алтын сарай эшләгәннәр, бакчалар үстереп куйганнар. Ә андагы хатын белән малайның сылулыгын әйтеп тә бетерерлек түгел: йөзләреннән нур чәчелеп тора. Безне алар бик яхшы итеп сыйладылар. Мондагы синең сыең аларныкына караганда чүп кенә ул, — дип сөйләп бирәләр кәрванчылар. Ә теге кортка:

— Әй, бу гаҗәпмени, гаҗәп диңгез төбендә ул! — ди. — Диңгез төбендә — казанлык, ә казанлык астында тугыз айгыр бар. Аларны беркем дә алалмый, — ди.

Егет, кәрванга ияреп, кире утрауга кайта да ишеткән-күргәннәрен әнисенә сөйләп бирә. Шуннан юлга чыгып китә. Бик күп таулар, елгалар үтеп, бер диңгезгә килеп чыга. Яр буендагы бер урын, әйләнеп, кайнап, ургылып тора, ди. Егет теге вакытта карт биреп калдырган арканны биленә урый да, балтасын кыстырып, шул казанлыкка ташлана. Диңгез төбенә төшеп җиткәч, теге айгырларны эзләп китә. Ә алар кеше исен сизеп, үрә сикерә башлыйлар. Егет диңгез төбендәге таш сарайның коймаларын серле балтасы белән куптарып ташлый. Атлар, сарайдан чыгып, кача башлыйлар. Егет тегеләрнең берсен арканы белән эләктереп ала да сикереп өстенә менеп тә утыра. Моны күреп, атларның башкалары болар артыннан ияреп килә. Егет тиздән өенә кайтып җитә.

Теге кәрван утрауга тагын туктый. Хатын белән малай аларны тагын сыйлыйлар. Кәрванчыларның сөлек кебек ялтырап, уйнаклап торган айгырларга исләре китә.

Егет, күренмичә генә боларга ияреп, тагы китә. Патша, зур мәҗлес җыеп, кәрванчыларны сыйлый:

— Йә, ни гаҗәп хәлләр күрдегез? Ниләр ишеттегез? — дип сораша.

— Әлеге утрауда тугыз айгыр күрдек, аларның сылулыгын әйтеп бетергесез, — диләр кәрванчылар. Теге кортка:

— Әй, ул гаҗәпмени, вәт мин бер гаҗәп нәрсә беләм. Фәлән диңгезнең фәлән җирендә бер шарлама бар, аның төбендә бик серле тегермән бар. Аны бик күп баһадирлар

алып чыгарга тырыштылар. Берсенең дә көче җитмәде. Тегермәнне алып чыгарга бик көчле тугыз ат кирәк, — ди.

Егет сиздерми генә әнисе янына кайтып төшкән дә шул тегермәнне алырга барачагын әйткән. Әнисе риза булган. Егет теге айгырларның берсен менә дә, калган сигезен ияртеп, диңгезгә таба чыгып китә. Китә, китә бу, йөри торгач, теге шарламаны килеп таба. Диңгез төбенә төшеп, тегермәнне алып чыга. Бу тегермән, ни телисең, шуны үзе тартып бирә икән.

Кәрван тагы килә. Хатын белән улы тегермәннән аккош мамыгы кебек ап-ак он тарттырып торалар икән. Моны күреп, кәрванчыларның исләре китә. Он шулхәтле әйбәт, үзеннән-үзе кабарып тора, ди. Кайтып патшага сөйлиләр. Тик әлеге-баягы кортканың гына һич исе китми икән.

— Әй, бу гаҗәпмени, әнә теге тау артындагы сарайда сигез тоткын малай бар, икенче җирдә тугыз тоткын кыз зинданда яши. Аларны аждаһа саклый. Аларны коткарыр өчен бик көчле тугыз ат кирәк, — ди.

Малай кайта да әнисенә шул сигез малайны алып кайтырга ниятләгәнен әйтә. Әнисе сизенә башлый. Күкрәк сөтен савып, бер күмәч сала.

— Баргач та, олы өстәлгә күмәчне куй, — ди. Егет тугыз айгырның тугызын да иярли дә аждаһа сараен эзләп китә. Барып тапкач, күмәчне өстәлгә куя. Шуннан сигез егет:

— Әнисбезнең исе килә! — дип йөгерешеп чыгалар да күмәчне бүлгәләп ашап та бетерәләр. Егетләрнең матурлыгыннан өй эче яктырып китә. Барсы да бертөсле икән болар. Сигез егет туганнарын танып калалар да кочаклаша, елаша башлыйлар, әниләрен сорашалар. Тавышны ишетеп, икенче ишектән берсеннән-берсе сылурак тугыз кыз килеп чыга. Егетләр белән кызлар бер-берсенә гашыйк булалар. Шулвакыт аждаһа, тау-таш җимертеп, яшен яшьнәтеп кайтып килә, ди. Егетләр атларына уты-

ралар да, тугыз кызны алып, чаба башлыйлар. Аждаһа аларны куып-куып карый, җитә алмый.

Кайтуларына энисе сый әзерләп көтеп торган. Бик зур туй үткәрәләр. Тугызы тугыз кызны алып, тугыз бүлмәдә төн уздыралар.

Иртәгәсен утрауга тагы әлеге кәрван килеп туктый. Туй дәвам итә. Кәрванчыларны да бик нык сыйлыйлар, өч көн, өч төн кунак итәләр. Дүртенче көнне барсы да, кәрванга төялеп, патшага кунакка китәләр. Патша хатынын танып кочаклап ала, шәһәрне бизәргә куша. Туй яңадан тугыз көн, тугыз төн дәвам итә. Патша, улларына бик зур байлыклар биреп, тугызын тугыз җиргә башлык итеп җибәрә. Тегермәнне егетләр этисе белән энисенә калдыралар. Ә теге кортка белән ике хатынны мичкәгә салып суга ыргытканнар, ди. Патша да, хатыны да, оланнары да һаман да бәхетле яшиләр, ди.

ЯТИМ КЫЗ БЕЛӘН МУЛЛА

Яшәгән, ди, әби белән бабай. Аларның бик сылу, бик уңган кызлары булган. Кыз үсеп буйга җиткәч, әби белән бабай бер-бер артлы үлеп киткәннәр. Мескен кыз ятим торып калган. Үләр алдыннан этисе күрше генә яшәгән муллага кызын карап торырга, кеше итәргә васыять әйтеп калдырган.

Бу карт мулла кызны гел күзәтеп, карап йөри башлаган. Кызның матурлыгына сокланган. Тора-бара бөтенләйгә кызга күзе төшә, аны һәр адымы саен эзәрлекләп йөри башлый. Кыз моны сизә, бик курка, пошына. Ахыр-

да күрше әбидән киңәш сорый. Әби моңа болай киңәш бирә:

— Олы урманга бар. Анда бәләкәй генә бер сукмак күрерсең. Шул сукмак буйлап тугыз көн баргач, бер өй күрерсең. Шул өйгә кер, үз өеңдә яшәгән кебек яшә. Анда алты казак булыр. Алар сунарга йөриләр, син аларның дөньясын көт. Мулла сине эзләп таба алмас, — ди. Кыз китә. Казаклар сунарда чак була. Ул боларның бөтен эшен бетерә. Менә берзаман ат тояклары тавышы ишетелә: алты казак алты яктан сунардан кайтып килә. Кыз куркып китә дә яшеренә. Казаклар кергәч, аптырап, ишек төбендә туктап калалар. Бөтен өй эче гөлт итеп тора, бөтен нәрсә җыештырылган, юылган, өйдә беркем дә күренми. Болар киңәшләшәләр дә болай диләр:

— Кем бар өйдә? Чык, яшеренмә. Олы кеше булсаң, әбиебез диярбез, яшь булсаң, сеңлебез диярбез. Рәнҗетмәбез, бертигез яратырбыз, — диләр. Кыз чыга. Шулай итеп, алар матур гына яши башлыйлар.

Бервакыт кыз мунча ягып йөргәндә, авылдан теге әби килә. Аны, бик күп акча түләп, мулла җибәргән икән. Алты казактан соң кыз мунча керә. Кереп беткәч, әби алып килгән, мулла сихерләп җибәргән күлмәкне кисә, шунда ук иссез булып егыла. Казаклар моны көтәләр-көтәләр дә, кыз һаман кайтмагач, иң өлкәне барып карарга була. Кыз үлгән дип уйлап, күтәреп алып кайта. Болар бик кайгыралар, елыйлар. Кызны бер агач башына бәйләп китәләр. «Биек җиргә куйыйк, бөтен кеше күреп соклансын», — диләр.

Бервакыт шушы илнең патшасы сунар итеп йөргәндә, кызны күреп кала. Бу, ничектер, сизенепме, кызның тәнен күрергә теләпме, ялчыларына кызның күлмәген салдырырга куша. Күлмәкне салдырулары була, кыз шунда ук терелә дә куя. Шуннан өйгә кереп, үзенең иске күлмәген киеп чыга. Патша кызны үзенә икенче хатын итеп ала. Болар патша белән бик әйбәт итеп яши башлыйлар.

Озакламый патша бер еллык сәяхәткә чыга, кыз буйга узып кала. Патша: «Мин кайтуга улым туар»,— дип сөенә. Ни өчен дигәндә, инде ничәмә ел бергә яшәсәләрдә, олы хатыны бер бала да тапмаган икән.

Яшь хатын чынлап та ул таба, үзе иссез булып авырып китә. Кендекче әби, патшаның олы хатыны кушуы буенча, малайны бер балыкчының мурдасына илтеп тыга да моның куенына яңа туган көчек алып килеп сала. Патша кайткач:

— Хатының көчек тапты,— диләр. Патша гарьләнә, бик нык ачулана. Сихерчесенә хатынны сихерләргә куша. Сихерче карчык хатынны эткә әйләндерә. Ә теге малайны балыкчы карт мурдасыннан табып ала да әбиенә алып кайта.

— Карт көнебездә алла ул бирде,— дип бик сөенәләр болар. Малай бик тере була, бик тиз үсеп, егет булып җитә. Кыз ярәшә, сунарга йөри башлый.

Бервакыт ул сунарда патшага очрый. Патша моны ошата, бик ярата. Егет моңа тоткан төлкесен бүләк итә. Болар дуслашалар. Патша хатыны, сизеп калып, сихерчегә бу егетне юк итәргә куша. Сихерче патшага әйтә:

— Фәлән җирдә дөнья уены бар. Шунда үзеңнең иң яраткан батырыңны җибәр, дәүләтең артыр,— ди. Патша бу эшне егеткә куша. Юлга чыгар алдыннан егет ярәшкән кызы белән хушлаша. Кыз бик акыллы, бик зирәк була. Егеткә болай ди:

— Дөнья уенын шым гына алырга кирәк. Сакчылар уянып куймасыннар. Ул бер өйдә бикле булыр. Ишеген майлап ач, тавышы чыкмасын. Тупсада яткан кәҗәгә солы бир, бакырмасын,— ди. Егет шулай эшли, күп тә үтми, патшага дөнья уенын алып кайтып бирә. Патша бик шатлана, ә сихерче кайгыра.

Азмы-күпме вакыт узгач, егет белән кыз өйләнешәләр. Туйга патшаны да чакыралар. Патша, бер көн кунак булып, егет белән кызны үзләренә чакырып кайтып китә.

Болар патшага кунакка барырга җыеналар. Шулвакыт кыз егеткә болай ди:

— Ишек төбендә бер эт ята. Башкалар кебек син аңа төкермә, чыбыркыңны да селтәмә, карап кына уз, — ди. Егет шулай итә. Патша ачулана:

— Нигә безнең тәртипкә буйсынмыйсың? — ди. Егет:

— Ул минем әнием бит, — ди дә бөтен хәлне ничек булган шулай сөйләп бирә. Патша сихерчегә этнең сихерен алырга куша. Бу яңадан япь-яшь, сылу хатынга әйләнә. Патша олы хатыны белән сихерчене юк итәргә куша. Ә болар: егет, кыз, карт, аның әбие, патша белән яшь хатыны алтаулап әйбәт итеп яши башлыйлар.

БЕРКАРЫШ

Борын-борын заманда өч туган булган. Өченчесе кәрлә икән, шуңа аны Беркарыш дип йөрткәннәр. Әтиләре-әниләре үлеп киткән боларның. Өчәү яши башлаганнар. Беркөнне олы агалары:

— Туганнар, сез яшәп торыгыз, мин читкә чыгып эшләп, азрак икмәк алып кайтыйм, — дигән.

Бу чыгып китә. Китә-китә, артына әйләнеп караса, бер адым җир үтә. Барып керә бер йортка. Ул йортта бер карчык тора, ди.

— Әссәламегаләйкүм, әбекәй!

— Вәгаләйкүмәссәлам, егет. Кайда барасың, балам?

— Мин казы белән ял ашаткан кешегә малайлыкка китеп барам.

— Мин тотам, улым.

— Ярый, алай булгач, синдә калыйм, әбекәй.

— Минем кырык баш малым бар, елкы малы, шуны күтәрсең, бик яхшыдан менеп йөрергә ат бирәм.

Бу карчык дию пәрие икән.

Егет көтү көткән. Беркөнне таң беленер вакытта яткан да йоклаган. Теге әби килә дә, бүре булып, елкының берсен ашый да китә. Егет иртә белән малын санап карый, берәү тулмый бит. Кайта бу.

— Әби, бер баш мал юк, бүре ашаган, — ди.

— Әйттем бит мин сиңа, ашатмас булсаң гына тотам дип! Хәзер сырт каешыңны телеп алам, — дип әби егетне сәке астына йомарлап тыгып куйды, ди.

«Абый һаман кайтмый, ни булды икән, барып килим әле», — дип шул ук юл белән икенче туганы чыгып китә. Әлеге йортка килеп керә. Агасы кебек сөйләшә дә елкы көтәргә кала. Төне буе керфек какмый йөри дә, таң якынлашкач, хәзер барыбер яктыра, дип ята да йоклый.

Теге әби килә дә тагы бер баш елкыны ашап китә. Егет малын санап карый, күпме санаса да, бер баш тулмый. Карчыкка кайтып:

— Әби, берәү тулмый бит, бүре ашаган, — ди.

— Әйттем бит мин сиңа, бүредән ашатмас булсаң гына тотам дип! Ә син яхшы карамагансың! Болай булгач, хәзер сырт каешыңны суеп алам, — ди дә әби моны сәке астына ыргыта.

Өйдә Беркарыш агаларын көтә, агалары юк. «Тукта әле, мин дә чыгып китим», — дип монысы да әлеге юл белән чыгып китә. Юлда бер йорт бар икән, агалары монда керми киткән булганнар. Сәлам биреп барып керә.

— Кайда барасың, улым?

— Әби, казы белән ял ашаткан кешегә байга торырга китеп барамын. Абыйларым киткән иделәр, кайтмыйлар.

— Әй-й, балам, моннан ерак түгел бер йорт бар, шунда карчык тора, ул дию пәрие, минем апа ул, — ди. — Малайлыкка керсәң, аның бер алама тае бар, шуны мен, — ди. — Тай дигәне тулпар ул, — ди.

Малай бара да теге йортка керә.

— Әби, казы белән ял ашаткан кешедә малайлыкта торырга килгән идем.

— Мин тотам, улым. Атның яхшысын мен.

— Миңа алама тай да ярар. Минем гәүдә дә бәләкәй.

— Юк, аруын мен!

Малай тамагын туйдыра да көтүгә китә.

Бара да ята да йоклый. Йокыны туйдырып, таң атар алдыннан теге алама тайны менә дә каршы тора. Беркакыт теге карчык бүре булып килә. Малай бүрене чукмары белән дөмбәсләп-дөмбәсләп куып җибәрә. Көтүне алып кайта. Мал төгәл. Карчык, юрганнарын ябынып, ах та ух булып, чәчрәп авырып ята.

— Әби, ни хәл? Авырып киттеңме әллә?

— Авырыйм, балам, авырыйм.

Әбинең килене белән баласы да бар икән. Килене тамакка әзерләп йөри.

— Беркарыш, бар әле менә бу баланы тышка чыгар!

Беркарыш баланы тышка алып чыга да:

— Ярау итмә, эчеңне теләрмен, — дип баланы азрак утырткан иде, бала ярау итмәде, ди. Тора биргәч, бала тагы:

— Тышка чыгам! — дип еларга тотына.

— Беркарыш, бар әле, алып чык эчен телгерене.

Беркарыш чыга да пәри баласының эчен телеп ташлый. Өйгә керә.

— Бала кайда?

— Үзең, эчен телгере, диден бит, эчен телдем мин аның.

Беркарыш тышка чыккан арада карчык киленено эндәшә:

— Килен, казы белән ялны күбрәк сал, качыйк без моннан.

Боларның сәрмәсе* бар икән, килен казы белән ялны сәрмәгә тутыра.

Сәрмә — турсык.

Беркарыш моны сизеп кала да тегеләр карамаган вакытта сәрмәнең эченә төшә дә ята. Бәләкәй бит инде бу. Әби белән килен Беркарыш юк дип качалар.

Качып бара торгач:

— Котылдык бит Беркарыштан! — ди теге карчык.

— Котылырсың Беркарыштан! — ди теге капчык эчендә.

— Тавышы колакка сеңешкән икән, — ди әби.

Бара торгач тагы:

— Котылдык бит Беркарыштан! — ди карчык.

— Котылырсың Беркарыштан! — ди малай.

— Колакка сеңешкән икән, — ди әби. Китә торгач, бер күл янына җиткәннәр.

— Әйдә, тамакка ашыйк әле! — диләр икән болар.

Сәрмәне чишеп:

— Котылдык Беркарыштан! — дигәннәр.

— Котылырсың Беркарыштан, — дип Беркарыш сәрмәдә кузгалган икән, тегеләр икесе дә куркуларыннан күлгә чумалар. Шунда тончыгып үләләр.

Беркарыш туйганчы казы белән ялны ашый да, калганын күтәреп, кайтып китә. Килә теге йортка, ике агасы үлеп ята. Хәзер ни эшләргә? Китә бу теге карчыкка.

— Әби, минем абыйларны буып үтергәннәр бит, — ди. — Әйдә, әби, барыйк әле!

Алай итә, болай итә торгач, әби килә, тегеләрне терелтә.

— Ай-һай, озак йоклап киткәнбез! — диләр икесе дә.

— Беркарыш булмаса, йоклаган идегез бөтенләйгә, — ди әби. Теге карчыкны өч ул асрыйлар, малны бүлеп алалар. Хатын алып, әле һаман дөнья көтеп торалар, ди.

ӘБҖӘЛИЛ

Борын-борын заманда бер авылда бер әби белән бабай яшәгән, ди. Аларның Әбҗәлил исемле бердәнбер уллары булган. Болар бик авырлык белән, интегеп көн үткәргәннәр. Мал-туарлары да, кош-кортлары да булмаган аларның. Бердәнбер көнне әби белән бабай үлеп киткән. Бәләкәч Әбҗәлил үксез ятим торып калган. Әтисеннән аңа бер кочак салабаш кабыгыннан башка бернәрсә дә калмаган, ди.

Беркөнне Әбҗәлил, әнә шул кабыкларны күтәреп, зур бер күл янына барган. Кабыкны суга салып шешендергән дә аннан салабаш суйган, шуннан озын итеп аркан ишәргә тотынган. Шулчакта судан күл иясе килеп чыккан да, аннан:

— Егет, син нәрсә эшлисең? — дип сораган.

Әбҗәлил, исе китми генә:

— Менә шушы арканны ишеп бетәм дә күлне күккә асып куям, — дигән.

Моны ишеткәч, күл иясен бөтенләй курку алган. Ул ялынып-ялварып:

— Калдырсана, егет! Күлгә тимә инде, җаның нәрсә теләсә, шуны бирермен, — дигән.

«Бу шөкәтсез мәхлуктан нәрсә сорарга икән соң?» — дип, Әбҗәлил уйга калган. Аның менеп йөрергә берәр яхшы атың булсын иде дигән күптәнге теләге бар икән. Әбҗәлил күл иясеннән бик шәп бер ат сорамакчы булган.

— Син миңа иң яхшы бер ат бир. Шулчагында күлне урынында калдырырмын, — дигән ул.

— Юк, егет, мин сиңа ат бирә алмыйм. Атым киттеме — даным да бетте минем, — ди икән күл иясе.

— Ихтыяр үзеңдә, мин көчләшеп тормыйм, ә күлне мин монда калдыра алмыйм, — дигән дә Әбҗәлил арканын ишә биргән.

Күл иясе уйга калган. Бераз уйлап торгач, Әбҗәлилгә карап:

— Син кул чаклы күлне күтәреп китәрлек шундый бер пәһлеван икәнсең, минем белән кемузардан йөгерешеп кара алай булгач. Күлне тирәләп йөгерешик. Мине узалсаң, ат синеке булыр, — дигән.

— Була ул, — дигән Әбҗәлил. — Тик шундый шарт белән: минем бишектә яткан бер кече энем бар, шуны йөгереп уза алсаң, икәү ярышырбыз. Аны уза алмасаң, мин синең ише белән йөгерешеп тә тормыйм.

— Ул энең кайда соң синең? — дип сораган күл иясе.

— Әнә теге куак төбендә ята, — дигән Әбҗәлил. Хәзер шунда бар да койрыгың белән куакка сугып ал, ул шунда ук йөгереп китәр.

Күл иясе куаклыкка барып, теге әйткәнне эшләгән икән, шунда ук куак төбеннән бер куян чыгып та йөгергән, ди. Күл иясе куркак куян артыннан төшкән, ләкин куып җитә алмаган.

Шуннан инде ул, Әбҗәлил янына кире килеп:

— Йә, егет, болай булгач, өчкә тикле ярышыйк. Хәзер көрәшеп карыйк, — дигән.

Әбҗәлил моңа да риза булган.

— Минем сиксән яшьлек дәү әтием бар, — дигән ул, — әгәр син шуны көрәшеп ега алсаң, күл синеке булып калыр. Дәү әтием әнә теге тал арасында ята. Бар да таяк белән каты итеп сугып ал. Шуннан ул синең белән көрәшә башлар.

Күл иясе таллыкка барып, йоклап яткан аюга таяк белән берне кундырып алган, ди. Аю әйбәтләп кенә урыныннан торган да, алгы аяклары белән күл иясен тотып алып, шунда ук җиргә егып салган.

Күл иясе аюдан көчкә ычкынып, яңадан егет янына килгән.

— Һәлак көчле икән ләса дәү әтиең! Болай булгач, синең үзең белән көрәшеп тормыйм инде, — дигән. Шуннан соң ул: — Минем алтмыш колач ала биям бар. Әйдә, шуны күтәреп, күлне берәр кат әйләнеп чыгыйк, — дигән.

— Тәүдә син үзең әйләнеп чык, ә аннан мин карап карармын, — дигән Әбҗәлил.

Күл иясе үзенең алтмыш колач ала биясен иңбашына күтәреп алган да күлне әйләнеп чыккан. Шуннан соң, Әбҗәлилгә карап:

— Йә, егет, хәзер син әйләнеп кил инде, — дигән.

Әбҗәлил аркан ишүен ташлап, алтмыш колач ала бия янына килгән дә, күл иясенә карап:

— Чамалавымча, син ул хәтле көчлеләрдән түгел икәнсең. Син атны иңбашыңа күтәреп йөрттең, ә менә мин аны аякларым арасына кыстырып кына да йөртә алам! — дигән.

Шул җирдә Әбҗәлил, атны җәһәт кенә менеп алган да күлне тирәләп чабып та чыккан.

Күл иясе хәзер инде вәгъдәсен үтәми булдыра алмаган. Ул үзенең елкы өереннән иң яхшы атны сайлап, Әбҗәлилгә китереп биргән, ә аты — алтынга алыштыргысыз булган: каты тояклы, шырт текә яллы, бөркет күкрәкле, чуртан сыртлы, шеш колаклы, җиз күзле, яңаклары тар гына, ияге очлаеп барып беткән сылулардан сылу чаптар бер аргамак икән, ди.

Әбҗәлил көтмәгәндә килгән бу бәхеткә куанып, чаптар аргамакка атланган да өенә чабып кайтып киткән, ди.

Шул көннән алып Әбҗәлилдә яхшы атлар үрчетәләр икән, ә егетләренең зирәклек, кыюлык белән тирә-якка даннары таралган, ди.

КАРТ БЕЛӘН ДИЮ

Борын-борын заманда булган, ди, үтә ярлы бер карт. Бернәрсәсе дә булмаган, ди, моның. Таягын таянып, әкрен генә тирә-ягын карап йөрер булгән бу. Саескан оясы туры киләме шунда, карга оясымы — карап-нитеп тормый, андагы йомырканы эчеп, җан асраган бу бабай.

Бервакыт, шулай кош йомыркасы алып кайтып килгәндә, моңа бер дию тап булган.

— Мин сине ашыйм! — дигән дию.

— Кем кемне ашар бит әле! — дигән карт. — Менә бу яткан ташны учыңда сытып, сары суын чыгара алсаң, син мине ашарсың, мин чыгарсам, мин сине ашармын! Шуңа ризамы? — дигән.

Дию риза булган. Карт, таш дип, кош йомыркасын учында сытып агызган. Дию кулына таш алып, әй кыскан, әй кыскан, сары су чыкмаган. Шуннан карт диюгә:

— Мин сине ашыйм! — дигән.

Дию, куркуыннан калтыранып:

— Зинһар, ашый күрмә, мин сиңа алтын бирермен! — дигән.

— Алтын биреп котылсаң гына котылырсың шул! — дигән була икән карт, ә үзе бер чиртсәң дә үләргә тора, ди.

Дию картны үзенең йортына алып киткән. Барсалар, өендә диюнең энисеннән башка җан иясе юк икән. Дию энисенә:

— Кунак килде, самовар куй! — дигән. Булган хәлне сөйләп биргән. Өчәүләп чәй эчкәннәр.

Төн җитә. Дию картка:

— Йокларга кирәк, шушында ят! — дип урын җәйгән. Карт:

— Мин өйдә йоклап өйрәнмәгәнмен, монда бөрчә дә бардыр. Чардакка менеп йоклыйм, — дигән. Дию берәр нәрсә эшләп куймагае, дип курка икән бу. Шуңа күрә чардакка менеп яткан.

Төнлә ул әкрен генә чардактан төшкән дә тәрәзәгә караган: өйдә дию балта кайрап утыра, ди. Үзе:

— Мин аны бер чабуда үтерәм дә куям, ике чабып та тормыйм, — дип сөйләнә икән. Әнисе аңа:

— Куйчәле, нинди кеше икәнен дә белмисең, изге кеше булуы бар, үзеңә начар булып куймагае! — дигән.

— Юк, мин курыкмыйм! — дигән дию.

Карт чардакка кеше зурлыгы бер черек түмәр алып менгән дә, чикмәне белән ябып, салып куйган: янәсе, ул йоклап ята! Үзе түбән төшеп тәрәзәгә карап тора башлаган.

Дию балтасын тотып, чардакка менгән. Бер чаба, ике чаба — түмәрнең черекләре генә бөркелеп тора, ди! Дию сөйләшеп тә тормый, чардактан төшеп, өенә кергән дә әнисенә:

— Бигрәк карт икән шул: тузаны гына очып тора! — дигән.

Болар йокларга яткач, карт чардакка менеп, телгәләнгән чикмәнен кигән. Бераздан төшеп тәрәзә төбенә баскан да:

— Торыгыз! Ай-бай, озак йоклыйсыз икән! Ачыгыз ишегегезне! — дип кычкырган.

Тегеләр куркалар, җәһәт кенә ишекне ачалар, самовар куялар. Карт, чәй эчә-эчә:

— Сез, бөрчә юк, дигән идегез, монда гына түгел, чардакта да бар икән. Ярый әле өйдә ятмаганмын, бөтенләй йоклатмаслар иде! — дигән, ә үзе яман тырнанган була, ди.

Чәй эчеп беткәч, дию кеше ите пешереп утырткан. Дию картка кеше башын тоттырган. Карт ашаган булып, башны ботарлап тирә-яктагы тишек-тошыкка тыгып утырган. Шуннан, туйдым, дип, урыныннан торып:

— Йә, исәпләшик! — дигән.

— Күпме күтәрә алсаң, алтынны шултиклем ал, — дигән дию.

— Гомеремдә бик күп исәр күрдем, иллә мәгәр си-

нең ишене күргәнем. юк иде әле! — дигән карт. — Күпме күтәрә аласың, имеш! Ә мин бөтен алтыныңны да, әниең белән үзеңне дә өең-иең белән бергә күтәреп китә алам! Алып кайтам да үзеңне ялчы итәм, әниеңнән өй эшен эшләтәм. Син үзең генә күтәреп илт инде алтыныңны, күпме күтәрә аласың, шулхәтле.

Дию куркуыннан коелып төшкән. Аркасына алтын салып алган. Үзе бөгелеп төшкән, ә карт алтынны аның саен өсти бирә икән. Кузгалып китәләр болар. Дию алдан, карт арттан бара, ди. Дию азрак бара да туктый, егылып та киткәли, ди.

— Бигрәк авыр, азрагын ташлыйк әле? — дигән дию.

— Әйдә, әйдә, атлавыңны бел! — ди икән карт.

Картка килеп җитәләр. Карт:

— Син шушында торып тор, мин хатыннан самовар куйдырыйм, — дип, диюне ишек алдында калдырып, үзе өйгә кергән. Корткасына:

— Мин сиңа ит пешерергә кушармын. Ә син: «Нәрсә ите пешерим?» — дип сорарсың, — дигән.

Карт диюне өйгә алып кергән. Аркасындагы алтынны иппәп кенә идәнгә куеп, чәй эчәргә утырганнар. Карт үзенең корткасына:

— Безгә ит пешереп бир! — дигән.

— Нәрсә ите? — дип сораган әби.

— Өлкән диюнең башын, уртанчы диюнең күкрәген, кече диюнең аягын пешер! Җитмәстәй булса, менә шушы диюне дә салып пешерербез! — дип бабай диюгә төртеп күрсәткән икән, дию өй почмагын күтәреп, чыккан да тайган, ди.

Бабай белән әби сыннары катып көлеп калганнар, ди.

ӘМӘЛЕНӘ КҮРӘ ГАМӘЛЕ

КУРАЙЧЫ

Борын-борын заманда яшәгән, ди, бер бай. Аның Гәрәй исемле бер улы булган, ди. Гәрәй яшьтән үк әтисенең ялчылары белән ауга йөрергә яраткан. Ул вакытта урманнарда ерткыч хайваннар бик күп булган, ди. Беркөнне Гәрәй әтисенә:

— Әти, мин бүген ауга үзем генә барам, — дигән.

Әтисе аңа ялгызына ауга барырга рөхсәт итмәгән. Гәрәй аның сүзен колагына да элмәгән, үзенең егетлеген күрсәтергә теләп, берсенә дә әйтмичә, япа-ялгызы чыккан да киткән. Шул китүдән ул кире кайтмаган. Бер көн үткән, ике көн үтеп киткән, Гәрәй һаман юк, ди. Бай ялчыларыннан Гәрәйне таптыра икән. Бер атна вакыт үткән, Гәрәй һаман да юк ди. Шунда бай үзенең ялчыларын җыйган да:

— Гәрәйне теләсәгез кайдан эзләп табыгыз. Кем дә кем миңа кайгылы хәбәр алып кайтып авызын ача, үзенә үпкәләсен: ерткыч бүреләргә ыргытачакмын, — дигән дә Гәрәйне эзләргә чыгарып җибәргән, ди.

Тегеләр әй эзлиләр, әй эзлиләр, ди. Гәрәй юк та юк, ди. Урман-тауны кыдырып эзли торгач, ертылып беткән канлы өс киемнәрен генә тапканнар. Шуннан ялчылар,

ничек байга кайтып күренергә белми, аптырашта калганнар, ди. Шулчак бер үткенче карт очраган. Алар картка барсын да тезеп сөйләп биргәннәр дә аннан киңәш сораганнар. Карт тыңлаган да:

— Ярар, оланнар, хәзер йокларга ятыгыз, иртән юлга чыгарбыз, мин дә сезнең белән барырмын, — дигән.

Ялчылар тынычланып йокларга ятканнар, ди.

Иртән күмәкләшеп юлга чыкканнар.

Бай йортына кайтып җитсәләр, хуҗа аларны капка төбендә үк көтеп тора икән, ди.

— Йә, таптыгызмы? Нинди хәбәр китердегез? — дип сорый башлады, ди, бай ялчылардан.

Ялчылар бер сүз дә әйтмиләр, ди. Шулчак әлеге үткенче карт кыныннан курай тартып чыгарган да уйнап җибәргән. Курайның тавышы шундый моңлы, сагышлы, ди, бакчадагы сандугачлар да, хәйран калып, сайрауларыннан туктап тыңлап торганнар, ди.

Бай да, ялчылар да бер курайчыга, бер курайга карап торганнар да елаганнар да җибәргәннәр, ди. Курай моңыннан бай улының һәлак булуын аңлаган. Курай моңыннан ләззәт табып кайгысын баскан, ди.

Ялчылар берсе дә авыз ачып бер сүз әйтмәгәннәр, ди.

Менә шулай курайчы кураеның моңы белән кешеләрне үлемнән алып калган, кайгылының кайгысын баскан, ди.

ПАТША БЕЛӘН САБАНЧЫ

Элекке заманда бер патша булган. Ул патша үзенең вәзирләре белән бик күп кешеләрне үлемгә хөкем иткән. Аның хөкеме асу да кисү булган.

Бервакыт, хөкем барганда, залга патшаның кызы килеп керә дә әтисеннән рөхсәт сорап, хөкемне тыңлый башлый. Хөкем залында бер кешене асарга хөкем итәләр.

Суд беткәч, кыз атасына бара да болай ди:

— Әти, бу кешене дөрес хөкем итмәдегез. Бар кеше дә бер үк сүзне сөйләде.

Патша кызының сүзен тыңлап тора да теге кешене әлегә асмаска кушып, вәзирләрен ияртеп кырга чыга. Күп тә бармыйлар, бер сабанчы күрәләр. Аның янына туктап китмәк булалар. Сабанчы җир башына чыга. Патша аңа сорау бирә:

— Әгәр-мәгәр?

— Дигәр-мигәр, — дип җавап кайтара сабанчы.

Патша:

— Бу җирнең файдасын күпме пайга бүләсең? — дип сорый.

Сабанчы:

— Файдасын бишкә бүләм: беренчесе — көтәргә алган идем, шуны түлим; икенчесе — бушка китә, зыяны да, файдасы да юк; өченчесе — көтәргә бирәмен; дүртенчесе — җилгә оча, бишенчесе — үзем ашыйм, — ди.

Патша сабанчыга:

— Кош җибәрермен. Йолка белерсеңме? — ди.

— Әй патшам, йолкып бетерермен, мамыгын да куймам.

Сабанчы шулай дигәч, патша, вәзирләрен ияртеп, юлын дәвам итә. Шуннан баш вәзир:

— Нәрсә турында сөйләштегез? — дип сорый патшадан. — Мин аңламадым, — ди.

Патша вәзиренә иртән шушы сөйләшкәнне фәлән сәгатькә белеп килергә боерык бирә:

— Белмәсәң, миннән изгелек көтмә. Хөкем итеп, теге кеше урынына сине астырырмын.

Вәзир әти-әнисе янына кайта. Әнисе аннан:

— Нигә бик тиз кайттың? — дип сорый.

Вәзир әнисенә:

— Патша белән китеп барганда, юлда бер акыл иясе очрады. Патша белән аның сөйләшкәнен тыңлап торсам да, ни турында сүз барганын аңламадым. «Әгәр иртәгә фәлән сәгатькә тиклем шуны белмәсәң, хөкем ителгән кеше урынына сине асармын» диде патша, — дип әйтте, ди, вәзир.

Әнисе тыңлап тора да вәзирне сабанчыга җибәрә. Сүзнең аешын шуннан сорарга куша.

Вәзир килә теге сабанчы янына. Үзенең ниятен белдерә, ләкин сабанчы берни дә әйтми:

— Җирне сөреп бетерәсем бар әле, — дип, аның сүзен колагына да элми.

Аптырап, вәзир кире кайтып китә.

— Әйтү түгел, янына да китермәде, — ди әнисенә. — Әгәр белмәсәм, патшаның мине астырачагын әйткән идем, «Кешене асканны карап торырга яратасың бит. Әйдә, сине асканны без карап торырбыз, әллә асылынасың килмиме?» дип кенә җавап кайтарды, — ди.

Әнисе:

— Болай итеп кара. Ал бер мичкә көмеш тәңкә, бер мичкә алтын тәңкә. Сабынчыга бир дә ялвар, — ди.

Вәзир алтын-көмешен төяп алып, яхшыдан-яхшы атлар, арбалар белән янә сабанчы янына китә. Сабанчы җирен сөреп бетеп килә. Вәзирне күргәч:

— Тагы килдеңмени әле? — ди.

Вәзир ялвара башлый.

— Әйт инде. Бер мичкә алтын тәңкә, бер мичкә көмеш тәңкә алып килдем, — дип карый, сабанчы ипкә килми:

— Корсак ачты әле, ашарга кайтам, — ди.

Вәзир ялвара да ялвара, ялвара да ялвара. Сабанчы азак килеп бер мичкә алтын тәңкәгә, бер мичкә көмеш тәңкәгә патша белән сөйләшкәнне әйтергә була. Анда да инәлтә. Азак:

— Ярар, син миңа алтын-көмешләреңне биреп киттең, ди. Азак, мин бирмәдем, талап алды, диярсең әле, мөгаен, — ди.

Вәзир кәгазь, каләм алып: «Бөтен нәрсәне дә үзем бирдем», — дип язу язып, култамгасын салып, сабанчыга тоттыра.

— Синең янына килгәч, патша әйткән сүз нәрсә дигән сүз була? — дип сорый хәзер вәзир.

Сабанчы үзенең җавабында:

— Патша миңа: «Әгәр-мәгәр», — дип әйтте, — ди. — Мин аңа каршы: «Дигәр-мәгәр», — дип җавап кайтардым, — ди. — Ул — «Исәнмесез, саумысыз», «Исәнбез, саубыз» дигән сүз булыр. Патша миннән: «Бу җирдән чыккан ашлыкны ничә пайга бүләсең?» — дип сорады. Мин: «Бишкә бүләм, беренчесе көтәргә алганга китә», — дидем. Ансы — «ашаганны түлим» дигәнем. «Файдасы да зыяны да юк» дигәнем — «Хатыным бар, шуңа ашатам» дигән сүзем. «Көтәргә бирәм» дигәнем — картайгач, безне карасын өчен, улымны асравым. «Җилгә оча» дигәнем — «Кызым бар» дигәнем. Бишенче пай — үзем ашыйм.

— Ярар, — диде, ди, вәзир. — Шуннан патша сиңа тагы: «Кош җибәрермен, йолкырсыңмы?» дигән иде, син: «Йолкып бетерермен, мамыгын да калдырмам», — дидең. Ансы ни булыр? — дип сораган иде, ди, сабанчы:

— Ансы инде — син. Сине ялангач калдырырмын дип әйтүем иде, — ди сабанчы. Шуннан: — Бөтен малыңны йолкып алдым, бар хәзер кайт, — диде, ди.

Вәзир йөгереп кайтып китә дә әйтелгән сәгатькә патшага бара. Баргач, сабанчыдан ишеткәннәрен әйтә. «Мамыгын да калдырмам» дигәнен төшереп калдыра. Шуннан патша сорый:

— Ә азакгы сүзләре нәрсәне аңлата? — ди.

— Сезнең: «Кош җибәрермен. Йолкырсыңмы?» дигәнегезгә каршы «Йолкырмын, мамыгын да калдырмам» дигәне — мин икән. Сабанчы мине сыпырып алып калды, — дип әйтеп, вәзир асылудан котыла.

Патша зур җыен җыя. Анда, сабанчы белән патшаның ни сөйләшкәнен аңламаган өчен, вәзирне вәзирлектән төшереп, аның урынына сабанчыны сайлап куялар.

Сабанчы вәзир булгач, асылырга хөкем ителгән теге кешегә яңадан суд була. Вәзир булган сабанчы патшага акыл бирә.

— «Чакырылган кешеләр барсы да килгәннәрме?» — дип сора. Алар, килдек, дип берәм-берәм әйтеп чыксыннар, — ди.

Патша:

— Чакырылганнар барсы да килгәннәрме? — дип сорый.

— Килгәннәр, килгәннәр.

Җавап шулай була.

— Килсәләр, берәм-берәм кемлегегезне әйтеп чыгыгыз, — ди патша.

Барсы да, чакыруларын тотып, кереп торалар, исемнәрен әйтеп торалар. Вәзир булган сабанчы башлап судка биргән кешене чакыра.

— Моны бер бүлмәгә ябып куегыз, — ди.

Ярдәмчеләре шунда ук әмерне җиренә җиткерәләр. Чакырылганнарның икенчесен икенче бүлмәгә, өченчесен өченче бүлмәгә ябып куялар. Шуннан вәзир-сабанчы судка биргән кешене чыгарып җавап ала.

— Бу гөнаһлы кеше гөнаһын кайда кылып ята иде, — дип сорый.

Теге кеше:

— Минә фәлән җиргә барган идек, минем улымны шушы кеше үтереп ята иде, — ди.

— Янында кемнәр бар иде?

— Минә шушы кешеләр бар иде, — дип судка бирүче шаһит итеп китергән кешеләрне күрсәтә. — Улымның авызыннан җаны да чыгып өлгермәгән иде, — дип өсти.

Вәзир:

— Бу вакыйга кайсы тирәдә булды: тауның итәгендәме, түшендәме, башындамы; көннең чыгышындамы, баешындамы, төшлек ягындамы, төньягындамы?

— Тауның түбәсендә, кояш чыгышы ягында иде.

Шуннан вәзир:

— Улыңны үтергәнне шаһитлар күрдеме? Бергә күрдегезме? — дип сорый.

— Бергә булдык, бергә күрдек, — ди теге кеше.

Шуннан вәзир-сабанчы аны кире бүлмәсенә ябарга куша. Хәзер шаһитны чакыралар. Вәзир булган сабанчы:

— Теге кешенең улын бу кеше үтереп ятканын бергә күрдегезме? — дип сорый.

— Ул безне тау башына алып менде. Анда агач төбендә үлгән кеше ята иде. Шуннан, улымны үтерүче шушы инде, дип миңа бу кешене күрсәтте, — ди шаһит.

Вәзир-сабанчы картны кире яптыра да бүлмәсенә икенче шаһитны чакыра. Вәзир аннан сорау ала башлый.

— Син бу кешенең кеше үтерүен ничек күрдең? — ди.

— Судка бирүче мине юлда күрде дә, миңа улымны үтергән кеше шушы инде, диде. Шуннан миңа, шаһит буласың, диделәр, — ди икенче шаһит.

Вәзир аны да кире яптыра да өченче шаһитны чакыра.

— Фәлән картның улын үтергәнне күрдеңме? — дип сорый вәзир.

Шаһит әйтә:

— Әйе, үтереп ята иде, без өстенә барып чыктык. Малайның авызыннан җаны да чыкмаган иде әле, — ди.

— Кайда үтереп ята иде: тауның итәгендәме, түшендәме, башындамы; көннең чыгышындамы, баешындамы, төшлектәме, төньягындамы? — дип сорый вәзир.

Шаһит:

— Кайсы җирдә дип ни, тауның нәкъ кояш баешы ягы түшендә иде инде, — ди.

Өченче шаһитны да кертеп ябалар. Хәзер инде вәзир гаепләнүчедән сорау ала.

— Ул көнне мин ул тау янында булмадым, ул тау янына бармадым, — дип җавап бирә ул кеше.

Шуннан суд хөкем чыгарырга киңәш бүлмәсенә кереп китә. Суд киткәч, залда тыңлап утыручылар:

— Хәзер судта бер зиһенле кеше бар икән. Шулай булгач, суд бөтенләй икенче төрле бара. Элек гаепләнү-

чене, сорап-нитеп тормыйча, атарга, асарга хөкем итә торган иделәр, — дип шатланалар.

Киңәш бүлмәсендә сабанчыдан вәзиргә әйләнгән кеше сөйли:

— Өч шаһит өч төрле сөйләде. Малайны үтерүдә гаепләнүче һич гаепле түгел. Аңа бер дә юкка пычрак ташлаганнар, — ди.

Суд чыгып, карар укыла. Гаепләнүче коткарыла, кешегә пычрак ташлаганга күрә, судка бирүчегә, шаһит булып килүчеләргә штрафлар салына.

Халык шатланып таралып китә. Шулай итеп, патшаның кызы судның бөтен эшен үзгәртеп җибәрүгә сәбәпче була. Сабанчы дөрес хөкем итүче ышанычлы вәзиргә әйләнә.

ЛОКМАН ХӘКИМ

Борын-борын заманда бер зур патшалыкта Локман Хәким исемле бик галим бер кеше яшәгән. Патша, күп белгәне өчен, аны күралмый, ничек тә булса юк итәргә хәйлә кора. Хәйләсе барып чыга, «сихерче» исеме тагып, ул аны тирән коега салдырып күмдерә.

Локман Хәкимне күмгәннән соң күп тә үтми, явыз патша үлеп китә. Аның урынына икенче патша тәхеткә утыра. Көннәрдән беркөнне ит ашаганда, патшаның тамагына сөяк утыра. Төрле табибларны чакыралар — берсе бер сөякне алалмый.

Бу патшалыкта күпне күргән, күп яшәгән бер карт була. Патша бу карттан, патшалыкта тагы берәр белем-

че юкмы икән, дип сорарга куша. Килгән патша вәзиренә карт:

— Моннан җиде ел элек Локман Хәким дигән бик галим кеше яши иде. Үлгән патша аны, күп белгәне өчен, коега салып күмдерде. Бәлки, җир астында яшәргә им тапкандыр. Итсә, шул гына ярдәм итәр иде, — дигән, ди.

Патша картны коедан казып алырга куша. Локман Хәким үлүгә үлмәгән, әмма бик нык йончыган була. Патшаның авыруын аңа әйткәч, Локман Хәким:

— Патшаның бер улы бар икән. Шул улын суеп, итен ашасын, сөяк аның тамагыннан чыгар, — дигән, ди.

Бу сүзләрне патшага әйтәләр. Патша үзенең бердәнбер улын суярга җәлли.

— Агачның яфрагын киссәң, икенче яфрак үсеп чыга, тамырын киссәң, агач корый. Җәлләмә бер баланны, суй, үзең тере булсаң, балаларың булыр әле, — дигән аңа бер вәзире.

Патша улын суярга риза була. Локман Хәким баланы салып, аны чаршау белән ышыклый да куй сарыгы китерергә куша. Куйны китерәләр. Карт шул куйны чалып җибәрә. Куйның чалу каны чаршау артында елап утырган патшага чаптыра. Патша, улымны суйдылар икән, дип:

— Ах! — дип кычкырып җибәрә. Кычкырып та җибәрә — тамагындагы сөяк атылып килеп тә чыга.

Шунда торган халык Локман Хәкимнең бу акыллы хәйләсенә шакката. Патша, улының суелмавын белгәч, куанып бетә алмый, ди. Ул шунда вәзирләренә мәҗлескә әзерләнергә, халыкны җыеп китерергә куша. Бу мәҗлескә төрле яктан күп халык җыела. Патша халык алдында Локман Хәкимгә рәхмәтләрен әйтә, күп байлык бирә дә:

— Болай ярлы булып яшәмә, шатлыкта, рәхәттә көн күр, кайгыны белмә, — ди.

Шуннан алып, картларны үтерми башлаганнар, ди.

Локман Хәким әле дә кайгы-хәсрәт күрми, шат-рәхәт яши, ди, авыру кешеләрне савыктыра, ди.

КӨТҮЧЕ ПАТША

Борын заманда Гали исемле бер патша булган. Бу патша патшалык итә торгач, комсызланып китеп, халыкны бик изалата башлаган, чиктән тыш авыр салымнар салган, ди.

Халык киңәшләшеп, бу патша өстеннән кәгазь язып, зуррак патшага бер кеше җибәргән. Гали патша моны сизми дә калган. Теге кеше зур патшага барып, халыкның зарын тапшырып, аннан фәрман алып кайта. Фәрманны почмак саен эләләр. Анда: «Гали патшаны иртәгәсе көн сәгать уникедә асмага», — дип язылган булган, ди.

Гали патша белми әле, үзенең тәхетендә утыра бирә. Патшаның бер якын вәзире була. Ул Гали патша янына керә дә:

— Патшам, син нәрсә ишетәсең? — ди.

— Бернәрсә дә ишетмим. Ни булган? — ди патша.

— Син берни белми утырасың, патшам, сине бит иртәгә сәгать уникедә асарга, — ди.

Патша чыга, карый, чынлап та шулай. Патша калтыранып китә. Нишләргә? Кайда барырга? Инде качарга гына кала.

Патша шул төнне үк качып китә. Үзе белән берни дә, хәтта ашарга да, акча да алмый кача. Тик Сәлимә исемле яраткан кызын гына ияртә. Көн буе баралар болар, төн буе баралар. Калаларга җитәләр, үтеп китәләр. Хәер

сорашып та алалар. Кичә тәхеттә утыр, бүген хәер сораш. Дөнья нишләтми бәндәсен.

Бара торгач, кызы белән патша тагы бер шәһәргә барып җитә. Шунда урын табып, куналар инде болар. Иртәгәсен базарга баралар. Базар туп-тулы, сатучылар эш башлаган. Бераз ашарга табып булмасмы, дип, урлашу ягын карап, теге икәү кибеткә керә. Кибет мануфактура кибете булып чыга. Шулай да бер почмакта кәстрүл белән май утыра икән. Патша кәстрүлне шылдырырга уйлап омтыла. Шулчак моны күреп калалар да кыйнап ташлыйлар.

Бер әби боларны кызганып хәер бирә. «Хәер сорашып кына тамак туйдырылмаса инде»,— дип уйлый Гали патша. Кызына да киңәш итә. Шуннан башка чарасы булмый шул. Эшләр иде — һөнәре юк, урлар иде — тукмыйлар.

Хәзер болар, хәер сораша-сораша, ишетмәгән-күрмәгән якларга китеп баралар. Күп бара торгач, бер авылга барып җитәләр. Шунда читтә генә бер өйгә фатир сорап керәләр. Анда әби белән бабай гына тора икән. Әби белән бабай аларга киңәш бирә:

— Сез, болай йөргәнче, безнең байга көтүгә яллаңыгыз. Тамагыгыз тук, өстегез бөтен булыр, ичмасам,— диләр.

Иртәгәсенә әби белән бабай, байның торган җирен өйрәтеп, боларны чыгарып җибәрәләр.

Гали патша Сәлимәсе белән бай йортына барып керә. Байның йөз баш сарыгы, илле баш сыеры бар икән. Шуларны көтәргә кирәк була. Инде көтү көтәләр аталы-кызлы. Елдан артык вакыт үтеп китә.

Берчак көтү көткәндә, төш вакыты җиткәч, Гали кызын елга буена су алырга төшерә. Үзе ут ягып җибәрә. Кыз су буена төшсә, куркып китә. Якыннан гына офицер киемендә бик матур бер кеше килә. Ул үрдәк атып йөргән икән монда. Егет тә кызны күреп, матурлыгына сокланып, ашыга-ашыга килә, ди. Сәлимә суын чайпылды-

ра-чайпылдыра этисе янына йөгереп килә. Егет аның артыннан бара. Ата белән кыз янына килә теге егет, исәнләшә, утыра. Аны-моны сөйләшмиләр. Кем икәнен сорарга Гали кыймады, ди. Теге егет хәер итепмедер, бераз акча бирә дә китә.

— Бу кеше сәүдәгәр малае микән, патша малае микән. Оялып, сорамадым да, — ди патша кызына.

Егет патша улы булган, ди. Сәлимәне күргәч тә, аңа күзе төшә. Кайткач, бу ашамый да, эчми дә икән. Патша хәвефләнеп:

— Безнең малайга ни булган бу? — ди, кеше аша сораштырып та карый.

Патшаның вәзире:

— Менә, патшам, — ди, — ауга йөргәндә улың бер көтүченең кызын күреп, шуңа гашыйк булган. Атам шул кызны алып бирсен, дип әйтә улың, — дигән.

Патша белән хатыны бик аптырашалар.

— Патша була торып, көтүче кызын алып булмас инде, — диләр. — Безгә кемнәр килми, — диләр.

Егет:

— Миңа башка кирәкми, — ди.

Ата белән ана, аптырагач, эчтәнме, тыштанмы — ансы билгеле түгел, риза булалар.

Патша:

— Көтүче ни кызын шатлана-шатлана биреп җибәрер минем улыма, — ди дә, атлар җиктереп, көтүче янына улы белән яучысын җибәрә.

Яучы Галигә:

— Менә, — ди, — шундый хәл, — ди. — Күптән түгел синең кызыңны бер патшаның улы күргән, кызыңны ул бик ошаткан, — ди. — Хәзер син биреп җибәр кызыңны патша улына кәләшлеккә, — ди.

Гали патша ашыкмый. Мин көтүче, дими әле. Кызын бирү турында да сөйләми.

— Ул егетнең, — ди Гали «көтүче», — ни эше бар соң?

Патша улы булгач ни, шәһәрдә тик йөри торгандыр бит ул? — ди. — Берәр һөнәре бармы соң аның? — ди.

— Нинди һөнәре булсын аның? Патша улы бит ул! Һөнәр нәрсәгә ул аңа? — ди яучы.

— Мин кызымны бертөрле дә һөнәр белмәгән кешегә утыртып җибәрә алмыйм. Иң элек егетегез һөнәр өйрәнсен, шуннан монда килер, — дигән Гали патша.

Егет кайтып китә хезмәтчеләре белән. Кайта да яхшы атына утырып чыгып китә бу. Һөнәргә өйрәнү урыны эзли башлый, ди, хәзер бу. Бер авылга бара. Анда эшкә өйрәтә торган осталык йорты бар икән. Тик анда бай малайларын, сәүдәгәр балаларын алмыйлар. Әти-әнисе булмаган ярлы-ябага гына һөнәр өйрәнә икән монда. Патша улына дүкәмит алу ни тора? Дүкәмитне яңадан әзерләп, ярлы киемен киенә дә китә бу осталык йортына.

— Мине ике көндә һөнәргә өйрәтеп чыгар, — ди патша улы хуҗага.

— Бер һөнәрең дә булмагач, сине ничек итеп ике көндә өйрәтеп чыгарасың? Бер һөнәргә өйрәнү өчен генә дә ким дигәндә ике атна вакыт кирәк, — диләр моңа.

Егет ике атнага риза була. Өйрәнеп йөри бу иплəп кенә. Чыпта сугарга өйрәтәләр моны. Чыпта сугарга өйрәнгәч, яхшы киемнәрен киенеп, ярсып торган атына утырып, өйгә дә кайтып тормый, Гали көтүче янына килә бу.

— Инде менә өйрәндем, — ди. Чыптасын күрсәтә.

Шунда гына Гали сөйләшә башлый егет белән.

— Мондый чыптаны көнгә күпме эшләргә була соң? — ди.

— Көненә берне эшләп була, — ди егет.

— Берсе бер сум торса чыптаның, тамагыгызны туйдыра алырсыз, ал кызымны, — ди. — Тик яланнан алып китмә, фатирыма кил, — ди.

Егет «көтүченең» фатирына килә. Ярәшеп патша йортына китәләр болар. Гали «көтүче» дә кода булып бара. Теге патша Галигә «көтүче кода» дип кенә эндәшә икән.

Ашыйлар, эчәләр кодалар. Бер-ике стакан эчкәч, телләре ачылып китә. Гали патша үзенең хәлләрен сөйләп бирә.

— Мин патшадан көтүче булдым, кода, — ди.

Теге патша шакката. Көтүче кызы булмады, патша кызы булып чыкты бит килен! «Менә мин дә бүген патшамын, иртәгә көтүче булуым бар», — дип куркуга төшә.

— Гали патша булса да, киявен тиккә генә һөнәргә өйрәттермәгән икән. Бүген патша, иртәгә әллә кем. Һөнәрле кеше һичкайда югалмас, — ди.

АКЫЛЛЫ КАРТ БЕЛӘН ИСӘР ПАТША

Моннан күп заман элек бер шәһәрдә булган, ди, бер яшь патша. Ул картларны бер дә яратмаган, ди. Шуңа күрә аларны үтереп бетерергә боерган, ди. Тик бер генә егет үзенең картаеп беткән әтисен, җир астына яшереп, үлемнән коткарып алып калган, ди.

Күп тә үтмәгән, күршедәге илнең патшасы бу яшь патшага сугыш ачкан, ди. Яшь патша гаскәр җыя башлаган. Әтисен яшергән теге егет, яуга китәр алдыннан хушлашыр өчен, әтисе янына җир астына төшкән. Әтисе улын болай дип озатып калган, ди:

— Улым, сез бик ерак җирләргә китәсез. Сезгә анда бик авыр булыр: арырсыз, ачыгырсыз, атларыгызны суеп ашап бетерерсез. Хәтта гаскәр башлыгының атын да суеп ашарсыз. Шуннан соң инде сез, теләмәсәгез дә, кире әйләнерсез. Кайтышлый бөтен сугышчылар үз атларыннан салдырып алган нәрсәләрен ташлап калдырырлар. Күтәреп килүе бик авыр булса да, син ияреңне белән йөгәнеңне ташлама. Сезгә күреп туйгысыз бер матур күк

ат очрар. Ияре, йөгәне булмаган кешеләргә ул якын да килмәс, синең яныңа җилеп килер дә алдыңа гына туктар, шуннан соң башын ияр. Син аңа йөгәненне сал да иярләп гаскәр башлыгына алып бар. Башлыгыгыз сине үзенең якын кешесе итеп күрер, шуннан инде үзенең дусты итәр. Ярар, бар, хуш бул, улым! — дигән, ди.

Бөтен нәрсә карт әйткәнчә булып чыккан. Яуга барганда, гаскәрнең ашарга азыгы беткән. Шуңа сугышчылар үз атларын суеп ашый башлаганнар. Бара-бара башлыкларының да атын ашап, башка суяр нәрсә калмагач, кире борылганнар, ди. Атларга җиңелрәк булсын өчен, сугышчылар суелган атлардан салдырып алган иярләрен дә, йөгәннәрен дә ташлап калдырганнар. Тик, әтисенең сүзләрен исендә тотып, теге егет кенә иярен дә, йөгәнен дә ташламаган, ди.

Шулай кайтып килгәндә, күреп туя алмаслык матур бер күк ат гаскәрнең каршына уйнаклап килеп чыккан, ди. Бөтен кеше аны тотып алырга теләгән, әмма ул беркемгә дә тоттырмаган. Шулай чабып йөри торгач, ул кулында ияре, йөгәне булган егет янына юртып килеп туктаган да башын игән. Егет аның башына йөгәнен салган да, иярләп, гаскәр башлыгына алып барган. Шуннан бирле ул гаскәр башлыгының дусы булып киткән.

Бервакыт патша үзенең гаскәре белән диңгез яры буена күңел ачып йөрергә чыккан. Яр башында торган патша диңгез төбендә бернәрсәнең елкылдавын күргән. Патша үз артыннан йөрүчеләргә шул елкылдаган нәрсәне диңгез төбеннән алып чыгарга боерган. Боерык буенча күп кенә кеше диңгез төбенә чумган, әмма берсе дә кире калыкмаган, ди.

Теге яшь егет чумарга нәүбәт якынлашып килгәндә генә атына сикереп менгән дә җилдереп кайткан да киткән. Егет җир астындагы әтисе янына төшкән дә аңа диңгез яры буенда булып яткан хәлне сөйләгән. Ул сөйләп беткәч, теге карт:

— Улым, диңгез яры буенда өлкән агач үсеп утыра,

шул агачның очында кош оясы бар, шул оя эчендә зур алмаз ята. Шушы алмаз ташының елкылдавы диңгез өстенә төшә дә күрер күзгә төптә яткан асылташ сыман тоела. Диңгезгә чумарга сиңа нәүбәт килеп җиткәч, патшадан: «Патшам, миңа да диңгез төбендә үлеп калырга туры килер, шуның өчен миңа шушы агач башына менеп, соңгы тапкыр туган авылым ягына карап алырга рөхсәт итсәңче!» — дип үтен. Ул сиңа рөхсәт бирер. Син кош оясындагы теге асылташны алып төш. Арытабан инде нәрсә эшләргә кирәклеген минем улым булган кеше үзе белергә тиеш, — дигән.

Егет:

— Нәрсә эшләргә кирәген үзем белермен, әти, — дигән дә, атын менеп, диңгез буена чабып та киткән.

Диңгез төбенә чумарга нәүбәт килеп җиткәч, патшага:

— Патшам, миңа да диңгез төбендә үлеп калырга туры килер, шуның өчен шушы агач башына менеп, соңгы тапкыр туган авылым ягына карарга рөхсәт итсәңче! — дигән.

Патша аңа рөхсәт иткән. Егет агач башына менеп, оядан алмазны алып төшкән дә патшага:

— Патшам, диңгез төбенә карагызчы. Әгәр анда теге нәрсәнең елкылдап ятуын күрә торган булсагыз, мин аны төшеп алып чыгармын, — дигән.

Патша диңгезгә караган. Елкылдау хәзер бөтенләй сүнгән булган.

— Нигә елкылдамый ул хәзер? — дигән патша.

— Менә ул, минем учта, шуңа елкылдамый, мин ул асыл нәрсәне агач башыннан алып төштем, — дип, егет алмазны патшага тоттырган да елкылдауның хикмәтен сөйләп биргән.

— Моңа ничек башың җитте синең? Сугыш вакытында бик матур ат тотып алып, гаскәр башлыгына бүләк иткәнсең, хәзер алмаз бүләк иттең, — ди патша.

Егет патшага:

— Әй патшам, әйтсәм дә куркам, әйтмәсәм дә кыен. Ярар, әйтсәм әйтим инде. Син картларны үтереп бетерергә боерык биргәч, картаеп беткән әтиемне яшереп алып калган идем. Үзем эшләгән шушы бөтен эшне мин аннан өйрәндем. Хөрмәтле патшам, әгәр син картларны үтереп бетерергә боермаган булсаң, алар бик күп яхшы киңәшләр биргән булырлар иде, — дигән, ди.

Шуннан соң инде егетнең әтисен патша җир астыннан чыгарырга кушкан, аны үз янына чакырып, зур хөрмәт күрсәткән.

Шушы көннән алып патша үзенең теге дуамал әмерен юкка чыгарып, картларны үтермәскә дигән яңа әмер биргән, ди.

АТА ВАСЫЯТЕ

Элекке заманда бер бабай үләр алдыннан улына васыять әйтеп калдырган.

— Урамга таяксыз чыкма,— дигән. — Атыңны кешегә йомыш итеп бирмә, — дигән. — Бичәңне үзеңнән башка кунакка җибәрмә, — дигән.

Шулай дигән дә бабай, күп тә тормый, үлеп киткән. Әтисе үлгәч, егет, әтинең васыятен сыныйм әле дип, өрьяңа киемнәрен киеп, таяксыз-нисез урамга чыга. Артыннан бер эт килеп җитә дә моның, чабуына ябышып, өрьяңа чапанын ерта. Егет кире кайта да чапанны бичәсенә белгертми генә сала да сандыгына алып куя.

Бервакыт бу егетнең күршесе килә:

— Бияңне биреп тор әле, күрше, — ди.

Бу егет биясен бирә. Күп кенә көннәр үтә, күршесе

бияне китереп бирми. Атын китермәгәч, егет басуга чыгып китә. Күршесенең сабан сөргәнен шәйли дә куак буеннан карап тора. Моның биясе бик яман тирләгән, сөрә алмый. Ул гына да түгел, колыш салган. Сабан сөрүче күршесе колынны куак арасына яшереп куйган, ди. Биянең сабан сөрер хәле булмагач, теге күрше аны тугарып, җитәкләп кенә алып кайтып китә. Егет колынны үләнгә төреп алып кайтып, чиннек сәндрәсенә салып куя. Күршесе атны китереп тапшырган. Бу бернәрсә дә әйтмәгән.

Егетнең бичәсе ике генә көнгә аталарына кунакка барып килергә сорый. Егет рөхсәт итә. Яшь баласын күтәреп, хатын җәяү генә дүрт чакрымдагы авылга әтисенә кунакка киткән. Бичәсе озаграк торды, ике кич урынына дүртне кунды, ди. Ире, йортын карарга кеше куеп, бичәсенең хәлен белергә китте, ди. Кайныларының йортына кермичә, икенче бер кешегә төште, атын тугарды, җәяү генә кайныларының ихатасына барды, ди. Караңгы төшеп килгән мәл була. Бу ир чиннек буена ышыкка гына качып утыра, утыра торгач, шәйләп ала, баласы ялгыз гына иске өйдә ята. Бичәсе ак мунчада элекке егете белән шаярып утыра. Ир тиз генә иске өйгә кереп, баласын ала да фатирына барып, атын җигеп алып кайта да китә. Бичәсе белән сөйләшеп тә тормый.

Кайткач та, баланы карарга бер карчыкка тапшырды, ди. Бичәсе, алты кич кунгач, елап кайтып төшкән булды, ди.

— Нигә елыйсың? — ди ир. — Нигә шулай озак тордың? — ди.

— Балабыз үлде, — ди бичәсе. — Баргач та нык кына чирләде дә, — ди, — өченче көн үлде, шуны җыештырып йөреп, озаклап киттем, — дип елый, ди. Ире:

— Әләйсә, өчен уздырыйк инде, — дип аш әзерләргә кушты, ди.

Бичәсе ашны әзерләде, егет каенанасы белән каенатасын да китерде, мулла белән мәзинне дә чакырды, ди.

Сабан сөрергә атын алган күршегә дә әйтте, баласын караган корткага азактан гына килергә кушты, ди.

Чакырылган кунаклар җыелдылар, ди. Кунаклар җыелгач, хуҗа алардан рөхсәт сорый.

— Ашка кадәре, рөхсәт итсәгез, әтинең васыятен сөйләп китим әле, — ди.

Кунаклар барсы да:

— Рөхсәт, рөхсәт, — диләр.

— Әти, урамга таяксыз чыкма, дигән иде. Бервакыт, әтинең васыятен сынар өчен, таяксыз чыктым, — ди. — Шуннан, чыккан гына идем, бер эт ябышып, өр-яңа чапанымның чабуын ертты, — ди.

Сандыктан чапанын алып күрсәтә. Карасалар, чабуы нык кына ертылган, ди.

— Икенче васыяте — атыңны кешегә йомыш итеп бирмә дигән сүзе иде, — ди. — Әтиемнең бу васыятен дә сынамакчы булып, биямне сораганга, күршемә биргән идем, сабан сөреп арытты да колын салдырды, — ди.

Шуннан чиннектәге колынны кертеп күрсәтә. Күршесе нишләргә белми аптырады, ди, бер кызарды, бер бузарды, ди.

— Өченчесе, — ди, егет әйтә, — бичәне үземнән башка кунакка җибәрергә кушмаган иде, — ди. — Ике кичкә генә дип әтисенә кунакка сорап китте дә алты кич кунып кайтты. «Өченче көн баланы җыештырдым. Бик нык чирләп үлгән иде», — диде. Мин, өчен укытыйк, дип әйттем,— ди.

Шулвакытта баланы күтәреп карчык килеп керә.

— Менә балаң тере. Күрдеңме инде, бичәм? — ди егет.

Кунаклар бу эшләргә хәйран калды, ди.

Шуннан соң егет ата сүзендә хикмәт барын белде, ата сүзен тотып яши башлаган иде, тормышы уңайга китте, ди.

АНА СҮЗЕ

Борын бер әби булган, ди. Аның өч улы булган. Бәләкәенә әйткән:

— Байлар белән куллашасың куллашуга. Агаларыңа якын бул, — дигән, ди.

Бу егет бай кешеләр белән бик дус, агаларына сыенып бармаган икән, ди. Шулай йөргән-йөргән дә, әнисенең әлеге сүзе исенә килеп төшкән. «Тукта әле, әнинең сүзен сынап карыйм, бу ничек булыр икән?» — диде, ди. Бер зур мичкә белән эчемлек әчетеп, киезгә ураган да базга төшергән. Шуннан бер дусына барган.

— Әйдә, дус, югарыдан уз.

— Югарыда йомыш юк. Мин бер эш белән килгән идем әле. Йомыш сорарга килгән бер кешегә суккан идем — үлде дә куйды. Шуннан, кайда барырга белми, сина килдем әле. Ни киңәш итәрсең икән? — ди.

— А-ай, дус. Юк-юк, булмый. Андый эшкә ничек итеп кысылыйм мин, — дип чыгарып җибәрә.

Егет, ярар, дип күңеленә салып куя да инде икенче дусына бара.

— Һәй, дус килә. Әйдә югарыдан, әйдә югарыдан, — дип бай дусы өзелеп тора, ди.

— Юк, югарыда йомыш юк. Мин бик зур эш белән килгән идем әле.

— Ни йомыш, дустым, әйт.

— Анавы ни, йомышка килгән берәү белән бәйләнешеп китеп, сугып та җибәрдем, үлеп тә китте. Шуны кайда куярга белми килдем сиңа.

— А-ай, юк, иптәш, юк, булмый.

Аннан чыккач: «Әни сүзе шул булдымы икән», — дип уйлап торган да барган кече агасына.

— Җиңгә, агаем өйдәме?

— Өйдә.

— Һай, энем, бер дә килми идең. Ничек килеп чыктың? — дип килеп күрешә агасы.

— Сиңа йомыш төшеп тора әле, агай.

— Соң, ни йомыш?

— Мин, агай, шулай-шулай бик начар эш эшләп ташладым бит әле, — дип дусына сөйләгәнне сөйләп биргән.

— Кайда ул, әйдә барыйк, тукта, мин киенеп алыйм да. — Шуннан урамга чыкканнар.

— Олы агайга да әйтмикме?

— Әйтик, әйтик. Икебездән генә эш чыкмас, өчәүләп киңәшләшкәнгә җитмәс.

Олы агаларына килеп керәләр.

— Әйдә әле, агай, безнең белән. Минем шулай-шулай эш булды бит әле, — ди.

— Соң, дусларыңа бармадыңмыни?

— Юк, агай. Берсе дә килми.

— Алай булса, әйдә тизрәк. Кешегә сөйләп кенә бетмәсәң ярар иде.

— Юк, юк, әйтмәгән идем әле.

Килгәннәр егетнең йортына. Кече агасын төшереп җибәрә базга.

— Минем хәлдән килмәс. Әйдә әле, олы агай, син дә төш.

— Үзең дә төш.

— Юк, мин карап кына торыйм.

Болар караңгыда сәрмәнеп эзлиләр-эзлиләр. Берни дә юк.

— Монда берни дә юк лабаса. Монда бөгәрләнеп кенә озынча бернәрсә ята ятуга.

— Җан биралмый бөгәрләнгәндер. Чыгарыгыз инде тизрәк. — Тегеләр күтәреп алып чыкса, энеләре яраштырып куйган сый-хөрмәт булган.

Тегеләр баз астыннан чыккач, утырып торып елаган егет.

— Минә әниемнең сүзе шул икән. Әнием сүзе хак икән: дус дип йөргәнең шулай була икән, үз агаларың болай була икән, — дигән, ди.

ПАТША САЙЛАУ

Әүвәл синең белән мин яшәгән җирдә, бабай белән әби булып, шулардан өч ул туган, ди. Ай артыннан ел үтеп, малайлар егет булып үсеп җиттеләр, ди. Өч улның да өйләнәсе килде, ди. Тик, аталары ярлы булганга, болар өйләнә алмый яшәделәр, ди.

Ул заманда калымны бик күп сораганнар.

Берчак боларның патшалары үлеп киткән. Патшаның бер улы да калмагач, аның бердәнбер кызына патша сайларга кушканнар. Бу кыз бик матур булган. Күргән берәүнең аңа күзе төшкән, ди. Кыз үзенә кияү, илгә патша булыр кешене иң йөрәклеләрдән сайларга карар иткән. Килә икән, ди, аңа күрше патшалар, шаһзадәләр килә, ди. Килгән берсе исән кайтмый, ди. Патша булам, кияү булам дигән кешене тәүге кичтә бер ялгызын бер бүлмәгә йокларга салалар икән. Төн җитте исә, аңа төрле убырлар, мәскәйләр, албастылар сурәтенә кереп, үлгән патша күренә икән. Шуннан кияү булыр егет коты очып үлә дә куя икән. Шул рәвешле бик озак патша сайлый алмый йончыганнар, ди.

Бабайның өч улы да бу бәхетне сынап карарга булган. Тәүдә олы улы киткән, ди. Аны патша кызы ягымлы гына каршы алган, сыйлаган, соңыннан йокы бүлмәсенә озаткан, ди. Төн уртасы җиткәч, нәрсәдер дөберди башлады, ди. Кинәт ишек ачылып китте дә, ди, ниндидер ут акрын гына килә башлады, ди. Куркуыннан олы улның йөрәге ярылды, ди. Олы улы кайтмагач:

— Ни булса да булыр, — дип уртанчы ул китте, ди.

Аны да патша кызы ягымлы гына каршы алды, ди, ашатты-эчерде дә йокы бүлмәсенә озатты, ди. Төн уртасы җиткән иде, тагы нидер дөберди башлады, ди. Егет курыкмас өчен, колагына мамык тыкты, ди. Капыл ишек ачылып китеп, ниндидер ут якынлаша башлады, ди. Егет дер калтырый башлады, ди. Ул, эсселе-суыклы булып китеп, салкын тиргә күмелде, ди. Бүлмәгә тагы ниндидер

сөмсез җан килеп керде, ди. Ул караваткa килде дә егетнең юрганын тартып ала башлады, ди. Егет тәмам агарынды, күзләре маңгаена менде, ди. Котсыз җан егетнең аяк очын ялап алуы булды, ди, егет «а-а-а!» дип кычкырып җибәрде дә һушын югалтты, ди. Кемдер шуннан кереп, аның муенын буды, ди.

Иртәгәсен әй көтәләр, ди, өйдә егетне этиләре, әй көтәләр, ди. Егет кайтмады, ди. Инде кече улга чират килеп җитте, ди. Әти-әнисе нитиклем генә җибәрмәскә тырышып караса да, егет, аларның ай-ваена карамый, китте, ди, чыгып.

Кече ул бик матур булган. Аны күреп патша кызы таң калды, ди. Бик озак кыймады, ди, моны сынарга. Сынамас иде — кияү кирәк, илгә патша кирәк. Ахырда йокы бүлмәсенә озатты, ди, моны да. Баягыча төн уртасы җиткән иде, нидер дөбер-шатыр килә башлады, ди. Егет куркырга уйламый да, ди, ичмасам. Җырлап торып җибәрде, ди, кычкырып торып озын көйгә салдырып, тыштан килгән тавыш та тынып калгандай булды, ди. Шуннан тагы дөберди, шатырдый башлады, ди. Ишек ачылып китте, ди. Ниндидер ут килеп керде дә акрын гына егет янына килә башлады, ди. Егетнең гаҗәпләнүдән авызы ачылды, ди. Ятагыннан төште дә, егет чакматашын чагып, ут яндырып караса, өстенә май шәме утыртылган бер ташбаканың әкрен генә килгәнен күрде, ди. Ташбаканы шунда утырган бер сандыкка салып бикләде дә, май шәмен баш астына куеп, менеп ятты, ди, тагы. Шул арада бүлмәгә бер сөмсез җан нясе килеп керде дә егетнең юрганын тарта башлады, ди. Егет ыргып торып сәрмәсә, ниндидер мөгез тотып алды, ди. Капшабрак караса, бу сөмсез җан кәҗә булып чыкты, ди. Бу юлы ишектән түбә тактасына тиярдәй булып бик озын, кеше сынлы, яман куркыныч, ап-ак бернәрсә килеп керде, ди. Ак шәүлә үзе туктаусыз үкерә, ди. Егет чөйдән бүреген алды да ак шәүләнең башына бәрде дә җибәрде, ди. Шәүлә кинәт кенә икәүләнеп, яртысы идәнгә барып төште, ди. Егет чакма

чагып, ут кабызса, идәндә таякка эленгән ак чүпрәк белән елмаеп торган сылу патша кызыннан башка берни дә күрмәде, ди. Егет аптырап торган мәлдә, патша кызы йөгереп килде дә муенына сарылды, ди.

— Һай-һай, егет. Үзең дә йөрәкле икәнсең. Бүгеннән башлап мин дә синеке, ил дә синеке, — диде, ди.

Шуннан болар өч көн, өч төн туй үткәрделәр, ди. Бабай белән әбине дә барып китерделәр, ди. Әле булса да дөнья көтеп, йон тетеп, әйбәт кенә патшалык итеп, яшәп яталар, ди.

Менә ничек ул! Һәрчак шулай йөрәкле булырга кирәк!

ФӘКЫЙРЬ КИЯҮ

Борын-борын заманда бер егет белән кыз бер-берсен бик яратып йөргәннәр, ди. Тик егет ярлы икән, кыз бер байның бердәнбер кызы булган. Егет кызга:

— Сине урлап алам. Әйдә, качып кушылыйк, — ди икән.

Кыз:

— Юк, без алай итмик. Син әтигә кил, ул нәрсә әйтер, — дигән.

Егет кызның әти-әнисенә килгән, үзенең кызны яратканлыгын әйткән, кызны үзенә кәләш итеп алырга уйлавын белдергән. Тегеләр егеттән көлмәкче булганнар. Бабай:

— Ярый, икенче тапкыр килерсең. Тик килгәнеңдә ат белән дә килмә, җәяү дә килмә, юл белән дә килмә, юлсыз да килмә, — дигән.

Егет икенче тапкыр аларга килергә чыккан. Ул сыер

җигеп алган да, ди, бер дә юлдан килми икән, тик көрт ярып килгән. Килгән, ди, бу кызның өенә. Бабай тагы да егеттән көләргә уйлаган.

— Менә минем бер дә якмаган ташландык өем бар. Син бүгенгә шунда йокла. Әгәр дә туңып үлмәсәң, кызны алырсың, — дигән, ди.

Егет бу өйгә кергән. Өй эт бәйләсәң дә тормаслык салкын икән, егетнең өстендә юньле бернәрсә дә булмаган. Бу өши башлый. Өшегәч, егет шушы өйдә торган зур таш бүкәнне ишек төбеннән түргә, түрдән ишек төбенә күтәреп йөри башлаган. Шулай йөри торгач, тирләп чыга. Йокларга яткан, ди, бу. Төнлә өшеп китсә, шулай таш бүкәнне бер урыннан икенче урынга күчереп җылына да тагы йокларга ята икән.

Таң ата. Егетнең исән-сау икәнен күргәч, кызының аталары аны соңгы тапкыр сынап карамакчы булалар. Бабай әйтә, ди:

— Минем әби икмәк пешерә. Син мичтән чыккан бер икмәкне эссе көе вак кына итеп тураклап тор.

— Ярый, — дигән дә егет өйгә кергән.

Әби мичтән чыгарган бөтен икмәкне тураклап бетте, ди, бу.

Бабай белән әби:

— Ярый, дөнья көтәрлек кеше икәнсең, — дип кызларын ярлы егеткә биргәннәр, ди.

КЫЗ СЕРЕ

Борын-борын заманда яшәгән, ди, бер карт. Аның исәр генә улы булган. Әтисе картайгач, эшләргә кеше булма-

ганлыктан, алар ач яшәргә мәҗбүр булганнар. Әтисе бер көн улын чакырып алган да:

— Улым, син шәһәргә барып, эш эзләп кил, ачтан үләргә ярамый бит, — дигән.

Исәр улы шәһәргә киткән. Шәһәргә барып җиткәч, бер бай йортка керә. Капкасы биек. Тимер. Ишек алды әйбәт. Бакчалы. Бакча эчендә бай үзенең хатыны белән чәй эчеп утыра, ди. Аларның янында йомышчылары чебен куып торалар, ди. Егет чәй эчеп беткәннәрен көтеп тора да байдан эш сорый. Бай чучка көтәргә куша.

Егет чучка көтә башлый. Ул өч чучканың берсен биергә, берсен уйнарга, берсен җырларга өйрәтә. Ял иткән чакта чучкаларын биеткән, уйнаткан, шулай итеп күңел ачкан.

Бервакыт егет янына бер бик матур кыз килеп чыккан. Кыз егетнең чучкаларын биетеп, уйнатып, җырлатып утыруын карап торган да бер чучкасын сораган. Егет бирмәгәч, ул болай дигән:

— Минем чәч арамда бер серем бар, шуны тапсаң, чучкаңны алмыйм, тапмасаң, берсен алам, — дигән.

Егет серне тапмаган. Кыз бер чучканы алып киткән.

Бераз вакыт үткәч, алтын көймәгә утырып, әлеге кыз тагы килә, тагы бер чучканы алып китә. Өченче килгәндә дә егет кызның серен тапмый. Кыз өченче чучканы алам дисә, егет байның, өченче чучканы да югалтсаң, тереләй тиреңне тунармын дигән сүзен хәтерләп, чучканы бирми. Егет бирмәгәч, кыз үз серен үзе әйтә дә чучканы ала. Егет, байдан куркып, качып кайтып китә. Әтисенә:

— Бай акча бирмәде, — ди.

Бервакыт кызның әтисе олы туй ясарга була.

— Кем дә кем кызымның серен таба, шул аның кияве була, — дип тирә-якка хәбәр тарата. Туйда байлар кыз серен эзләргә, ярлылар карап кына торырга тиеш була. Кызның янында өч чучка да бар, ди. Дөрес әйтмәгән кешеләрнең шунда ук башын кискәннәр. Төрлечә әйтеп бетәләр: имеш, кызның аяк астында чокыры бар, яки ул

баскан җирдә чишмә чыга. Берсе дә дөрес булмый. Шулчак әлеге фәкыйрь егет үзенең кыз серен табарга теләвен әйтә. Әйтсә дә, аны җибәрмиләр. Егет кат-кат үтенгәч кенә рөхсәт итәләр. Егет кызның чәче арасыннан ике алтын чәч таба. Барсы да гаҗәпләнәләр. Ярлылар шатлана. Тик бай кызын ярлыга бирергә теләми, егетләрне тезеп утырта да:

— Кыз кем янына барса, шуңа бирәм, — ди.

Кыз килә дә ярлы егеткә хушбуйлар, байларга теләсә нәрсә сибеп китә. Байның һаман бирәсе килми.

— Кем әйбәт бии, кызны шуңа бирәм, — ди.

Бай малае биергә төшсә, әлеге биюче чучка аның киемен сыпыра да ала. Ярлы егет биергә төшкәч, бер чучка биеп китте, икенчесе җырлап, өченчесе уйнап җибәрде, ди.

Бай кызын ярлы егеткә бирергә риза булды, ди.

БАЛКАНТАЗ

Борын бер бабай белән бер әби булган. Берзаман әбинең бер малае туган. Аңа Балкантаз дип исем кушканнар. Озак та тормый, бабай үлеп киткән. Малайны әнисе тәрбияләп үстергән. Тора биргәч, ул да үлгән. Үксез ятим калган Балкантаз. Шуннан беркөн өен сатып, чыгып киткән, ди, бу, эш эзләп. Арыган, талган, ачыккан, хәле беткән малайның. Бер зур шәһәр читенә җиткәч, хәл җыярга утырган. Утыра торгач, бер бабай килеп чыккан:

— Әссәламегаләйкүм. Нишләп утырасың? — дигән.

— Вәгаләйкүмәссәлам! Талчыктым. Шуңа хәл җыеп утырам. Ерактан килдем. Эш эзләп йөрим. Берәр патша

хезмәткә алмасмы икән дип, Мәк шәһәренә китеп барам, — дигән Балкантаз.

— Алай булгач, мин сине малайлыкка алам. Минем алты улым, җиде киленем, бер кызым бар. Оланнарым көллесе дә аучы, гел ауга йөриләр. Син куй күтәрсең, кичен минем шул бердәнбер кызымны каравылларсың, — ди теге карт.

Егет, риза булып, теге бабай белән китә. Бу бабай патша булып чыга. Алты улы да, чынлап, аучылар икән. Ак киекләрне, күк бүреләрне сугып алып йөриләр, ди. Иң олысының ике бичәсе бар икән. Оланнарыннан патша берни дә эш эшләтми икән.

Хезмәтче егет бик әрсез булып чыга, армый-талмый эшли, ди. Патша моңа бик куана.

Бермәл оланнары аудан бик уңып кайталар. Кайталар да әтиләреннән сорап куялар:

— Әти! — диләр, — без уңганмы, әллә хезмәтче малаең уңганмы? — диләр.

— Сез уңган. Сездән бигрәк хезмәтче малаем уңган: кичен йорт тирәсендә бер аяк тавышы ишетелми, көндез куйлар туеп кайта, — дип Балкантазны мактаган, ди, патша. Кече улы әтисенә әйтә:

— Әти, — ди, — безнең бер солдат сеңлекәшне сората, күзе төшкән, — ди.

— Кызымны беркемгә дә болай гына бирмим. Табышмак әйттертәм, кем дә кем табышмакка җавап таба, шуңа бирәм, тапмаса, башын кистерәм, — ди патша.

— Алай ярамый, әти, бер дә юкка, затлы кешеләр алар. Бернисез берәр кеше табышмагыңны табар да сеңлекәшне алыр, — дип уеннан кире күндерергә итә тегеләр.

Патша күнми:

— Кешем күп. Үлсә үләрләр. Йортка өч йөз егет чакырам, табышмак әйтсеннәр, таба алмасалар, өч йөзенең дә башын кистерәм, — дип үз сүзен куәтли.

— Кешене бушка, юкка кырасың, — дип оланнары ачуланып чыгып китәләр.

Бу чакта олы җиңгәнең бер энесе кунакка килгән була, уртанчы жиңгәнең энесе патша гаскәренә солдатка алына (болары патшаның яшь кодалары була инде). Хәзер патша өч йөз кешене чакырта, арасында әлеге ике кодасы да була. Берәмләп кертеп табышмак әйттерә башлый. Табышмакның җавабын берсе дә табалмый. Солдатлар боларның башларын кисеп бәреп кенә торалар, ди. Ике коданы да үтереп, тупсага сузып салалар. Җиңгәләр килеп керә. Ни күрәләр — энеләре үлгән. Олы килене патшага:

— Син минем энемне үтердең. Мактаулы кызыңны көтүчеңә бирдереп, хур итмәсәмме!.. — дип өстәл сугып чыгып китте, ди.

Шул чыгуында ук Балкантазны чакырып хәбәр җибәрә. Аны шул сәгатьтә китереп тә җиткерәләр. Теге хатын аулакта гына Балкантазга эшнең нидә икәнен төшендерә. Шуннан патша йортына алып бара. Йортка кайткач, Балкантаз хәйран кала.

— Җиңгә, бу нинди корбаннар?! Сугыш булдымы әллә? — дип агарынып китә.

— Әлеге шул табышмакларны таба алмаганга, патша үтертеп бетерде. Бар әле, син дә кереп чык! — ди.

— Оялам бит әле бу алама кием белән, — ди Балкантаз.

— Оялма. Кер дә, алама киеменне салмый-нитми, идән уртасына утыр, — дип патша килене һаман көчләшә.

Балкантаз керде ди. Кызны күрде, ди. Кызны күргән иде — утыра төште, ди. Кыз шултиклем матур, таз, сүз әйтә алмый, авызын ачып тик утыра, ди. Кыз әйтә:

— Балкантаз, чыгып чишен дә, кереп, минем табышмагымны тап. Тапсаң, сиңа барам! — ди, үзе көлә.

Балкантаз елдам гына чыгып китеп, чишенептереп керә. Кыз эти-энисе белән килеп рәхәтләнеп көлә, ди.

— Менәмен дигән солдатлар алалмады, бу бахыр да

үлемен эзләп килгәндер инде. Утыр утыргычка! — диләр.

Балкантаз бүкәнгә утыра.

Шуннан, ни, кыз тотына табышмак әйтергә, Балкантаз җавап бирергә.

— Агач башы алт(ы) аер(ы) —
Ул ни булыр, Балкантаз?
— Агач башы алт(ы) аер(ы) —
Алт(ы) агаең түгелме?

Исе китеп патша тәхетеннән егылып төште, әнисе һаман утыра, ди, әле.

— Җикән төбе җид(е) аер(ы) —
Ул ни булыр, Балкантаз?
— Җикән төбе жид(е) аер(ы) —
Җиде җиңгәң түгелме?

Шулай дигән иде — әнисе егылып төште, ди. Хурланып-гарьләнеп, кыз һаман утыра, ди, тазны җиңәренә ышанып.

— Ике кавын нык симез —
Ул ни булыр, Балкантаз?
— Ике кавын нык симез —
Ик(е) имчәгең түгелме?
— Түгәрәк күлдә эт өрә —
Ул ни булыр, Балкантаз?
— Түгәрәк күлдә эт өргән —
*Балкан аерык * түгелме?*
— Ялан җирдә ут яна —
Ул ни булыр, Балкантаз?
— Ялан җирдә ут янган —
Бүре күзе түгелме?

---

* *Аерык* — ялгыз зат(ырусыз мәгънәсендә).

Кыз бик гарьләнә, хурлыкка түзә алмастай булып та китә. Ни хәл итсен, хәл юк, тагы такмаклый:

— Син таз белән булганчы,
Бу хурлыкны күргәнче,
Күк чабак мин булыйм,
Дәрьяга кереп чумыйм!
— Күк чабак та син булсаң,
Күк чуртан мин булырым,
Дәрьядан тотып алырым!
— Син таз белән булганчы,
Бу хурлыкны күргәнче,
Ак чабак мин булыйм,
Диңгезгә төшеп чумыйм.
— Ак чабак та син булсаң,
Ак чуртан мин булырым,
Диңгездән тотып алырым!
— Син таз белән булганчы,
Бу хурлыкка түзгәнче,
Күк күгәрчен мин булып
Күккә менеп китәрем.
— Күк күгәрчен син булсаң,
Күк карчыга булырым,
Күктән тибеп алырым.
— Син таз белән булганчы,
Бу хурлыкны күргәнче,
Ак күгәрчен мин булып
Һавага менеп китәрем.
— Ак күгәрчен син булсаң,
Ак карчыга мин булып,
Һавадан тибеп алырым.
— Син таз белән булганчы,
Бу хурлыкны күргәнче,
Ак карчыга мин булып,
Болытка кереп китәрем.

— Ак карчыга син булсаң,
Ак бөркеткәй мин булып
Болыттан тибеп алырым!

Шулчак кызның олы җиңгәсе килеп керә (нишлиләр икән, дип кергән инде белергә). Кыз җиңгәсенә карап такмаклый:

— Әйрән бирче бу тазга,
Әйләнеп чыгып китсәче!

Таз тагы җавапсыз калмаган:

— Әйрән бирсәң, әчәрем,
Әйләнеп сине кочарым!
— Корыт бирче бу тазга,
Корышып чыгып китсәче!
— Корыт бирсәң, әчәрем,
Корышып сине кочарым!
— Өйрә бирче бу тазга,
Өерелеп чыгып китсәче!
— Өйрә бирсәң, әчәрем,
Өерелеп сине кочарым, —

ди дә Балкантаз җиңгә белән чыгып китә.

Абыйлары, аудан кайткач, шулхәтле корбанны күреп, хәйран калалар. Хатыннарыннан сорашып, хәлне белгәч:

— Нишләп кермәдегез инде, нигә туктатмадыгыз? — дип үпкәләгәннәр.

— Ничек керәсең анда, курыкмый? Сез үзегез юри качтыгыз. Белә торып нигә качтыгыз? — дип бичәләре чыр-чу килеп елашып алалар.

— Сылуыгызны* хәзер Балкантазга бирәбез. Каенатамның шартын шул гына үтәп чыга алды: сылуыгызның

* *Сылу* — сеңел.

бөтен табышмакларына җавап тапты, — дип хәбәр салган иделәр, кече егет ыргып килеп торды, ди. Килеп торды да:

— Әтием кайда? Кайда әнием? Алар нәрсә карап утырды? Сылуыбыз нишли? — дип кычкырып ук җибәрде, ди.

— Әти-әниең исе китеп ята, хурлыгына чыдый алмый. Сылуың ни, нишләсен? Утыра инде хәзер, әллә нинди карулгә барам дип.

Кече абыйсы, ярсып, кылыч тотып, йортка кереп китте дә, ди, җилтерәтеп, сылуын китереп чыгарды, ди.

— Башын чабып өзәм.

Абыйлары, җиңгәләре кызны чак алып калалар.

— Ул үзе теләп алган, табышмагына җавап табучыдан башка берәүгә дә бармыйм, дип. Үтермә! — диләр.

Әти-әниләрен торгызалар, дару иснәтеп аңнарына китерәләр. Кыз инде күзен-башын сыйпап, җаны әчеп утыра.

Патша үлекләрне күмәргә әмер бирә. Зур чокыр казытып, бөтен мәетләрне бер җиргә аударта. Башларын гел бер якка салдырып, иң өстенә ике кодасын салып күмдерә.

Кызның олы җиңгәсе белән олы абыйсы киңәш кора: кызны Балкантазга тизрәк кушарга. Алты җиңгәсе кызны алып китә бер ташландык аранга, Балкантазга кушарга. Абыйлары китә качып, кешедән оялып. Йортка кереп бикләнәләр. Патша утыра аптырап.

— Бичә, нишлик инде?

— Балкантазны укытыйк, патша булырлык итеп. Укытучы тап, — ди бичәсе.

Абыйлары сорый:

— Туйлыкка нәрсә бирәсез?

— Мең баш ат алыгыз.

— Юк! Егерме биш яшьлек үгез суеп ашатыгыз, — дип гарьләндереп чыгып китә абыйлары.

Патша җир астына укытучы эзләп чыгып китәргә булды, ди. Бичәсенә:

— Бикләрсен, ачкычны үзең ал, берәүгә дә бирмә! — ди.

Бераз вакыт үткәч, оланнары сораша әнисеннән:

— Әти кайда?

— Укытучы эзләп китте. Патша итәр өчен Балкантаз кияүне кырык ел укытабыз.

— Таралышып китеп бетик, — ди оланнарның берсе. Икенчесе әйтә:

— Мәк шәһәре зур шәһәр, китәсе килми бит әле...

Кечесе әйтә:

— Нигә анда китәргә! Үзен (патшаны әйтә инде) үтердек — тыктык!

Патша, әҗерен кайтаруга сөйләшеп, яшь укытучы табып алып кайта. Хәзер кызны да, тазны да җир астына төшерергә булалар.

Таз сорый:

— Нишләтәсең безне? Нишләп хәзер мин начарга калдым?

— Юк-юк! Сине патша итәргә укытам.

— Ярар, патша тоткан каләмне без дә тотарбыз! — дип кыз иң тәүдә төшә аска. Ә Балкантаз карулаша, ди.

— Һава алышынмый бит, монда ничек итеп яшәрбез, үрчеп, ишәеп китәрбез, бала-чага булыр лабаса?

Патша:

— Җир астында матур-матур уку йортлары бар, — дип алдатып, тегеләрне җир астына төшереп бикләп, төнлә үзе кайтып китә. Кайтып килеп ятканда, олы улы, сагалап торып, ата да ега моны.

Балкантаз кәләше белән кырык ел укыганның соңында, чыгып, каенатасы урынына патша булып утырды, ди.

ҚАШИКАРИП БЕЛӘН МАҺИМӨҺЕР

Борын-борын заманда бер әби булган, ди. Аның Қашикарип исемле улы да янә бер кызы булган. Алар бик ярлы яшәгәннәр, ди.

Қашикарип бер ярлы гына кешенең Маһимөһер исемле кызына гашыйк булган. Аларның арасына бай малае төшә икән. Маһимөһерне ул үзенә кәләшлеккә алмакчы итә, ди.

Бердәнбер көнне Қашикарип, акча эшләп кайтырга дип, шәһәргә эшкә китәргә уйлый. Бай малае да аның белән бергә бара. Алар, икесенә бер ат алып, озын юлга чыгып китәләр. Баралар, баралар, бер зур елгага очрыйлар. Елганы ничек аша чыгарга, дип торганда, бай малае Қашикарипкә:

— Син, чишенеп, алдан йөзеп чык, мин синең артыңнан, киемеңне алып, ат белән йөзеп чыгармын, — ди.

Қашикарип, аны-моны уйлап тормый, йөзеп чыга да китә. Бай малае Қашикарипнең киемен алып, чабып кайтып китә.

Қашикарип, ояла-ояла, якындагы бер бәләкәй авылга барып җитә дә читтәге бер өйгә керә. Анда бер ир кеше утыра икән. Қашикарип үзенең кайгысын сөйләп бирә. Аны киендереп, ашатып шәһәргә озаталар. Қашикарип шәһәрдә эшкә урнаша: бер сәүдәгәрнең кибетендә сату итә.

Бу сәүдәгәр, авылдан-авылга йөреп, товар саткан була. Бервакыт ул Қашикарипләр авылында була. Маһимөһер сәүдәгәрнең Қашикарип эшләгән шәһәрдән икәнен белгәч, аңа бер поднос бирә дә:

— Шушыны кибеткә куй, килеп хакын сораган кешегә минем хакта сөйләрсең, — ди.

Сәүдәгәр подносны алып кайтып, кибеткә куя. Қашикарип, таныш подносны күреп, сораша башлый.

— Сине бүген үк кайтырга кушты Маһимөһерең, аны бай баласына кушалар, — ди тегесе.

Кашикарип җәяүләп юлга чыга. Бара торгач, кич була башлый. Бер тау янына җиткәч, ул, бүген барыбер кайтып җитеп булмый, ни эшләсәм дә, соңга калырмын, дип, тауга менә. Кыядан ташланырга уйлый. Шулай аска карап торса, анда бер күк атлы кеше:

— Егет, нишлисең анда? — ди.

— Үләсем килә, — ди Кашикарип.

— Алайса, кил, үзем үтерәм, — ди теге кеше.

Кашикарип таудан төшә дә теге кешегә хәлен сөйләп бирә.

— Әйдә, сине хәзер үк авылыңа илтеп куям, — ди теге кеше. — Күзеңне йом, — ди.

Кашикарип, атка менеп, күзен йомып утыра. Алар күк тулпар белән очыртып китәләр.

Теге кеше бер авылга барып төшерә дә:

— Күзеңне ач, авылың шушымы? — дип сорый.

— Юк, — ди Кашикарип.

Алар тагы очыртып китәләр. Баралар, баралар, тагы бер авылга барып төшәләр.

— Күзеңне ач, авылың шушымы? — ди теге кеше.

— Әйе, тик минем бер көндә кайтуыма ышанмаслар, берәр һөнәргә өйрәт әле, — ди Кашикарип.

Теге кеше ат тоягы астыннан бер уч туфрак алып бирә:

— Бу туфракны җиде ел сукыр булып утырган кешенең күзенә сөртсәң, күзе ачылыр, — ди.

Кашикарип теге кешегә рәхмәтләр укып торып кала.

— Мине өегезгә кертегез әле, йоклап кына чыгыйм, — дип әнисенең өенә керә.

— Кертмим. Үзем менә җиде ел сукырмын. Балам читкә киткәнгә елап, сукыр булдым, — ди әнисе.

Шулчак кызы әнисенә:

— Керсен, бәлки, абыемдыр, — ди.

Әнисе:

— Куй, юкны сөйләмә, үлгән кеше кире кайтамы? — ди.

Кызы ялынгач, әнисе риза була. Кашикарип керә, чишенеп үз хәлләрен сөйли башлый, кем икәнен белдертми. Шулчак күзе курайга төшә.

— Әбекәй, рөхсәт итсәгез, курайда уйнар идем, — ди.

— Куй, балам, газиз баламның истәлеге ул, төсе итеп саклыйм, — ди әнисе.

Егет үз сүзендә тора. Ялына торгач, курайны ала.

— Монда уйнама, энә, байларда туй бара, шунда барып уйна, — ди карчык.

Егет, куанып, курайны кулына тотып, туй барган өйгә китә. Рөхсәт сорап керә. Аны ишек төбендәге зур сандык өстенә генә утыртып куялар. Егет моңландырып курайда уйный башлый.

— Кем син? — дип сорыйлар аннан.

Кашикарип исемен үзгәртеп әйтә. Үзе күргәннәрне, башыннан үткәннәрне дөрес итеп сөйләп бирә. Сөйли торгач, үзенең Кашикарип икәнлеген таныта. Туйдагы кешеләр ышанмыйлар.

— Ышанмасагыз, җиде ел сукыр утырган бер кешене алып килегез, шуның күзен ачам, — ди.

Сеңлесе моны ишетеп, йөгереп кайтып, әнисен алып килә. Кашикарип аның күзенә теге туфракны сөртә. Шунда ук карчыкның күзе ачыла. Ул, алдында торган улын танып:

— Балам! — дип кочаклап ала.

Кашикарипнең кайтканын ишетеп, Маһимөһер дә йөгереп килеп җитә, Кашикарипне кочаклап ала. Туйдагылар аптырашта калалар. Бай малае нишләргә белми. Кылыч алып, Кашикарип белән Маһимөһерне үтерәм, дип килгәндә, Кашикарип калган туфракны тегенең күзенә сибә. Бай малае шунда ук сукырая. Кашикарип, Маһимөһерне, әнисен, сеңелесен алып кайтып, кураен уйнап, туйны үз өендә дәвам иткән, ди.

БУЙДАК ПАТШАНЫҢ ТӨШТӘ ГАШЫЙК БУЛГАНЫ, ӨНДӘ КӘЛӘШ АЛГАНЫ

Элек буйдак бер патша яшәгән, ди. Вәзире гел генә аннан калмый, янында булыр булган, теләгән вакытта, сорап-нитеп тормастан, патша янына кереп-чыгып йөри алган. Бервакыт вәзир патшасы йоклап яткан мәлдә килеп керә. Шул мәлдә генә патша төш күреп яткан була. Вәзире килеп кергәч, уяна да патша, иргып торып, кылычына ябыша, тегене чапкалап ташларга уйлый. Шулчак вәзир:

— Сабыр ит, патшам, чапмый тор, азак чабарсың! — дип әйтеп өлгерә.

Патша кылычын төшереп, уйланып торган да:

— Ярар. Хаталык миндә. Әле мин төшемдә бик сылу кыз күреп ята идем. Гомер андый кыз очраткан юк иде. Ни чара кылып карарга икән инде хәзер, кайдан, ничек итеп кенә табарга икән шул кызны? — дигән.

— Ни кыяфәтлерәк иде? Шуны гына әйтеп бир миңа. Ходай насыйп иткән булса, мин аны табармын, — диде, ди, вәзир.

Патша, кызны ничек итеп күргән, шулай сөйләп бирә. Вәзире кәгазьгә язып ала да, шуның буенча кызның сурәтен төшереп, юл чатына куя, ди. Икенче бер шәһәрдән килеп, үтеп баручы бер адәм сурәтне күреп:

— Сөбханалла, безнең шәһәр патшасының кызы лабаса. Кем эше булыр икән бу? — дип хәйран калды, ди, кызның кем булуын сөйләп бирде, ди.

— Бервакыт елга ярындагы бакчада утырганда, янгын башланып китә. Бакчада тутыйкошлар яшәгән, ди. Балаларын коткарам дип, инә тутыйкош утта янып үлде, ата тутыйкош балаларын уйлап та бирмәде, уттан качып, очып китте дә барды, ди. Шул хәлне күргәч, патша кызы, ирләр мәрхәмәтсез булалар икән, дип кияүгә бармаска тәүбә итә. Шуннан алып әлеге вакытта да кыз көе утыра, ди.

Шуны ишеткәч, вәзир:

— Мине шул шәһәргә җибәр әле, табып алып кайтыйм шул кызны, — дип патшадан рөхсәт сорады, ди.

Патша вәзирен сәфәргә озата.

Тегендә барып җиткәч, төрле буяулар белән өй эчләрен бизәп, вәзир үзенең һөнәрен күрсәтә башлый. Патша кызы ишетеп кала да әтисенә:

— Безнең шәһәргә бер оста килгән, ди. Өй эчен бик матур итеп бизи, ди. Мин яшәгән өйне дә бизәтеп алганда инде, — дип әйтте, ди.

Әтисе вәзирне табып китереп, кызы яшәгән йортны бизәтергә әмер бирә.

Вәзир кызның өен җилле генә итеп буйый. Анда үзенең патшасының сурәте дә, балалары белән инә ишәк, ата ишәк тә төшерелгән була. Бакчага сибәргә су ташыганда, ишәк балалары ага да китә. Аларны коткарам дигәндә, ата ишәк үзе суга бата. Инә ишәкнең балаларында эше дә юк, ди, печән ашарга киткән дә барган, ди.

— Аңладыңмы, сурәтләр ни сөйли? — дип сорый вәзир кыздан.

— Юк, аңлашылып җитми, — ди кыз.

— Әләйсәң, болай ул, бу ишәкләрне күргәч, безнең патшабыз хатын-кыз халкыннан һич кенә дә мәрхәмәт өмет итәрлек түгел икән ул, дип кәләш алмаска булды, — дип аңлатып бирә вәзир.

Шуннан кыз:

— Мин, ирләрдә чак кына да мәрхәмәт юк, дип йөрсәм әле, хатыннар да мәрхәмәтсез була икән. Шулай дип, ничәмә җирдән яучы килеп тә, кияүгә бармаган идем. Болай булгач, әти бирсә, тормышка чыкмый булмас, — дип салды, ди.

Шул сүзне ишетүе була, вәзир патшага: «Кызың тормышка чыгарга риза. Син аны безнең патшабызга бирмәссеңме икән?» — дип хәбәр җибәрә. Патша: «Алай булса, бик кулай», — дип җавап бирде, ди.

Вәзир кайтып, барсын да түкми-чәчми патшасына сөй-

ләп чыга. Бу хәбәрне патша бик хуш күрә дә вәзирнең үзен яучы итеп җибәрә. Кызның этисе моңа куанып бетә алмый.

— Соратуы чын булса, ул патшаны минем янга китерегез, — дип буйдак патшага кешеләрен җибәрә.

Алар барып, буйдак патшаны алып та киләләр. Патша аны:

— Киявем дә киявем, — дип өзелеп каршы ала да, шунда ук кызын биреп, никах укытып, зур туй ясадылар, ди.

ГАНИ СӘҮДӘГӘР БЕЛӘН ВӘЗИР

Борын заманда бер патшаның шәһәренә Гани исемле сәүдәгәр килгән, ди. Аның бик чибәр сеңлесе булган. Гани сәүдәгәр үзенең кибетендә патшаларга тәгаен һәртөрле маллар йөрткән.

Көннәрдән беркөнне патшаның кызы аның кибетеннән бер әйбер алган. Әйбер бик ошаган — патша Гани сәүдәгәргә үзенең кызын бирмәкче булган.

Бу патшаның якын күргән бер вәзире булган. Исеме Заһит иде, ди. Патша элек кызын Заһиткә бирергә вәгъдә иткән булган. «Патшаның кызын Гани сәүдәгәргә бирәләр» дигән хәбәр ишеткәч, Заһит патшага:

— Синең шәһәрдә торган Гани сәүдәгәр зиначы икән,— дип әйткән.

— Аны кайдан беләсең? — дип сораган, ди, патша.

— Мин аның карендәше белән зина кылдым. Анда Гани дә катнашты, — дигән, ди, вәзир.

Патша сәүдәгәрне чакыртып алып:

— Син шундый эшләр кыласың, имеш. Син минем шәһәремдә торма, хәзер үк чыгып кит, юкса үтерермен, — дигән.

— Әй, падишаһым, әгәр ул минем карендәшем белән зина кылган булса, әйтсен, карендәшемнең янбашында миңе бар, ул кайсы якта икән? Әгәр дә дөресен әйтсә, мине үтерерсең, ялган әйтсә, аны үтерерсең, — дигән, ди, Гани.

Патша Заһитне чакырып:

— Ганинең карендәшенең янбашында миңе бар икән, кайсы янбашында икәнен дөрес әйтсәң, Ганине үтерәм, ялган әйтсәң, сине үтерәм, — диде, ди.

Заһит бу сүзгә бик көйде, ди, сыраханәгә кереп, башын түбән салып, бик озак уйланып утырды, ди. Шул сәгатьтә бер карчык ишектән кереп, Заһиткә:

— Нигә болай кайгырып утырасың? — диде, ди.

— Әй, әби, эш шулай: Гали сәүдәгәр сеңлесенең янбашында миңе бар икән. Уң ягтамы, сул ягтамы — шуны белә алмыйм, шуңа хафаланам, — дигәч, әби:

— Син кайгырма, аны белүе бик ансат. Миңа ун алтын бирсәң, үзем белеп килермен, — диде, ди.

Карчык, хәерче булып киенеп, Гани сәүдәгәр йортына барган, тик Гани сәүдәгәрнең сеңлесе өйдә булмаган. Хезмәтче кызлар бу хәерчегә бәләкәй генә итеп икмәк биргәннәр, ди. Карчык бу икмәккә риза булмыйча:

— Нигә син миңа бу тиклем бәләкәй икмәк бирәсең? Бу икмәк Гани карендәшенең уң янбашындагы миңе хәтле дә юк бит, — диде, ди.

Хезмәтче моңа:

— Аның миңе уң янбашында түгел, сулында, — диде, ди.

Әби ашыгып кайтып, Заһиткә әйтте, ди. Заһит бик шатланып, әбигә рәхмәт әйтеп, патшага барып:

— Аның миңе сул янбашында, — дип әйтте, ди.

Ганине чакырып алып, бу турыда әйткәч, Гани:

— Заһит дөрес әйткән, — диде, ди. — Тик Заһитнең

сеңлем белән зина кылуы дөрес булса, сеңлемнең гәүһәр кашлы йөзеге бар, шуны китерсен, — диде, ди.

Патша Заһитне чакырып, бу сүзләрне аңа җиткерде, ди. Күп тә үтмәде, теге әби килеп тә керде, ди. Заһит аңа үзенең кайгысын сөйләп бирде, ди.

— Әгәр дә миңа йөз алтын бирсәң, йөзеген китереп бирәм, — диде, ди, әби. Заһит риза булды, ди.

Әби Гани сәүдәгәр өенә китте, ди. Ул барып кергәндә, Ганинең сеңлесе, йөзеген бер як читкә салып куеп, камыр басып тора иде, ди. Хәерчегә сәдака бирим, дип, икенче бүлмәгә чыккан арада, карчык йөзекне урлап чыгып та китте, ди.

Йөзекне Заһиткә биреп, йөз алтын алып, карчык өенә кайтып китте, ди.

Заһит йөзекне патшага алып барып бирде, ди. Патша Ганине чакыртып алып, йөзекне күрсәтте, ди. Гани йөзекне таныды, ди. Патша үзенең хезмәтчеләренә, халыкны мәйданга җыеп, таган асарга кушты, ди. Гани, һушы китеп, өенә кайтып егылды, ди. Моны күреп, сеңлесе дә һушыннан язды, ди.

Гани һушына килгәч, бөтен башыннан үткәннәрне сеңлесенә язып калдырды да, үзе мәйданга китте, ди. Сеңлесе язуны алып укыгач, аптырашта калды, ди. Тиз генә пар ат җиктереп, кыйммәтле әйберләр алып, Ганине аса торган мәйданга китте, ди. Юлда барганда, бер сыңар пирчәткә бәйләде, ди.

Ул барып җитүгә, мәйданга Ганине асарга китергәннәр, ди. Кыз, Ганинең язып калдыруы буенча, Заһитне таныды, ди. Заһитнең бугазыннан алып, патшага алып китте, ди. Кыз патшага:

— Менә шушы кеше минем сыңар пирчәткәмне урлады, — дип әйткән, ди. Заһит:

— Мин бу кызны тәү тапкыр күрәм, аны белмим, — диде, ди.

— Өч тапкыр ант ит! — диде, ди, патша.

Заһит өч тапкыр ант итте, ди. Шуннан соң гына кыз:

— Мин Ганинең сеңлесе булам, — дип әйтте, ди.

Патша моны ишетеп, Ганине таганнан төшерергә кушты, ди. Ә явыз вәзир Заһит үзе чокыган чокырга үзе төшеп һәлак булды, ди. Патша Ганигә кызын биреп, зур туй ясады, ди.

Ике-өч ел үткәч, патша үлеп китте, ди. Патша үлгәч, Гани патша булып калды, ди. Ике уллары булды, ди. Шат, рәхәт, бер кайгысыз торалар, ди.

УНИКЕ БИГЛЫЙ

Борын бер ир хатыны белән унөч ел бергә гомер иткән. Бервакыт җәй көне печәндә ятканда, унике биглый * килеп, моның куышын баскан, ди. Болар моның хатынын сораганнар. Унөч ел бергә торган хатынны биреп җибәрәсе килмәгән ирнең. Унике биглый хатынны тартып алып киткән дә барган. Ир кеше иртүк торып, үзенең этен ияртә дә эзләп китә. Эзләп бара торгач, урман эчендә таба тегеләрне. Моның хатынының алдында бер биглый ята. Хатын аның башын карап утыра икән, ди.

Ире килә дә хатынга:

— Кил әле, — дип ымлый.

Хатын алдында яткан биглыйны күрсәтә икән.

— Алдымда кеше бар, мин синең алдыңа бара алмыйм, анавында иптәшләре бар, — дип әйтергә итә икән, ди.

Ир түзми, теге биглыйга килеп ябыша. Биглый көчле

---

* *Биглый* — беглец — качкын.

була, ирне җиңеп алып бара. Ир хатыныннан ярдәм сорый.

— Ярдәм ит, хатын, — ди.

Хатын:

— Кайсыгыз җиңә, мин шуныкы, — дип, тик тора, ди.

Сугыш бик хәтәр бара. Тегесе бу ирне бөреп алып бара. Шуннан ир үзенең этенә кычкыра, эте килеп биглыйның балтырыннан ала. Икәүләп биглыйны үтерәләр. Шуннан хатынына әйтә ир:

— Ни өчен мине якламадың? — ди. — Бер төн эчендә боларга әвәрәләнеп тә киттеңме? — ди.

Хатын әйтә:

— Мин курыктым. Иптәшләре килереннән курыктым, — ди. Ире әйтә:

— Мин бит тәүдә аларын бетердем, — ди.

— Алдама, — дип хатыны ышанмый, ди. Ире канлы пычагын күрсәткәч, — уянып китәр, дип янына бара алмадым, — дип ялварып караган, ди.

— Алайса, без сугышканда нигә: «Кайсыгыз көчле, мин шуныкы», — дип тордың? — дип үпкәләгән ир. Моңа каршы хатын бер сүз дә әйтә алмаган. Азаккы сүзендә ир:

— Шул кылган кылыгың өчен, хатын, мин сине үтерәм инде, — дип хатынны үтерә дә биглыйларның уникe атын алып кайтып китә.

Авылга барып халыкка хәлне сөйләп, дөресен яздырган да:

— Атың белән хатыныңа ышанма, этеңә ышан икән, — дип куйган.

«Атың белән хатыныңа ышанма, этеңә ышан» дигән мәкаль шуннан торып калган, ди.

НАЗЛЫ ҚЫЗ

Борын-борын заманда бер патша бар иде, ди. Аның бик матур да, бик иркә дә, бик назлы да бер кызы бар иде, ди. Кыз үсеп, буйга-сынга килгәч, аны сорап яучылар килә башлады, ди. Аңа төрле җирдән килделәр, ди. Кыз берсен дә яратмады, ди. Барсыннан да бер гаеп табып, яучылардан көлеп, кайтарып торды, ди. Моңа патшадан да килделәр, байлардан да килделәр, ди.

Яучылар йөрүе ун ел дәвам итте, ди. Назлана торгач, кыз олыгаеп та китте, ди. Бара торгач, моны соратып, яучы да килми башлады, ди. Бу хәлне күреп, патша бик кайгыра, пошына башлады, ди. Ничек кенә булса да, кызын кияүгә бирәсе килде, ди. Шуннан, ун ел эчендә кем яучы җибәргән, шул егетләрнең барсын да патша беркөнне үзенә кунакка чакырды, ди. Егетләр барсы да килделәр, ди. Аларны бер бүлмәгә кертеп, тезеп утырттылар, ди. Патша кызын егетләр каршысына алып чыкты, ди.

— Кызым, сиңа яучы җибәргән егетләр шушылар инде. Хәзер башка соратыр кеше юк. Менә шушылар арасыннан үзеңә берсен сайла инде, — диде, ди.

Кыз егетләр арасына кереп каранды-каранды да, ди, берсен дә ошатмады, ди.

— Монсы чыпчык борын, монсы йомран күз, песи койрык, монсы чөгендер кебек, монсы камыр кебек, — дип барсыннан да бер гаеп табып чыкты, ди.

Шуннан бу эшкә патшаның бик ачуы килде, ди. Кызына:

— Иң элек сине бер хәерче генә, җырчы егет сораткан иде. Ул әле монда юк. Бик ачуымны китерсәң, мин сине шуңа бирермен дә куярмын, — диде дә, ди, патша чыгып китте, ди.

Кыз чыпчык борын дип хурлаган егет икенче бер патшаның улы икән, ди. Әле кызның әтисе әйткән сүзне ишеткәч тә, бик иске киемнәр киде дә, капчыкларын асып,



таң белән патша янына килде, ди. Патша янына кергәч тә, егет бик әйбәтләп, җырлап җибәрде, ди. Шуннан патшадан кызын сорады, ди. Патша риза булды, җилтерәтеп китереп чыгарды да, ди, кызын «хәерче егеткә» тоттырды, ди. Егет кызны колагыннан тотты да алып та китте, ди.

Китеп баралар, ди, егет белән кыз, китеп баралар, ди. Матур йорт күргән саен кыз:

— Эх, менә бу йортка керсәң! Ах, менә бу йортка керсәң! — дип бара, ди.

Бара торгач, егетнең өе тәңгәленә дә барып җитәләр икән. Ул инде бигрәк тә матур, бигрәк тә биек икән.

— Монсы кем өе? — дип сорады, ди.

Егет:

— Бу ни сине сораткан патша малаеның өе. Син аны, чыпчык борын, дип мыскыл итеп җибәргән идең, — ди.

Кыз:

— Ах, мыскыл итмәгән булсам, шунда керер идем бит, — дип елап җибәрде, ди.

Баралар, ди, болар, һаман баралар, ди. Бара торгач, кыексыз бер өйгә барып җиттеләр, ди. Анда барып җиткәч, кыз егеттән:

— Монда нәрсәгә туфрак өйгәннәр? — дип сорады, ди.

Егет:

— Минем өй. Әйдә, шушында керәбез инде, — дип, кызны колагыннан тотып, җилтерәтеп алып керде, ди.

Кыз кычкырып елый-елый кереп китте, ди. Эчкә кергәч, егет аш пешерергә, самовар куярга, өйне җыештырырга кушты, ди.

Кыз:

— Мин ул эшләрне эшли белмим. Аш пешергәнем юк, самовар кайнатканым юк, өй җыештырганым юк, — дип караган иде, ди, егет аңа:

— Корсагың ача башласа, эшләү түгел эшләрсең, — дип чыгып китте, ди. Ни хәл итсен, ачыга башлаган иде, аш пешерде, ди, самовар куйды, ди, егет кайтканчы, өйне

дә җыештырды, ди. Шулай итеп, болар ир белән хатын булып яши башладылар, ди. Егет көн дә иртә белән:

— Мин базарга барып эш юньләп килим, — дигән булып чыгып китә дә үзенең теге биек матур өенә кайтып китә икән, кызны җир өйдән чыгармый, ачлы-туклы гына тота икән, ди.

Бер айдай торгач, кыз йомшарды, ди. Иренә булышырга теләп, базарга чыгу турында уйлый башлады, ди. Бу уен егеткә дә белдерде, ди. Егет:

— Алай булса, менә син шушы йомыркаларны сатып кайтырсың, — дип кызга бер йөзләп йомырка бирде, ди.

Яшь хатын йомыркаларны бер кәрзингә салып, базарга чыгып китте, ди. Базарга барып, кәрзинен ачып бер почмакка гына утырган иде, ди, бик шәп ат җиккән бер кеше, атын тыя алмыйча, моның кәрзинен аударды да китте, ди. Йомыркалар ян-якка тузып тәгәрәшеп, берсе дә имин калмады, ди. Яшь хатын, ни әйтергә дә белмичә, елый-елый җир өенә кайтты, ди.

— Ни генә дип җавап бирермен инде? Йә инде, — дип сөйләнә-сөйләнә, ире кайтканчы елады, ди, ул, күзләре шешенеп бетте, ди.

Шуннан ире кайткач, хәлне яшерми, ничек булган, шулай сөйләп бирде, ди. Ире тыңлады да, тыңлап беткәч, бер сүз дә әйтмәде, ди. Шуннан беркөнне:

— Син, әнә, теге сине сораткан чыпчык борын патша малаеның өенә бар да эш сора. Анда синлек кенә эш булыр. Ару гына йөрсәң, тамагың да туяр, өстең дә бөтәер, — дип киңәш бирде, ди.

Кәләше бу сүзгә риза булды да иртәнчәк теге биек йортка барып, эш сорады, ди. Моны аш пешерүчегә булышчы итеп алдылар, ди. Бу шунда һич карышмый гына эшләп йөри. Көн буе аш-су белән булыша, савыт-саба юа — һәммәсен дә эшли, кич кайтып ире янында йоклый, таң сарысы белән торып, тагы эшкә китә, ди. Шулай итеп, оста ашчы янында тырышып эшли торгач, әллә ничәмә төрле ашлар пешерергә өйрәнеп алды, ди. Бер ай

дигәндә, бар эшчедән дә артык аш пешерү остасы булып китте, башкаларны үзе өйрәтерлек булып җитте, ди.

Шулай бик әйбәт кенә йөргәндә, бердәнбер көнне йорт хуҗасы булган патша улы яшь хатынның янына килеп, моны бер почмакка кысрыклый башлады, ди. Хатын кычкыра башлады, ди. Хатын кычкыра, кычкыра — гаҗәп, берәү дә чыгып карамый, ди. Хәзер егет моны өске бүлмәгә сөйри башлады, ди. Яшь хатын тартышып караса да, берни чыгара алмады, ахырында җиңелеп, менде, ди. Өскә менгәч, тәрәзәдән сикерергә итеп тә карады, ишектән чыгып качарга да итеп карады, ди, булдыра алмады, ди. Ахырында егет моны биленнән тотып, сәкегә утыртты да, ди:

— Йә, миңа туры гына кара әле, таныйсыңмы, мин кем?

Яшь хатын ояла-ояла гына баш калкытып бер сирпелеп карады, ди. Шуннан тагы карады, ди, карый торгач кына, аның үз ире икәнен төсмерләде, ди.

— Менә мин синең ирең. Үзең чыпчык борын дигән, атаң хәерче җырчы дигән кеше мин булам инде, — диде, ди.

Кыз аптырап калды, ди. Оялып, оялышыннан тагы еларга кереште, ди.

— Елама, елама инде. Мин сине артык назлы булганыңа күрә, юри хәерче булган булып алдым. Шуның өчен сине азрак кына балыкчының җир өендә тоттым. Базар хәлен белсен дип, йомырка саттырырга чыгардым. Аны, ат белән бәрдертеп, сыттым. Аннан соң аш-су әзерләргә өйрәттем. Ул артык назлылыгыңны хәзер кабатламассың, дип уйлыйм. Без икәү шушы өйдә торырбыз, — диде, ди, егет.

Шуннан соң өсләренә яңа киемнәр кидереп, каенатакаенаналарын чакырып, өр-яңадан туй ясады, ди. Патшаның назлы кызы назлануын онытып, патша улы булган кияве беләν бер-берсен яратышып, әле булса да шул биек матур йортларда яшиләр, ди. Тфү, тфү, тфү...

ХАЛИКЪ КЫЗЫ ХӘДИЧӘ

Гали абзый авылда акыллы булуы белән дан алган кеше иде, ди. Аның бердәнбер улы Габдулла, әти-әнисе карт булуы сәбәпле, солдатка барудан котылды, ди. Көз матур гына үткән иде, әтисе чирләп китте дә, озак та ятмый, үлеп куйды, ди.

Габдулла да, әтисенә охшап, бик акыллы иде, ди. Гафифә карчык:

— Улым, үзең кеше булдың инде. Мин бик картайдым. Балам, хәзер сиңа җәмәгать алырга кирәк. Мин исән чакта өйләнеп кал. Хәзер мин йортны карарга булдыра алмыйм. Менә үзебезнең авылда да сиңа яраплык кызлар бар. Вәли абзыйның Гөлсеме. Үзе акыллы, үзе кияү өчен күптән әзерләнгән. Атасыннан өерелеп, гомерегезгә җитәрлек малы килер. Бәхетле торырсыз. Эшкә бик оста. Әллә шуңа кода җибәрикме? Мин үзем дә барып кайтырмын, — дигән, ди.

Габдулла:

— Мин аны алырга һич кенә дә риза түгел. Аның байлыгы миңа кирәкми. Хәзергә өйләнмим әле, — дигән.

Гафифә әби, әллә бу мин күрсәткән кызны ошатмыймы икән, дип үзләренең авылыннан тагы бик күп кызларны күрсәтте, күрше авыл кызларын санап чыкты, ди. Тик Габдулла берсенә дә риза булмады, ди.

— Минем күзем төшкән бер кызым бар. Ул, әнә, күрше авыл Халикъ абзыйның кызы, Хәдичә исемле кече кызы, — диде, ди.

— Син, балакаем, акылдан яздыңмы? Аның Хәдичәсе тиле кыз бит. Белгәне — тик яту бит аның. Аны алып, ике имгәк асрар идеңме? Аның кебек диванаиы хатынлыкка алалармыни? Балакаем, атаң кебек син дә акыллы бит. Сиңа теләгән кеше теләгән кызын бирәчәк, — диде, ди, әнисе.

Габдулла:

— Юк инде, әни. Мин өйләнсәм, шуңа гына өйләнәм. Өйләнмәсәм, бөтенләй өйләнмим, — ди.

— Алай булгач, балам, үзеңә тапшырам. Ләкин аны алсаң, үзеңнән күләрләр генә бит.

Габдулла әнисенең ялгыз йорт эше белән шөгыльләнерлек түгел икәнен уйлады, ди. Бердәнбер көнне күрше авыл Халикъ абзыйга үзеннән-үзе кода булып барырга булды, ди.

Халикъ абзый ишек алдында арбасын төзәткәләп йөргәндә, Габдулла килә.

— Әссәламегаләйкүм, Халикъ абзый, исәнме?

— Вәгаләйкүмәссәлам, Габдулла икән, әйдә, балам, өйгә рәхим ит. Атаң бик үз кеше иде, бик тә акыллы кеше иде. Әйдә, өйгә керик әле.

Алар өйгә керәләр.

— Ни хәлләр бар, Габдулла?

— Хәлләр ару әле. Мин сезгә бик зур йомыш белән килгән идем әле.

— Рәхим итеп, сөйләп җибәр. Нинди йомышларың бар? Мин аны үтәп җибәрергә әзер.

Габдулла болай дип сүз башлады, ди:

— Әле менә әтием дә үлеп китте. Әнием: «Әллә, Габдулла балам, өйләнеп куясыңмы?» — диде, шуңа сиңа килгән идем. Син гаеп итмәссең инде, мин сезнең Хәдичә исемле кызыгызны иптәшлеккә сорап килдем.

— Әй Габдулла, син бит акыллы кеше. Минем Хәдичә исемле кызым дивана бит ул. Аны син алып, берни дә эшли алмассың. Минем Хәдичәдән зуррак Сажидә, Мәрьям исемле кызларым бар. Синең кебек тәвәккәл кешегә мин аларны бирергә һәрвакыт әзермен.

— Халикъ абзый, мин үзем Хәдичәне бик яратам. Без аның белән бик әйбәт көн итәрбез. Миңа шул Хәдичәне генә бир инде, — ди.

Халикъ абзый да:

— Болай булгач, мин сиңа өч кызымның кайсысын алсаң да, бирәм, — ди. Габдулла:

— Бик риза булып кына миңа Хәдичәне бирсәң иде,— ди.

Халикъ абзый:

— Бирәм, бирәм, кайсысын гына алсаң да, бирәм. Тик соңыннан үпкәләмә. Мин Хәдичәне сиңа кулай булыр дип уйламыйм.

— Алай булгач, мин аны озакламый өемә алып китәрмен, әниемә булышчы кирәк, — дип Габдулла сүзне ныгытып кайта.

Ике-өч көннән Хәдичәне алырга килә. Хәдичәгә хәлне аңлаталар. Аны әйбәтләп киендерәләр, ләкин ул бер дә мич башыннан төшәргә теләми.

— Мин кияүгә бармыйм, — дип тик утыра.

Аны ничек җитте шулай Габдулла янына кертеп кушалар. Ике көн булгач, каенана, каенатасына тиешле бүләкләрне тапшырып, Габдулла кәләшен алып кайтырга рөхсәт сорады да кайтып китте, ди.

Бер атна үткәч, Габдулла үзенең күк тимер алашасын кыңгыраулы дуга, яхшы камытлар белән карандас арбага җигеп, күршесе Сөләйман картның уналты яшьлек Сәлихын кияү егете итеп утыртып алып китте, ди. Халикъ абзыйлар әзерләнеп, көтеп торган булганнар. Ике кич кунак булгач, Габдулла кайтырга әзерләнә. Өйдәгеләр Хәдичәгә биреп җибәрәсе әйберләрен әзерлиләр. Аларны китерү өчен, Халикъ абзый кызына карандаска җигелгән бер атын да бүләк итеп бирде, ди.

Шулай итеп, Хәдичәне ике апасы мыскыллау белән, әти-әнисе борчылу белән озатырга чыктылар, ди. Атлар кузгалып китте, ди. Халикъ абзый корткасы Хәлимә белән капкадан чыгып елап карап калдылар, ди.

Ике авыл арасы өч кенә чакрым. Бик тиз кайтып җиттеләр, ди. Болар кайтып җитүгә, капка төбенә бик күп халык, яшь-җилкенчәк, бала-чагалар җыелып торалар иде, ди. Шулар арасыннан Габдулланың Алабай дигән эте килеп, аяк астында уралана, ялагайланып, койрыкларын

болгап, ике арткы аякларына басып, борыны белән аның битен төрткәли башлады, ди. Габдулла аңа:

— Кит моннан! — диде, ди. Эт китмәде, ди. Габдулла тагы:

— Кит моннан! — дип кычкырды, ди. Эт һаман ялагайлануында булды, ди. Габдулла ала биреп башына чүкеч белән берне сукты да үтерде, ди.

Капкадан керү белән Габдулла:

— Тыр-р! — ди. Ат һаман туктамады, ди. Икенче мәртәбә:

— Тыр-р! — диде, ди, Габдулла. Ат һаман да туктамады, ди. Габдулла тиз генә күтәрмә төбендә яткан балтаны алды да атының башына чапты, ди.

Кәләше һаман арбадан төшми утыра, ди.

— Хәдичә, төш, — диде, ди, Габдулла.

Хәдичә эшне аңлап алды, ди: «Ике мәртәбә әйткәндә тыңламасаң, рәт юк икән», — дип уйлады да арбадан сикереп тә төште ди. Габдулла аңа:

— Өйне җыештыр, аш пешер. Күршеләрне кунакка чакырырбыз, — дип кала.

Хәдичә йөгереп йөреп өй җыештыра, аш пешерә. Кунаклар килеп, сыйланып, киленнең уңганлыгына аптырап кайтып киттеләр, ди.

Биш-алты атна үтү белән, Хәдичәнең әнисе:

— Баламның хәлен белеп килим әле, — дип Габдуллаларга килде, ди, исәнлек-саулык сорашты, ди. Габдулла аны бик яхшы каршылады да:

— Сез утырып торыгыз. Хәдичә, син чәй кайнат, сыйларыңны әзерлә, мин лавкага барып килим, — дип чыгып китте, ди.

Габдулла чыгып киткәч, кыз белән әнисе сөйләшергә тотындылар, ди. Әнисе:

— Нихәл, балам, тормыш авыр түгелме? Яхшы торасыңмы?

— Әй, әнекәем, әйтмә дә инде безнең тормышны. Бик

кыен хәлдә торам. Эш кушканда, ике генә әйтә. Тыңламасаң, утерә дә куя, — ди Хәдичә. Әнисе:

— Кара син аны, каһәр суккыры нәрсә, минем кызымны шулай тота икән. Җанымны көйдерсә, кызымны алып кайтып та китәрмен, — дип әйтүе булды, ишек артында тыңлап торган Габдулла бик кызу килеп керә дә:

— Хәдичә, кайда әле, әзерлән. Хәзер иң элек бәрәңге утыртып алабыз, тиз бул. Каенанам, син дә ярдәмгә барырсың. Хәзер мин атны карыйм да, — дип, өтәләнеп чыгып китте, ди.

Хәдичә белән әнисе бик тиз арада бакчага китәргә җыендылар, ди.

— Каенанам, син теге билчәннәрне йолык. Хәдичә, син минем арттан бәрәңге утыртырсың, — диде, ди.

Шулай итеп, зур бакча тиз арада утыртылып та бетә.

— Менә хәзер ашарга да була. Хәдичә, чәй кайнат, сый әзерлә, тиз бул, — дигәч, Хәдичә йөгереп кереп китеп, самоварга тотына.

Хәлимә әби алдын-артын карамый:

— Каһәр суккыр кияү, гомеремдә мондый эш эшләгән юк иде. Кулкайларым калмады, яргаланып бетте, — дип тизрәк кайту ягына сыпырта.

Хәлимә әби аһылдап, хәлдән таеп, кайтып егыла. Әбиен шул хәлдә күргән Халикъ абзый аптырап кала.

— Нәрсә булды сиңа? Әллә берәрсе кыйнап кайтардымы? — дип сорый.

— Куй инде, кызыбызны кешегә түгел, торганы бер шайтанга биргәнбез икән. Менә чәй дә эчермәде. Җитмәсә, бакчасындагы билчәннәрне йолкыттырып, кулларымны бетерде. Гомеремдә эшләмәгән эшемне эшләтте! — ди.

Халикъ абзый:

— Тукта әле, мин дә аларның хәлен белеп килим, — дип юлга чыкты, ди.

Габдулла аны да ачык йөз белән каршы алды да, ди:

— Хәдичә, син хәзер самовар куй. Сыйларыңны әзерлә. Мин лавкага барып килим, — дип янә чыгып китте, ди.

Әтисе сораша башлый:

— Ничек торасыз?

— Әй, әтекәем, әйтмә инде, бик авыр торабыз. Габдулла эшне бер мәртәбә генә әйтә. Ике мәртәбә әйткәнен көтеп торсаң, үтерә.

— Шулай кирәк, кызым, бик әйбәт итә икән кияү, бик дөрес эшли икән. Сезгә шул да аз, — диде, ди.

Ишек артында тыңлап торган Габдулла, бу сүзне ишетү белән, лавкага йөгерә. Күп итеп ашарга, эчәргә алып кайта.

— Хәдичә, әле ашарга өлгермәдеменн? Хәзер барсын да әзерлә, — дигәч, шунда ук барсы да әзер булды, ди.

Шуннан Габдулла каенатасын сыйларга тотынды, ди. Халикъ абзый шулхәтле сыйланды, ди, өч көн кунак булганын да белми калды, ди. Өченче көн кияү тагы да каты сыйлап, күчтәнәчләр биреп, кайтарып җибәрде, ди.

Халикъ карт өйгә бик күп күчтәнәчләр белән кайтып керде, ди. Кайткач, әбиен азрак орышып алды, ди, кияүен мактап бетә алмады, ди.

Шулай итеп, ел артыннан ел үтте. Халикъ абзый тагы да ике кызын кияүгә бирде, ди. Бер ел торгач, бөтен кияүләрен кунакка чакырды, ди. Карт аларны нык сыйлады, ди. Кунаклар кызып киттеләр дә үзара:

— Минем кәләшем яхшы.

— Минем кәләшем акыллы, — дип мактаныша башладылар, ди.

Халикъ карт:

— Ярый, бушка бәхәсләшмәгез, без аларны сынап карарбыз. Кем унган, кем яхшы, кайсысы тыңлый, белербез. Барыгыз да йөзәр сум акча бирегез. Кемнең хатыны тыңлый, акчаны шуңа бирербез, — диде, ди.

Бөтен баҗалар да бу тәкъдимгә кушылалар, акчаны картның кулына бирәләр. Өч кияү өч йөз сум салды, ди. Акчаларны картның өстәленә тезеп куялар, ди.

Хатыннарны сынау башлана. Иң элек өлкән баҗадан

башлыйлар. Сөйләшү буенча, ул утырган җирдән генә үзенең хатынын чакыра:

— Мәрьям, Мәрьям, — ди.

Мәрьям икенче бүлмәдән:

— Әү! — ди.

— Мәрьям, кил әле монда, — ди кияве.

— Ярый ла! — дип җаваплый Мәрьяме, керми.

Нәүбәт уртанчы кияүгә җитә.

— Саҗидә, кер әле тиз генә! — дип чакыра уртанчы баҗа.

— Ярар ла! — дип кычкыра Саҗидә, керми.

Яңадан:

— Саҗидә, кер әле, — дигәч:

— Нәрсә, син әллә урманда адаштыңмы? — дип кычкыра, керми кала.

Хәзер чират Габдуллага җитә:

— Хәдичә, кер әле, — дигән иде, ди, Хәдичә ялт итеп килеп тә керде, ди.

— Нәрсә кирәк? — дип сорады, ди.

Габдулла:

— Ал анавы акчаларны, ыргыт мичкә, — диде, ди.

Хәдичә акчаларны итәгенә сыпырып алып, мич авызына килеп, ыргыттым дигәндә генә, Халикъ карт тотып алып калды, ди.

Габдулла белән Хәдичә акчаларны кесәгә салып, кайтып китәләр.

Халикъ карт:

— Тырышсаң, ташка кадак кагарсың, дигән бабайлар. Дөрес әйткәннәр. Тырышсаң, диванацы да кеше итеп була икән, — дип калды, ди.

Габдулла шулай итеп, Хәдичәсе белән әле булса да дөнья көтеп, теттереп яшәп ята, ди.

ЯВЫЗ ХАТЫН БЕЛӘН ДИЮ ПӘРИЕ

Борындырмы, яңарактырмы инде, ул тиклемен кем белсен, бер заманда бик акыллы, бик итагатьле бер кешенең биктән бик явыз хатыны бар иде, ди. Ул ирен гел генә бимазалап, мыжып әрләп кенә торган, ди. Ни генә эшләмәсен, барсын да ире теләгәннең киресен эшләр булган. Ир бөтен көчен салып, тату яшәргә тырышса да, һич кенә дә барып чыкмаган, ди. Бичәсен юлга салыр өчен, бар чараларны да кулланып караган — файдасы тимәгән, ди. Файдасы тию түгел, бичәнең явызлыгы артканнан-арта барган, ди. Ахырда килеп соңгы чараны чамалап карарга булды, ди, ир кеше. Илдән чыгып качсам да, барыбер котылып булмас, куймас, кеше белмәс бер урын табарга кирәк, дип уйлады, ди.

Бу хатын белән ир яшәгән җиргә якын гына бер кыялыкта упкын бар иде, ди. Ир кеше шунда төшеп яшеренмәкче булды, ди. Бу эшен никадәтлем генә яшереп эшләргә тырышмасын, бичәсе сизеп алды, ди.

— Кайда бармакчы буласың болай итеп? — дип төпченә башлады, ди.

— Эш бар иде.

— Эш? Бирермен әле мин сиңа эшне. Син аркан сатып, миннән башка кәсеп итмәкче буласың инде, мөгаен. Саттырырмын мин, саттырмый ни. Киттек бергә, — дип тавыш күтәрергә тотынды, ди.

Хәл юк, упкынга икәүләп киттеләр, ди. Упкын янына килгәч, ир арканының очын аска төшерә башлады, ди.

— Бу ни эшең, кабәхәт?

— Хәзинә ята бит анда. Шуны алмакчымын.

— Кая әле үзем төшеп алыйм, син өстә генә торып тор.

— Юк, син монда торып тор, үзем алып меним, — диде, ди, ире.

Ир белән хатын әй бәхәсләштеләр, әй бәхәсләштеләр, ди. Ахырда ире чигенергә булды, ди. Бичә упкынга төшә

башлады, ди. Бичә төшеп киткән иде, ирнең башына бер уй килде, ди: бичәнең үзен шунда калдырып була лабаса. Ир кеше тиз генә арканны кисте дә, куанычы эченә сыймый, өенә кайтып китте, ди.

Күпмедер вакыт уткәч, тыныч тормышта рәхәтләнеп яшәгән ир, ничектер, әлеге упкын яныннан үтешли, бичәсенең хәлен белмәкче булды, ди. Чокырга якын килсә, астан җан өзгеч тавышлар ишетелә, ди. Упкынга якын килеп, адәм баласы бит инде, ир, җәлләп, мескен бичәсен чыгармакчы булды, ди. Мөгаен, рәткә керердәй булгандыр, дип уйлаган булды, ди. Шулай итеп, упкынга аркан төшерде, ди. Арканның очы төшеп тартылгандай булгач, бичәсе тотынган икән, дип өскә сөйри башлады, ди. Тартып тора, тартып тора арканны. Әнә чыга, менә чыга, дип бичәсен көтеп торса — бауга ябышып, сыңар күз пәри чыгып килә, ди. Күзе маңгаеның тап уртасында тора, ди. Ир, бауны кисеп, кире төшереп җибәрмәкче булган иде ди, теге телгә килде, ди.

— Әй, мәрхәмәтле бәндәгенәм, мин гомер бакый шушы өнемдә тыныч кына яшәгән идем. Хәзер булмый, янарак бер адәми бичә килеп төште дә, көн бетте миңа. Җәфа чигүләремнең чиге юк. Әй мәрхәмәтле бәндәм, коткарсаңчы мине шул бичәдән. Синең тугры таянычың булырмын, чиксез байлык алып бирермен, — дип ялварды, ди.

Теге кеше чыгара бу мәхлукны. Бу инде куанычыннан ни алып, ни бирергә белми, ди.

— Сиңа өч тапкыр исәпсез күп акча алырга юл ачылыр. Син чиксез баерсың. Дүртенче тапкыр сорый күрмә, әмет тә итмә, көтмә дә, мин синнән котылган булырмын, юкса башыңа бәла төшәр.

Пәри коткаручысы янында яши башлый, озакламый үзенең вәгъдәсен тормышка ашырырга тотына.

Бу кешедән ерак түгел бер бай яшәгән икән.

— Шул байның бердәнбер кызы авырыр. Әтисе саранланмаса, коткарып булыр. Кыз торган саен ныграк

җәфаланачак, җенләнәчәк. Әтисе тирә-юньнән данлыклы багучыларны, муллаларны чакырыр — файдасы тимәс. Син барырсың да кызны савыктырачагыңны әйтерсең. Аның өчен, күпме телисең, шултиклем хак сорарсың. Мин кызны ычкындырырмын. Ул әүвәлгечә сап-сау булып китәр. Шуннан байдан бүләк алырсың, — диде, ди, пәри теге иргә.

Барсы да теге нәрсә әйткәнчә булды, ди. Байның кызы чәчрәп авырып китте, ди. Сынчы дип сынчы, багучы дип багучы, мулла дип мулла калмады, ди. Берсеннән дә дәва-дәрман тапмады, ди, кыз. Шуннан бу адәм китте, ди. Дию пәрие өйрәткәнчә, тәүдә бай белән хак сөйләштеләр, ди. Килешеп бетеп, кызны караган иде, теге пәри кызны ычкындырды, ди.

Кыз савыккач, теге пәри:

— Онытма, бер шарт үтәлде, тагы ике генә шарт калды, — дип искәртеп китте, ди.

Озак та үтми, пәри тагы бер байның ялгыз гына улының авырып китүен әйтә. Күп акчага сөйләшеп, аны да савыктыралар.

— Инде бер генә шарт калуын онытма. Тагы сорасаң, үз башыңа булыр, — ди, теге нәрсә.

Тиздән шул ук чир белән өченче бер байның бичәсе авырып китте, ди. Аны да әлеге пәри ярдәмендә күп акчага савыктырды, ди. Шуннан теге пәри коткаручысына:

— Мин өч шартны да үтәдем. Бүтәнчә мине чакырма. Чакырсаң, башыңа булыр, — диде, ди.

Аңарчы булмады, ди, шул ук чир белән хан улы авырып китте дигән хәбәр таралды, ди. Әлеге адәмнең мондый чирне бик оста дәвалавы турында ханга җиткерделәр, ди. Хан аның артыннан чапкынчылар чаптырды, ди. Ханның әмерен ишеткәч, бик зур уйга калды, ди, теге адәм. Кайгыга калмый ни итсен, бармасаң — җәза, барсаң — үлем. Хәл юк, барырга була. Хан сараена керер чакта теге котсыз пәринең тавышын ишетеп кала бу.

— Ничек килдең син монда, минем әйткәнне тотмыйча? Хәзер үзеңә үпкәлә инде.

— Мин монда сине авыру егетнең эченнән куып чыгарыр өчен килмәдем. Мин теге бичәнең, упкыннан чыгып, сине эзләп йөрүен аңлатыйм дип кенә килгән идем, — диде, ди, бу адәм.

Шулай дип әйтүе була — теге нәрсә, алдын-артын карау юк, ничек җитте шулай, таю ягына карады, ди. Хан малае сәламәтләнеп, әүвәлге хәленә кайтып, ыргып килеп торды, ди. Хан «имчегә» зур бүләкләр биреп, рәхмәтләр укып, кайтарып җибәрде, ди.

Шуннан алып яман хатыны булган кешеләрдән җен-пәриләр куркыр булды, ди. «Бозык хатын җен-пәридән яман» дигән сүз шуннан калган, ди, бит ул.

ГАҖӘП ИСЕМНӘР

Борын заманда ике бертуган патша булган. Бер үкелны берсенең хатыны, икенчесе үзе үлеп киткән, ди. Бичәсе үлгән патшаның бер кызы булган. Шул патша үлгән энесенең бичәсен алган. Әүвәлге җиңгә, шулай итеп, үги әни булып киткән. Җиңгәле-каенсеңелле чакта тату гына яшәгән булсалар, хәзер үгигә әверелгәч, эшләр киткән, ди, кирегә. Үги әни ятим кызны һич кенә дә яратмаган. Һәрвакыт аны кимсетеп кенә торган. Этисенә:

— Кызың ялкау, үзе гарьчел, — дип әләкләр булган. Беркөнне килеп:

— Илтеп ташла, югалт кызыңны күземнән! Кайда куйсаң да куй! — дип җикергән.

Кызын бик жәлләсә дә, патша хатынының сүзен ега алмаган, кызын кара урманга алып барып адаштырган. Кыз бу урманда байтак вакытлар адашып йөргән. Йөри

торгач, бер елга буена килеп чыккан. Шунда ул сусынын басканчы су эчеп, юынып хәл алган да агач башына менеп утырган. Төнне ул шулай үткәреп, иртәгәсенә инде ни эшләргә, дип утырса, бер көтүче су алырга килеп төшкән. Сирпеп су алыйм дисә — суда бик матур кыз сынын күреп кала. Көтүче аны су кызы икән дип уйлый да:

— Чык, сылу кыз. Чыкмасаң, чишенеп төшәм дә үзем алып чыгам, — ди.

Кыз эндәшмәгәч, бу егет чишенә башлый. Шулчак агач башындагы кыз:

— Куй, төшмә, егет, суга. Минем өчен ирәм булырсың, — дигән.

Егет тавыш килгән якка караса, агач башында бер матур кыз утыра, ди.

Кыз агач башыннан төшкән. Егеткә үзенең монда ничек килеп чыгуын сөйләп биргән.

Егет кызны өенә алып кайткан. Алар ирле-хатынлы булып бик матур итеп яши башлаганнар. Өч уллары туган. Беренче уллары Нидем, икенчесе Ниулды, өченчесе Ниулчак исемле булган.

Берчак абыйлары бәләкәй Ниулчакны чанага утыртып, берсе алдан сөйрәп, берсе арттан этеп, тауга киткәннәр. Таудан шуганда, сәфәрдән кайтып килгән патшага очраганнар. Сөйкемле йөзләрен күреп, малайларга сокланып карап торган да патша аларның исемнәрен сораган. Балалар әйтеп биргәннәр. Ят исемнәрне ишетеп, патша бик гаҗәпләнгән. Шуннан ул малайларның атасын чакыртып алган.

— Шундый исемнәрне кайсыгыз уйлап тапты? — дигән.

— Улларымның исемнәрен хатыным уйлап тапты, — дигән ир.

Патша ярлының хатынын да чакырткан. Тик хатын:

— Өстемә кияргә күлмәгем юк, — дип, чакырган җиргә бармаган.

Шуннан патша аның янына үзе барган. Барса, ни күзе

белән күрсен, алдында үзе урманга адаштырып киткән кызы тора, ди. Кызын бер күрүдә үк таныса да, сер бирмичә, теге балаларның исемнәре турында сорашкан. Хатын әйткән:

— Элек мин бер патшаның бердәнбер генә кызы идем. Аннан көтүче хатыны булдым. Алда ниләр булачак, ансы билгесез. Шуңа минем балаларым Нидем — ни идем, Ниулды — ни булды, Ниулчак — ни булачак, — дигән.

Патша кызның кыюлыгына, зирәклегенә сокланып, шул урында үзен таныткан. Көтүче кияве белән кызын алып кайтып китеп, киявенә ярты патшалыгын биргән, ди.

ЯВЫЗ ПАТША БАШЫНА ҖИТКӘН ПАТША МАЛАЕ

Борын заманда бер патша үлеп китә. Хатыны сигез яшьтәге бер ир бала белән торып кала. Бердәнбер вакыт икенче бер шәһәрдән яңа патша сайлап куялар. Ул патша тора торган урынына килеп, үлгән патшаның хатынын алып, үзенең хөкемен йөртә башлый.

Бервакыт бу яңа патша төш күрә дә:

— Безнең малай, бер ак-күк ат менеп килеп, мине суга салган, башымны кискән икән дип күрдем, — дип сөйли.

Төш юраучылар чакырып, патшаның төшен тикшереп карыйлар. Алар патшаның үлеме малайдан булуын дөреслиләр. Патша малайга хәвеф тота башлый. Моны ничек кирәк үтерергә уйлый. Хатынына әйтә, хатыны риза булмый. Ире бик нык торгач, кайда барсын инде, бахыр, тора-бара ризалаша.

Малайны ачыктырып үтерергә мәслихәт итәләр. Төр-

мәгә ябып куялар. Каравылчылар аңа ризыкны бер тишектән генә бирәләр. Ике көн уткәч, патша бер хатын кешене малайның хәлен белергә җибәрә. Хатын барса, теге бәләкәй туп уйнап утыра.

— Әй, балам, хәлең ничек? Ачыгасыңмы?

— Юк, мине монда ачыктырмыйлар. Тәрәзә тишегеннән сөт тә, икмәк тә бирәләр, — ди малай.

Хатын патша янына китә.

— Ничек? Начарланганмы?

— Юк, начарланмаган.

— Юк, ул болай үлмәс, әйдә, агулыйк, — ди патша.

Агулап, күмәч пешерәләр, бер шешә сөткә агу салалар. Теге хатынны тагы җибәрәләр. Бу хатын юл уңаенда өенә кереп, бер телем икмәк, бер савыт сөт алып чыга да агулы икмәк белән агулы сөтне, су чыккач та, ыргытып китә. Егеткә үзенең ризыкларын ашата. Ашаткач, тагы патша янына килә:

— Ашаттыңмы?

— Ашаттым.

Иртәгәсенә тегенең хәлен белергә патша янә бу хатынны җибәрә. Хатын бара. Егет шәп бит инде. Кире кайтып, патшага бара хатын.

— Сөйләшәме?

— Сөйләшә.

— Булмады болай булгач, әйдә, аттырабыз!

Патша ике солдат җибәрә. Солдатлар малайны зинданнан чыгарып алып китәләр дә:

— Син, егет, кач, — дип малайны икенче илгә качырып җибәрәләр, үзләре мылтыкларын һавага атып, патшага ишеттерәләр дә кайтып китәләр.

— Булды болай булгач, — дип патша тынычланып кереп ятты, ди.

Малай китә. Күп җирләр киткәч, бер су буена бара. Су буйлап китә. Арый. Арыгач, йокларга була. Уянып китсә, су янында ята. Малай су эчте дә, ди, азрак ризык кабып, салкынга барып тагы ятты, ди. Яткач, йоклап кит-

те, ди. Төнлә өшеп китеп, уянып, караса — бер ут күренә, ди. Малай торып, шунда таба китте, ди. Барып җитте, ди. Караса, икенче бер мәмләкәттән бер пароход килеп туктады, ди. Малай шул тирәдә бәләкәй тубын алып уйнап йөри башлады, ди. Шунда аны бер түрә күреп калды, ди:

— Син нинди малай? — диде, ди.

— Мин шулай, шулай йөрим.

— Әтиең бармы?

— Юк, мин шулай йөреп тамак туйдырам. Йокым килсә, ятып йоклыйм.

— Син безгә барасыңмы?

— Барам.

Түрә малайны корабка алып керсә, анда тагы бер түрә.

— Мин бер малай таптым.

— Ай-һай, ничек ансат кына! Алай булгач, әйдә, шобага тотыйк малайга, — ди тегесе.

Шобага тоткан иделәр, малай алып кергән кешегә чыкты, ди. Малайны алып кайтып китәләр. Зурая малай. Матурая. Өйләнә. Өйләнгәч, моның да бер ир баласы була.

Шулай бер ашханәгә барып керә. Керсә, бер буйдак егет утыра. Сөйләшеп, танышып китәләр.

— Син кайсы яктан?

Егет сөйләп бирә хәлен. Якташ булып чыгалар.

— Әйдә кайтыйк.

Кайтырга сөйләшәләр, көн куялар. Бер айдан китәргә булалар. Бер ай тулгач, пароход белән китәләр. Шуннан пристаньдә төшеп, җәяү китәләр. Китеп барсалар, бер елга туры килә. Шунда болар туктап ял итәргә булалар. Хатынлы егет:

— Ары йөреп килим. Берәр кошмы, куянмы туры килмәсме, — ди дә, мылтыгын алып чыгып китә.

Чыгып та китә, урманда юл таба алмый адаша да куя. Таң аткач, тегеләр калган җирне көч-хәл белән эз-

ләп таба. Килсә, бәй, ни күрә: бер арыслан үлеп ята, кып-кызыл кан, теге егет тә үле. Хатын белән бала юк.

— Арыслан ашаган икән! — дип кайгыра патша улы. Егетне бу читкә күмде, ди. Күмде дә ары китте, ди. Байтак җирләр баргач, бер шәһәр күренде, ди. Егет шунда барып, бер байга кереп, хезмәт итә башлады, ди. Бер ел эшләде, ике ел эшләде, ди. Өченче ел эшләгәндә, бер сабый килеп керә моның кырына. Егетнең эштән кайтып, чәй эчеп кенә утырган чагы була. Сабыйга икмәк бирә.

— Энем, син кайда яшисең?

— Шушы шәһәрдә.

— Кемнәрең бар?

— Әнием бар.

— Ничек көн итәсең?

— Менә шулай йөреп көн итәм, әнием кер юа.

— Әтиең кайчан үлде?

— Әтиемне арыслан ашаган.

— Әйдә әниеңнең кер юган җиренә барыйк, безгә дә кер юучы кирәк.

— Әйдә.

Китәләр болар. Барсалар, алтыпочмаклы өй, ди. Малайның әнисе кер юып йөри, ди.

— Сеңелкәш, ни хәлдә?

— Ару гына.

— Миңа кер юучы кирәк иде... — дип әйтеп тә бетмәде, болар бер-берсен танып та алдылар, ди. Китте, ди, елаш.

— Ни булды?

— Ни булды? — дип хуҗалар йөгереп килеп чыкты, ди.

Шулай да шулай, дип төшендереп бирделәр, ди. Өч ел янәш яшәгәннәр, бер-берсен белмәгәннәр. Кайда инде хәзер кер юу кайгысы?! Тышта карандаслы ат тора, ди. Егет боларны утыртып, үзенең йортына алып китте, ди.

Бер ел хезмәт иттеләр, ди. Өч ел да булып китте, ди. Хуҗа карт:

— Син өч ел хезмәт иттең. Өч кешегә ашарга-эчәргә бер елга җитәрлек акча бирәм, — ди. — Ак-күк атны яратып менеп йөрдең, үзеңә ал. Әнә, карандас-арба, ансы да сиңа булсын, — ди.

Төянеп, ирле-хатынлы малайлары белән кайтып киттеләр, ди. Хәзер инде әтисенең шәһәренә килделәр, ди. Кайтып килеп, бер әбигә фатирга төштеләр, ди.

— Ни хәлдә яшәү, әбекәй?

— Бик хөрт яшибез, балам. Патшабыз бик алама кеше булып чыкты. Гадел хөкем итми, элекке патша әйбәт иде. Аның улы, бәлки, начар патша булмас иде дә. Әллә ни төш күргән булып, аттыртып үтертеп куйды патша. Менә шулай бик кайгылы яшибез, балам, — ди әби.

Бу егетнең өстендә гаскәр киеме. Кылычы бар. Күк атны менде, ди, патшага килде, ди. Керде, ди. Керсә, энисе чәч тарап тора, ди.

— Кем сине монда кертте?

— Рөхсәт белән кердем. Кычкырма.

Кылыч кумтасы * була бит инде. Кумта белән энисенең чигәсенә бер биреп алды, ди.

— Башта патшаның башын кисәм, аннан — синең нәүбәт, — диде дә, ди, атына менеп, егерме биш чакрымдагы җиргә китте, ди. Барса, бер рота гаскәр тора, ди.

— Егетләр, мин сезнең белән исәнләшергә килдем, — ди, барып җитү белән.

Командирлары аерым палаткада яталар икән, анда барса, сакчылар җибәрми.

— Җибәрмисеңме?

— Юк.

— Әләйсә, менә сиңа.

Башын кисте дә ыргытты, ди, каршы торган кешенең. Аңарчы булмый, патша куышыннан чыгып, атына менеп качты, ди. Бу артыннан төште, ди, тегенең. Егет хәзер куга камалый тегене. Ничек кирәк яр башына алып барып

---

* *Кылыч кумтасы* — кылыч кыны.

та житкерде, ди. Алып барып та житкерде — патшаның башын кисеп тә төшерде, ди. Сикереп төшеп ике колагыннан тишеп иярдәге йөк бәйли торган бауга бәйләде дә гаскәр янына барды, ди:

— Егетләр, ачуланмагыз. Мин патша малаемын. Мине бу бәндә аттырмакчы булган иде. Әтиемнең хакына солдатлар атмады, мин читтә йөреп ир җиттем. Әгәр кабул итсәгез, сезгә хезмәт итәм, — ди.

Солдатлар кычкырып:

— Без риза, без риза, — дип аның сүзен мәслихәт иттеләр, ди.

Егет илгә кайтып, патшалык итәргә тотына. Патша бар игенне, юк, дип, халыкны интектергән. Егет җан башына бишәр пот иген бирде, ди.

Шулай итеп, патшаның төше дөрес килде, ди: патшаның башы киселде, ди. Яңа патша халыкка киңәш итеп, халык белән бергә-бергә яши, ди.

МУЛЛА БЕЛӘН СӘҮДӘГӘР КЫЗЫ КӨНСЫЛУ

Борын-борын заманда бик зур бер авылда бай сәүдәгәр яшәгән, ди. Ул кызы Көнсылу белән бергә сату иткән. Бердәнбер көнне сәүдәгәр утыз дөя җигеп, ерак илләргә товар алырга киткән. Чыгып китәр алдыннан, үзенең исәнсау йөреп кайтуын теләп торыр өчен, шул авылда яшәүче муллага хәер биреп чыккан, ди.

Әтисе ерак илләргә чыгып киткәч, Көнсылу берүзе генә сату итә башлаган.

Байның чыгып китүенә өч көн тулуга, мулла үзенең кызы Хәрбидәгә: «Кызым, туган көнеңә дусларыңны ку-

накка чакыр»,—ди. Кемнәрне кунакка чакырырга кирәклеге турында да әйтә.

Кунаклар җыелышып беткәч, мулла өенең икенче катында уен-көлке, күңел ачу башлана. Хәрбидәгә туган көне белән котлап бүләкләр китерәләр. Көнсылу Хәрбидәгә бүләк итеп бик кыйммәтле көмеш комган китерә. Мулла Көнсылуны үзенең янына, беренче катка чакыра да көмеш комганнан үзенең кулын юарга су салып торуын сорый. Шулвакыт ул Көнсылу белән шаярмакчы була, аны кочаклап алырга итә. Кыз мулланы бик нык итеп этеп җибәрә. Икенче кабат омтылганда, көмеш комганы белән башын сугып яра да куя. Мулла иссез егыла. Тавыш булмасын өчен, кызларга Көнсылу бу турыда беркемгә дә сөйләмәскә куша.

Башы ярылгач, мулла ун көн мәчеткә бара алмый. Хәзер ул кешеләргә башы нәрсәдән ярылганын ничек аңлату турында хәйлә уйлый. Уйлый-уйлый да тәһарәт алганда, башыма ай ватылып төште, дип әйтермен, ди. Шәп җавап табуына мулла эчтән генә куанып бетә алмады, ди. Куанса да күңеле тынычлык тапмады, ди. Ничек тә булса, байның кызына явызлык эшләргә уйлый башлады, ди бу. Байның бик зур алма бакчасы, сыер көтүе булган була. Мулла бөркөнне байның алма бакчасын караучыны, малларын көтүчеләрне үзенә чакырып ала.

— Мин сезгә бик күп акча бирәм, сез алма бакчасын корытыгыз, сыерларны, елкыларны үтерегез,—дип агу бирә.

Ун көн эчендә бик күп җирдә алмагачлар корый, берничә баш сыер, елкы үлә.

Китүенә кырык биш көн тулды дигәндә, сәүдәгәр утыз биш дөягә төялгән мал белән кайтып төшә. Иң беренче муллага килеп керә.

— Сәфәрдән әйбәт кенә кайтып киләм, асыл товарлар китерәм,—дип, муллага бик әйбәт җилән кидерә.

Мулла аңа:

— Юлда әйбәт кенә йөреп кайткансың да ул, монда

эшләр начар бит әле, — ди. — Алма бакчасы корый башлады, елкы, сыерлар зыян күрде. Син киткәч, Көнсылу сату эше белән булышмады, егетләр арасында күңел ачу булды шөгыле, — ди.

Сәүдәгәр дөньясын барып караса, чынлап та, алма бакчасы корыган, маллары үлгән. Икенче көнне мулла байга:

— Синең калган дөньяң бер елдан корып бетәргә тиеш, — дип әйтә. — Дөньяң корып бетмәс борын, Көнсылуның күзен, кулын бәйләп урманга алып бар да башын кылыч белән кистереп, миңа аның канын китереп эчерт, — ди.

Икенче көнне сәүдәгәрнең хезмәтчесе Көнсылуны егерме чакрымдагы урманга алып килә. Монда бер батальон солдат тактика буенча өйрәнү үтеп йөргән була. Хезмәтче Көнсылуның күзен чишеп, кулын ычкындырып, кылыч белән чабам дигәндә генә, бик әче тавыш ишетелә. Бу эшне командир күреп торган булган икән. Йөгереп килеп, хезмәтчене туктата да эшнең рәтен-чиратын сораша. Хезмәтче барсын да сөйләп бирә. Командир уйга кала. Уйлап торгач, бер куян тотып китерә. Хезмәтче, командирның өйрәтүенчә, куянны суеп, канын агызып алып кайтып, муллага эчерә.

Көнсылуны командир үзенә алып кала. Алар бик тату гаилә корып җибәрәләр.

ЯВЫЗ КАРТ

Борын-борын заманда бер әби белән бабай яшәгән, ди. Алар бөтен тирә-якка даннары чыккан мәшһүр бай бул-

ган. Урамнары тулы мал, келәтләре тулы иген, сандыгы тулы җиһаз да акча икән, ди... Аларның матурларның матуры, сылуларның сылуы, бар кешене таң калдырырлык бер генә бөртек кызлары да булган, ди.

Бервакыт хуҗаның хатыны, кинәт кенә авырып, үлеп киткән. Хуҗа икенче хатын алган.

Бердәнбер көнне байларны бик ерактагы нәселләре чакырып хат җибәрәләр. Хуҗалар йортларына күршедәге бабай белән әбине калдыралар да үзләре кунакка китәләр.

Күрше бабае Явыз кушаматлы була. Явыз бабай өйне дә ныклап карап торырга, кызга да күз-колак булырга ышандырып кала. Хуҗа бигрәк тә кызны нык сакларга куша:

— Җиткән кыз, күп чыгып йөрмәсен, аның янына егет-җиләннәр килмәсен, — ди.

Кич җитә, караңгы төшә. Явыз бабай белән әби куна китәләр. Күрше булуына карамастан, бу картның кызны шушы көнгә тиклем ныклап күргәне дә, якыннан караганы да юк иде, ди. Күргәч, кызның чибәрлегенә Явыз бабайның һушы китә дә кызга гашыйк була, кыз белән сөйләшәсе, аны кочаклыйсы килә. Кыз белән аулак калу нияте белән, бабай:

— Балаларга күз-колак булырсың, үзебезнең өйдә кун, — дип хатынын кайтарып җибәрә.

Карчык, берни дә сизмичә, кайтып китә. Карчыгы кайтып киткәч, бабай үзенең мәхәббәте турында кызга әйтә. Кыз, бу сүзне ишетеп, бөтенләй аптырап кала. Аның өстенә бер эссе су, бер бозлы су коелгандай була. Кыз куркуыннан үзенең бүлмәсенә йөгереп килеп керә дә ишеген элә дә утыра. Карт төне буена кызның янына керергә тели, ишекне дөбердәтә:

— Яхшылык белән ачмасаң, ишекне ватып керәм, — дип куркыта.

Ишекне ватып керергә итсә, ишек бик нык була, тиз генә ватылырлык түгел, ди.

Явыз бабай шулай һәркөнне килеп куна да һәркөнне кызны куркыта. Кыз бик кайгыра, курка, ашаудан яза, саргая, ябыга. Тәрәзәдән күзен алмый, этиләренең кайтуын көтә. Әтисенә Явыз бабайның этлекләрен сөйләп, аннан тизрәк үч алдырасы килә.

Явыз бабай да башсыз булмый. Кызын куркытканы өчен, хуҗадан өлеш эләгәчәген белә. Моннан котылу өчен, хәйлә уйларга тотына.

Менә бервакыт, яхшы атларын уйнатып, кыңгыраулаларын кыңгыратып, хуҗалар кунактан кайтып төшәләр.

Иң алдан Явыз бабай каршы йөгереп чыга да тегеләр төшәр-төшмәстән, кызга яла ягып, үз хәбәрләрен сөйли башлый:

— Синең мактаулы кызың бик бозык булып чыкты, безнең йөзебезгә кара якты. Син мине хуҗа итеп калдырсаң да, минем сүзне тыңламады, уе егетләрдә булды, аларны чакырып китереп кунып йөрде, бозыклык итә торгач, хәтта ябыгып та бетте, — ди.

Хуҗалар өйгә кереп карасалар, кыз ябыгып-саргаеп беткән. Явыз бабайның сүзе дөрескә чыга. Хуҗалар аның сүзенә ныклап ышаналар да кыздан котылу юлын уйлый башлыйлар. Үги ана үтерергә өнди. Әтисе моңа риза булмый, адаштырырга киңәш бирә. Кызны урманга алып барып ташлап китәргә булалар. Әтисе кызны матур итеп киендереп:

— Урманнарны күрсәтеп йөрергә итәм, — дигән булып, атка утыртып алып чыгып китә.

Арбага ярык казан, ярты табак он, ярты калак тоз салып алалар. Бик күп вакытлар барганнан соң, адәм үтә алмаслык кара урманга барып керәләр. Урман эче буйлап күп җирләр барганнан соң, бер агач төбенә туктыйлар. Әтисе кызына шушы җирдә казанын асып, оныннан умач уып, тозын салып, аш пешереп торырга куша.

— Ашың пешеп чыгуга, мин әйләнеп килермен әле. Мин якында гына утын кисә торыйм, минем утын кискән

тавышларым ишетелеп торыр, — ди дә атына утыра да китә.

Кызның әтисе бер биек агач башына имән тукмак аса да үзе качып кайтып китә. Имән тукмак җилгә тирбәлеп агачка так-ток, так-ток итеп бәрелеп тора, ди. Кыз аш пешерергә куя, әтисе һаман килми. Аш пешеп чыга, әтисе һаман да юк. Так-ток, так-ток итеп утын кискән тавышы гына ишетелә. Көтә торгач, кыз арып бетә, шомлана башлый да тавыш ишетелгән якка килсә, ни күзе белән күрсен — агач башында бер имән тукмак асылынып тора, ди. Шуның тавышы балта тавышы булып ишетелгән икән. Кыз хәзер эшнең нәрсәдә икәнлегенә төшенеп ала. Тәгәрәп-тәгәрәп елый да бер якка чыгып китә. Күпме генә йөрсә дә, күпме генә тырышып караса да, урман читенә барып җитә алмый. Һаман да шул биек, эре агачлар. Агач арасыннан күк йөзе чак-чак кына күренә. Ул агач җиләкләре, гөмбәләр, бөреләр ашап тамак туйдыра.

Менә бердәнбер вакыт еракта: «Һайт та һайт, һайт та һайт», — дигән тавышлар ишетелә.

Кыз шул тавыш ишетелгән якка китә. Этләр ияртеп, мылтыклар асып, һайтылдап кычкырышып, кызның каршына сунарчылар килеп чыга. Алар икенче бер якта яшәүче бер бабайның оланнары була. Куян атарга сунарга чыкканнар икән. Авыллардан бик еракта булган бу урманда бер кыз баланың килеп чыгуына сунарчылар бик гаҗәпләнәләр, монда ничек килеп эләгүе турында сорашалар. Кыз баштанаяк барсын да дөрес рәвештә сөйләп бирә. Егетләр, аны җәлләп, үзләре белән бергә өйләренә алып кайтып китәләр. Малайларның әти-әнисе бу табып алган кызга үз балалары кебек күреп, мәрхәмәт белән карыйлар.

— Шундый матур, акыллы баланы ташлап качарга намусы җиткән ата нинди кеше икән, шуны күрсәң иде, — диеп үзара сөйләшеп тә алалар.

Берчак болар кыз турында бернәрсә дә белдермичә, кызның аталарын, әбие белән Явызны да кунакка чакы-

ралар. Кунаклар киләләр. Яхшы мәҗлес корыла. Мәҗлес барган вакытта хуҗа:

— Минем бер ятим хезмәтче малаем бар, шуны кертеп, ишеткән-күргәннәрен сөйләтеп алыйк әле, — ди.

Алдан сөйләшелгән буенча, кыз хезмәтче малай киемнәре киеп, ишек төбенә генә кереп утыра.

Малай:

— Ишеткәнемне сөйләсәм, буш булыр, күргәннәремне сөйлим әле. Болай булды. Урманга барганымда, этисе тарафыннан адаштырып калдырган бер кыз бала очраттым, — дип үзенең башыннан үткәннәрне бөтен дөреслеге белән сөйләп бирә.

Кыз сөйли бирә, аталары эшнең нәрсәдә икәненә төшенә баралар, ди. Шуннан килеп кызны да танып алалар да, анын-тоңын белмичә явызлык эшләгәннәре өчен үкенеп, кызларын кочаклап, түгелеп елыйлар. Шулай итеп, танышып, табышып бергә кунак булалар.

Иртәгәсен кыз кунакларга мунча яга, эссе башларга Явыз белән әбиен җибәрә. Алар барыр алдыннан мунча ташы өстенә бер куш учтай тавык тизәге алып барып сала. Картлар мунчага кергәч тә, кыз ишекне тыштан йозаклый да китә. Явыз бабай белән әбие шунда тончыгып үлә.

Ата-ана белән очрашу туй мәҗлесенә әйләнеп китә. Кызны урманнан табып алып кайткан егетләрнең иң яшенә кияүгә бирәләр: алар шул көннән башлап бер-берсен яратып йөргән булалар. Бик яхшы итеп туй үткәрелә. Авылдагы бер кешене дә калдырмыйча сыйлыйлар. Кызның этисе белән әнисе яшьләргә озын гомер, шатлык белән бәхетләр теләп, үзләренә кайтып китәләр.

Кияү белән кыз матур итеп дөнья көтә башлыйлар. Алар әле булса шулай дөнья көтеп, йон тетеп яшәп яталар, ди.

ХАҖИ ҚЫЗЫ

Борын заманда яшәгән, ди, бер бай. Аның бер улы, җитеп килгән бик чибәр бер кызы булган, ди. Бу бай беркөн улы белән хаҗга китәргә уйлый, ләкин кызын калдырып китәр кешесе юк, ди. Ышанычлырак кеше итеп, кызын бер муллага тапшырып, улы белән икәү юлга чыкты, ди.

Мулла белән кыз бергә ашап-эчеп, бер йортта тора. Берничә көн үтүгә, кызга күзе төшеп, мулла төрле хәйләләр кора башлый. Ләкин кыз аны һичбер якын китерми. Хәйләле уйларын гамәлгә ашыра алмагач, ахырда килеп мулла кызны кысмакка ала башлый. Кыз һаман каршылаша. Түземе беткәч, авыл читендәге бер ярлы гына карчыкка барып, хәлен сөйләп бирә. Карчык аңа өенә кайтмаска киңәш бирә.

— Әтиеңнәр кайтканчы, үземдә торып торырсың, — ди.

Кыз өенә кайтмый, шул әбидә тора башлый. Мулла бу кызга ачу итеп, аталарына: «Кызыгыз тәмам азды, көн дә егетләр китерә. Читтә куныи кайта, егетләре тәрәзәләрне ватып бетте», — дип хат яза. Әтисе хатны алып укый да улына:

— Син хәзер кайт та сеңлеңне үтер, күзем күрмәсен шуны, — ди.

Егет кайта. Күрә, чынлап та, тәрәзәләр ватылган, кыз өйдә юк. Мулла:

— Менә шулай азды. Хәзер кайтмый да башлады инде, — ди.

Егет кызны эзләргә тотына. Эзли торгач, таба да ни эш белән килүен сөйләп бирә. Кыз абыйсына:

— Минем һичбер гөнаһым юк. Миңа мулла үзе кызышты. Шуңа мин менә шушы әби янында сез кайтканчы торып торырга булдым, — дип, башыннан үткән хәлләрне сөйләп бирә.

Егет сеңлесен бик җәлли, үзе нишләргә дә белми: әтисенең әмерен җиренә җиткерергә тиеш, җиткермәс иде,

әтисеннән курка. Ахыр читтә сеңлесенә әйтә дә икәүләп калын урманнар арасына кереп китәләр. Бик күп җирләр баргач, кара урман уртасында абыйсы:

— Мин сине үтерә алмам инде. Кулым бармый. Сине кызганам. Син шушы урманда кал. Исән калсаң, калырсың, исән калмасаң, үләрсең. Син хәзер бездән аерыласың инде, — ди дә кызның ялгызын калдырып, урман арасына кереп югала.

Кыз, кайда барганын үзе дә белми, бер яры чыга да китә. Күп җирләр үтә, күп сулар кичә. Бик ачыга бу. Ни туры килсә, шуны ашый. Өс-башлары ертылып бетә. Кеше күзенә күренер җире дә калмый. Бара торгач, арып, ачыгып, хәлдән тайганда, бер күл янына килеп чыга да шуның янындагы бер агач башына менеп утыра. Бераз вакыт үткәч, бу күлдә үрдәкләр атарга дип, бер сунарчы егет килә дә агач башындагы кызны күреп, аның ни икәнен белми, атарга итә. Кыз кычкыра:

— Әй, егет, мине атма, мин адәм баласы. Минем гөнаһым юк, — ди. Егет аптырап китә дә:

— Алай булса, төш, минем яныма кил, — ди.

Кыз аңа:

— Минем өс-башым бик начар, ертылып беткән, төшәргә оялам, — ди.

Өстендәге киемен сала да егет, үзе читкә китеп тора. Кыз төшеп киенеп, егет янына бара. Егет кызны күреп аптырап кала. Кыз искиткеч чибәр, ләкин үзе бик ябык, ди. Сунарчы егеткә кыз үзенең башыннан үткән вакыйгаларны сөйләп бирә. Егет аны бик кызгана.

— Әйдә, бергә кайтыйк. Мин сине сөям, үземә хатын итеп алам, — ди.

Кыз каршы килә.

— Минем кебек урманнан табылган кеше ничек итеп сезгә тиң була алсын инде. Сез, мөгаен, бер зур кешенең баласыдыр әле, — ди.

Егет аңа:

— Әйе, мин патша улы, — ди дә үзенең теләген кабатлап әйтә.

Кыз аптырап-аптырап тора да риза була.

— Ләкин җиде ел үткәч, җиде көн дә тормый, мине әтиемнәргә илтеп күрсәтерсең, — дип үзенең шартын да әйтә.

Егет риза була. Кызны алып кайтып тәрбия кылдыра. Ашаттыра, эчертә, яхшы тәрбияләтә. Бер айдай вакыт үтүгә, кыз көрәеп, тазарып китә, дөньяда тиңе булмаган чибәр кызга әйләнә.

Шушы вакытта аталары егетне чакыртып алып:

— Син үсеп җиттең инде. Сине өйләндерергә вакыт. Без сиңа фәлән патшаның кызын димлибез, шуны сиңа алып бирмәкче булабыз, — диләр. Егет аталарына каршы:

— Минем яраткан кызым бар. Мин шуңа өйләнер идем, — ди.

Аталарының кызны күрәселәре килә. Егет үзенең кызын бик яхшы итеп киендерә дә аталарына китереп күрсәтә. Кызны күргәч, ата-ана улларының теләге белән килешмәскә чара тапмыйлар. Боларның ике баласы була. Патша улы генерал булып, атасына хезмәт итә, эше буенча төрле якларга чыгып йөри. Киткән саен хатыны сагынып, көтеп алыр була. Хатыны көнне, елны исәпләп кенә тора.

Бервакыт боларның кавышуына җиде ел тула. Җиде ел тулып, өч көн үтеп китә. Ире сәфәр чыгып йөреп, моны онытып китә. Эшен бетереп, беркөн кайтып керсә, бичәсе каршы да чыкмый, өйгә керсә, эндәшми дә. Генерал бик аптырай. «Моңа ни булды икән?» ди. Бичәсеннән сәбәбен сорый — бичәсе эндәшми. Генерал ялына башлый. Шуннан соң бичәсе аңа әйтә:

— Җиде ел тулып узды, син вәгъдәңдә тормадың, — ди.

Генерал гафу үтенә, эш белән онытып ташлавын белдерә дә:

— Хәзер иленә озатам. Үзем һаман да бара алмыйм, мөһим эшләр бар. Тагы командировкага китәм, — ди.

Әмма кем белән озатырга? Ышанычлы кеше юк. Шуннан патшаның бик хыянәтсез вәзиренә ышанып, ике баласы белән корабта озатырга була.

Юлда бу хатынга әлеге вәзирнең күзе төшә. Уңай вакыттан файдаланып калырга уйлый. Хатын һич якын килми. Вәзир төрле хәйләләр кора, куркытып та карый. Һаман эш чыкмый. Ахыр чиктә бу хатынның бер баласын суга ташлый. Хатын һаман риза булмый. Икенче баласын да ташлый вәзир, тик һаман да эш чыгара алмый. Иң соңында бу хатынга:

— Хәзер үзеңне суга ташлыйм, — ди.

Хатын:

— Ташласаң, ташларсың инде, — дип һаман каршы килә дә котылып булмасны сизгәч, ахырда: — Ярый, риза булам. Мин хәзер чишенәм, соңрак килерсең, — ди дә бүлмәгә бикләнеп, чишенә дә эчке күлмәкчән генә суга ташлана.

Вәзир кире урап керсә, хатынның күлмәкләре генә ята, үзе юк. Шуннан соң вәзир матрослар белән борылып кайта да патшага, хатынның ире генералга:

— Теге хатын кеше затыннан булмаган икән. Ике баласын ашап бетте дә, үзе очып китте, бездән качты, — ди.

Суга ташланган хатын бик күп йөзеп баргач, ярга житә. Яр буеннан ук куе урманнар башлана. Ул агачларга ябышып кына чыга да тагы урман белән китә. Үзенең кайда барганын да белми. Бара торгач, бер шәһәргә барып чыга. Шәһәргә керергә өс-башында юк. Аптырый. Шәһәр янына килә дә башын гына калдырып юл буендагы тирескә күмелеп ята. Шушы вакыт шәһәрнең бер зур врачы командировкадан кайтып килгәнендә, бу башны күреп, туктый да карый. Караса — теге кеше башы. Врач сораша. Хатын мәсьәләне сөйләп бирә. Врач өстендәге халатын салып бирә дә бу хатынны үзе белән алып китеп, больницага сала. Хатын ашый-эчә, ял итә, тазарып китә.

Врач бу хатынны яратуын белдерә. Хатын каршы килә, азак кача.

Тагы бик ерак китә. Бара торгач, тагы бер шәһәргә барып чыга. Анда шәһәр читендәге бер ярлы гына карчыкка керә дә шәһәрдә эш эзли башлый. Эзли торгач, бер байга сату эшенә керә. Бик яхшы эшли башлый. Халык бу хатынга кызыгып, кирәксә-кирәкмәсә дә килеп тора, товарын сатып алып китеп тора.

Бу хатын бераз акча җыеп хәлләнә дә үзенә генерал киеме тектерә, аннан кулына бер наган тотып ала да бу шәһәрдән чыгып китә.

Бара торгач, хатын бер зур суга килеп җитә. Көймә сорый. Моңа бер егет көймә бирә. Бу хатынны күрү белән аңа егетнең күзе төшә. Су уртасына тиклем килеп җитә дә егет көймәне ишми, хатынны шаярта башлый, көймәне чайкалдыра. Хатын капыл кесәсеннән наганны чыгара да:

— Аръякка чыгарасыңмы, юкмы? — ди.

Егет шыр... Тиз-тиз генә көймәсен ишеп, хатынны чыгарып җибәрә. Бара торгач хатын ире торган шәһәргә барып җитә. Шәһәрдә патша: «Генерал кирәк», дип белдерү тараткан була. Чөнки бу хатынның ире генерал, аны нык яратканга, аның турында яман хәбәр ишеткәч, кайгысыннан эчүгә салышып, бик яман алкоголикка әйләнгән иде, ди. Төрмәгә керүче дә, канау буенда ятучы да шул иде, ди. Бу хатын генерал киемнәрен киеп, патша генералы булып хезмәткә керә. Генерал булып эшли башлагач, элекке ире белән төшкән карточкаларын табып ала. Табып алгач, аларны күбәйттерә дә почмак саен ябыштырырга куша. Кем дә кем килеп карап, аны таныса, шунда ук тотып алып хибескә* ябарга әмер бирә.

Бервакыт бу хатынның аталары өендә калган мулла бу карточканы килеп карап торса, тотып алып китәләр дә ябып куялар. Хатын-генерал бу кешене килеп карый да эндәшми. Аннан соң патшаның вәзире килеп карый. Аны

---

* *Хибес* (арх.) — төрмә.

да тотып ябып куялар. Аннан врач килеп карый, аны да ябалар. Көймәдә чыгаручы егет тә килеп карый, аны да ябып куялар. Ахырда бу хатынның ире килеп, аптырап карап торганда, аны да ябып куялар. Беркөн хатын-генерал бу кешеләрне хөкемгә чакырта. Иң әүвәл мулланы чакырта да сораша:

— Син бу карточкага нигә карадың? Кемне таныйсың? — ди.

Мулла бу хатынның аталарын алдап хат язуынча җавап бирә.

— Бу шул кыз булырга тиеш, — дип тора идем, ди.

Хатын:

— Алдыйсың, оятсыз мулла, — ди дә шунда ук йөз розга сугарга әмер бирә.

Мулла урыныннан калкып та тора алмый. Аннан соң вәзирне чакырта. Вәзир дә бу хатын турында аның иренә, патшага алдап әйткәнчә җавап бирә:

— Бу хатын шул булырга тиеш бит дип карадым, — ди.

Хатын моңа да йөз розга суктыра.

Чакырта врачны. Врач вакыйганы сөйләп бирә. Хатын-кыз генерал:

— Синең шулай ярдәм итүең өчен рәхмәт, әмма ләкин моннан болай һәрбер яраткан хатынга алай карама. Һәрбер матур хатын синең хатының була алмас. Бар кайт, — ди.

Көймәдә чыгаручы егеткә дә:

— Моннан болай очраган бер хатынга алай итмә. Бар кайт, — ди.

Иң азак үзенең элекке ирен чакырта да шундый ук сорау куя. Ире егыла да китә, егыла да китә — бер сүз дә әйтә алмый, бу хатынны танымый да. Хатын аны яңадан яптырып куя.

— Азак килерсең, — ди.

Шуннан хатыннар киеме кия дә ирен тагы чакырта. Эчкече генерал бичәсен таный да иссез булып егыла. Ан-

нан соң ис җыеп, сөйләшәләр, аңлашалар да кабаттан кушылып, өр-яңадан рәхәтләнеп тора башлыйлар.

БАТЫЙМАКАЙ

Борын-борын заманда яшәгән, ди, бер әби белән бер бабай. Аларның уллары, киленнәре, Батыймакай исемле кызлары булган, ди.

Бердәнбер көнне җиңгәсе белән Батыймакай су буена кер чайкарга китә. Болар, эшләрен бетергәч, үзара бәхәсләшә башлаганнар, ди. Җиңгәсе, ачуланып, Батыймакайны су төбенә төртеп төшереп җибәргән.

Кич булган. Караңгы төшеп килгән вакытта, Батыймакайның өйдә юклыгын белеп, каената белән каенана киленнәреннән кызларын сораша башлыйлар. Киленнәре берни дә әйтми, ди.

Шуннан соң кызның әтисе, эзләп, су буена киткән. Су буена барганда, болай дип такмаклаган:

— Җирдәме син, Батыймакай,
Күктәме син, Батыймакай?..

Ә кызы әтисенә болай дип әйткән:

Җирдә дә юк, атакай,
Күктә дә юк, атакай.
Кара бөдрә чәчләрем
Тал төбендә, атакай.
Ап-ак, ап-ак йөзләрем
Су төбендә, атакай.

Тимер ыргак китерсәң,
Чыгар идем, атакай.

Этисе тимер ыргак алып килергә киткән, ди. Тимер ыргак китергән, ләкин кызын чыгара алмыйча, кире өйләренә кайтып киткән, ди.

Әтисе кайткач, Батыймакайның абыйсы су буена килгән дә әтисенең сүзләрен кабатлаган:

— Җирдәме син, Батыймакай,
Күктәме син, Батыймакай?

Кыз такмаклап җавап биргән:

— Җирдә дә юк, абыкай,
Күктә дә юк, абыкай.
Кара бөдрә чәчләрем
Тал төбендә, абыкай.
Ап-ак, ап-ак йөзләрем
Су төбендә, абыкай.
Тимер ыргак китерсәң,
Чыгар идем, абыкай.

Абыйсы да тимер ыргак китереп чыгарып карый, чыгара алмыйча, кире кайтып китә.

Бер аю Батыймакай абыйсының тавышын ишетеп тора да, абыйсы китү белән, су янына килә.

Аю калын тавыш белән:

— Җирдәме син, Батыймакай,
Күктәме син, Батыймакай, —

дип акырып җибәргән, ди.

Батыймакай, аюның тавышын танып, аңа җавап кайтармаган. Аю тимерчегә телен чарлатырга киткән. Телен чарлатып килгәч, кызның әтисе булып эндәшкән:

— Җирдәме син, Батыймакай,
Күктәме син, Батыймакай?

Ә кыз, этием дип белеп, әлегечә җавап кайтарган:

— Җирдә дә юк, атакай,
Күктә дә юк, атакай.
Кара бөдрә чәчләрем
Тал төбендә, атакай.
Ап-ак, ап-ак йөзләрем
Су төбендә, атакай.
Тимер ыргак китерсәң,
Чыгар идем, атакай.

Бу сүзләрне ишеткәч тә, аю, тимер ыргак белән су төбеннән кызны тартып алып, үз өенә алып кайтып киткән, ди.

Аю кызны өеннән җибәрмәгән, үзенә хатынлыкка алган. Батыймакай туган йортын сагына, аның кайтасы килә башлый. Аюдан рөхсәт сорап карый, ләкин аю аны җибәрми, ди.

Бердәнбер көнне Батыймакай күчтәнәч пешергән дә аюны өйләренә кунакка җибәрмәкче булган, ди.

— Мине өеңә җибәреп, үзең качмакчы буласыңмы? — ди икән аю.

— Нишләп качыйм, ди, син күчтәнәчләрне алып китәрсең, мин өй башына менеп утырырмын. Ышанмасаң, артыңа әйләнеп карый-карый барырсың, — дип әйтте, ди, Батыймакай. Шуннан гына аю риза булган.

Батыймакай өйләренең башына киле утырткан да, ана күлмәк кидереп, кеше ясаган. Ә үзе капчык эченә кереп яткан, ди.

Аю капчыкны күтәреп, Батыймакайлар авылына китте, ди. Үзе бара, үзе артына әйләнеп карый, ди. Авылга житәрәк аюга каршы этләр абалап чыккан икән, аю капчыгын ташлаган да кире чапкан, ди. Шуны гына көткән Ба-

тыймакай, капчыктан чыгып, этисе өенә табан йөгергән.

Ләкин Батыймакайга берсе дә ишек ачмаган. Шуннан соң ул сарык сараена кереп яткан. Аны төнлә бүреләр ашап киткән, ди. Тик бер-ике бөртек чәче генә торып калган, ди.

Иртәнчәк абыйсы печән арасыннан ике бөртек чәч табып алган да, скрипкасына куеп, уйный башлаган. Аның уйный башлавы була, скрипка кеше кебек җырлый башлый. Тавыш — Батыймакайныкы. Әтиләре аптырап китә. Ә Батыймакай болай дип җырлый, ди:

— Абыкаем, басып тартма,
Башкынаем авырта;
Билә-билә тартмасана,
Билкәйләрем авырта.
Миңа ишек ачмадың,
Хәзер килеп елатма.

Абыйсы скрипканы җан-фәрманга атып бәргән икән, алларына Батыймакай килгән дә баскан, ди.

Шуннан алар шатлыкларыннан елашып алганнар. Алар әле булса ал да гөл дөнья көтеп яталар, ди.

УБЫРЛЫ КАЕНАНА БЕЛӘН БАХЫР КИЛЕН

Элекке вакытта түбәсез алачыкта яшәгән, ди, бер убырлы карчык. Ул карчыкның кәсебе шул булган: җәйге җиләк вакытында болынга килеп, яшь кызларны алдап, үзенә алып китә дә юк итә, алып китә дә юк итә икән. Шуннан авылдагы кызлар куркышып, җиләккә йөрми башлаган. Ахырда бу карчык чишмә буена, кызларның су алырга төшкән җиренә килә башлаган.

Шулай бервакыт, иртәнчәк, авылдагы бик уңган бер кыз суга төшкән. Төшсә, алдында бик матур бер егет басып тора, ди. Кыз тәүдә оялып карамаган, азак күз кы-

рые белән генә карап алган икән, теге егет йөрәгенә кергән дә утырган, ди.

Икенче көн кыз шулай иртәнчәк суга төшсә, теге егет тагы да шунда тора, ди. Кызның йөрәге җилкенеп киткән. Егет:

— Яучы җибәрәм, миңа киләсеңме? — дигән.

Кыз җавап бирмәгән, бу хәлгә тәмам аптыраган. Суын алган да кайтып киткән. Кайтып керсә, өйгә яучы килгән. Кызны көтеп утыралар, ди. Кыз бер сүз дә эндәшмәгән. Әти-әнисе ризалык биргән. Шуннан бик әйбәтләп туй ясап, кунаклашып алганнан соң, кызны озатканнар.

Киләләр, ди, егет белән кыз, киләләр, ди, килгән саен кияүнең матурлыгы югала бара, ди. Кыз бер сүз дә эндәшми, шым гына килә. Куркып та китә бу бахырың. Шулай болар бер урманга килеп керделәр, ди; урманга кергәч, теге егет бөтенләй ямьсезләнеп, шөкәтсезләнеп калды, ди. Бу егет убырлы карчыкның улы икән, убырлы карчык аны шулай төрле сурәткә кертеп йөртә икән. Тешләре ыржайган, танавы кәкрәйгән, колагы чоңкасында, күзе маңгаенда, ди.

Кыз бик курыккан, кайгырган, әкрен генә елап та алган, ди. Шулай болар убырлы карчыкның алачыгына кергәннәр.

Карчык киленне каршы алган.

— Әйдә, килен, хуш килдең, — дип янына килгән дә арбадан бәреп төшергән, ди. Тукмый-тукмый эшкә кушкан, ди, бахыркайны.

Бахыр килен шулай эшләгән дә эшләгән, ди, еламыйелый. Убырлы карчык тегенең җилкәсеннән төшмәгән.

Берчак шулай килен үзенең туган-үскән, кендек кискән җиренә кунакка барып килергә уйлаган. Тик бахыр киленнең кунакка барырлык рәте-әмәле булмаган: ашап, ашка туймаган, киеп, киемгә куанмаган, дөнья көтеп, дөньяга котаймаган. Киндер күлмәк, үлән чәй, әче катык, каты икмәк белән генә көн күргән. Килен боеккан да боеккан, сарыга сабышкан. Беркөн килеп, тәрәзә аша өй ар-

тындагы каенга караган да зарланып кына елап җибәргән:

Агач башы шау-шу итә,
Кешеләр кунакка китә.

Явыз каенана моны ишетеп калган да:

— Көлчә пешер дә син дә кит! — дигән.

Килен күп кенә көлчә пешергән дә киеп барырга күлмәк эзләп, авылга чыгып киткән. Кайтуына каенанасы бөтен көлчәсен ашап бетергән, бары берне генә калдырган, ди. Бахыр килен:

— Әй-әй, каенанакаем! Көлчәләрем кайда булып беткән икән? — дип елап җибәргән.

Явыз каенана тагы ырылдап кычкырды, ди:

Һай, килен, килен, килмешәк,
Үлә алмаган бер ишәк!
Пешерә белгәч, ашерә дә бел иде,
Өй кыегына эл иде.
Эре тычкан ашагандыр,
Баз астына ташыгандыр.

Килен шулай иске өйгә бара алмый, әти-әнисен күрә алмый калды, ди.

Икенче көн килен тагы:

Агач башы шау-шу итә,
Кешеләр кунакка китә, —

дип елый икән; усал каенана:

— Көлчә пешер дә син дә кит! — дигән.

Килен янә көлчә пешергән. Үзе бу юлы аягына эзләп чыгып киткән. Кайтуына убыр каенана көлчәләрен янә ашап бетергән, бары берне генә, майламый куйган көлчәне генә калдырган.

Бахыр килен кайтып:

— Әй каенанакаем, көлчәләрем тагы юк булган, — дип елап җибәргән.

Убыр каенана тагы ырылдап кычкырды, ди:

Һай, килен, килен, килмешәк,
Үлә алмаган бер ишәк!
Пешерә белгәч, яшерә дә бел иде,
Җир астына кертеп эл иде.

Бахыр килен тагы иске өйгә бара алмый, эти-әнисен күрә алмый калды, ди. Бахырың өченче көн тагы моңланды, ди:

Агач башы шау-шу итә,
Кешеләр кунакка китә.

Явыз карчык тагы кычкырды, ди:

— Көлчә пешер дә син дә кит!

Бахыр килен бу юлы көлчәне пешерә дә җир астына кертеп элә.

Шуннан башына бәйләргә шәльяулык эзләп чыгып китә. Кайтуына, элеге дә баягы, бер генә көлчә исән калган, ди. Киленнең аптыравына каршы убыр каенана, төкерек чәчеп, тагы кызып китте, ди:

Һай, килен, килен, килмешәк,
Үлә алмаган бер ишәк!
Пешерә белгәч, яшерә бел!

Шуннан бахыр килен аптырап йөри-йөри дә шул көе генә китәргә була. Баласын алды да, ди, калган өч көлчәне салды да китте, ди, юлга чыгып. Убыр карчык тегенең артыннан куа чыга. Үзе куа, үзе такмаклый, ди:

Һә дигәнче тотармын,
Башыңны өзеп йотармын!

Килен бер көлчәсен ташлап җибәрде, ди. Убыр карчык аны чәйнәми дә йотты, ди. Бераз үтүгә теге карчык бөтенләй якынайды, ди:

Һә дигәнче тотармын,
Башыңны өзеп йотармын!

Бахыр килен көлчәләрен берәм-берәм ташлап бетерде, ди. Карчык һаман җир ертырдай улап килә, ди:

Һә дигәнче тотармын,
Башыңны өзеп йотармын!

Килен, аптырап, бер бармагын өзеп алды да артка табан ыргытты, ди. Бераз гына йөгергәч, теге убыр тагы җитә башлады, ди. Килен тагы бер бармагын өзеп ташлады, ди. Килен шулай бармакларын өзеп, берәм-берәм ташлап бетерде, ди. Сул кулын өзеп ыргытты, ди. Теге карчык баласын сорый, ди, бит хәзер, каһәр суккыры! Килен баласын җәлләп бирми, ди. Ахыр чиктә иске өйгә килеп җитте, ди. Килеп җиткәч:

— Әнекәем, ишек ач! — дип эндәште, ди.

— Төнлә йөрер кызым юк!

— Әтекәем, ишек ач!

— Төнлә йөрер кызым юк!

— Җиңгәкәем, ишек ач!

— Төнлә йөрер каенсеңлем юк, каенсеңелем читтә, кияүдә.

Шул арада убыр каенана да, ах-бах итеп, килеп житте, ди. Килен, качып, сарык абзарына кереп китте, ди. Убыр карчык киленен табып, баласы белән икесен ашап бетереп, бары тик бер эчәгеи генә калдырып, абзар ишегенең тоткасына элеп китте, ди. Иртән торып, абыйсы тышка чыккач, эчәк күреп, өйгә сөрән салды, ди:

— Сарыкны бүре ашаган, эчәге генә калган!

Әтисе:

— Я, ашаса, ашар. Хәерле каза булсын. Әнә скрипканның кылы юк иде, киптереп кыл яса, — дип әйтте, ди.

Абыйсы кыл эшләп, скрипкасын уйнатып җибәрсә, яңа кыл үзәккә үтәрлек моңлы итеп җырлый, ди:

Әни ишек ачмадың —
Убырлы карчык ашады.
Әти, ишек ачмадың —
Кодагыең ашады.
Җиңгәм, ишек ачмадың —
Убыр хатын ашады.
Абый, ишек ачмадың —
Убыр каенана ашады...

Моны тыңлагач, өйдәгеләр эшнең нидә икәнен аңлап зар елашып алдылар, ди. Шуннан абыйсы скрипкасын кулга алып, теге убыр карчыкка китте, ди.

Барып керсә, карчык юк. Өйдә бер бик матур кыз утыра, ди.

— Хуш килдең! — дигән була, ди, кыз кыланып.

Егет скрипкасы белән кызның башына берне суккан икән, теге бер гыйфриткә әйләнгән. Егет скрипкасын куеп, кылычы белән башына чапкан икән, гыйфритнең башы аз гына өзелми калган. Шуннан теге ике башлы зур еланга әйләнгән. Егет кылычын алып, тагы селтәгән дә ике башын берьюлы өзеп куйды да, ди, индс ут кабызып яндырыйм гына дигәндә, бер тавыш ишетте, ди:

Абыкаем, яндырма,
Безне монда калдырма!

Шуннан теге егет әрдәнә кебек туракланып өелгән елан гәүдәсен актарырга тотынды, ди. Берсеннән бу егетнең сеңлесе килеп чыкты, икенчесеннән аның баласы килеп чыкты, ди. Кочаклашып елашып, бергә кайтып кит-

теләр, ди. Кайткач, барсы да бик шатланышып, бергә-бергә гомер иттеләр, ди.

Теге егетнең скрипкасы әле булса уйный икән, уйнаганда җырлый икән:

Убырга ишек ачмагыз,
Киленегезне какмагыз,
Киленегез ач йөрмәсен,
Мин күргәнне күрмәсен...

Халык җыелып тыңлый, ди, скрипка көйли, һаман да шул хәбәрне сөйли, ди:

Киленегез ач йөрмәсен,
Мин күргәнне күрмәсен...

МӘКЕРЛЕ ҖИҢГИ

Борын-борын заманда бер әби белән бабай яшәгән. Аларның бер улы, бер кызы булган. Алар бик хәлле яшәгәннәр. Балаларын яхшы тәрбия биреп үстергәннәр. Бабай улына кәләш алып биргән. Шулай тату гына гомер иткәннәр.

Беркөнне бабай авырып китә. Авырып киткәч, улына васыять әйтеп калдыра:

— Туганыңны ятимсерәтмә, яхшы кара, — ди.

Бабай белән әби үлеп киткәннәр, агасы өй хуҗасы булып калган. Ул сеңлесен читләтмәгән, яхшы караштa булган, аны кадерләгән. Эштән кайткач, тәүдә туганыннан саулык сораган. Азак хатынына саулык биргән.

Хатыны туганын абыйсыннан көнләшә башлый. Аны ничек булса да суындырырга тырыша.

Бу егетнең лавкасы була. Үзе бер якка китсә, ачкычны туганына бирә торган була. Туганы һәрвакыт лавкага кереп уйнап йөрер булган.

Бердәнбер көнне җиңгәсе, кыздан ачкычны алып, лавкага керә дә бөтен савыт-сабаларны кырып чыга, абыйсы кайткач, туганы дөресен әйтә алмый, җиңгәсеннән курка. Җиңгәсе:

— Әнә, күр туганыңны, барысын да кырып бетте, — дип ялганлый.

Абыйсы:

— Ярый, мин аны үзем табам, ярылсын әйдә, — ди дә тагы эшкә китә.

Аның сунарга йөри торган бик яхшы аты белән эте бар икән. Җиңгәсе, ялганлап җиңә алмагач ирен, сунар аты белән этен үтерә. Абыйсы эшеннән кайткач, туганыннан саулык сорый.

— Син, аны кадер итеп, аннан алда саулык сораган буласың, ә ул сине эшкә санамый, атыңны да, этеңне дә үтерде, — ди җиңгәсе. Абыйсы атына да, этенә дә кайгырмый.

— Табылыр әле, баш сау булсын, — ди.

Туганы жаныннан артык күргән атын үтерсә дә, мине эшкә санамый, туганын кадерли, ди дә хатыны үзенең имчәк баласын үтерә. Агасы эштән кайткач, тагы да туганыннан саулык сорый. Хатыны тагы әләкләшә, ире эндәшми, тик утыра.

Бердәнбер көнне абыйсы еракка, лавкага вак-төяк китерергә дип, юлга чыга. Барып җитеп, әйбер алгач, туганына, кайчан кайтасын белдереп, хат яза. «Туганым, сине кадер иткәнгәме, минем юлым бик уңды. Бер өлешкә ун өлеш алдым. Шулкөнне фәлән сәгатькә кайтып җитәрмен», — ди.

Җиңгәсе хатны алып укый да хәйлә кора башлый. Күрше егетен йөз сум акчага яллый.

— Син минем ирем кайту белән тәрәзә чирт. «Әйдә, чык. Нигә чыкмыйсың? Абыеңның кайтырын белмәдеңме? Нигә вәгъдә бирдең?» — дип әйт, — ди.

Абыйсы әйткән вакытына кайта. Сеңлесеннән дә, хатыныннан да саулык сорый. Чәй эчәргә утырсалар, теге егет килә дә кызны чакыра. Абыйсы эчәр чәен эчә алмый, кире утыра.

— Мин сине кадер итеп, эшләгән җинаятьләреңне дә онытып килдем, ә бу хурлыкка түзә алмыйм, — ди. Тарак балта алып, ул туганын үтерергә була. Төнен аны күл буена алып бара, үтерергә җәлли. Чишендереп, киемен суга ташлый да ике кулын кисә. Туганын шунда калдырып, үзе кайтып китә. Кыз елый-елый йоклап китә.

Таң ата, кояш туып килгән чакта күл буйлап бер сунарчы килә. Бу патша улы икән. Кыз ялангач булгач, оялып күлгә төшеп утыра. Егет кызны күреп кала, кыз бик сылу булганга, аны егет су иясе дер дип уйлый.

— Син ни эшләп монда утырасың, син кемсең? — дип сорый патша улы. Кыз егеткә башыннан үткән хәлләрен сөйләп бирә. Егет кызны бик нык ызгана.

— Син риза булсаң, мин сине алып кайтам, бергә торырбыз, — ди. Кыз риза була.

— Тик минем ике кулым да юк, — ди.

— Ике кулың булмаса да мин сине килеп алырмын, — дип, патша улы кайтып китә. Кием китереп, кызны киендереп алып кайта. Бергә дөнья көтә башлыйлар. Егетнең этисе дә, әнисе дә киленнәрен бик яраталар.

Беркөнне патша улын икенче бер патшалыкка киңәшкә җибәрә. Егет киткән чакта этисенә:

— Әгәр улым туса, солдат җибәрегез, кыз туса, хат җибәрегез, — дип әйтеп китә.

Егет китә. Берничә көннән соң аларның улы туа. Патша бик нык куана. Улына сөенчегә солдат та, хат та җибәрә. Солдат юлга чыга, бер авылга килеп бер хатынга фатирга төшә. Бу хатын кызның җиңгәсе булып чыга. Җингәсе солдатның кайда, ни йомыш белән баруын со-

рый. Солдат сөйләп бирә. Җиңгәсе кызның кем икәнен белеп кала. Ул солдатны мунча кереп чыгарга кыстый башлый. Солдат юлдан арып килгәнгә, тиз күнә. Киемен өйдә чишә дә мунчага китә. Җиңгәсе хатны алып укый. «Балам, бик матур таза улың туды. Без бик шатбыз», — дип язылган була. Җиңгәсе бу хатны ертып ташлый да үзе хат яза: «Менә, адәм сурәте күрмәгән ул тапты. Бездән адәм көлә. Патша булып безгә мондый киленне тотуы оят. Ни эшләтик?» — дип яза. Хатны кесәгә кире сала. Солдат, мунчадан чыгып, киемен ала да үз юлына китә.

Патшаның улы теге патшаларга үзенең бик матур хатыны булуын, тик ике кулы булмавыннан зарланып сөйләгән икән. Патшалар җыелып утырган чакта, солдат барып төшә. Егет урыныннан ыргып тора. Солдатны шатланып каршы ала, хатны алып укый. Бер сүз дә әйтми, хатны кесәсенә салып куя. Иптәшләре:

— Нигә безгә укымыйсың? — дип үпкәли башлыйлар. Хатны егеттән басып алып укыйлар да көлә башлыйлар.

— Сиңа, патша улына, мондый хатын белән торуы оят. Әти-әниеңнең рәнҗүен алма, икенче матур кыз ал! — диләр.

— Начар булса да, мин кайтканчы яшәсен, бала минеке, — дип хат язып җибәрә патша улы.

Солдат кайтканда тагы әлеге авылга төшә. Кызның җиңгәсе көтеп торган була. Солдатка мунча ягып әзерләп куя. Солдат аны-моны уйламый, тагы мунчага китә. Җиңгәсе хатны укып карый да ертып ташлый, яңадан хат яза: «Ярый, бик яхшы, минем матур улым булган икән. Тик минем андый хатын белән торасым килми. Иптәшләрем көлә. Кайдан китергәнбез, шунда алып барып ташлагыз. Мин кайтканчы, аны юк итегез».

Солдат кайта, хатны кызга бирә. Кыз укый да елап җибәрә. Каенатасы белән каенанасы:

— Нигә елыйсың? — дип сорыйлар.

— Менә, улыгызның хаты, — ди кыз.

— Улым үзе килмичә без бернәрсә дә эшли алмый-

быз. Аның килүен көтәбез, — диләр каената белән каенана.

— Сез шулай итәсез дә, улыгыз килгәч, миңа кыен булыр. Мине хәзер алып барыгыз. Ни күрсәм дә, мин күрим, — ди килен. Бик елагач, каенатасы киленен алып барырга риза була. Баланы сандыкка салып, киленнең муенына асалар. Азык салып, чатыр корып, киленне урманда калдырып, елый-елый хушлашып, кайтып китәләр.

Килен, чатырда туенып алгач, су эчәргә дип күлгә бара. Иелеп су эчкәндә, баласы күлгә төшеп китә. Кулы булмагач, ала алмый. Елап-елап чатырга кереп йоклый.

— Елама, балаңны чыгып ал! — дигән тавышка уянып китә. Чыгып караса, чынлап та, бала судан калкып чыккан була. Йөгереп барып, баланы алам дисә, күлдән кулы ялганып чыга. Ике кулы да булгач, шатланып баласын ала. Аны имезә, үзе дә туеп алгач, ул юлга чыга. Хатын авылдан-авылга йөреп, орчык белән йон эрләп, тамак асрап йөри. Баласы йөрерлек булгач, бу хатын тегүче эшенә өйрәнеп ала. Оста тегүче булып китә. Тирә-якка тегәргә йөри. Аның оста тегүче дигән даны тарала. Ир-аттан саклану өчен хатын чәчен кистереп, ирләр киеме киенеп йөри икән. Аны ир кеше дип уйлыйлар. Абыйсы белән җиңгәсе дә оста тегүче хакында ишетәләр. Абыйсы аны алырга килә. Кыз матур итеп кием тегеп бирә абыйсына. Бу оста тегүче турында патша улы да ишетә, аны эзләп шушы авылга килә. Тегүче үзен танытмый. Патша улының аның сылулыгына исе китә. Үзенең хатынына бик нык охшата. Тегүчене үзенең өенә чакыра. Тегүче:

— Бүгенгә көт, иртәгә сезгә барырбыз, — ди. Егет көтәргә риза була.

Кыз абыйсына сигез йөз сум акча бирә дә:

— Мин бүген бер мәҗлес үткәреп китәм, сигез түрә китер, сигез тәгам китер, — ди. Абыйсы барын да китерә.

Җыелып ашарга утыргач, кыз:

— Мин сезгә бер хикәя сөйлим, мин сөйләгәнне кысыл-

мый гына тыңлап утырыгыз, — ди. Мәҗлес халкы риза була, ризалыкларын белдертеп, кәгазьгә кул куялар.

— Кем дә кем мин сөйләгәндә кысыла, шул кешегә йөз сум штраф, икенче тапкыр кысылганда алтмыш, өченчегә — йөз таяк җәза бирү, — ди кыз.

Тегүче үзенең башыннан үткәннәрен сөйли башлый. Кызның ат белән эт үтерү турында сөйләргә кучүе була, җиңгәсе түзә алмый:

— Сине без монда юк-бар сөйләргә китермәгәнбез, — ди. Бу хатыннан йөз сум штраф түләтеп алалар. Тегүче сөйләгәндә берсе дә кысылмый тыңлыйлар. Тик җиңгәсе генә өч тапкыр кысыла. Аны йөз алтмыш таяк белән суктыралар.

Сүзен сөйләп бетеп, җиңгәсен җәзага тарттыргач, кыз үзен таныта.

— Менә бу минем абыем, монсы җиңгәм, монсы хуҗам, монсы улым, — дип әйтеп бирә. — Мин үземне саклау өчен ирләрчә киенеп йөрергә булдым, — ди.

Шул җирдә кызның абыйсы хатынына:

— Тугыз өем утынга риза буласыңмы, әллә тугыз кысыр бия биримме? — ди. Җиңгәсе эшнең аешын аңламый.

— Тугыз кысыр бияне алам, — ди.

Бияләрне бер-берсенә бәйләп, иң арттагысының койрыгына җиңгәсен бәйләп җибәрәләр. Бияләр бер-берсеннән өркеп, тузып йөри башлыйлар. Теге явыз хатын бөтен халык күз алдында үлеп кала. Шул явыз хатынның чәче тигән җир тау, арты тигән җир күл булып калды, ди. Абыйсы яңадан хатын ала, болар тату гына гомер итә башлый. Патша улы да куанып бетә алмый. Ул, хатынын, баласын алып, үз иленә кайтып китә, бергә-бергә гомер итәргә тотыналар. Әле һаман да бу ятим кыз, патша хатыны булып, матур тормыш корып тора, ди.

КЕШЕ СҮЗЕ КЕШЕ ҮТЕРӘ

Элек бер әби белән бер бабай яшәгән. Аларның балалары булмаган. Байлыклары мул икән. Картая башлагач, үзләрен карарга, үлгәч, байлыкларын калдырырга кеше табарга уйлаганнар. Шулай эзли торгач, күрше авылдан болар бер тол хатын таптылар, ди. Хатын бик егәрле, таза иде, ди. Күңелләренә ошады, ди. Әби белән бабай моңа:

— Без үлгәч, дөнья сиңа кала, безне тәрбиялә, — диделәр, ди.

Байтак еллар үткән. Картлар, тәрбияле булгач, яшь биргәннәр. Картлар һаман үлмәгәч, хатын уйлана башлаган. Үзенең башы җитмәгәч, бер карчыкка барып, киңәш иткән бу. Карчык:

— Бабаеңа: «Синең карчыгың кеше белән йөри бит», — дип әйт. Әбиеңә: «Бабай кеше белән йөри бит», — дип әйт, — дигән, ди.

Бу хатын кайткан да тәүдә әбигә әйткән. Әби сорый икән:

— Нишләргә соң?

— Бабай йоклагач, сакалын кисеп ал да, яндырып, көлен бөтен тәненә ышкырсың. Шулай итсәң, бабай сине һич ташламас, — дигән.

Бабайга болай дигән:

— Бабай, әбиең өстеңнән икенче кеше белән йөри, саклан, сине үтерергә итәләр.

Бабай сакланып кына йоклап ята. Менә берчак әби пычак ала да бабайның сакалын кисәргә итә икән. Шул вакыт бабай: «Мине чалмакчы була икән бу», — дип сикереп тора да карчыгын үтереп тә ташлый.

Хатынның туганнары килеп, апаларын үтергән өчен, үлемгә — үлем, дип бабайны да үтерә.

Шулай итеп, дөньяга теге хатын хуҗа булып кала.

КЕШЕ БЕЛӘН ШАЙТАН

Борын заманда бер шайтан булган. Ул шайтан кешеләргә дошман булып, аларны үзара сугыштырып йөри икән, ике кеше дус булса, аларның арасын бозып, дуслыктан аерырга тырыша икән. Ул шайтанның бар эше шул булган.

Бервакыт бу шайтан бер сукыр белән бер саңгыраунын дус булганын күрә. Алар шундый дуслар, ди, су коеп та аерырлык түгел, ди. Шайтан аларның да арасын бозмакчы була. Тик эше һич унайламый, ди. Ничаклы тырышмасын, аларны ызгыштыра алмый, ди. Шайтан бөтен осталыгын салып карый — юк, булмый, ди. Ул тырышкан саен, сукыр белән саңгыраунын дуслыгы арта гына бара, ди. Аптырый шайтан.

— Гомердә мондый эш күргән юк иде әле, — дип, нишләргә белми, ди.

Шулай аптыраган-аптыраган да үзе кебек кеше арасын бозучы бер кешегә киңәш итеп караган.

— Әгәр шул сукыр белән саңгыраунын арасын бозсаң, ни сорасаң, шуны бирермен, — ди.

Теге кеше шайтаннан шул сүзне ишеткәч:

— Шулмы инде синең шайтанлыгың? — ди. — Мин аларны бер күрү белән сугыштырырмын, бер-берсен күралмаслык итеп суындырырмын, — ди.

Шайтан тагы аптырый. Теге кеше шайтанны ияртеп, сукыр белән саңгырау янына бара. Үзе шайтанга:

— Әй, син, шайтан, карап тор. Менә мин аларны ничегрәк ызгыштырам, — ди.

Бара да бу саңгырауны тышка чакырып чыгара. Чыгара да, өйгә ишетелерлек итеп, колагына кычкыра:

— Сукыр иптәшең өйдәме?

— Ул нәрсәгә кирәк? — ди саңгырау.

— Ул кирәген кирәк түгел, син булсаң да ярый.

Болар ни сөйләшер икән дип, сукыр эчтә тыңлап утыра, ди.

— Мин сезгә бик кыйммәтле бүләкләр бирәм. Аларның берсен үзеңә ал, берсен иптәшеңә бир. Икегезгә гадел итеп, тигез бүлешеп алыгыз, — ди теге кеше.

— Ярар, ярар. Кешенеке миңа кирәкми. Тапшырырмын, — ди саңгырау.

— Мә, алайса, монсы үзеңә, монсы сукырга, — дип, теге кеше моны уңлы-суллы чәбәкләгән, ди.

Саңгырау өйгә башын тотып килеп керә. Сукыр ак салган күзләрен пычкылдатып бер ачып, бер йомып:

— Кайда, кайда, китер, дус, теге кеше ни бүләк итте? — дип түземсезләнеп сорый. Саңгырау:

— Нәрсә бирсен? Берни дә бирмәдече, — дигән.

— Юкны сөйләмә, алдашма. «Берсе үзеңә, икенчесен иптәшеңә бир», дип әйтте бит. Мин ишетмәгән икән дисеңме? Ишеттем. Нигә бирмисең? Бир, — дип даулаша. Саңгырау:

— Әй дус, сиңа ул биргәнне бирсәм, ачуланырсың бит, белми сорап, буынны кырасың! — дип карый, ди.

Юк, сукыр алдына алганын куймый, ди:

— Бирмәсең, ачуланам, йә, йә, бир, — дип моңа омтыла да башлый.

— Алай бик тә сорагач, бирим инде, — дип киерелеп торып, сукырның яңак төбенә тондырды, ди, саңгырау. Сукыр:

— Ә-ә-ә? Иптәш, син мине үтерергә итәсең икән әле, үтереп бүләкне үзең генә алмакчы икәнсең әле, тукта әле! — дип тегеңә барып ябыша.

Болар чынлап сугыша башлыйлар, ди. Шулай итеп, дуслыктан бернәрсә дә калмады, ди.

Читтән тамаша кылып торган шайтан:

— Кешенең явызлыгы минекеннән яман икән, — дип бот чабып аптырады, ди.

ҚЫРЫК КАРАК

Борын-борын заманда бер әби белән бабай яшәгән, ди. Әби белән бабай дигәч тә, ялгыз түгел инде, берәү генә булса да кыз балалары бар иде, ди, боларның. Шул кыз бала зурайган, җиткән.

Хәзер йөриләр, йөриләр болар. Шуннан әби белән бабай еракка кунакка китәргә булдылар, ди.

Ялгыз торып калгач, кызлары ахирәтләрен җыеп, чыра яндырып, төнлә киндер эрлиләр, ди (чыра яндырмый, ни белән яктыртсыннар, лампа булмаган бит әүвәле).

Болар эрлиләр, эрлиләр, эрлиләр, ди, төнен. Шулай эрләп утыра торгач, бу өй хуҗасы кызның орчык башы базга төшеп китә. Шуннан соң ул:

— Уй, иптәшләр, орчык башым базга төшеп китте, төшеп кенә алыйммы икән, алмыйммы икән? — дип әйтә, ди.

Теге кызлар:

— Аласың инде, — дип әйтәләр, ди.

Шуннан бу базны ачып төшсә, бер кеше утыра, ди. Учына йомган, ди, теге орчык башын. Орчык башын тырнак очы белән генә тырнап алган да, ди, бу кыз чыккан да базны япкан да куйган, ди, хәзер. Курыккан үзе эченнән, иптәшләренә әйтмәгән, ди.

— Иптәшләр, булмаса, эрләмик, куй, ятыйк, ятыйк, — дип әйтә, ди.

Кызлар әйтә:

— Нишләп эрләмибез? Нишләп, эрлик әле, эрлик.

— Куй, ятыйк, куй, ятыйк, кызлар, чыра да бетте, — дигәч, ятканнар, ди, күмәкләшеп тезелеп.

Әүвәле сәке бит инде, бүтән нәрсә юк. Тезелешеп ятканнар да теге кызлар, шул арада йоклап та киткәннәр. Бу йокламый ята. Ята бу, ята, теге кешене карап ята, ди: «Чыкмый калмас, чыгар, мөгаен», дип. Шуннан, көтеп ятса, теге кеше баз капкачын күтәреп, иплән кенә килеп чыккан. Ул кырык каракның берсе булган, ди. Кызлар йоклаганны иптәшләренә әйтмәкче булып, урамга чыккан

икән, кыз торып, ишекләрен элгән дә яткан. Инде нишләргә? Бу килә бит инде тагын.

Теге карак килгән ишеккә. Килгән дә ишекне тарткан — ишек бикле. Хәзер тәрәзәне алып кына кермәкче була, бу кызны тотып алыргамы инде, тегеләрнең барсын да үтерергәме инде. Керәп кенә килә икән — бу кыз башын чабып өзгән дә куйган теге каракның. Хәзер гәүдәсе тышта, башы эчтә, ди, тегенең. Бу кыз нишләргә белмәгән. Теге кызлар йоклый, нишлисе икән? Башны алып тәрәзәдән ыргыткан да, ишекне тыштан бикләп, бертуган абзые бар икән якын гына, шуңа йөгергән. «Абзыема әйтим дә бернәрсә кылыйм», — дип уйлаган. Йөгереп барып, тәрәзәсен чирткән. Абзые чыккан:

— Абзый, әйдә әле безгә бар, мин берәүне үтердем бит әле, — ди кыз.

— Ай алла, ай алла, нишләдең, нишләдең? — дигән дә киенгән абзые, килгән.

Хәзер бу кыз белән абзые ат җигеп, алып барып таш бәйләп, бер күлгә ташладылар, ди, теге каракны. Шулай итеп, җыештырып кайтканнар, аңарчы таң аткан. Бу кыз, тегеләр торганчы, өйне җыештырып, идәннәрен дә юган. Бернәрсә дә сизелерлек түгел, ди.

Тегеләр тордылар, ди. Торгач та:

— Кайтабыз, кайтабыз, — ди башладылар, ди.

— Атак, нишләп бу хәтле агардың, нишләп бу хәтле агардың? Әллә берәр нәрсәдән курыктыңмы? — дип моннан сорашырга тотындылар, ди.

— Юк, курыкмадым, курыкмадым. Юньле йоклый алмадым, шуңа шулаймындыр, — дигән, ди, кыз.

Шуннан хәзер кызлар кайтып киткәннәр. Бу һаман да куркып: «Инде нишлим инде, нишлим? — дип йөри ди инде. — Боларның тагы берәрсе килер инде монда. Килер, килми калмас. Бу нинди галәмәт булды», — дип әйтә икән кыз.

Икенче көнне әниләре кайткан.

— Ай алла, балам, авырыйсың бит. Берәр нәрсәдән

курыктыңмы әллә? Төсләрең дә качкан, ябыккансың да, — дип әйткән, ди, энисе.

— Юк, курыкмадым, әни, бернәрсәдән дә курыкмадым, — дип әйтүдән башка эндәшмәгән, ди, кыз.

Шуннан әниләре белән әүвәлгечә дөнья көтеп торалар инде.

Бермәл бер кеше килгән боларга. Шулхәтле бай киемле, мәһабәт кеше, ди. «Нәрсәгә килгән икән бу кеше? Бу кеше тикмәгә килмәгән бит, мөгаен», дип уйлаган кыз. Бу кеше кыз сората, ди. Кыз җиткән булган бит инде. Җиткән дип ни, әүвәлге заман бит, булса, уналтыда йә унбиштә булгандыр инде күп булса.

— Шулай итеп, сезнең кызыгызны соратырга килгән идем әле. Шулай-шулай туй ясарбыз, шулай-шулай әйберләр алып килермен, — дигән теге кеше.

Энисе:

— Әллә шул. Безнең кыз берәү генә. Алай ерак җиргә бирмәбез, авылга гына бирербез. Бер генә бала бит, — дип әйтә, ди.

— Нишләп ерак булсын. Ерак дип ни, ят җир түгел бит. Бик ерак дисәгез, шунда да торырлар, — дип теге буран көчли*, буыннарына төшә, ди.

Көчләшә торгач, кичкә табан килешкәннәр болар. Әллә нинди басалы туннар, чапаннар, җиләннәр, кашмаулар алып килергә, энисен, этисен вич киендерергә, кызны да яхшы итеп киендерергә. Бу кыз шикләнүләрен әйтмәгән, риза булып калган.

— Фәләнчә көнне кияү килеп, шуннан яхшы туй ясарбыз. Сезнең якның чыгымын да үзебез күтәрербез, — дип кайтып китә теге.

Бер ике-өч көн үткән икән, теге кияү килгән мона. Бөтен нәрсәсен төяп, байлык белән килгән. Бу бахырлар ни, ярлы кеше, киемгә алданганнар инде. Кыз һаман шиген әйтмәгән. «Ай-һай, шуларның берсе инде. Алып китә

---

* *Буран көчли* — нык көчли.

инде», — дигән дә эчтән генә куркып тик йөргән. Кияү булып алгач, хәзер бу:

— Кызны бергә алып кайтам, калдырмыйм, — дип әйтә, ди.

Әниләре:

— Әле үзең генә кайтып тор да соңыннан килеп алырсың. Бердәнбер балабызны капыл гына җибәрсәк, ялгыз калырбыз инде, — дип елый, ди.

Нишләсен инде, бахырлар, биреп җибәрергә булганнар. Өч кич кунган да кияү кызны алып киткән, ди. Киткәннәр-киткәннәр икәүләп, кара урман арасыннан үткәннәр. Бу кыз куркышыннан: «Харап кына булдым, мине шул караклар алып китте инде», — дип елап тик бара икән. Урман арасында караклар бар икән дигән хәбәрне электән ишетеп йөргән булган. Киткәннәр, киткәннәр, төн җиткән, төн үтеп, таң аткан. Шунда бер җиргә барып җиткәннәр. Бу каракларның урыны шул кара урман арасындагы бер базда икән. Кырыгына кырык бүлмә икән. Кияү кызны шунда алып төшеп киткән. Киткәннәр, киткәннәр, төптәге бүлмәгә кереп, болар йокларга ятканнар. Бу көндез булган хәл инде. Кич булып караңгы төшкән, барсы да, базны ачып, кәсепкә чыгып киткән, кыз берүзе калган. Хәзер ишекләрне ачып карап йөри, карап йөри, ди, бу. Бер бүлмәгә керсә — ит, бер бүлмәгә керсә — казы, бер бүлмәгә керсә — май, бер бүлмәгә керсә — кием. Рәттән карап чыкты — барсында да ашып-ташып торган нәрсә, ди. Янә бер бүлмәгә керсә, бер әби утыра, ди. Бәйләп беткәннәр, чак ябышып утыра, торалмый да, ди.

—Уй, балам, син монда кайдан килеп чыктың? — дип әйткән, ди.

— Уй, әбекәй, мин ялгыштым, ялгышлыктан килеп чыктым, — дип, бу кыз елап җибәргән, ди.

Теге әби дә елый, ди:

— Мин әби түгел, мин яшь-яшь кенә кыз идем әле. Синең шикелле яшь кенә чакта мин дә, шушы кырык каракның кулына эләгеп, чыгып китә алмадым. Менә шулай-

теп имгәнеп бетеп, хәзер картаеп утырам. Хәзер чыгар хәлем дә юк. Йөрер дә әмәлем юк. Тамагыма кертеп ыргытсалар, шуны ашыйм да шушында утырам, — дип әйтә, ди. — Монда якты дөньяны күрә алмадым, хәзер инде үлемемне көтеп утырам. Нигә генә, балам, килдең, белмәдеңмени? — дип әйтә, ди.

— Азрак кына ишетеп кала идем, сизә торып, харап булдым, — дип әйтә, ди, теге кыз. — Әниемнәр байлыкка, киемгә алданды, — дип әйтә, ди, — акчага алдандылар да менә шулай итеп бирделәр дә, мине өч көндә алып та китте, — дип әйтә, ди.

— Әй, балакаем, харап булмас борын, кач син, балам, кач. Менә шулай итеп, эңгер булгач, чыгып китәләр, таң яктыруга, кайтып киләләр дә барсы көндез гөр-шар йоклый. Ишеген, капкасын карап кына йөр дә, ансы йозаксыз була аның, төртеп кенә чык та кач син, кич була башласа, бер җир табып, яшерен. Шулайтеп, өч көн эчендә, балам, кач. Алтын ал азрак, биленә әнә чак кына корт белән бал басып бәйлә дә кач. Үзәгең өзелгәндә, ялап алырсың. Кач, балам, ничек булса да, кач, — дип өйрәткән моңа теге әби.

Бу хәзер чыгып китеп, һаман бүлмәләрне караган. Караган да аптыраган, караган да аптыраган. Хәзер таң аткан, тегеләр дә кайтып кергәннәр.

Шул кич үк качыйм дигән инде теге кыз. Кич булган. Төн дә булган хәзер. Тегеләр чыгып китеп беткән, ди, хәзер. Бу әлеге балга басып корт белән алтын бәйләгән дә биленә, чыккан да качкан. Йөгергән дә йөгергән. Ашау кайгысы да юк, эчү кайгысы да юк. Кара урман, кайда китеп барганын да белми бу хәзер. «Кайда гына барыйм икән, кайда гына барыйм икән»? — дип аптырап килсә — алдында бүре оясы, ди. Шуны күргән дә, ни булса да булыр, аллага тапшырыйм да шуңа керим, дип, аяк ягы белән кереп, баш ягына туфрак өеп, шунда бикләнеп яткан.

Төн булган икән, чыкканнар тегеләр чабышып моның артыннан:

— Күрсәк, атыйк, үтерик, җанын гына алыйк, куй, җанын гына алыйк, — диләр.

Дер селкетеп, моның өстеннән үтеп китәләр, ди, тегеләр. «Әй ходаем, үләсе көннәрем шушы икән, ходаем, үзең генә коткар инде», — дип ята, ди, теге кыз. Әй дөрселдәделәр, әй дөрселдәделәр, шулхәтле күп йөрделәр, ди. Шуннан тавыш тынган. «Әй аллам, тавышлары тынды, таң аттымы икән?» — дип, иплэп кенә чокып кына караса, таң аткан, яктырган, ди.

Бу хәзер чыккан да тагы йөгергән. Йөгергән дә йөгергән. Йөгергән дә йөгергән. Су булса, су гына эчеп алган да янә йөгергән. Инде хәзер тагы кич булып бара. Кояш чак кына төшә, ди. «Инде кич була бит инде, кайларга гына керим икән», — дип, урын эзли, ди. Урын эзли дә урын эзли, ди. Караса, бер тирәк егылып ята, ди. Эче череп төшеп беткән, ди. Үзе умартадан да юан, ди. Шуны караган да: «Әһә, бу кереп ятарлык икән», — дип, аяк ягы белән кереп, баш ягын бу якка куеп, черекләре белән камап яткан инде хәзер.

Тегеләр янә чыктылар, ди, эзләргә. Һәммәсе атта, шарт та шорт аталар, ди, әй аталар, ди. «Килеп кенә тимәсен инде», — дип ята ди, кыз куркышыннан калтыранып. Берсе:

— Әй, шушында юкмы, шушында юкмы? Ай, шушындадыр, — дип әйтә, ди. Икенчесе килеп:

— Ни кылып ятсын ул монда? — дип әйтә, ди.

— Тотсак, атып үтерер идек, — дип йөргәннәр-йөргәннәр дә әйләнеп кайтканнар.

Тота алмаганнар, тавыш беткән, гауга басылган.

— Әй аллам, карыйм әле, — дип караса кыз, яктырып беткән, көндез, ди.

Инде чыккан да тагы йөгергән. Йөгерә, йөгерә, йөгерә, су туры килсә, су гына эчә дә тагы йөгерә икән бу. Инде янә кич булып бара, ди. Кыз бер акланга килеп чыккан.

— Әй аллам, йөгерә торгач, әллә үзебезнең якларга

килеп чыктыммы? — дип, караса, бер бабай тора, ди, печән төяп.

— Әй, бабай, кайдан гына килеп чыктың? Мине генә шушы арбаңның астына сал әле. Шулай-шулай мине караклар алып качкан иде, шулардан качып килә идем. Бабай, мин сиңа алтын бирермен, безнең әниләр дә бай. Бүтән нәрсә дә бирермен, әнекәйләремнән алып. Әй, бабай, арбаңның астына гына сал инде, — дип ялына, ди.

— Алай булгач, куй, салмыйм, балакаем, алар сине дә табарлар, мине дә үтерерләр. Салмыйм, балам, — дип әйтә, ди.

— Бабай, сал инде. Ни булса да булыр. Аллага тапшырып, мине генә шушы арбага сал, — дип ялына, ди, кыз.

Арба эчен тутырып төягән печәнгә бу бабай салган тегене чарасыздан. Кыз яткан, бабай аның өстенә печән төягән хәзер.

— Үлмәмен әле, бабай, басып, тапап, ныгытып төя, — дип әйтә, ди.

Шуннан бабай төягән, аркан тарткан. Күзенә яулык бәйләгән. Ул кызның эченә бәйләгән яулыгы булган. Аны тегеләр белмәгән булган.

— Бабай, кузгалып кит инде. Күзеңне бәйлә дә, килеп сорасалар: «Әй, балалар, миндә кеше кайгысы юк, күзем күрми, чактан-чак йөрим. Менә юлга гына төшереп җибәрегез инде мине, үзегезгә теләк теләрмен», — дип аякларына тәгәрәп ялын, бабай, — дигән булган кыз.

Хәзер караңгы төшеп килә бит инде. Теге караклар килеп чыкканнар.

— Бабай, шушында бер кыз күрмәдеңме? Качкан кыз? — дип әйткәннәр, ди.

— Юк, балам, күрмәдем, күрмәдем.

— Юк, бабай. Син күрдең аны. Син йөк астында калдыргансың. Бушат әле йөгеңне, бушат, — дигән берсе. Икенчесе килеп:

— Нигә тиясең ул аңа? Йөк астында кеше ятамыни? Җибәр! — ди. Өченчесе килеп:

— Шушында, шушында, — дип әйтә, ди. Дүртенчесе килеп:

— Куй, куй, бабайны җәзаламагыз, — ди икән.

— Менә күземне бәйләгәнмен, күзем дә күрми, балалар. Ходай хакы өчен җибәрегез, нинди кыз килеп печән астына кереп ятсын, юкны сөйләмәгез. Менә юлны күрмим, балалар. Караңгы төшә хәзер, мине, зинһар гына, ходай хакы өчен, юлга гына төшереп җибәрегез инде, — дип әйтә, ди.

Берсе җитәкләп, моның атын юлга төшереп җибәргән. Киткән бу хәзер котылып. Киткән, киткән, авылына барып җиткән. Хәзер авылына барып җиткәч, печәнен бушаткан, теге кызны төшергән инде. Теге кыз яулыгын чишкән дә тегеңә алтын биргән. Авыллары моннан якын гына булган икән.

— Рәхмәт мине коткаруың өчен, мин онытмам әле, әтиемнән тагы берәр нәрсә алып бирермен үзеңә, — дип, бу төшеп йөгереп кайтып киткән.

Хәзер төн бит инде. Кайтып җитеп тәрәзә чирткән, әниләре ачканнар.

— Ай, балам, ай, балам, кайдан килеп чыктың? — дип әнисе кочаклап алган тегене.

— Шулай, шулай, менә хәлләр шулай булды. Карак бар дигәннәре чын хәбәр икән. Кырык каракка эләгеп, харап кына була яздым. Анда бер әби утыра. Шулайтеп бәйләп торып утыртып куйганнар. Хәзер инде ул эшлектән чыккан. Шул әби әйтеп, менә өч көн эчендә качып, чак котылдым, — дип кыз башыннан үткәннәрне сөйләп биргән.

Кызларының үлемнән котылуына куанышып, хәтта хәерләр биргәннәр. Хәзер бу кыз:

— Өч көннән миңа теге бай карак килер. Бер сүзенә дә ышанмагыз. «Ярар-ярар», дип кенә әйтегез, мин хәзер бер эш кылам, — дигән.

Шуннан соң болар хәтта куркып саклананалар, ди, инде.

Өч-дүрт көн үткән икән, теге каракларның башы килгән. Ул тегеләрнең иң бае булган була. Хәтта инде матур киенеп килгән, ди, теге.

— Сезне чакырырга килдем. Кызыгыз бай, бәхетле урынга туры килде, киявегез дә монда килер. Сезне менә туена чакырырга килдем, алырга килдем, — дип, боларны алып кайтырга килгәнлеген әйткән.

— Алай булмый ул, кода. Безне ала килү белән, безнең дә үзебезгә күрә, алама булса да, дөньябыз бар, әле генә без бара алмыйбыз. Менә кыз белән кияү кунакка килеп китсеннәр, шунда ияреп барырбыз. Шулай дип әйт син анда. Әле генә без ничек кузгалып чыгып китик? Ансыз да сагындык инде кызыбызны, сагындык, — дигәннәр, ди, болар.

— Ярар ату, тройкалар белән төнлә килеп үзебез алып китәрбез. Әзрәк торгач, чыгыгыз, кеше эзләп табыгыз да дөньягызга, — ди теге.

Хәзер тегенең белән сөйләшеп, акчалар биреп тегеңә, азрак эчереп, алдаштырып, кайтарырга булалар. Кыз, үткер балта тотып, әзерләнеп тора, ди, ишектән чыгуына, моны чабарга. Шулай итми нишләсен инде, үзәгенә үткәч бахырның. Хәзер бу чыгып кына килә икән, теге кыз ишек артында гына торган да үткер балта белән башын чабып өзеп тә куйган.

— Уй алла, харап булдык, — дип әнисе куркуыннан тәгәрәп тә киткән. Әтисе:

— Уй, кызым, нишлибез инде хәзер? Аны нәрсә эшләтәбез инде хәзер без? — дип җыеп салып кына куйганнар да (хәзер төн бит инде, төнгә каршы йөри бит инде теге караклар), теге кыз абзыена йөгергән.

— Абзый, әйдә, мин кайттым, шулайтеп, берсен харап иттем, әйдә әле безгә, — дигән.

Абзые ат алып килеп, арбага салып әлегене, күлгә алып барып, таш баулап, күлгә салып, котылып кайткан-

нар. Шуннан кыз өйнең эчен-тышын юып, бер әзен дә калдырмый, тазартып куйды, ди.

Караклар боларның йортына бүтәнчә аяк та басмаган, ди. Килерләр иде, нык курыкканнар, ди. Курыкмаслар иде, кыз икәүсенең башына җиткән. Шуннан әби белән бабай кызлары белән куанып, шатланып, дөнья көтеп, йон тетеп торалар, ди.

ИРӘНДЕК

Борын Урал таулары арасындагы бер авылда бер бабай белән әби булган, ди. Алар ярлының да ярлысы булганнар: ишек алдында серәеп утырган бер чувалдан, өй дигәннәренең эчендә бер коштабак белән өч калактан, бер ужау белән өч тустактан башка бер әйберләре дә булмаган, ди, боларның.

Бабай картлыктан үлеп киткән, әби Оморзак исемле буйга җитеп килгән бердәнбер улы белән торып калган, ди. Бердәнбер көнне әби улына:

— Монда серәеп утырган чувалны саклап ятудан файда булмас, улым. Илгә чыгып, өс-башыңны әзрәк бөтәйтеп, әз булса да ризык табып кайту җаен карар идең, — дигән.

Шуннан Оморзак читкә чыгып киткән, ди. Урал буйлап күп җирләрне үткән — бер адәм рәтле эш тапмаган. Йөри торгач, бер байга ялчы булып кергән, ди, бу. Өч көн үткән, биш көн үткән, җиде көн үткән, бай һаман бернинди эш кушмый, ди, Оморзакка. Атна үткәч, бай янына килеп:

— Тик яту бик ялкытты бит әле, бай абзый. Берәр төрле эш булмасмы? — дип сораган.

— Булыр, — дигән бай.

Бай Оморзакка көтүгә барып, бер кызыл бозауны салып, тиресен толыптай сыдырып алып кайтырга кушкан. Оморзак моны эшләгән. Шуннан бай өч зур кычыткан капчык табып китерергә кушкан. Егет монсын да үтәгән. Шуннан алар ат җигеп, арбага бозау тиресе белән өч капчыкны салып алып, тау арасына чыгып китканнәр, ди.

Кыятау дигән бер текә тау итәгенә килеп җиткәч, бай атны туктатып, бозау тиресен арбадан җиргә алып куярга кушкан. Оморзак тирене алып куйгач, бай шуның эченә кереп, бөгәрләнеп ятарга кушкан. Егет, бернн аңламаса да, монсын да эшләгән. Шуны гына көтеп торган бай Оморзакны тыштан озын-озын итеп теленгән каеш белән чорнап бәйләгән дә ташлаган, ди.

Шуннан соң бай, читкәрәк китеп, күзәтеп тора башлаган. Күп тә үтми, сәмруг кош чаклы ике зур бөркет килеп. тырнаклары белән «бозауны» эләктереп алганнар да Кыятау башына күтәрелгәннәр. Шунда алар, үзләренең табышларын чукышлары белән чукып, тырнаклары белән каерып, тирене өзгәли башлаганнар; тире эчендә бозау түгел, тере кеше ятканын күргәч, куркышып, очып киткәннәр. Тирене дә үзләре белән алып очканнар, ди.

Оморзак торып, тирә-якка караштырып алса, үзеннән башка бер генә җан иясе күренми, ди. Шулчакта Кыятау астыннан Оморзакны күзәтеп торган бай:

— Нигә син анда катып торасың? Аяк астыңда яткан асылташларны, алтын-көмешләрне ташла монда! — дип кычкыра икән.

Оморзак иелеп караса, аяк астында, чынлап та, алтын-көмеш, әллә ничә төрле матур-матур асылташлар ялтырап, күзнең явын алып ята, ди. Оморзак шуларны түбәнгә карый ыргыта башлаган, бай кычыткан капчыгына тутырып торган.

Капчыкларның икесе тулып барганда, Оморзакның

башына: «Бу хәзинәне ташлавын ташлыйм да бит әле мин, үзем ничек төшәрмен икән соң?» — дигән уй килгән.

— Әй, бай абзый, мин моннан ничек төшим? — дип кычкырган.

— Син шундагы хәзинәне ташлавыңны бел! Капчыкларның өчесе дә тулгач, мин сиңа ничек төшәргә икәнен үзем өйрәтермен! — дип сөрәнләгән бай астан.

Оморзак байның әйткәненә ышанып, аяк астында сибелеп яткан алтын-көмешне, төрле-төрле асылташларны җыеп, тау астына ташлаган да ташлаган. Капчыкларның өчесе дә тулгач, бай аларны бәйләп арбасына салган да, китеп барышлый:

— Мин сине җиде көн эшләтми ашатып тоткан идем, бу ташларың шуның өчен булыр! Хәзер инде сиңа шул басып торган урыныңда бөтенләйгә калырга туры килер. Тирә-юнеңне абайлабрак кара әле — анда синең кебекләрнең сөяге тулып ята! — дип кычкырган.

Оморзак абайлабрак караса, чынлап та, тирә-ягында кеше сөякләре тулып ята икән, ди. Явыз бай бик күп ялчыларын шулай калдырып һәлак иткән икән. Оморзак, анда сугылып, монда сугылып, Кыятаудан төшү юлын эзләп караса да, бер дә уңайлы урын таба алмаган, ди. Кыятау теп-текә булып күккә күтәрелеп тора, ди. Шул текә кыялы булганга да аңа Кыятау дигәннәр дә инде.

Кыятаудан төшәргә бернинди дә әмәл таба алмый, өч көн, өч төн ашамый-эчми, хәлсезләнеп ятканда, сәмруг кош чаклы баягы ике бөркет бер бүрене очыртып алып менгәннәр дә өзгәләп ашый башлаганнар. Шулчакта Оморзакның башына бер уй килгән. Кесәсендәге пәкесен алып, бөркетләргә ташланган бу. Бөркетләр куркышып очып киткәннәр, күзләре чукылган бүрене Оморзак пәкесе белән чәнечкәләп үтергән дә тиресен сыдырып алып, гәүдәсен яшергән дә үзе шул тирене бөркәнеп яткан, ди.

Күп тә үтми, баягы ике ач бөркет тагы килеп кунган. Оморзакның юклыгын күргәч, бөркетләр «бүре»гә ябышып, өзгәли башлаганнар. Шулчакта Оморзак тире астын-

нан кулларын чыгарып, ике бөркетнең ике аягын кысып тотып алмасынмы! Бөркетләр куркышып, чаң-чаңлап, һавага күтәрелгәннәр дә очып киткәннәр. Оморзак аларның аякларын ычкындырмый,ябышып барган, ди.

Аякларына асылган авыр йөктән берничек тә котыла алмаган бөркетләр, түбән төшәргә куркып, Уралның бер биек җиренә килеп туктагач кына, Оморзак кулларын ычкындырган. Куркышкан бөркетләр шунда ук күздән югалганнар, хәйләсе барып чыккан Оморзак куанычыннан:

— Хәзер инде өйрәндек, — дип кычкырып җибәргән, ди. Менә шул көннән бирле бу тауны Ирәндек дип йөртә башлаганнар, ди.

Оморзак, Ирәндектән төшеп, тамак яллык булса да берәр эш табылмасмы дип, ары сугылып, бире сугылып, авыл арасында йөреп ятканда, теге байга янә тап булган, ди.

— Мине ялчы итепме, көтүче итепме эшкә алмассызмы икән, бай абзый? — дип сораган Оморзак.

Бай Оморзакны танымаган. Ни өчен дисәң, бердән, аны сакал-мыек басып беткән булган, икенчедән, Оморзакның исән йөреп ятуы байның уена да кереп чыкмаган.

— Миңа бер уңган гына ялчы кирәк, — дип, бай Оморзакны үзенә алып кайтып киткән.

Өч көн үткән, биш көн үткән, җиде көн үткән, теге чактагы сыман, һаман бернинди дә эш кушмаган, ди, бай. Оморзак сигезенче көнне:

— Тик яту бик ялкытты бит әле, бай абзый, берәр төрле эш булмасмы? — дип сораган.

— Булыр, — дигән бай.

Бай Оморзакка көтүгә барып, бер кызыл бозауны суеп, тиресен сыдырып алып кайтырга кушкан. Оморзак моны эшләгәч, бай аңа өч кычыткан капчыгы табып китерергә кушкан. Монсы да булгач, ат җигеп, арбага бозау тиресе белән капчыкларны салып алып, тау арасына чыгып киткәннәр.

Кыятау итәгенә килеп җиткәч, бай атны туктатып,

арбадагы бозау тиресен җиргә җәеп салдырган да Оморзакка шуңа уранып ятарга кушкан.

— Берни дә төшенмим бит әле, бай абзый, нишләргә кирәк икәнен тәүдә үзең күрсәтеп бирер идең! — дигән Оморзак.

— Төшенмәслек берни дә юк монда, менә шулай ятарга гына кирәк, — дип, байның бозау тиресенә уранып ятуы була — Оморзакның аны чорнап бәйләп ташлавы була.

— Әй, нишләвең бу, улым? Чыгар мине тире эченнән! — дип, ялынып-ялынып кычкыра башлаган бай.

Оморзак моңа карап, рәхәтләнеп көлеп торган арада сәмруг кош чаклы ике зур бөркет килеп, тирене, яшь бозау икән дип эләктереп алып, Кыятау түбәсенә очыртып мендергәннәр дә, чукышлары белән чукып, тырнаклары белән тарткалап өзгәли башлаганнар, ди. Тире эчендә тере кеше ятканын күргәч, бөркетләр куркышып очып киткәннәр, ди.

Байның, тире эченнән чыгып, аякка басуын күргәч, Оморзак тау астыннан:

— Әй, бай, нәрсә карап торасың, шундагы алтын-көмешне, төрле-төрле асылташларны ыргыта башла монда! Минем кебек җәһәт-җәһәт эшлә! — дип кычкырган, ди.

Бай шулчакта гына ялчының Оморзак икәнен белгән.

— Оморзак балакаем, син моннан ничек төшә алдың соң? Мине дә өйрәт әле! — дип ялына башлаган, ди, бай.

— Күп теленә салынып торма, шундагы хәзинәне ташлавыңны бел! Капчыкларның өчесе дә тулгач, ничек төшәргә икәнен өйрәтермен! — дип кычкырган Оморзак.

Бай Кыятау башыннан алтын-көмешне, төрле-төрле асылташларны түбәнгә ташлап торган. Оморзак аларны кычыткан капчыкларына тутырып торган, ди. Өч капчык та тулгач, Оморзак, аларны бәйләп, арбага күтәреп салган да, байга карап:

— Әй, бай, тирә-ягыңны абайлабрак кара әле, анда синең этлегең аркасында һәлак булган кешеләрнең сөякләре тулып ята. Таудан ничек төшәргә икәнен син әнә шу-

лардан сора! — дип, бер йөк хәзинә белән үзенең авылына, әнисе янына кайтып киткән, ди.

Бай күпме генә кычкырынмасын, ничаклы гына җикеренмәсен, аны ишеткән-ниткән кеше булмаган, ди. Тик шул сәмруг кош зурлыгы ике бөркет кенә, үзләренә җим өчен, байның бөтенләй хәлсезләнеп егылыр чагын көтеп утырганнар, ди.

ШОМБАЙ

Борын-борын заманда яшәгән, ди, әби белән бабай. Аларның балалары булмаган, ди. Картая килә, аларга йорт эшен башкару авырлаша башлаган. Елдагыча печән вакыты килеп җиткән. Бу эш үзләренең хәленнән килмәстәй булгач, печән әзерләшергә малай тотарга киңәшләшә башлаганнар, шулай итеп, бабай малай эзләп чыгып киткән. Озатканда, әби:

— Шомбай исемле булмасын. Шомбай исемле булса, алма! Шомбай исемле малайлар бик усал була ул, — дип бабаен кисәтеп калган, ди.

Бабай китеп бара, китеп бара. Бара торгач, бер авылга барып җитә. Авылның очында бер малай тора, ди. Бабайны күрү белән әллә кайдан ук сәлам биреп, хәл-әхвәлен сорашып тора, ди. Бабай үзенең хәлен сөйләп биргән, ди.

— Мин дә берәрсенә малайлыкка ялланыйммы икән әллә дигән уйда тора идем әле, — дигән, ди, малай.

— Алай булгач, әйдә миңа яллан да куй, — дигән, ди, бабай.

Малай риза булып, сөйләшеп-килешеп беткәч кенә, бабай әбиенең әйткәнен исенә төшереп:

— Балам, синең исемең ничек соң әле? — дип сораган, ди.

Малай:

— Шомбай, — дип җавап кайтарган. Бабай шөбһәләнә башлаган:

— Ай эттәгенәсе, болай булгач, балам, сине алып булмый инде. Әби: «Шомбай исемле малайлар усал була. Шомбай исемле булса, алма», — дип җибәргән иде бит әле. Ярар, теге як очка барып әйләним әле, бәлки, башка малайлар очрар, бик тә булмаса, кире килермен, — дип китеп тә барган, ди.

Бабай кузгалып китү белән, киртә артыннан гына малай аргы очка йөгергән, ди. Бабай аргы очка килсә, янә малай тора, ди. Бабай килеп җитәр-җитмәстән аның хәл-әхвәлен сорашып тора, ди. Бабай гадәтенчә хәлен сөйләп биргән, ди. Малай:

— Мин дә берәрсенә малайлыкка торырга кирәк булыр дигән уйда тора идем әле, — дигән, ди.

— Алай булгач, әйдә миңа бар да куй. Тик синең исемең ничек? — дип сораган, ди бабай. Малай:

— Шомбай, — дигән.

— Болай булгач, булмый инде. Әби: «Шомбай исемле малайлар бик усал була», — дип, Шомбай исемлене алырга кушмаган иде шул, — дип, бабай икенче авылга китеп барган.

Бабай киткәч, Шомбай аңа күренми генә тугай буйлап, алдагы авылга килгән, ди. Болар монда да авылның бирге башында да, аргы очында да очрашып, шул ук сүзләрне әйтешеп, аерылышканнар, ди.

Бабай өченче бер авылга юнәлгән, ди. Шомбай да аның артыннан калышмаган. Бабай өченче авылда да бирге башта да, аргы очта да Шомбай исемле малайны гына очраткан. Бу якта малайлар гел Шомбай исемле генә икән, дип аптырап, ахрысы, алырга булган. Алмас иде,

печән вакыты җиткән; йөри-йөри арып та беткән. Шулай итеп, бабай Шомбай исемле малай белән авылына әйләнеп кайтып киткән, ди.

Әби аларны капка тышына ук чыгып каршы алган. Бабай:

— Әби, малай табуын таптым да ул, тик Шомбай исемле генә булды бит әле, — дип әйткән икән. Әби шунда ук тузып киткән:

— Мин сиңа нәрсә дип әйтеп җибәрдем? Шомбай исемле малайлар усал була димәдемме мин сиңа?!

Бабай кайда йөрүен, ничә малай очратса да, барсының да исеме Шомбай булуын бәйнә-бәйнә сөйләп биреп:

— Ул якларда бөтен малайларның да исеме Шомбай икән, — дигәч кенә, әби әзрәк тынычлана төшкән.

Иртәгәсенә бабай белән малай таңнан торып, куна ятып печән әзерләргә киткәннәр. Әби аларга ярты гына икмәк, әзрәк май салып биргән дә:

— Калганын соңыннан үзем алып барып бирермен, — дип калган, ди.

Бабай белән малай әби салып җибәргән ризыкны бер утыруда ашаган да беткәннәр, ди. Кичкә ашарга калмаган, ди. Әбине көтәләр — юк, көтәләр — юк, ди. Ахырда бабай:

— Икәүләп кайтып йөргәнче, яшь кеше, син генә кайтып кил, — дип малайны кайтарып җибәргән, ди.

Шомбай кайтса, өйдә сөйләшкән тавыш ишетелә, ди. Малай иләп кенә барып тәрәзәдән караса, тап-таза өч егет сыйланып утыра, ди. Бу егетләрнең элек-электән кылыклары шул булган: бабай өйдә юкта әбигә килеп сыйланып китәләр икән. Әби дә үзенең ару ашларын аларга алып барып биреп йөри икән. Менә егетләр тамакларын туйдырып китәргә җыена башлаганнар, ди. Шомбай аларны тыңлап тора, ди. Әби боларга:

— Иртәгә иртәнчәк азык алып барып биреп китәрмен, тик кайсы юлдан барырга белмим, үзегез киткән юлга ка-

зык кагып китегез. Минем бабай да сезгә якын гына эшли бит. Юлны бутап куюым бар, — дип әйтә, ди.

Моны тыңлап торган Шомбай өйгә кереп тә тормыйча, егетләрнең артыннан төшә. Юл чатына барып җиткәч, егетләр үзләре киткән юлга казык кактылар да ары киттеләр, ди. Боларны күзәтеп килгән Шомбай казыкны үзләре киткән юлга күчереп каккан да бабай янына киткән, ди. Килсә, бабай аның азыксыз килүенә аптырап калган, ди. Шомбай аптырап тормаган, җавабын тапкан:

— Әбекәй пешереп өлгермәгән әле, иртәгә үзем алып барам, дип калды, — дип әйткән, ди.

Иртәгәсенә көч җиткесез итеп азык күтәреп әби килеп җиткән, ди. Бабай ачыкканлыктан аңа-моңа игътибар итеп тормаган, тизрәк ашау ягын караган. Шомбай, берәр файдасы тияр әле дип, белмәмешкә салышкан. Менә алар чәй эчәргә утырдылар, ди. Болар утырган җирдән теге егетләрнең кибән койган җире күренеп тора, ди. Әби шул яктан күзен алмый, ди.

— Нишләп шул якка карыйсың да карыйсың? — дип сораган, ди, бабай.

— Әнә тегендә өч егет кибән сала, ата-аналары да юк. Аларның да шулай тәмләп-татлап ашап-эчәселәре киләдер инде бахырларның, — дип әйткән булды, ди, әби.

— Шомбай бавырсак алып барсын әйдә, — дип бабай да кызганып куйган, ди, тегеләрне.

Шуны гына көтеп торган Шомбай такыясына бавырсак тутырып алган да кибән коеп йөргән егетләр янына йөгергән. Йөгереп барышлый, такыясының төбендәге тишектән бавырсагын коя-коя барган, ди. Егетләр янына хәле бетеп барып җиткән, ди. Егетләр аптырашып, ни булды да, ни булды, дип аны сырып алдылар, ди.

— Без әнә тегендә бабаем белән кибән сала идек. Әбекәй безгә азык китерде. Бабаем кичә сезнең килеп ашап киткәнне белгән дә, шуңа әбекәйне тукмый. Хәзер оч сәнәге белән килеп, сезне дә тукмамакчы була. Шуны әйтергә дип килгән идем, — дигән, ди, Шомбай.

Егетләр, нишләргә дә белми, куркышып киткәннәр, ди. Шомбай кире йөгергән, ди. Кайтып килгәндә, чәчкән бавырсагын җыя-җыя бара, ди. Әби белән бабай, иелеп бу нәрсә эшли икән, дип, аптырап карап утыралар, ди. Әби белән бабай янына килеп җиткәч, такыядагы бавырсакны күрсәтеп:

— Анда бавырсаклар тәгәрәшеп ята, шуны җыеп алдым, — дип әйтә, ди. Әби белән бабай:

— Куй, булмаганны сөйләмә, алдыйсыңдыр, — дип әйттеләр, ди.

Ышанмыйча, әби үзе барып карарга китте, ди. Шунда Шомбай:

— Бабай! Теге абзыйлар сине кибән очлашырга килмәсме икән, дип әйткән иделәр. Килер булса, сәнәген алсын да монда йөгерсен, дип калган иделәр, — дип әйткән, ди.

Бабай үзенә күрә бик кешелекле, ярдәмчел генә кеше булган. Шуңа да үзеннән ярдәм сораганны ишеткәч тә, оч сәнәген алган да, йөгерә-атлый тегеләр ягына китеп тә барган. Әбие аның кайда барганын сорап өлгерә алмый калган да, йөгереп килеп Шомбайдан:

— Бабаең кайда китте алай өтәләнеп? Сиңа әйтмәдеме? — дип сораган, ди. Шомбай:

— Бабаем, ни, кичә теге егетләрне сыйлаганыңны белгән дә, аларны барып тукмыйм да, шуннан килгәч, әбиеңә дә өлеш чыгарырмын, дип китте, — дип әйткән, ди.

Әби куркышыннан торган да авыл ягына йөгергән, ди. Теге егетләр дә бабайның оч сәнәге тотып килгәнен күргәннәр дә, безне тукмарга килә икән, дип, өчесе өч якка качарга тотынган.

Бабай аптырап, кире әйләнеп килсә, әбие авыл ягына сыпыртып ята, ди.

Шуннан бабай Шомбайдан:

— Әбиең кайда йөгерде? — дип сораган, ди. Шомбай:

— Өйгә ут капкан, дип йөгерде, — дип әйткән, ди.

Бабай да:

— Тизрәк кайтыйм, — дип, кулын болгап, кычкыра-кычкыра әбие артыннан төшкән, ди. Әбие борылып карый да, бабай мине тукмарга килә икән, дип, җан көченә йөгерә, ди, борылып карый да йөгерә, ди. Шулай итеп, бер-берсен куышып йөгерә торгач, бабай җиттем дигәндә генә — хәле беткән әби тәгәрәп китте, ди. Аңа эләгеп бабай сөрлегеп барып ятты, ди. Әби, чәчи-чәчи:

— Бер генә булды, бабакаем, кабат андый хәл булмас, — дип кенә әйтеп калган, шул җирдә икесе дә дөнья куйганнар, ди. Үзләре үлгәч, бөтен байлык хәйләкәр Шомбай кулына калды, ди. Әби белән бабайның өендә Шомбай әле һаман да дөнья көтеп тора, ди.

Эндәшми генә, астан эшне бетереп йөргәннәргә «Шомбай кебек йөри» дип әйтү шуннан торып калган, ди.

ЭЧТӘЛЕК

Әкиятләр. *Ә. Сөләйманов* 5

ҮЗ КЕТӘГЕНДӘ ӘТӘЧ ТӘ БАТЫР

Ач аю, төлке, егет 12
Төлке белән бытбылдык 13
Тычкан, аю, бүре, төлке 16
Куян белән арыслан 20
Куян белән керпе 23
Сорысай белән Карасай 26
Тавык белән тилгән 35
Сандугач 37
Казлар нигә ала булган? 39
Карамулла 42
Үгез 45
Сәфәр 49
Тимерказык 59
Сонтай егете 61
Кара көчек 71
Төлке белән торна 80

БАТЫР ЕГЕТ — ИЛ КҮРКЕ

Урал батыр 82
Акъял батыр 97
Исмай 124
Алтын чабак 133
Алпамыша батыр 145
Оморзак батыр 154
Камыр батыр 159
Караганда патша белән кыз батыр 166
Ак бүре 172
Өч батыр 177
Хәтәр шәп батыр 183

ХӘЙЛӘСЕЗ БАТЫР — БАХЫР

Незнай 188
Таз батыр 204
Бәхет күле 231
Алтынчәч 236
Кинҗәбулат 240
Кече ул 253

Тугыз олан 257
Ятим кыз белән мулла 263
Беркарыш 266
Әбҗәлил 270
Карт белән дию 274

ӘМӘЛЕНӘ КҮРӘ ГАМӘЛЕ

Курайчы 278
Патша белән сабанчы 279
Локман Хәким 285
Көтүче патша 287
Акыллы карт белән исәр патша 291
Ата васыяте 295
Ана сүзе 298
Патша сайлау 300
Фәкыйрь кияү 302
Кыз сере 303
Балкантаз 305
Кашикарип белән Маһимөһер 313
Буйдак патшаның төштә гашыйк булганы, өндә кәләш алганы . 316
Гани сәүдәгәр белән вәзир 319
Унике биглый 322
Назлы кыз 324
Халикъ кызы Хәдичә 329
Явыз хатын белән дию пәрие 336
Гаҗәп исемнәр 339
Явыз патша башына җиткән патша малае 341
Мулла белән сәүдәгәр кызы Көнсылу 346
Явыз карт 348
Хаҗи кызы 353
Батыймакай 359
Убырлы каенана белән бахыр килен 362
Мәкерле җиңги 368
Кеше сүзе кеше үтерә 374
Кеше белән шайтан 375
Кырык карак 378
Ирәндек 387
Шомбай 392

Литературно-художественное издание

БАШКИРСКИЕ СКАЗКИ

(на татарском языке)

Мөхәррире **Фирдинә Зиннәтуллина**
Техник мөхәррире **Зәйтүнә Чингизова**
Корректоры **Зилә Адыева**

ИБ № 5491

Җыярга бирелде 17.06.96. Басарга кул куелды 19.11.96. Кәгазь форматы 70×108¹/₃₂. Китап-журн. кәгазе. Әдәби гарнитура. Калку ысул белән басылды. Шартлы басма таб. 17,5+0,17 форз. Шарты буяу отт. 17,67. Исәп-нәшер таб. 18,23+0,32 форз. Тиражы 4000 данә. Заказ № 249. Бәясе ирекле.

Башкортстан «Китап» нәшрияты, 450001, Уфа, Левченко урамы, 4а. **Уфа полиграфия комбинаты, 450001, Уфа, Октябрь проспекты, 2.**